
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1988

5

(787)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

И. САЛАХОВ. Тайгак кичү. *Роман-хроника* 3

БЕЗДӘ КУНАКТА — БАШКОРТСТАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

М. КӘРИМ. Билгесез солдат. *Шигырь* 59
Н. НӘҖМИ. Бүдәнә белән тартай. *Шигырь* 60
Ә. АТНАБАЕВ. Буш имезлек. *Шигырь* 60
Р. САФИН. Табигатьнең кәләш кенә чагы. *Шигырь* 61
Т. ЙОСЫПОВ. Сабый тавышы. *Шигырь* 61
Р. БИКБАЕВ. Туган төбәктәге оланарга. *Шигырь* 61
А. ХӘЛИМ. Гади сорау. *Шигырь* 62
К. АРАЛБАЕВ. Таштугай. *Шигырь* 62
Ф. ТУГЫЗБАЕВА. Танышыйк. *Шигырь* 63
Р. МИФТАХОВ. Югалтмыйк! *Шигырь* 63
Р. ХИСАМЕТДИНОВА. Ирәмәл тау кызлары. *Шигырь* 63
Т. КАРАМЫШЕВА. Көянтә. *Шигырь* 64
Ә. ӘХМӘТХУҖИН. Дулкын. *Шигырь* 64

БАТУЛЛА. Юл буенда зәңгәр чәчәк. *Повесть* 65
З. НУРИ. Тезләнүләр. *Шигырьләр* 124
Г. АФЗАЛ. Биек үрдән торып. *Шигырьләр* 129
М. ӘМИРХАНОВ. Ир хатыны. *Хикәя* 133
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Фронтовиклар. *Шигырьләр* 142

ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. МОСТАФИН. Матросовчылар 145
Б. КАМАЛОВ. Юллар, юллар... 150

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

И. КУРМАШЕВ. Кама суы буенда *(Алабуга районы)* 154

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Ә. РӘШИТОВ. Шигырь һәм тәнкыйть 157
Р. ШӘРИПОВ. Шигырь белән уйнамыйк 163
Р. АБДУЛЛИНА. Тәкъдимнәрем бар... 164

Ә. СӘХАПОВ. Тере хәтер 168

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Р. УТӘБАЕВ. **«Хәсәния мәдрәсәсе»** *(А. Тимергалина рәсеме)* 166

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. ИСЛАМОВ. **Әдәбиятлар дуслыгын яктыртучы хезмәт** 173
Г. ГЫЙЛМАНОВ. **Моң елгасы** 175

ЮБИЛЕЙЛАР

Т. ӘЙДИ. **Укытучы, матбугат эшчесе, язучы** *(Зариф Бәширинең тууына 100 ел)* 178
А. ЯХИН. **Кичә генә әле февраль иде** *(Х. Госманга 80 яшь)* 179

Н. АРСЛАНОВ. **Шагыйрьне искә алганда...** 181

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. **Кашан шәһәре** 183

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Яңа әсәр укыгач** 185

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Х. ХӨСНУЛЛИН. **Кәгазь җыю кооперативы.** *Шигырь* 188

**Китаплар дөньясында** 189
**Культура тормышы көндәлеге** 190
**Тышлыктагы сурәтләр** 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60.
баш редактор урынбасары —
53-07-09.
җаваплы секретарь — **53-07-65,**
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Продолжение романа-хроники И. САЛАХОВА «Тернистый путь», повесть Р. БАТУЛЛИНА «Вдоль дороги синий цветок», рассказ М. АМИРХАНОВА «Жена своего мужа», стихи З. НУРИ, Г. АФЗАЛА, Б. СУЛЕЙМАНОВА.
В рубрике «У нас в гостях поэты Башкирии» М. КАРИМ, Н. НАДЖМИ, А. АТНАБАЕВ, Р. САФИН, Т. ЮСУПОВ, Р. БИКБАЕВ, А. ХАЛИМ, К. АРАЛБАЕВ, Ф. ТУГУЗБАЕВА, Р. МИФТАХОВ, Р. ХИСАМУТДИНОВА, Т. КАРАМЫШЕВА, А. АХМЕТХУЗИН (стихи).
«Публицистика»: очерк Ш. МУСТАФИНА «Матросовцы», очерк Б. КАМАЛОВА «Пути-дороги».
«Татарстан — родной мой край»: выступление первого секретаря Елабужского горкома КПСС Ю. КУРМАШЕВА.
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи А. РАШИДОВА, Р. ШАРИПОВА и Р. АБДУЛЛИНОЙ. Статья А. САХАПОВА о творчестве Ш. Ракипова.
В рубрике «Библиография» рецензируются книги С. Акбиева и Н. Акмалова.
«Памятники татарской культуры в Уфе» — медресе «Хасания».
В номере отмечаются 100-летие со дня рождения татарского писателя-просветителя З. Баширии; 80-летие литературоведа, доктора филологических наук Х. Усманова.
Воспоминания Н. АРСЛАНОВА о народном поэте Татарии С. Хакиме.
«Города древней Булгарии»: «Город Кашан» — статья Ф. ГАРИПОВОЙ.
Слово читателя.
«Юмор и сатира» — стихотворение Х. ХУСНУЛЛИНА.
В мире книг.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: «Золотое шитье. Женское нагрудное украшение», газетно-журнальное издательство в Казани.

*Җаваплы секретарь Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 22.02.1988 ел. Басарга кул куелды 14.04.1988 ел. ПФ 05175. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67049. Заказ А-84. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

## ПРОЗА

Ибраһим Салахов

# ТАЙГАК КИЧҮ

РОМАН-ХРОНИКА

## Таныш түгел дус

### I



Мин кабат-кабат 1938 елның май аена әйләнеп кайтам. Унбиш-егерме көн эчендә ашык-пошык, аеруча бер салкын канлылык, игътибарсызлык, хәтта җирәнүле караш белән, халыкның 1905—1917 еллар революцияләре дулкынында күтәрелеп чыгып, шул революция җиңүе өчен фидакарь көрәшкән, кан койган, әмма бөгелмәгән, һаман әле бөек көрәш сафында калган газиз уллары һәм кызлары бер гаепсез, нигезсез «халык дошманы» дип гаепләнделәр. Өлкә партия комитеты һәм пленумы әгъзалары, шулай ук Верховный Совет депутатлары, халык комиссарлары, галимнәр, язучылар, артистлар, карт большевиклар, башка совет оешмалары җитәкчеләре күз дә йоммыйча үлем җәзасына хөкем ителде. Азларына гына «шәфкать» күрсәтеп, аларны ун-унбиш ел төрмәгә, әгәр дә инде аннан үлмичә алай-болай чыга калса, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән хөкем чыгардылар.

Мин, мөгаен, яшь булуым аркасында, бәхетлеләр төркеменә — төрмә җәзасына тартылганнар арасына эләктем. Казаннан соң Бөгелмә, Уфа, Свердловск, Чиләбе, Төмән төрмәләрен кичтем.

Бу юл бик авыр узылды. Һәрбер төрмә — йөрәктә кан саркып торган төзәлмәс ачы яра булып калды. Әле хәзер кырык елдан соң да ул төрмәләр, камералар, карцерлар төшемә керсә, мин куркып, саташып, шабыр тиргә батып, тетрәнеп уянам.

Эссе җәй айлары. Тоткыннар белән шыгрым тулы камералар — ятарга түгел, басып торырга да урын җитми. Парашалар тулып ага. Сасы ис бугазны буа. Ашарга коры паек. Су юк. Төрмәдән төрмәгә Столыпин вагоннарының кысрык камера-бүлмәләрендә күчерәләр. Анда да бар ризык — балык. Анда да — тәүлегенә бер кружка су.

---

Дәвамы. Башы 4 санда.

Казан төрмәсеннән бу юлны без, «аеруча куркыныч биш жинаятьче», бергә башладык. Беренчебез — яңак сөякләре калкып торган зур кара күзле, калын, кара чәчле Мәхмүт Әбҗәлимов. Һич борын төшерми, кайгырмый, нинди дә булса бер кызык уен, сүз табып кына тора. Икенчебез — Мәхмүткә капма-каршы, тәбәнәк, юан, әмма гаҗәеп матур сынлы — Гений Измайлович Республиканец. Казанда В. И. Ленин музеен оештыручы, аның беренче директоры.

Өченчебез — атлет гәүдәле Николай Васильевич Акимов.

Дүртенчебез — Ардалион Михайлович Нижегородцев, киптерелгән балык төсле ябык. Сары чәчле. Зур пыялалы күзлектән. Гел хәвефләнеп, тынычсызланып тора.

Алда бер әйткән идем инде: Мәхмүт тә, Николай да, Ардалион да — бу хәлләр килеп чыкканчы комсомол җитәкчеләре булып эшләгән егетләр.

Бишенчебез — үзем.

Без беренче тапкыр 1938 елның көзендә Казан вокзалындагы Столыпин вагонының бер караңгы, тар камерасында очраштык. Менә шуннан башлап бик күп еллар бергә булдык — уртак камерада утырдык, бер кашыктан ашадык. Ахырында Колыма прискаларына кадәр барып җиттек.

## II

Поезд Төмән станциясенә килеп туктады.

— Мөгаен, безне монда төшерерләр. Иртәгә Октябрьнең егерме бер еллыгы бит,— диде Мәхмүт, тимер рәшәткәгә колагын куеп тыңлап.— Әнә, овчарка чиный, алырга килүләре анык.

Әйтеп тә өлгермәде, конвой башлыгы йөгереп килеп, безнең камера-купеның йозагын ача башлады:

— Чыгыгыз! Әйберләрегез белән! Тизрәк!

Атылып-бәрелеп тамбурга чыгуыбыз булды, күзләребез чагылды: перрон ап-ак, беренче күбек кар төшкән. Хуш ис, кар исе. Тынчу камерадан соң сулап туя алмыйбыз.

— Төшегез!

Ап-ак кар түшәлгән перронга төшәргә өлгермәдек, тагын боерык:

— Тезләнегез! Кыбырсымагыз!

Мондый әмерләргә без инде күнегеп беткән — вагоннан төшкәндә, вагонга менәргә әзерләнгәндә тоткын җиргә тезләнергә тиеш. Яңгыр явып, перрон измә пычракмы, хәзерге кебек тездән кармы, конвойның эше юк — тезлән!

Бу юлы да карга чумып тезләндек. Бер генә кат чалбардан, суык балтырны чеметеп алды — дерелди башладык. Паровоз сузып кычкырды да пошкырды, поезд китте.

— Басыгыз! Берәм-берәм, марш!

Без — биш тоткын. Ә безне каравыллап төрмәгә алып барырга алты конвоир һәм бозау хәтле бер эт килгән. Бигрәк зур «илтифат»!

Төрмә капкасы янына җиткәч, конвой башлыгы безне туктатты да, конвоирларга пышылдап кына нindидер бер боерык биргәч, вахтага керде. Без стенага таба елыштык.

— Алло, алло,— конвой башлыгының телефоннан сөйләшкән карлыккан тавышы ишетелде.— Иптәш начальник, аеруча хәтәрләрне алып килдек. Кая олактырырга?

Без кычкырып көлеп җибәрдек. Конвой шашып калды.

— Сез нәрсә? Сез? Акылдан шаштыгызмы әллә?— Аннан гадәти әмерләрен бирделәр:

— Тезләнегез, контр кисәкләре!

Тагын карга батып көрткә тезләндек. Ә үзебез елмаябыз.

Инде икенче ел төрмәдә утырабыз. Һәрберебезгә зинданны шәп чәпәгәннәр. Ләкин һаман әле үзебезнең бу хәлгә — арестант булуыбызга, бигрәк тә аеруча куркынычлы җинаятьче, халык дошманы булуыбызга ияләшеп бетә алмыйбыз. Менә ни өчен конвой башлыгы «аеруча хәтәр» дигәч, без пырх итеп көлеп җибәрдек.

Әмма бу көлүебез хәерлегә булмады — кар эчендә тезләнеп, сәгатьтән артык көтәргә туры килде. Тешләр-тешләргә сугылып, шакылдап, калтырап, туңып, күгәреп беттек. Тагын бераз болай кар эчендә утырсак, бөтенләй катып кала идек.

Ниһаять, безне торгызып, иң әшәке сүзләр белән сүгә-сүгә, төрмә ишегалдына керттеләр, аннан приклад белән суга-төртә, карцер бинасына әйдәделәр. Төрмә капкасы алдында болай озак утыруыбызның сәбәбен соңыннан гына белдек. «Аеруча хәтәрләр»не урнаштырыр өчен төрмәнең карцерын ашыгыч рәвештә бушатырга туры килгән икән.

«Кара козгын» чайкалып кузгалды. Без тагын киттек. Кая? Билгесез. Уйла, борчыл. Газаплан. Вакыт җитәрлек синә, арестант. Ун еллык юлың башланды гына бит әле.

Әүвәл ярыйсы гына иде төсле монда. Әмма, бара торгач, тын кысыла, баш чатный башлады. Өстә форточка булган. Ләкин хәзер ул бозланып каткан, тыштан һава керә алмый. Озакламый сару кайнарга тотынды.

— Ачыгыз, һава җитми!

— Һава! Һава!— дип кычкыра башлаган идек, ишекләргә шартшорт приклад белән сугарга тотындылар.

— Өнегез чыкмасын! Дөмекмәссез!

«Козгын» каядыр түбән төшеп китте. Чайкалды. Үпкәм бугазыма тыгылгандай булды — чыдый алмадым, укшып, косып җибәрдем. Дерелдәп туңып күзләремне ачсам, кар өстендә ятам. Тирә-якта, минем кебек үк сузылып, иптәшләрем ята.

Кемдер арт яктан килеп башыма типте.

— Тере!

Карасам, конвой башлыгы. Бәрән тиресеннән тегелгән колакчын бүректән. Тездән түбән төшеп торган, озын бөрмә билле туннан, ак пималардан — арлы-бирле атлап, кар өстендә аунап яткан тоткыннарның «хәлен» тикшерә — типкәләп уза.

Ул тагын бер әйләнде дә, авызындагы папиросын төкереп ташлап, әмер бирде:

— Юләр сатуны туктатыгыз! Торыгыз!

Конвоирлар йөгереп килеп, тарта-йолыккалый башлады:

— Әйдә, әйдә, кыланма!

Мин, торырга дип кузгалган идем, икенче якка авып киттем, аяклар җансыз. Конвой башлыгы ашыгып килеп билемә типте:

— Кара син контрның назлануын!

...Бер төн, бер көн сугылып-авырып, үлә язып, икенче тәүлек иртәсендә генә Тубыл төрмәсенә килеп егылдык. «Кара козгын» төрмәнең эчке ишегалдына — коридорына ук килеп туктаган. Шуның өчен без шәһәрне дә, хәтта үзебез утырачак төрмәне дә тышкы яктан күрә алмадык. «Кара козгын»нан аңгы-миңге, көч-хәл чыгуга, беренче әмер:

— Чишенегез!— булды.

Суык ишегалдында шыр ялангач калып чишендек тә бозланып каткан цемент идәнгә бастык.

Алып килүче конвой башлыгы, кулындагы папкадан безнең гамәл дәфтәрен чыгарып, фамилияне әйтә башлады:

— Әбҗәлимов!

Инде бу барлауга күнегеп беткән тоткын бер адым алга атлый һәм тын да алмыйча тезеп китә:

— Әбҗәлимов Мәхмүт. 1913 елда Казанда туган, ун ел төрмә, биш ел мәхрүмлек, илле сигезенче статья (фәлән-фәлән пунктлар).

— Кулларыңны күтәр!
Култык астын карыйлар.
— Колаклар?
Колак тишекләрен карыйлар.
— Бөгел...
Шулай берәм-берәм һәрберебезнең бар җирен тикшереп карыйлар. Катып, туңып беттек. Тикшерү, тентү тәмамланганчы киенергә ярамый.
Ниһаять, алу-бирү, тентү бетте, безнең формулярлар конвойдан төрмә администрациясенә күчте.
Коридорның аргы башындагы бер ишекне ачтылар. Надзиратель әмер бирде:
— Алга марш!
Я алла, бу көнне дә күрәсебез бар икән — мунча! Ләүкә. Краннар, Ләгәннәр. Сабын кисәкләре — барысы да бишәрдән.
Төрмәгә эләккәннән бирле, мондый иркен мунчаны күргәнебез юк иде. Бигрәк тә хәзерге кебек, катып-туңганнан соң...
Салкын су, кайнар су. Пар. Җәннәт. Ләүкәдән төшмибез. Барыбызның да тәне кабыкланып каткан. Кайнар су, пар белән җебеткәч, кабык салына башлады. Бер-беребезне тырнакларыбыз белән кырып юабыз. Бер кат тиребез салынды, ахрысы.
Юынып бетеп коенгач, икенче бүлмәгә чыктык — сөлге, күлмәк-ыштан — һәрберебезгә аерым-аерым.
— Кирәк-ярак алыгыз,— диде надзиратель, ишекне ачып.
— Выты, багыгыз әле, душаларым,— ди Мәхмүт юри мишәрчәләп. Үзе, арлы-бирле атлап, өр-яңа формасын күрсәтә.— Выты, нинди кураж булдым, ә?
— Петлицаларында алтын йолдызлар гына юк, маршал булыр идең,— ди Акимов көлеп. Мин дә яңа формага төрендем. Үзеңдәге күренми, кеше өстендәге чекерәеп тора.
Безгә өр-яңа төрмә киемнәре: бушлат, гимнастерка, чалбар, колаклы бүрек бирделәр. Алар барысы да куксел калын киндердән тегелгән һәм барысында да канәфер төсендәге «ямаулар». Чалбарның тезләрендә, гимнастерканың — якаларында, бушлатның да шулай ук якасында, җиң очларында, бүрекнең колакларында. Бу «ямау»лар, билгеле инде, киндер житмәүдән түгел, алай-болай качып китсәләр, әллә кайдан аның кемлеге кычкырып торсын өчен. Ботинкалар да бирделәр, тик шнуры гына бер тотым. Озын ярамый, асылынуыбыз ихтимал бит.

## III

Сез Федор Михайлович Достоевскийның «Үле йорт язмалары» исемле китабын, һичшиксез, укыгансыздыр. Нинди фаҗигале күренешләр, нинди газаплар, вәхшәтлекләр күз алдыннан үтми аны укыганда. Йөрәк тетри, әрни. Коточкыч ул — Тубыл төрмәсенә багышланган бу китап. Икенче тапкыр кулга алырга да куркасың аны — җаның өши. Менә шул китапта тасвирланган — Ф. М. Достоевский җәфаланган төрмәдә — Тубыл зинданында миңа да 1938 елның ноябреннән 1940 елның маена хәтле ел ярымга якын утырырга туры килде.
Башта Федор Михайлович михнәт чиккән иске төрмәдә әсир булдык. Аннан 1939 елның мартында безне, «җәмгыять өчен аеруча куркыныч политик җинаятьчеләрне», әле яңа гына салынган махсус корпуска күчерделәр. Кеше, бигрәк тә тоткындагы кеше, һәрбер үзгәрешкә, хәтта бер камерадан икенчесенә күчүгә дә сөенә. Яңалык! Надзирательдән башка камерага күчәчәгебезне ишеткәч, без дә сөендек — кабындык. Кем белә, яңа төрмәдә бәлки тормышыбыз яңача — җайлырак китәр.
Әмма... Әмма кышын ашыгыч салынган яңа корпусның тар, тимер баскычларыннан күтәрелеп, әле цементы да кибеп җитмәгән, тар, ярым

каранגы коридорыннан узгач, ике яктан тезелеп киткән камераларның авыр тимер ишеген ачып, бусагасыннан атлауга, бар өметләр челпәрәмә килде.

— Әйе... Федор Михайлович утырган борынгы төрмә оҗмах булган икән,— дидем мин ачынып, шыңшып-чинап камера ишеге ябылгач. Җаным өшеп-тетрәнеп китте. Әйтерсең лә, тере килеш ләхеткә куйдылар мине.

Хәер, болары әле алдарак... Әлегә безнең бу төрмәгә яңа аяк басу...

— Бу минуттан башлап исем-фамилиягез формулярда гына кала. Все! Бу минуттан башлап сез бары үзегез утыра торган камера саны һәм ятак саны белән генә аталасыз. Все! Аңлашыламы?

— Аңладык!

— Все!

— Бер сорау бирергә мөмкинме?

— Тондыр!

— Безгә туганнарыбыз белән хат-хәбәр алышырга мөмкинме?

— Мин сезгә төшендердем. Тубыл төрмәсе гади төрмә түгел. Ул полит-и-зо-ля-тор! Төшендегезме?

— Юк.

— Менә юләр. Барысын да монда мин хәл итәм. Инде төшендеңме?

— Әйе.

Төрмә башлыгының безне — аеруча куркынычлы биш сәяси җинаятьчене — беренче кабул кылуы шуның белән тәмамланды. Баш надзиратель безне төп торакларга алып китте. Коридорның урта бер төшендәге таныш камера алдына килеп туктадык.

— Туксан алтынчы.

Әүвәле йозак, аннан камераның авыр ишеге ачылды.

— Керегез.

Монда атлауга, күзләребез чагылып китте — каршы стенада зур-зур өч тәрәзә. Рәшәткәләр дә, башка төрмәләрдәге төсле бөтен тәрәзәне томалап тормый, шпага рәвешендәге уклар рамнарның урта күзләренә генә житеп туктый. Өске як — рәшәткәсез, ачык. Бу камераның озынлыгы сигез, киңлеге биш метр чамасында. Биеклеге дә әйбәт, өч метр ярым булыр кимендә. Түшәм һәм стеналар бик яхшылап известь белән акшарланган. Бу бүлмә һич төрмә камерасына охшамаган. Әйтерсең, мәктәпнең класс бүлмәсе. Бигрәк тә — хәзер, иртәнге кояш нурларында бүлмә ялт итеп тора.

Ул гынамы? Тагын бер сюрприз. Менә шушы киң, биек, якты бүлмәдә унике караван. Шуларның бишесе бик пөхтәләп урын-җир: яңа одеал, ике җәймә, киез мендәр белән җыелган. Һәр караван башында ап-ак сөлгеләр.

Исебез китте. Әллә инде безне иреккә чыгарырга җыеналармы?

Ул гынамы? Форточка ачылды:

— Төшке аш алыгыз.

Сөенечтән әле әйтергә дә онытканмын: бүлмә уртасында озын өстәл, ике якта — өстәл буена — ике эскәмия. Билгеле инде, караватларның, өстәл-урындыкларның аяклары идәнгә болт белән ныгытылган. Менә шушы өстәлгә ризык килде — зур җамаяк тулы уха. Кечерәгендә — солы боткасы. Бер чәйнек чәй, берәр шакмак шикәр. Паекка исә — алты йөзәр граммлы бодай күмәче!

Мондый тәмле ухасы, мондый тәмле ботканы, мондый тәмле күмәчне, мондый тәмле чәй-шикәрне минем моннан соң төрмәдә дә, төрмәдән чыккач та һичбер җирдә ашаганым, эчкәнем булмады.

Гаҗәп тантаналы бер сый булды бу Тубылдагы беренче ашыбыз. Сыйланып туйгач, өс-башыбызны салып, ап-ак җәймәләр ябынып ял итәргә яттык. Өнме бу? Төшме?

Изрәп йоклап киттек.

— Торыгыз! Кичке аш!

Сикерешеп тордык. Бу ни бу! Төн. Кояш сүнгән. Лампочкалар кабынган. Нинди рәхәт йоклаганбыз.

Кичке ашка зур гына җамаяк белән туп-тулы солы боткасы. Изелеп пешкән, сөтләнеп тора. Бер чәйнек чәй, шикәр биш шакмак. Төшкедән калган яртышар паек күмәчләр дә бар иде. Туйганчы ботка ашадык, аннан тәмләп-шикәрләп чәй эчтек. Кайдан килде бу рәхәт?

Кичке аштан соң озакламый тикшерү булды:

— Туксан алты-беренче, туксан алты-икенче...

— Урынында.

Менә шунда гына инде без үзебезнең исем-фамилияләребезне югалтып, бары тик санга калуыбызны төшендек.

Тикшерүдән соң түшәмдәге лампочка өч тапкыр «күзен кысты».

Отбой.

Без тагын йокларга яттык. Караватта одеал ябынып, башны мендәргә салып йоклавы нинди рәхәт.

## IV

Гений Измайлович икенче көнне иртәнге чәйдән соң, кизү буенча кружкаларны юып, өстәлне сөрткәч, бик җитди кыяфәт белән:

— Беләсезме, егетләр,— диде,— минем башта бер даһи план туып килә. Көне буе монда бот күтәреп яту эш түгел.

— Әйдәгез, егетләр,— яткан урыныннан Николай сикереп торды,— хәзер начальниктан чаңгылар сорап алыйк та Иртеш артына походка китик.

Кемдер көлә башлаган иде, Гений, «күз»гә күрсәтеп, бармак янады.

— Тсс... Тик тормаган телдә бәла бар, ди. Көләбез дип карцер режимына эләкмик.

— Үзең башладың,— Ардалион, кызарып-бүртенеп ачуланырга кереште:— Синең даһи planыңнан тыш та сару кайный.

— Поход — киләчәк эше,— диде Гений, Николайга карап, Ардалионны ишетмәгәнгә салышып.— Анысы да булыр. Ә хәзергә мондый план— расписание тәкъдим итәм. Тыңлагыз...

— Әйдә инде, сузмыйча гына сөйлә.

— Ә сез бүлдермәгез. План мондый: һәр иртәдә — физзарядка. Аштан соң — дәрес.

— Менә бусы даһиларча, инде мәктәпкә йөри башлыйбыз,— диде Ардалион мыскыллы көлеп.

— Йөрмәскә дә була. Менә шушы бүлмәдә.

— Укытучылар!?— диде Ардалион һаман каныгып.

— Беренче укытучы — син, физикадан. Ибраһим — шагыйрь, әдәбияттан, Николай математикадан, Мәхмүт тарихтан. Ә мин культура тарихыннан лекцияләр укый алам.

— Чыннан да, план гениальный, тик мөмкинлекләребез... чамалырак,— диде Николай мыек астыннан гына көлеп (ул инде мыек җибәргән иде).

Дөресен әйткәндә, башта мин үзем дә Генийның бу «даһи планы» эшкә ашуына шикләнеп, башкалар төсле, көлеп караган идем. Ләкин көйләнде бит.

Беренче лекцияне «Дөнья культурасы тарихы» буенча Гений Измайлович үзе башлады. Буйга кечкенә, гәүдәгә тулы, йөзе нурлы, борынгы грек скульптураларына охшаш матур сынлы (ярыйсы ук зур «тубал» баш). Ул, өстәл янына килеп басып, бик җитди кыяфәт белән:

— Иптәшләр, без тыңлаячак лекцияләрнең кереш темасы...— дип, профессорларча вәкарь белән сөйли башлагач, колакларыбыз торды.

— Кара әле, тубалбаш, сине юкка гына Гений дип атамаганнар икән,— аркасыннан кагып, Мәхмүт аны мактап та алды.

Беренче лекция тирән эчтәлеге белән барыбызга да ошады.

Икенче көнне кафедрага Ардалион чыкты. Математика тарихыннан башлады. Аннан Мәхмүт, Николай, мин...

Шулай итеп, безнең биш факультеттан торган университет эшли башлады.

Уянгач ук — физзарядка. Аннан барлау. Иртәнге аш. Аннан соң барыбыз да өстәл янына тезелеп утырабыз. Бары тик конспект язар өчен кәгазь, карандаш кына юк. Лекция төшке ашкача. Аннан соң ирекле уеннар. Мәхмүт ипидән бик матур итеп шахмат сыннары эшләде.

Уеннан соң уку. Төрмә китапханәсе бик бай икән — барлык классиклар да бар. Кичке ашка хәтле һәр кеше үзе яздырып алган китапны укый. Аштан соң — әңгәмә.

Башта һәркем чират белән үзе укыган китабының кыскача эчтәлеген сөйләп чыга.

Ә аннан соң — «Истәлекләр кичәсе». Кем нәрсә сөйли. Монда инде беренче мәхәббәт тә, беренче өметләр дә, мәзәкләр дә. Җаның ни тели — барысы да... Ассортимент киң...

— Сезнең җәйге таңда сандугач сайраганын тыңлаганыгыз бармы? Гаҗәп бит ул. Никадәр моң! Никадәр виртуоз маһирлек. Йөрәк эри... Күңел дулкынлана, ташый. Бу җырны ишеткәндә, онытыласың. Илаһи бер диңгездә йөзәсең. Барлык кайгыларың онытыла. Шатлык бирә сиңа. Менә шундый сихерле моң ул таң алдындагы сандугач сайравы. Минем Зифам да шулай җырлый, сандугач булып сайрый. Менә нинди җырчы ул минем Гөлзифам.

— Бераз арттырмыйсыңмы? — Ардалион әйтеп тә бетермәде, Гений — аның колак төбенә шап бар көченә... Селедка Ардалион шундук авып китте. Без ни әйтергә, нәрсә эшләргә дә белмичә калдык — кайсын әрләп, кайсын якларга?

Гений кызарып, еларга җитешеп урыныннан торды да тәрәзә янына барып басты.

— Генка, гафу ит, мин бит шаярып кына... Зифа Басыйрованың чыгышларында мин булдым, яхшы җырлый. Ә син шундук колакка. Әле дә авырта, — Ардалион, кып-кызыл булып янып киткән колагын сул кулы белән каплап, уң кулын Республиканецка сузды: — Әйдә килешик. Бигрәк кызу канлы икәнсең.

Республиканец кулын бирмәде, кискен бер хәрәкәт белән борылып, камераның икенче башына китте — ашыгып атлап. Үзе мыш-мыш килә.

Могҗиза булмый диләр. Юк, була икән. Үзем күрдем, ышандым. Менә үзегез чамалап карагыз әле: бу хәл могҗиза түгелме? Нәкъ менә шул төнне изрәп йоклап киткән генә идем, кемдер тарткалый:

— Тор әле, тор тизрәк! Әнә, ишетәсеңме, ул җырлый.

— Кем? Кайда? Җылый?

— Юләр! Еламый, җырлый... Тор инде.

Торып утырдым. Иптәшләр дә торып караватларында утыралар. Каяндыр еракта җыр тавышы ишетелә — татарча моңлы җыр. Бик-бик ягымлы, хатын-кыз тавышы:

> Төнгә каршы бераз моңлы итеп, Рамай,
> Агрылышу көен җырлады.
> Тынга калды урман буйлары да, Рамай,
> Чишмәләр дә акмый тыңлады.

— Уф алла, — Гений тавышланып көрсенде, — Зифа... Зифа җаккисәгем җырлый бит.

Төрмә ныгытмасы аръягындагы шәһәр майданына куелган репродуктордан искиткеч моң-зар түгелде.

— Акрын... Тавышланма инде... — Мәхмүт, үрелеп, Генаның күлмәгеннән тартты, — дежурныйны китерерсең.

Ә җыр, аз гына тынып-өзелеп торды да, мөгаен, Зифа анда, ерак

Казанда, радиостудиядә күкрәгенә күбрәк сулыш алуга, тагын канат какты:

> Сахраларга чыгып бер сызгырдым, Рамай,
> Чапкан печәннәрем кипсен, дип;
> Безне генә кемнәр каргады икән, Рамай,
> Гомерләре аерым үтсен, дип.

Гений бер торды, бер ятты — иңрәде. Ә җыр моңлы, көр тавыш аның саен үсте.

> Агыйделкәйләрнең яры биек, Рамай,
> Күренеп тора Казан каласы;
> Шушы аерылудан күрешә алмасак, Рамай,
> Гомерлеккә йөрәк ярасы.

Камера эче моң белән, нур белән тулды. Генаның гына түгел, минем дә, билгеле инде, камерадагы башка иптәшләрнең дә күзләренә яшь тулды. Кайнар яшь. Сагыш. Үзем уйлыйм: Гена бәхетле. Бәхетле! Аның сөйгән яры бар. Ул аны онытмый, сагына. Өметләнә. Чакыра. Көтә. Сөйгәненең илаһи тавышы Себергә, Тубылга, безнең камерага хәтле килеп житте... Ә минем кемем бар? Бердәнбер ышанычым Зәйтүнә хәзер мине чаккан елан кочагында.

Гений иңрәп идәнгә төште.

Җыр өзелде.

Йозак шалтырады. Чинап, камераның авыр тимер ишеге ачылды. Бусагада баш надзиратель һәм дежурный. Йөзләрендә кан әсәре юк. Иреннәре дерелди.

— Бу нинди фетнә?

— Гражданин надзиратель,— Гений ишек төбенә килеп басты, тотлыкты.— Гражданин... на...чальник... минем хатыным җырчы... Ишеттегезме?

— Камера өч тәүлеккә карцер режимына утыртыла! — диде баш надзиратель бар тавышына акырып.— Иртәгә иртәнге ашны бирмәгез.

Ишек шалтырап ябылды. Гений иңрәп, үксеп урынына егылды.

## V

Башта, кизү торучы надзиратель әйткәндә, бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белми аптыраган идек.

Хәзер менә бишебез дә өстәл янында утырабыз. Һәрберебезнең алдында бер табак ап-ак кәгазь һәм карандаш. Инде елдан артык кулларыбызга тотканыбыз юк иде төрмә өчен куркынычлы бу коралны.

Камера эче тып-тын. Хәтта бер-беребезнең сулыш алуын да ишетәбез. Кул дерелди. Башта уйлар, уйлар, уйлар! Ничек башлап китәргә, нәрсә язарга, нәрсәне калдырып торырга? Рәхәтләнеп күңелне бер ачып җибәрәсе, анда җыелган барлык аһ-зарны түгәсе иде. Ярамый! Ярамый! Ә нәрсә турында гына язарга соң алай булгач?

Әнием әле мин бала чакта ук үлде. Шуның өчен хатны этигә язам. Менә инде ике ел дигәндә беренче хат. Бу хатны алуга ничек куанып әткәем. Барлык туганнарга йөгереп йөреп, хатны күрсәтер. Бер көн эчендә бөтен Күкчәтау исән булуымны ишетеп сөенер.

— Ибраһим, кара әле,— Мәхмүт хатын язып бетереп, миңа борылды.— Син ничек уйлыйсың, бу хат Казанга ничә көндә барып җитәр икән, ә? Апама яздым, әнкәем күптән үлде бит.

— Ничек әйтергә, минемчә, берәр атна үтәр.

— Нигә бер атна? — Ардалион хатын борын төбенә китереп (ул начар күрә, калын пыялалы күзлек киеп йөри), кабат укый-укый, сүзгә катышты: — Нигә атна? Атна озак. Әйтик Тубылдан Төмәнгә бер көн.

Аннан поезд белән...

— Җуләр.— Николай, язудан туктап, башын күтәрде:— Син әле һаман ирекгәге сыман уйлыйсың. Бу төрмәдә бер генә камера түгел... безнең камера гына туксан алтынчы, исәпләп кара.

— Син, Николай, артык пессимист.— Ардалион, хатын өстәлгә куеп, кызып бәхәскә ташланды, үз фикерен өскә чыгарыр өчен кычкыра башлады:— Һәр нәрсәгә кара күзлек аша карыйсың!

— Ә син ал күзлектән, әйеме?

— Мин... мин,— Ардалион тотлыга башлады, чак кына күзлеге төшеп китмәде, тотып калды.— Мин бик реальный карыйм. Бу хатлар биш-алты көндә адресатлар кулында булачак. Нигә дисезме? Бу төрмәдә хатны камералар чират буенча язалар. Без, мөгаен, иң соңгылардан.

Форточка ачылды:

— Я, хатларны, карандашларны бирегез.

Николай хатының читенә бер-ике сүз язды да надзирательгә сузды.

Мин дә хатны, карандашны бирдем. Республиканец алпан-тилпән килеп, дежурныйга хатын сузды да кире тартып алды:

— Гафу итегез, улыма сәлам язарга онытканмын.

— Җитәр! Вакытыгыз тулды, сәламне киләсе айда әйтерсез.

Надзиратель карандашларны санап, кисеп алып кыскартмаганнармы дип тикшереп, бер-берсенә куеп үлчәп алды да форточканы шап иттереп япты.

— Беләсезме, егетләр, мин Гөлзифага үткән төндә радиодан аның тавышын, моңлы җырын ишетүемне яздым. Барыбыздан да рәхмәт, дидем.

— Булдыргансың! — Ардалион Генаның кулын кысты.— Шәп иткәнсең! Зифа, чыннан да, сандугач икән. Аның гүзәл тавышы әле дә колагымда...

## VI

Белмим, нигәдер яңа ел якынлашкан саен, күңел иләс-миләс килә. Әллә ниләр уйлыйсың, әллә никадәр өметләр өясең аңа. 1938 ел туар алдыннан, Пләтән төрмәсендә дә күңел шулай җилкенгән иде бит... Нигә начарга юрарга? Кем белә, 1939 ел кинәт өр-яңа, якты, сөенечле ел булыр. Бәлкем иптәш Сталин Яңа ел котлавында: «Безнең илдә нахакка төрмәдә утыручылар булырга тиеш түгел! Тикшерегез!»— дияр, һәм 1939 елда барча гаепсез мәхбүсләр ирекккә чыгарлар. Ниһаять, хакыйкать өстенлек алыр, явызлык, ялган ялалар җимерелер.

Өметләнәбез. Укыйбыз. Яңа ел кичәсенә номерлар хәзерлибез. Мәхмүт — җыр, Гений — шигырь, Ардалион — мәзәк, Николай — чуваш җыры. Ә мин яңа бер шигырь чыгарырга тиешмен. Күңелле булырга тиеш ул Яңа ел алды кичәсе.

Нәкъ утыз бере көнне иртәнге чәйдән соң камераның ишеге ачылып, өч надзиратель килеп керде дә:

— Туксан алты-беренче, тиз киен, коридорга чык,— дип боерды.

Аптырап калдык.

— Поклыйсыңмы әллә, тизрәк!

Мәхмүт, киенеп, һәрберебезнең кулын кысты.

Ишеккә атлады:

— Хушыгыз, иптәшләр.

Мәхмүт артыннан, караватт саннары буенча, бер-бер артлы Ардалион Нижегородцев, Гений Республиканец, Николай Акимов күрешеп чыгып киттеләр. Кая? Билгесез. Төрмәдәге иң газаплы җәза,— мөгаен, менә шушы билгесезлек. Алып чыгалар, алып китәләр, кая икәнен әйтмиләр. Мәхбүс телгаләнә — нинди язмыш алда?

Менә бу юлы да елдан артык бергә булган, үзләренә бертуган сыман иягләшкән дүрт дустымны кинәт каядыр алып киттеләр. Тагын күрешербезме, юкмы? Күрешсәк — кайда?

Нинди авыр газап бу — билгесезлек. Шалтырап, чинап, ишек ачылды:

— Туксан алты-бишенче, чык!

Соңгы тапкыр зур, якты камерада бушап, үксезләнеп калган биш караватка карадым да күзләремә яшь тулды.

## VII

Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзә юк. Тәрәзә урынына югары почмакта түшәм кырыенда — форточка хәтле генә бер күз — эченә тимерчыбык челтәр калдырып коелган соргылт пыяла. Аннан кояш нурлары да үтеп төшә алмый, бары тик соргылт бер шәүлә генә төсмерләнә. Камераның сул почмагында цементтан катырылган берсе биек, берсе тәбәнәк тумба. Биеге өстәл, тәбәнәге урындык. Ишек төбендә параша. Ә ятагы кайда соң бу хөҗрәнең? Каранам. Уң як стенаның түбәнге өлешендә ниндидер уем һәм тимер ятьмәләр. Кинәт түшәмдәге электр лампасы өч тапкыр күзен кысты, теге уем эчендәге ятьмәләр сикереп идәнгә төште — ятак пәйда булды. Өстендә — киез, мендәр, одеал. Шундук ишектәге форточка ачылды. Надзиратель:

— Йокла! Башыңны ачык калдырып, чалкан ят. Кагыйдәне бозучы — карцерга ябыла. Өч яктылык сигналы бирелгәч, тор. Тиз тор. Караватны автомат рәвештә җыела. Ят!

Мин тиз генә чишенеп яңа урынга яттым. Арылган. Көне буе әле бер камерага, әле икенчесенә кертеп, озак-озак тотып тинтерәткәннәр иде. Әмма күзләремне чытырдатып йомсам да, йоклый алмыйм.

Әле иртән генә без бишәү идек. Бергәләп Яңа елны каршыларга, «концерт» бирергә әзерләнә идек бит. Сез кайда, дуслар? Сез дә хәзер, минем кебек, бу цемент ләхеттә йоклый алмый газапланасызмы?

Ә Яңа ел? Ул кайда? Уздымы? Килеп җитмәдеме? Одеалны башымнан урап, камераны күрмәскә тырышып, уйга чумдым.

Нинди булырсың икән соң син, яңа 1939 ел?

Шак-шок.

Сикереп тордым. Форточкада наздирательнең ачулы чытык йөзе:

— Нигә тәртипне бозасың? Нигә башыңны урап яттың? Тәртипне тагын бер бозсаң, карцер! Ят!

Шак-шок, шак-шок.

Коридорда йөргән дежурныйның дагалы итеге. Бер ераклаша, бер якынлаша. «Күз» ачыла. Ябыла. Тагын шак-шок. Шак-шок.

## VIII

Дүрт якта да сары таш стена. Кояш нурлары төшми. Иптәшләр дә юк. Таш капчык. Мин япа-ялгыз. Нишләргә? Аптырагач, авыз эчемнән генә җырлыйм:

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем барсын да;
Уйлама, күңлем, барсын да,
Син уйлап шашарсың да.

Чыннан да, болай беркемне күрми, беркем белән сөйләшми, көнетөне япа-ялгыз утыра, уйлана торгач, акылдан язу да ерак түгел. Нишләргә? Аптырагач, ишекле-түрле йөри башлыйм. Дүрт адым алга, дүрт адым артка — шулай баш әйләнгәнче. Күз аллары караңгылана башлый. Тумбочкага утырам. Караватт стенадагы уем эчендә. Ул үзенең расписаниесен бозмый — кичен төшә, иртән күтәрелә дә стена эченә кереп ябыла — көн буена. Уйсигез сәгать тумбочкада утырырга кирәк. Утырасың — әллә көн, әллә төн. Түшәмдәге лампочка гел чекерәеп тора. Каршыда — тимер ишек. Анда форточка һәм «күз». Форточка тәүлегенә өч тапкыр — иртәнге, төшке, кичке ашны — баланданы биргәндә ачыла. Тагын арлы-бирле атлый башлыйм. Хат барып життеме икән, ә? Куанганнардыр. Куанмыйча, мин бит әтинең бердәнбер улы.

— Улым, инде син укы. Тырыш. Кеше бул! — диган иде ул мин Күкчәтаудан Казанга укырга киткәндә.

Тырыштым. Казан педтехникумында кердем, иске-москы киеп, ачлытуклы йөрсәм дә, лекцияләрне калдырмадым. Мине әле техникум комсомол комитетының (меңнән артык комсомол) секретаре итеп сайладылар. Ул эшне дә кулдан килгән кадәр тырышып алып бардым. Алдынгы, тырыш комсомол дип, партия сафларына алдылар. Әүвәлгедән дә җәһәтрәк йөгерә-эшли укый башладым. Техникумны бетергәч, комсомол өлкә комитеты (беренче секретаре бичара Мәхмүт Баһаутдинов иде) Акташ районына, иптәш Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе чыкканнан соң, ялгышларны төзәтергә, колхоз оештырырга җибәрде. Илтән-Бута авылында балалар укыттым һәм колхоз оештырдым. Кулаклар мәктәпне яндырдылар. Төнлә тәрәзәдән аттылар — чак кына үлемнән калдым.

Тагын Казан. «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр», «Пионер каләме» редакцияләре. Шигырьләр. Хикәяләр. Беренче китап, икенче китап басылып чыкты. Кызыл Армия. Пединститут. Әти җаным, мин нәкъ син әйткәнчә, кеше булырга тырыштым. Көннән-көн күтәрелә, үсә бара идем бит...

— Әй, балыкчы! — Форточка ачылгач, сискәнеп, аягүрә бастым. — Ха-ха! Балык тота идеңме? Туры утыр!

Форточка шап итеп ябылды. Уйларым таралды. Тагын утырдым. Стенадагы уемга ябылган урын-җирдән бер җеп асылынып тора. Аптырагач шул җепне тарта башладым. Сузыла. Тагын тартам — сузыла. Кызык. Теге җепне бармакка урый башладым. «Күз» ачылды да ябылды. Мин һаман теге җепне тартып бармакка урыйм. Бераздан «күз» тагын тиз генә ачылып ябылды. Ә бераздан форточка ачылды. Надзиратель бармагы белән ишарәләп мине үзенә чакырды. Пышылдады:

— Нишлисең?

— Бернәсә дә эшләмим.

— Ничек бернәрсә дә? Яле, бармакларыңны күрсәт әле!

Ике кулымны да суздым — мин җеп тартып, бармакка урап утырганымны онытканмын да. Надзиратель кинәт бал корты чаккандай сикереп китте, тавышланып кычкырды:

— Ә бу? Бу нәрсә?

Форточка шап итеп ябылды.

Бер унбиш минуттан, шыгырдап, чинап тимер ишек ачылды. Гаҗәп! Ул иртә-кичен генә ачыла иде.

— Киен!

Бушлатны, бүрекне кидем.

— Чык! Кулларыңны артка куй, марш!

Караңгы коридор буенча бераз атлагач, яңа әмер:

— Тукта!

Туктадым. Алда — баскыч. Бер надзиратель алга төште.

— Аска марш!

Күзләремне озак-озак итеп йомып-ачып, йомып-ачып карадым — берәр нәрсә күренмәс микән? Юк, тычкан күзе хәтле дә яктылык шәйләнми. Дөм-караңгы. Шулай да тикшереп карарга кирәк — мин нинди капчыкта? Стена буйлап капшанып, аякларны акрын гына шудырып-шудырып алга таба үреләм. Үзем куркам — алда су тулы баз булып, төшеп китмим? Кем белә нинди мәкерле карцерга китереп тыгуларын. Уйлап та өлгермәдем, сул аягым каядыр төшеп китә язды, тартып алдым. Йөрәк дөп-дөп итә. Тез буыннарым калтырый башлады. Бераз артка чигенеп хәл җыйдым. Аннан тагын «сәяхәтне» башладым. Бая төшеп китә язганым бер чокыр гына икән. Аны уздым — каршы стена! Ниһаять, монда бераз торып тынычлангач, идәнгә бөгелдем — берәр утыргыч юк микән. Йөри-йөри арылган. Өстәвенә күңел тынычсызлыгы. Идән — боз. Карцер идәнен тезләнеп йөреп чыктым — урындык юк. Бастым. Нишләргә? Утырасы иде. Тагын капшана башладым. Чү! Бу нәрсә! Ике кулым белән капшап тикшерә башладым — карцерның түр почмагында, түбәндә — уентык. Утыргыч. Ниһаять, утырдым. Инде бер тынычлап ял итим. Каяндыр җил өрә сыман. Өшетә башлады. Бер дә кеше утырмаганга суыктыр — цемент бит. Утырам. Утыргыч бер дә җылынырга уйламый — өшеткәннән өшетә генә бара. Өрә, җил өрә. Кайдан? Тирә-якны капшыйм — берәр ярык-тишек юкмы? Юк. Ә җил өрә. Аптырагач, торып, урындыкны капшый башладым. Тишек. Стенада нәкъ утыргыч турысында торба сыман тишек. Менә кайдан җил өрә икән. Әйе. Яңа төшендем бу хикмәткә. Бик акыллы эшләнгән. Урындык бар — утыра алмыйсың. Җил. Суык. Бу тишек тә төрмә хезмәткәрләренең бер яңалыгыдыр. Артык арыган, йончыган булсам да, суык җил утыргычтан куып торгызды. Дер-дер киләм. Торып, карцер буенча арлы-бирле әйләнә башладым.

Башта өер-өер уйлар. Очы да, кырые да юк. Саташып авыргандагы кебек куркыныч уйлар. Хәтта күз алдында нинди дер хәшәрәт күләгәләр авыша кебек. Юк! Юк! Ничек тә бу уйлардан арынырга кирәк.

> Әллә күпкә, әллә бик озакка,
> Ахры, мәңге оныта алмамын
> Тамбов урманнары уртасында
> Усак яфраклары шаулавын...

Күңелдән, әз генә пышылдап, Такташның «Мокамай» шигырен сөйли башладым. Тынычланып киттем. Уйлар таралды. Тагын-тагын Такташны исемә төшерәм.

Белмим, күпме вакыт үткәндер, тәнем әйләнми башлады, аякларның хәле китте — стенага тотына-тотына, теге тишек урындыкка барып, лык итеп утырдым. Карцерның ишеге ачылды. Дежурный:

— Чык! — дип боерды.

Чыктым. Надзиратель мине коридор буенча ишегалдына алып чыгып китте. Әллә инде камерага кайтара? Юк, ләгънәт төшкере, икенче якка борды. Эңгер-меңгер. Әле генә кар явып үткән. Хуш ис! Яңа кар исе. Рәхәтләнеп сулыйм...

— Тукта!

Туктадым. Каршыда карцер корпусының бер як стенасына бастырып-төреп куйган табутлар. Болай да өшеп торган тән чымырдап китте — нигә дим бу табутлар янына китерде соң мине дежурный? Боерык:

— Менә шуларның берсен күтәр дә камерага!

Читтәге бер табутка килеп тотындым. Ярыйсы ук авыр — калын, чи тактадан эшләнгән. Каһәр төшкерене көч-хәл карцерга өстерәп кертүгә, ишек ябылды. Отбой. Йокларга! Аска да, өскә дә, баш астына

да — бер бушлат. Шулай булгач, аны салып тормадым, киенгән килеш кенә табут эченә кереп сузылдым. Ичмасам монда тере килеш ятып хәл җыйыйм. Йокы ястык теләмәс, диләр бит. Күзләремне йомдым. Дер-дер киләм. Баягыдан да көчлерәк туңа-калтырый башладым. Астан суык килә. Ята торгач такта җылыныр дигән идем. Юк, һаман өрә. Аптырагач торып утырдым. Табутның төбен капшый башладым — бу ни бу? Исем китте. Табутның төбендәге такта тишек-тишек. Гаҗәпләнеп тишеккә бармак тыгып карыйм — йомычка. Яңа төшендем суыкның кайдан килүен. Барысы да бик акыллы эшләнгән. Бу ястык ике төпле икән. Арасына йомычка тутырылган. Ул көн озын тышта торып суык җыя, ә монда керткәч, шул суыкны чыгара... Менә шундый ястыкта йоклап кара.

Өченче тәүлек дигәндә мине төрмә башлыгы кабинетына китерделәр.

— Сез, йөз алтмыш сигезенче тоткын,— диде өстәл артында тирән креслога утырган түрә, ниндидер кәгазьләргә кул куя-куя, башын күтәрми генә,— төрмәнең эчке кагыйдәсен бозган өчен, өч тәүлеккә карцерга ябылган идегез, срок тулды. Мин сезне чыгарам. Ләкин, карагыз аны, тагын да тәртипне бозсагыз, моннан да катырак җәза куллanырмын. Төшендегезме?

— Төшендем.

— Алып китегез.

Үземнең йөз алтмыш сигезенче икәнемне белеп, камерама кайттым. Кара нинди якты, нинди иркен икән минем бу куышым.

## X

Иртәнге чәйдән соң шәфкать туташы күренә башлады. Билгеле инде, ул ялгыз гына түгел, йөзен чыткан надзиратель янында күләгә булып басып тора.

Форточка нибары ике-өч минутка гына ачыла. Менә шушы минутлар хәзер минем өчен иң кадерле, иң сөенечле минутлар. Бу минутларда мин барлык кайгы-хәсрәтемне, хәтта үземнең төрмәдә икәнемне дә онытам, камерам кинәт яктырып, балкып китә. Изге минутлар! Форточка ачыла да ябыла. Шатлык сүнә. Камера караңгылана. Мин тагын егерме дүрт сәгать, шул изге могҗизаны көтеп, өметләнеп яшим. Нинди бөек көч икән ул сагыну, көтү, өметләнү!

Бары тик ике-өч минут. Әмма аларда никадәр илаһи көч һәм тылсымлы канатлар...

Һәр иртәдә паекны икегә сындырып, яртысы белән бер кружка чәйне эчәм дә ишек янына басып көтә башлыйм — җаным, тәнем белән көтәм. Тыңлыйм. Менә коридор башындагы ишек ачылып ябылды. Керделәр. Ике кеше. Берсе дөп-дөп итеп тупас атлый. Икенчесе нәфис. Тык-тык итеп җырлап килә. Алар бераз киләләр дә туктыйлар, киләләр дә туктыйлар — күрше камераларга. Тагын дөп-дөп. Тагын тык-тык. Менә алар тынып калдылар.

Надзиратель форточканы ачты.

Менә ул зур, соргылт күзләр. Бик нәфис, бит алмалары алсуланып торган түгәрәк йөз. Алсу иреннәр һәм гаҗәеп бер елмаю. Ул якты да, татлы да, тылсымлы да.

— Хәерле иртә!

Нинди ягымлы, иркәләүче саф тавыш. Әйтерсең лә көмеш кыңгырау чыңлады.

Мин ашыгып «рәхмәт»емне әйтеп бетерә алмыйм, тагын тылсымлы чың:

— Берәр җирегез авыртмыймы?

Менә шушы мөкатдәс минутларны, бик азга гына булса да сузарга тырышып, мин, тәүлек буе әзерләгән «авыруларым»ның берсен — көн дә бер үк чирне атап булмый ич — әйтергә ашыгам:

— Тамагым авырта... төн буенча йөткереп чыктым. Әһе-әһе.

Ул, аптечка сумкасын форточка капкачы-өстәленә куеп, даруларны эзли. Мин аның йөзенә карап туя алмыйм — сокланам. Ул буйга артык озын түгел, башы нәкъ форточка биеклегенә туры килә. Шуның өчен һәрвакыт туп-тулы бөтен йөзе белән күренә. Ә рәттән торган дежурный озын буйлы. Камераны күрер өчен аңа бөгелергә туры килә. Бөгелү — эш, шуның өчен дежурный үзен артык «мәшәкатьләми» — бөгелми. Миңа бит шул гына кирәк.

— Мәгез,— нәфис бармаклар миңа ачык пакетта порошок суза,— эчеп җибәрегез.

Мин пакетны алып, порошокны авызга салам да кәгазьне кире дежурныйга бирәм. Менә шуның өчен дә шәфкать туташы янында дежурный йөри — мәхбүс кулында кош теле хәтле дә кәгазь калдырырга ярамый. Шарт итеп форточка ябыла.

Ә камерада никадәр хушбуй исе, яктылык, нур кала... Мин, сихерләнгән кеше кебек, ишек яныннан китә алмыйча торам.

Иртәгә тагын килер микән?

Минем өчен иң авыр, газаплы көн — якшәмбе. Якшәмбе — ял көн. Иртәнге чәйдән соң инде гадәттәгечә форточка ачылмый. Мине кара-караңгы уйлар баса. Үземне кая куярга белми өзгәләнәм. Акылдан шашармын дип куркам ул дәһшәтле якшәмбеләрдә. Дөньяда иң авыр газап сөйләшмәү икән. Бу камерага кучүнең беренче көннәрендә мин әле бу дәһшәтне сизеп бетермәгән идем. Ә хәзер көннән-көн баса. Ялгызлык. Бер кешене күрмәү, бер авыз сүз алышмау. Ичмаса надзирательләр дә сөйләшмиләр.

Бу кабер тынлыгы, ялгызлык кайчанга хәтле сузылыр? Бер ай? Өч ай? Бер ел? Ун ел?

Юк! Юк! Ун ел бу ләхеттә түзә алмам, акылдан шашармын! Шашармын!

Менә шушы фаҗигале язмышта зур соргылт күзле кыз! Ул — фәрештә! Ул мине дөньяда яшәргә өндәүче бердәнбер изге көч! Мин аны көтәм һәм аның күренүенә юанып кына яшим... Ул килер. Ул елмаер. Ул миңа, «хәерле иртә», дияр. Һәм касә тулы женьшень шәрабы — әбелхәят суын бирер. Мин йотылып эчәрмен бу күзгә күренми торган илаһи шәрабны!

Ниһаять, китап укырга рөхсәт иттеләр. Көне-төне укыйм.

Тормышымда тагын бер яңалык — шигырь ятлау. Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасын күңелгә биклим. Иртә белән чәйгә хәтле бер бүлеген әкрен генә сөйлим. Төштән соң тагын бер бүлеген. Шулай һәр көн. Поэманы сөйләп бетергәч, яңадан башлыйм. Дөрес, берничә тапкыр надзиратель:

— Йөз алтмыш сигезенче! Кисәтәм, тавышланмагыз! Карцер! — дип бармак янады.

Нишлим. Карцер булса, карцер. Анда да укырмын.

— Хәерле иртә!

Менә шушы шәфкать туташы күренә башлаган көннән башлап, үземдә гаҗәп бер үзгәреш сиздем. Иртә белән автоятактан сикереп төшүгә, элеккедәй йокымсырап утырмыйм — гимнастика белән шөгыльләнәм. Юынырга чыккач та элекке кебек, битне арлы-бирле чылату белән канәгатьләнмим, чын-чынлап сабынлап юынам, тешләремне дә чистартам. Гимнастерка белән чалбарымны да киез астына җәеп үтүкли башладым...

## XI

Көтмәгәндә тагын бер бәхетсезлек. Бар таянычым, юанычым китап иде. Аннан да аерылдым.

Бүген, бәхетсезлегемә, катырак йоклап киткәнмен — лампочка торырга күз кысканны сизмичә калганмын.

— Нигә ятасың?! — дип, надзирательнең акыруына, атылып-бәрелеп тордым да, тумбочка өстендәге чалбарны алам дип, күзлегемне цемент идәнгә төшереп җибәрдем. Чәлпәрәмә!

Хәзер күзләрем кызарып китте. Уку түгел, күтәрелеп тә карый алмыйм — яшь ага.

— Хәерле иртә.

— Рәхмәт.

— Сезгә ни булды, һаман түбән карыйсыз?

— Күзлегемне ялгыш ваттым. Хәзер күзлексез карый алмыйм.

— Алайса, мин сезне күз врачына язам.

Форточка ябылды.

Тумбочкага утырдым. Күзләрем кырып, чәнчеп авырта, яшь ага. Я алла, бу нинди газап тагын...

Шул ук көнне төшке аштан соң надзиратель мине икенче корпустагы күз врачына алып барды. Врач, күзләремне карап, күзлек алырга рецепт язды да кырыс кына:

— Счетыгызда акчагыз бармы? — диде.

— Юк,— дидем аптырап һәм борчылып.

— Һәрбер арестантка күзлек алып бирергә төрмә приют түгел.— Врач, маңгаенда янып торган ялгыз «күзен» салып, ачу белән этеп җибәргәндәй эндәште: — Төшендеңме?

— Әйе.

— Алып китегез!

Мин Александр Марлинскийның (Бестужев) Себер төрмәләрендә, Кавказда язган хикәя, романнарын, бигрәк тә «Амалотбек» романын кызыксынып укый идем. Бу әсәрләр миңа ничектер якын, сердәш. Бәлки аны язучының да минем төсле мәхбүс булуы тәэсирне көчәйткәндер. Платән төрмәсендә Алкиннан өйрәнеп калган «Бестужев әлифбасы» әле дә миңа ара-тирә күрше камералар белән бәйләнешергә ярдәм итә бит...

Менә шул бердәнбер сердәш тә хәзер әнә тумба өстендә ята. Укыйсы килә, китапны алып, күзләремә китерәм — томан. Яшь ага, кыра. Сызлый.

## XII

Форточка ачылды. Теге йомшак, нәфис тавыш:

— Сез күзлек алдыгызмы?

Күзләремнең авыртуына чыдый алмый, сөлге белән башымны урап, тумбага иелгән идем, сикереп тордым — сөлгем төшеп китте.

— Юк. Счетымда акча юк бит.

Зур соргылт күзләр миңа текәлде. Нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, бик серле итеп, яратып, пошынып карады алар миңа.

Форточка ябылды. Күзләремнән мөлдер-мөлдер яшь ага башлады. Әллә авыртканга, әллә...

Әтигә хат язганга инде бүген сиксән алтынчы көн, һаман җавап юк. Нигә икән? Әллә адресны дөрес язмадыммы? Алай булса, мин бит Күкчәтауга Сафа абзыйлар адресына яздым. Ул өйдә туганнарның берсе булмыйча булмас. Әллә? Әллә инде... Юк! Юк! Нигә алай начарга юрыйм. Бәлки инде хат килгәндер, төрмә өсталендә алганны

көтеп ята торгандыр. Хат белән бәлки аз-маз акча да җибәргәннәрдер. Күзлек алырга. Менә әйбәт булыр иде.

Шулай бер көнне төшке аштан соң форточка ачылды да баш надзиратель миңа ниндидер кәгазь сузды. Мөгаен, хат! Сөенечемнән егылып китә яздым.

— Сезнең лицевой счетка илле сум акча килде. Әгәр эчке тәртипне бозмасагыз, аена ун сумлык ашамлык, тәмәке алдыра аласыз. Менә карандаш. Кирәк әйберләрегезне бу бланкка языгыз.

Форточка шап итеп ябылды. Кәгазь, карандашны тоткан килеш катып калдым — өнемме, төшемме?

Тагын форточка ачылды:

— Нәрсә карачкы сыман басып торасың? Бир бланкны, карандашны.

Шунда гына исемә килеп, бер генә сүз яздым да бланкны, карандашны надзирательгә кайтарып бирдем. Я алла, теләгем кабул булган. Хатым барып җиткән! Камера буенча әйләнәм, йөгерәм, сикерәм.

— Йөз алтмыш сигезенче! Тәртипне бозмагыз.

— Юк, юк! Зинһар мине заказымнан мәхрүм итмәгез. Мин шатлыгымнан.

— Утыр!

Утырдым. Тын да алмыйм.

## XIII

Күзлекне бер киям, бер салам. Әле ишеккә, әле түшәмгә — лампочкага карыйм... «Амалотбек»ка күз салам. Күрәм, күзләрем авыртмый. Укыйм!

— Әти, җаным, сиңа мең-мең рәхмәт. Мине иң авыр газаптан коткардың. Рәхмәт. Тик менә, нигәдер хатыңны бирмәделәр. Бәлкем? Тукта, син бит бары гарәп хәрефләре белән генә язасың. Шуңа күрә аны, конспирация дип, утка якканнардыр. Алай да син инде исән икәнлегемне беләсең. Мин дә тере икәнеңне беләм һәм бәһасез булэгең өчен сөенәм — башым күккә тия. Яшә, әти җаным!

Форточка ачылды.

— Ничек күзләрегез, авыртмыймы?

Көлеп җибәрдем. Бу камерага күчкәннән бирле беренче тапкыр. Форточкадагы гүзәл кыз да елмайды, ап-ак, энҗе тешләрен күрсәтеп, яктырып елмайды. Я алла, мондый да гүзәл җан булыр икән дөньяда.

— Җитәр! — диде безнең елмаю-көлүне күреп тырпайган надзиратель. — Утыр!

Форточка ябылды. Камерада якты, көләч сөенеч калды.

Нинди илаһи кыз бу шәфкать туташы. Үзе сылу, күзләре сылу, иреннәре сылу. Күңеле сылу. Әнә күз врачы. Ул да медицина әһеле. Ә үзе аю кебек акырып тора. Сүзләре — ук. Ә бу кызның һәр сүзе, һәрбер авазы — касә тулы тере суы. Аның «хәерле иртә» дигән бер генә сүзе дә тәүлек буена көч, егәр, өмет өсти.

Исеме кем икән! Вера? Надежда? Любовь? Ничек кенә булса да, аның исеме җисеменә хас матурдыр. Яңгырашлы булырга тиеш. Һичшиксез шулай.

Яшә, Вера! Яшә, Надежда! Яшә, Любовь!

Мин сиңа бәхет-сәгадәт телим. Язмышың якты, бик якты булсын. Бәхет кошы сине бервакытта да, бервакытта да ташламасын!

Нигә, нигә синең соргылт күзләр,
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, әйтче, әй аппагым,
Керфек очларыңнан тамалар?

Хөрмәтле Һади абый, син инде мине гафу ит, шигыреңне аз гына үзгәрттем. Синең урман кызың — Әминәң кара күзле булган. Минем өметем соргылт күзле. Шуның өчен мин кара күзләрне соргылт иттем. Бар юанычым да шул гына бит, ачуланма инде, Такташ абый.

## XIV

— Хәерле иртә! Үзегезне ничек хис итәсез?!

Тагын сагынып көтелгән көмеш кыңгырау чыңлады. Якты, изге күзләр. Чү, алар нигәдер йомылып алдылар төсле. Сул каш нәрсәгәдер ишарәләп, сикереп алды түгелме? Кайчандыр кызлар шулай кашлар, керфекләр белән сөйләшә иделәр түгелме? Бәлкем хәзер дә!.. Шәфкать туташы — өметем форточканың нәкъ каршына баскан. Ул үзенең нурлы-мөлаем йөзе белән миңа карый. Ә надзиратель — кырыйда, аның усал күзләре бары тик миндә, күршесенә игътибар итми.

Шәфкать туташы форточка өстәле өстенә аптека сумкасын куеп актара башлады һәм миңа карап, сул күзен кысты:

— Әле дә башыгыз авыртамы?

— Инде өченче төн йоклый алмыйм...

— Яхшы, хәзер мин сезгә анальгин бирәм.— Нәфис бармаклар сумкадан кәгазь пакетка төрелгән порошок алдылар: — Мәгез.— Сул күз тагын кысылып — баш әз генә иелеп тә алды: — Тиз генә йотып җибәрегез.

Гадәттә, кагыйдә буларак порошок кабы ачык килеш бирелә. Мәхбүс порошокны шундук эчеп-йотып, кәгазен дежурныйга кайтарырга тиеш. Бу юлы да порошок миңа ачык килеш бирелде. Тоткын сизгер була бит ул, порошок пакетын алуга, бармакларым тойды: кәгазь ике кат!

Кыз юри, ахры, дежурныйга нидер әйтте — игътибарын миннән алды. Шул вакыт мин порошокның аскы кәгазен төшереп җибәрдем, порошокны авызыма салдым, калган капны дежурныйга бирдем.

Форточка шап итеп ябылды.

Аяк тавышлары ераклашуга, идәнгә иелдем, порошок кәгазен алдым — язу! Ишекнең төбенә үк утырып — «күз» ачыла калса, кулымдагы кәгазь күренмәсен дип, дулкынланып укый башладым. Вак кына хәрефләр: «Боекмагыз. Үз-үзегезне саклагыз. Хаклык килер».

Адымнар! Кәгазьгә тагын бер кат күз йөртеп чыктым да авызыма каптым.

— Нишләп торасың?

— Парашага чыгам.

«Күз» ябылды. Мин кәгазь бөтине чәйнәп йотып җибәрдем.

— Боекмагыз! Үз-үзегезне саклагыз! Хаклык килер!

— Килер! Килер! Килер!

— Нәрсә, акылдан шашасыңмы?!

Мин елмайдым, бөтен тәнем жиңеләеп китте.

## XV

Яшьлек, күксел таулар төсле,  
Киткән саен матур, ягымлы,  
Томаннарга төренер яшьлегемне,  
Мин онытмам кайнар чагымны...

Әллә кайчан инде, Күкчәтауда вакытта язган бер шигыремнән бу бер куплетны соңгы көннәрдә кат-кат кабатлый башладым. Сагынам. Ярсыйм. Дулкынланам. Миңа инде егерме сигез яшь. Иптәшләрем инде укуларын тәмамлап, өйләнеп, балалар тәрбиялидер. Ә мин?..

— Киен дә чык.

Ишек ачылып, дежурныйның камерага керүен дә сизмичә калганмын.

Зур, якты бүлмә. Дүрт өстәл, һәр өстәл артында ап-ак халат кигән кешеләр утыра. Барысы да ирләр.

Мине кырыйдагы өстәл янына китереп бастырдылар. Өстәлдә бик күп папка-формулярлар. Күзлек кигән урта яшьләрдәге кеше, бер папканы ачып, миңа карамыйча гына сораулар бирә башлады:

— Исем, фамилия, этиең исеме? Туган ел? Статья, пунктлар, срок?

Барысын әйткәч — папка ябылды. Мине күрше өстәлләргә күчерә башладылар. Нәкъ армиягә алгандагы кебек, анадан тума калдырып тикшерә башладылар. Үпкәне, йөрәкне, күзләрне, колакларны...

Берсе-бер сөйләшми, әйтерсең лә, чукраклар. Карыйлар да язалар — ниндидер карточка-бланк тутыралар.

Тагын камерага китерделәр.

Әллә инде армиягә алырга җыеналармы? Мин бит инде өч ел хезмәт иткән кеше. Политрук. Әллә? Тумбочкадан сикереп торып, арлы-бирле йөри башладым.

— Бәлкем? Бәлкем... безнең болай нахакка төрмәдә утыруыбыз иптәш Сталинга барып җиткәндер дә...

## XVI

Бу ни бу?

Коридорда шыгырдап, чинап, камера ишекләре ачыла башлады. Ыгы-зыгы, шау-шу. Кычкырып сөйләшкән тавышлар. Хәтта көлүләр. Ул арада минем камераның да ишеге ачылып китте. Надзиратель, камерага кермичә, бусагадан тыныч кына:

— Чык! — диде һәм тукталмыйча узып китте.

Камерадан чыгуга, зур-зур сакаллы өч кеше мине кочаклап алды, сөякләрне чытырдатып кысалар, үбәләр.

— Сез кем? Сез кем?

— Ә син кем?

— Кара, син нәкъ Карл Маркс шикелле булгансың ин, Ибраһим, сакалың биленә җиткән.

Тагын кочаклаштык. Көчкә танызым үзләрен. Мәхмүт, Ардалион, Николай.

— Ә Гений кайда? Нигә ул күренми?

Әйтеп өлгермәдем, туп төсле тәгәрәп, Республиканец килеп чыкты, уртабызга ташланды. Күтәреп алдык, чөя башладык.

— Ирек!

— Ирек!

Бу төрмә, аның ярым караңгы коридорлары бервакытта да мондый күнелле шау-шуны ишетмәгәндер, мөгаен. Нинди генә тавышлар юк монда. Көлү, кычкыру, акыру, үкереп елау һәм шатлыклы җыр, ирек турында җыр.

Читтән карасаң, мөгаен, исең китәр иде — барысының да чәчләре җиткән, сакаллары үскән, йөзләре агарган, үзләре акылдан шашкан төсле тавышланалар, коридорның әле бер, әле икенче ягына чабалар, егылалар, кочаклашалар.

Беренче ташкын! Сөенү ташкыны! Монда әле акыл баш була алмый. Монда әле йөгәнсез, тезгенсез хисләр! Хисләр! Хисләр! Башкача мөмкин дә түгел бит. Ярты елга якын кешене күрми, бер кеше белән сөйләшми ләхеттә яткан кешеләр алдында кинәт ишекләр ачылсын да, кинәт бу хәтле халык белән очраш. Бу могҗиза түгелме? Монда инде үлчәү юк, кем күпме һәм ничек кычкыра ала — кычкыра, кочаклый, үбә һәм тыела алмый елый.

Ә менә без, биш дус, бер-беребезне кочаклаганбыз да һич аерыла алмыйбыз. Тәннәребезне капшыйбыз — бу безме? Без түгелме?

Гений, тамагын кырып, көр тавыш белән жырлап жибәрде:

> Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
> Коллар һәм ачлар дөньясы...

Шау-шу тынды. Бөтен коридор бары бер жыр — «Интернационал»ны жырлый башлады.

## XVII

Төрмә ишегелдына чыгуга — башыбызга таш төшкәндәй булды. Тавыш-тын бетте. Йөзләр караңгыланды. Башлар иелде. Әле бер генә минут элек балкыган, канатланган өмет сүнде. Кара болыт каплады безнең күкне. Арестант! Мескен арестант. Син нинди беркатлы сабый! Вакытсыз ачылган камера ишеге дә синең өчен ирек капкасы булып тоелды, ашыгып-ярсып, ирек жырлары жырлый башладың. Канатланып оча да башлаган идең...

Ә хәзер? Хәзер алдыңда — ачы хакыйкать: калын таш стеналар. Чәнечкеле тимер чыбыклар. Манаралар. Мылтыгын кулыннан төшерми, туктаусыз әйләнеп-карап торучы сакчылар. Һәм һау-һаулап өрүче этләр.

— Утырыгыз.

Баскан жиребезгә утырдык.

Мәйдан уртасында берничә өстәл. Өстәл өстендә өем-өем папка-формулярлар. Өстәл артында урындыкларга утырган, басып торган, арлы-бирле йөгергән түрәләр.

— Өченче кат, каптеркага!

Бер төркем тоткын торып, төп корпус янындагы кечерәк бер таш йортка таба атладык. Зур таш келәтнең бер почмагында тау булып эреле-ваклы капчыклар ята. Һәрберсендә бирка. Биркага камера һәм мәхбүснең шифры — хужаның «исеме» язылган.

— Бишәр-бишәр кереп биштәрләрегезне алыгыз,— диде келәт башлыгы.

Чират белән актара башладык. Үткән көзне төрмәгә килеп төшкәч, үзебезнең сәләмәләрне салып, капчыкларга тутырган идек. Аларны монда өйгәннәр икән. Чират миңа да житте: әллә ничә йөзләгән капчыкларны арлы-бирле ташлый торгач, йөз алтмыш сигез саны сугылган кечерәк кенә биштәр дә килеп чыкты. Кирәге чамалы. Алыгыз дигәч кенә алам. Анда рәтле бернәрсә дә юк.

Шулай да, иске булса да, моннан бер ел элек өстеңдә булган әйберләрне күрү кызык бит. Ул киемнәрнең яңа чагы, киеп куанган чак искә төшә. Мин дә келәтнең икенче бер почмагына китеп, башкалар белән бергә биштәремне актара башладым. Менә күн тужурка. Мин аны Печән базарыннан «Дуэль» повесте гонорарына биш йөз сумга алган идем. Ул сап-сары, ялт-йолт итеп тора иде. Аны беренче тапкыр күргәч, Зәйтүнә:

— Бу тужурка сиңа бик килешә,— дигән иде.

Нигә әле аны искә алам, хәерсез? Гимнастерка, чалбар сатып алынмаган — гаскәрдә узган еллар истәлеге. Ә итек? Нинди әйбәт хром кунычлы иде. Солдат итеген сүттереп, яңадан тектергән идем. Үзе аяк-ларга таман — кысмый да, буш та түгел — галифе чалбар белән бик килешә иде. Зәйтүнә белән танцага йөргәндә — бигрәк тә. Фу, тагын Зәйтүнә! Хәзер итекнең кунычлары җәелеп ята — үрә бастырып тотканда, балтырлар шешкәч, телеп алганнар иде бит...

Чү, шул итекләр эчендә ниндидер кәгазьләр. Берсен күтәреп селкедем — теге кәгазьләр коелды. Хатлар. Мөгаен, өйдән килгәннәрдер! Бирергә өлгермәгән булганнардыр. Куанып, ашыгып беренче хатны кулга алып, адресын карауга, хәлсезләнеп идәнгә чүктем. Үземнең хат! Әтигә язган хат. Ашыгып икенче итекне селеккаладем. Аннан да хатлар төште.

Минем хатлар! Кыш буенча язылган, җавап китерергә тиешле хатлар!

— Ибраһим, кара әле, синең биштәрдә хатлар бармы?— диде артымда капчыгын актарып маташкан Гений,— мин... мин... Зифадан хат көтәм...

Ул арада башка иптәшләр дә биштәрләрен күтәреп килделәр — чырайлары сытылган.

— Ичмасам яндырсалар, белмәс идек, көтәр идек... Ә монда иң эшәке рәвештә мыскыл итеп, үз хатыңны бер елдан соң кулыңа тоттыралар!— диде Мәхмүт, ярсып.

## XVIII

Башта гомуми камераларга ябылган мәхбүсләрне егермешәр-егермешәр кешедән машиналарга утыртып озата башладылар. Кая? Билгесез. Әмма тоткын тоя: монда, төрмә мәйданында, барысы да диярлек яшь-таза халык. Димәк, каядыр эшкә җибәрәләр.

— Бер кешелек таш капчыкта утырганнан җир казыганым артык,— диде Мәхмүт этап икәнен сизгәч.

Мин дә, башкалар да бу фикергә кушылдык. Чыннан да, дүрт стена арасында тилмерүдән саф һавада, кешеләр белән бергә эшләүгә ни җитә. Әйдә, җәһәннәм чокырына җибәрсәләр дә җибәрсеннәр, тик кире ялгызак камерасына гына бикләмәсеннәр.

Төшке баландадан соң «одиночник»ларны төйи башладылар. Безгә аеруча хөрмәт — «кара козгын» машинасы. Ичмасам киткәндә Тубыл шәһәрен күреп калырбыз, дигән идек, ул өмет тә өзелде...

Июнь башы иде. Сибәләп кенә яңгыр явып үтте. Бераз чыландык. Әмма яңгырдан соң кояш чыкты. Һава юылып, яктырып китте. Саф һава. Бигрәк тә тынчу камерадан соң, ул безгә — җофар исле. Ә шәһәр өстендә аллы-гөлле тасма булып сузылган салават күпере. Аны күрмәгәнгә инде ике елдан артыктыр. Нинди гүзәл син, нинди тылсымлы син, бөек сөенеч күпере! Менә шушы күпер буйлап Күкчәтау далаларына хәтле китәсе дә китәсе иде.

— Тиз! Тизрәк машиналарга!

Иң соңгы булып килгән унбиш «одиночник»ны йөк машиналарына утырта башладылар. Мөгаен, безгә «кара козгын» җитмәгән. Аңа үпкәләмәдек.

Менә нинди икән син Тубыл — Русия арестантларының пайтәхете — декабристлар, Петрашевичлар интеккән шәһәр.

Без утырган зиндан артта кала бара. Ул тау өстендә икән, Казан Кремленә охшаган — биек таш стена белән уратылган. Эчтә — зур-зур корпуслар, хәтта гөмбәзле, алтын тәреле чиркәү! Машинабыз таудан төшеп, Тубылның зур урамыннан бара. Берәр, икешәр катлы агач өйләр. Нәкъ Күкчәтау шикелле. Тик минем туган шәһәрем тау итәгендә утыра, ә Тубыл — Иртеш буенда. Иртеш хәзер биектән караганда, ука тасма булып ялтырый.

Урамның ике ягында, капка төпләрендә халык — картлар, яшьләр, бала-чага. Күрәсең, бөтен Тубыл халкы тоткыннарны озатырга чыккан. Шау-шу юк. Тынлык. Халык зур бер дикъкать белән сөзеп, безнең машиналарга, йөзләргә карый, кемнедер эзләгән кебек, күреп калырга тырышкан кебек карыйлар, озаталар алар безне... Безнең күзләр дә аларда. Әнә алда — чаттагы өйнең ишеге төбендә, баскычта бер кыз басып тора. Зәңгәр күлмәктән, зәңгәр яулык-кыекчадан. Йөрәгем дерт итеп китте. Ул да... ул да... Нәкъ шушындый күлмәктән күренә иде бит. Менә ул уң кулын маңгаена, каш өстенә канатландырды — карый. Җентекләп, капшап карый сыман...

Машина якынлашканнан-якынлаша бара. Минем бар игътибарым шушы сынга бирелде. Ул түгелме?! Ул! Ул! Я алла, чак кына кычкырып

жибәрмәдем «хуш, хуш!» дип. Минә безнең карашлар очрашты. Кыз башындагы зәңгәр кыекчасын йолкып алып селкеде. Машина аны тузан белән күмеп узды...

Пристаньга килеп туктадык. Безне ниндидер бер иске, кара майга буялып беткән баржаның трюмына төшерделәр. Озакламый, чайкалып, баржа кузгалды, безне каядыр алып киттеләр. Трюм эче тып-тын булып калды — уйга калдык.

— Син безне кая, нинди язмышка алып барасың, Себернең бөек чал елгасы Иртеш? Кая?

## Кояш баеганда

Кайвакыт анда челпәрәмә килеп кыйралган салават күперенең хәрабәләре балкый. Кайвакыт ниндидер бихисап зур тылсымлы кала ялкынланып ала. Ә кайвакыт...

Ничек кенә булмасын, һәр көнне кояш үзенә хас бер тантана белән байый. Әмма бу тантанада һәрвакыт ниндидер олы бер сагышның шәүләсе ята. Нинди сагыш икән ул? Мөгаен, аерылышудыр. Һичшиксез, шулайдыр. Чыннан да, аерылышудан да газаплырак сагыш бармы икән бу дөньяда? Бармы икән?

Кояш көнозын иркен күктә йөзеп, җир шарын яктырта, җылыта, аны зөбәрҗәт яшел үсемлекләр белән, аллы-гөлле чәчәкләр белән бизи. Ә аннары? Аннары ул, җир шарын ташлап, каядыр еракка — офык артындагы мохиткә китә. Бата. Югала. Менә шуның өчен, ахрысы, кояш офыкка якынлашкан саен, аерылышу минутлары якынлашкан саен, сүрәнләнә, моңаеп кызара башлый.

— Шәфәкъ елый, хәерлегә генә булсын инде,— ди торган иде мәрхүмә әнкәм, кояш баеган якка карап, дога укый-укый.

Мин үзем дә бала чактан ук кояшны озатып калырга яратам. Озак, бик озак торам мин ул сагышлы тантананы карап. Уйга чумам. Бигрәк тә, нахак тоткынга әләккәч, кояш белән бергә баеган, еракта калган гомер искә төшә. Һәм эчтән генә «Зәңгәр шәл» көен шыңшыйм. Кычкырып җырларга тавышым юк.

> Ал яулык, зәңгәр шәл,
> Үтә гомерем бигрәк җәл...

Менә хәзер дә нәкъ шундый шәфәкъ баеган сагышлы чак иде. Әмма,кояш сүрелсә дә, вагон эчендәге эсселек сүрелми. Киресенчә, көнозын кояш күзендә кызып барган вагон, хәзер үзенең бар кызуын эчкә өрә һәм шуның өчен монда, чамасыз ягылган кара мунчадагы төсле, эссе, тынчу. Вагонның ике ягына корылган, аслы-өсле сәкеләрдә билдән ялангач кырык мәхбүс лычма тир эчендә. Җитмәсә, вагон ярыкларыннан тузан тула. Сулыш алып булмый. Тоткыннарның күбесе — урын тапканнары, сәкеләрен ташлап, идәндә аунын. Мин дә идәндә, ишек кырыенда, бозга ташланган балык төсле чәбәләнәм.

Шулай җәфаланып ятканда, өске сәндерәдән кемдер кычкырып җибәрде:

— Байкал! Байкал!

Салкынча, дымсу җил кагылды. Вагон эче җиләсләнеп китте. Барыбыз да сикереп торып, тимер рәшәткә белән челтәрләнгән форточкаларга өерелдек. Бу ни бу? Башта үз күзләребезгә үзебез ышанмыйча, имәнеп калдык — могҗиза. Чыннан да могҗиза — алсу дулкыннар. Биек таш кыятаулар итәгеннән бормаланып барган эшелон алдында — офыкта алсу дулкыннар чайкала. Алар вакыт-вакыт күтәрелеп, ишелеп, офыкның үзен күмеп китәләр, алтын хәрабәләрне юалар. Аннан кире чигенәләр, тагын янып яткан тылсымлы кала өстенә үрләләр...

Без, сихерләнгән кебек, тәрәзә рәшәткәсенә ябышканбыз, бу гаҗәп күренештән күзләребезне ала алмыйбыз. Алдан тау итәге буйлап борылып барган паровоз да, аның өстендәге бөркелеп барган төтен-толымнар да алсу, хәтта ул янып, һаман-һаман кызара бара... Паровоз ашыга, көнчыгышка — Бөек Тын океанга ашыга. Йөге авыр. Алтмышлап вагондыр. Бары алда һәм койрыкта гына яшел пассажир вагоннары. Анда эшелон сакчылары. Уртада — ишекләре зур-зур йозаклар белән бикләнгән, тәрәзәләре чәнечкеле тимерчыбыклар белән капланган, мал-туар ташый торган кызыл вагоннар. Ул вагоннарның һәрберсендә кырыклап тоткын. Менә шушы җанлы йөкне паровоз ашыгып ыңкылдап Владивостокка таба тарта һәм канлы офыкка керә бара.

Паровоз сузып кычкырды. Байкал өсте шыңлап китте. Бераздан гудок тавышы кире кайтты.

— Ту-ту-ту-у.

Мөгаен Байкал ярындагы таш кыяларга сугылып кире чигенде бу тавыш. Ә паровоз һаман ашыга, көнчыгышка ашыга. Вагон тәгәрмәчләре тык-тык, тык-тык итә. Буферлар чыңлап китә. Вагон чайкала. Без бер-беребезгә сугылабыз.

Менә инде унҗиде тәүлек без бу күчмә төрмәдә чайкалабыз, какланабыз һәм каядыр ашыгабыз. Кая? Безнең өчен билгесез. Мөгаен Владивостокка. Ә аннан? Ходай белсен.

Безне, Тубылдан сайлап алынган яшьләрне, тазаларны иске бер баржа трюмына тутырдылар да Иртеш буйлап Омскига китерделәр. Андагы озату төрмәсендә бер атна тоткач, бик ашыгыч рәвештә шушы эшелонга төяп алып киттеләр.

Июнь ае, яңгыр юк. Вагоннар иртә таңнан кичке шәфәкъка хәтле кояш астында. Юлда коры паек — илле грамм икмәк һәм бер порция — ике йөз грамм чамасы горбуша кисәге бирәләр. Бу балык үзе чи тоз. Ашыйсы килүгә түзә алмыйча, алуга кимереп куясың, аннан соң ул су сорый башлый. Эшелон зур станцияләрдә генә туктый. Конвой башлыгының кәефе яхшы булса, һәр вагоннан ике кеше төшереп, икешәр чиләк су алдыра. Ә инде аның кәефе кырылган булса — вагон ишекләре ачылмый. Сусау түгел — җаның чыксын. Менә шуның өчен суга эләксәң, аерыла алмыйсың — кайнаганмы, кайнамаганмы — аны уйларга вакыт юк. Соңыннан дизентерия башлана. Бикле вагонда дизентерияне күз алдына китереп карагыз...

По диким степям Забайкалья,
Где золото роют в горах,
Бродяга, судьбу проклиная,
Тащился с сумой на плечах.

Йомшак баритон тавыш, йөрәк тавышы. Ул акрын, бик акрын башланды. Бер урыннан икенче урынга күчү, тәрәзә кырые өчен тавышлануүгенү кинәт тукталды. Вагон эче тып-тын булып калды. Анда бары моң, йөрәктән тулып ташыган сагыну моңы, сагыш дулкынланды:

Бежал из тюрьмы темной ночью,
В тюрьме он за правду страдал.
Идти дальше нет уже мочи.
Перед ним расстилался Байкал...

Бу Василь Шевченко җырлый. Гаҗәп киң, көр тавышлы егет ул. Баеп барган шәфәкъка — Байкал күленең алсу дулкыннарына тәрәзә кырыеннан караган да моңлана... Мин аның белән баржада — Тубылдан Омскига күчкәндә таныштым. Карар күзгә дә бик килешле, баһадир гәүдәле егет — киң җилкәле, тулы гәүдәле. Ашыкмыйча, акрын, ышанычлы адымнар белән атлап йөри. Холкы да кыяфәтенә тиң, тыныч-салмак — бервакытта да кызып китми, үлчәп кенә сөйләшә. Ачуланмый да. Үзе ми-

ңа кордаш. Срогы да минеке төсле «бер катушка, биш тагылма» — ун ел төрмә, биш ел мәхрүмлек.

— Арестка хәтле Украинада комсомол өлкә комитеты секретаре булып эшләгән идем,— ди күңеле ташыганда ачылып китеп.— Үзем инде күпчелек белән бергә. Ә менә әнкәй... Ул бу кайгыга, бу мәсхәрәгә түзә алмас. Бердәнбер улы — халык дошманы... — Василь авыр сулый.— Ул үзе — Постышев белән бергә подпольеда эшләгән революционерка. Эти гражданнар сугышында һәлак булды. Ярар! — Кинәт ул, уянып киткәндәй, башын чайкый, авыр уйларны чәчеп ташларга тырыша, ахрысы, жырга күчә: — Әйдә, булмаса, комсомол көннәрне искә төшереп алыйк!

Бүген дә «Наталка-Полтавка» ариясеннән, үзенең иң яраткан комсомол жыры «Саубуллашу»га күчте. Аны башкалар да күтәреп алды. Бу вагонда барыбыз да диярлек яшьләр, комсомолецлар:

Уходили, расставались,
Покидая тихий край.
«Ты мне что-нибудь, родная,
На прощанье пожелай».

Җыр үсте, күтәрелде, канатланды. Бу жыр тәэсирендә үзебезнең арестант икәнебезне дә, бикләнгән тимерчыбыклар белән уратылган вагонда — билгесез жиргә баруыбызны да оныттык. Яңадан үзебезнең дәртле комсомол чагыбызга кайттык — гөрләшеп бертавыштан жырны гөрләттек:

И родная отвечала:
«Я желаю всей душой:
Если смерти, то — мгновенной,
Если раны — небольшой».

Без күп булсак та, барыбызның тавышын күмеп, Васильнең көчле баритоны яңгырый — ул канатланып күтәрелә, үсә һәм йөрәкләрне дерелдәтеп, еракка-еракка сузыла, сүнеп барган шәфәкъка, Байкалның алсу дулкыннарына үрелә. Бу жыр яңгыраган минутлар Василь өчен дә, башкалар өчен дә иң изге минутлар. Барлык кайгы, хәсрәтләр онытыла. Бары тик жыр, бары тик аның тылсымлы канатлары. Алар, безне еракта калган яшьлеккә — комсомол учакларына алып очалар.

— Так-ток!

— Так-ток!

Ике яклап ике каен чукмар белән вагон стеналарына суга башладылар. Без жырга мавыгып, поездның станциягә килеп туктаганын да сизмәгәнбез. Беренче чукмар сугуына, жыр очланмыйча өзелде. Шундук ишек ачылып китте — вагонга Чыпчык сикереп менде. Ул — бу эшелонны озата баручы конвой башлыгы — тәбәнәк, ябык. Әмма шундый житез — чыпчык кебек очып-кунып кына йөри. Хәзер ул очып түгел, атылып менде. Нечкә иреннәре каты кысылган, күгәргән. Чырае сытылган, күзләре ялт-йолт итә.

— Уңга!

Без уң як сәкегә өерелдек.

— Сулга!

Без, ашыгып, бер-беребезне таптый-таптый сул сәкегә тыгызландык.

— Тиз-тиз!

Чыпчык кулындагы резина таяк белән кырыйда калганнарны яра башлады.

— Өскә! Өскә!

Өстә инде урын юк. Менгән берсе авып төшә. Ә резина камчы һаман чож-чож килә.

— Күзлекләрем... — Ардалион, елап, кычкырып идәнгә ташланды.

— Мә сиңа күзлекләр,— Чыпчык сикереп күзлек өстенә басты, пыяла челпәрәмә килде.— Контр! — Камчы Ардалионның аркасына төште. Ул сыгылып идәнгә ауды.

— Уңга!
— Сулга!
— Тиз-тиз, контр-еланнар!
Чыпчык безне шулай бер уңга, бер сулга куып, бик озак азаплады. Үзе кызарды, карлыкты, тиргә батты. Ахырда күгәреп, сөйли алмас хәлгә килде. Ә без инде бөтенләй хәлдән тайдык, кузгалырлык чама калмады, тагын арлы-бирле кумаса гына ярар иде.
— Шәп җырлыйсыз, Байкал шыңлап торды. Ха-ха!
Без аптырап калдык, әллә мактый, әллә сүгенә. Нигә бу иблисчә көлү!
— Җырны башлаучы кем? Тавышы бик әйбәт икән.
Вагон шып тынды. Бу инде хәтәр сорау иде. Мондый мактауга җавап бирмәү хәерлерәк булыр.
— Гражданин начальник,— безнең арада Иркутск төрмәсеннән генә кушылган бер бурят егете бар иде, ул елмаеп алга басты.— О, безнең староста булдыра, опера артистыннан һич тә ким түгел.
— Мин үзем дә шулай уйлыйм,— диде Чыпчык, чак кына авызын кыйшайтып һәм шундук елан булып ысылдады.— Яле, опера артисты, монда кил әле.
— Мине әйтәсезме, гражданин начальник?
— Сине, сине! Ишеккә якынрак кил әле.
— Һау! Һау!
Ул арада эт җитәкләгән ике солдат-конвоир безнең вагон каршысына килеп туктады. Ике тапкыр кыңгырау чыңлады.
— Тиз бул, староста.
Василь ишеккә якынлаша килеп, каршысына басарга да өлгермәде, Чыпчык сикереп, ике куллап аның яңагына сукты:
— Россияне агитировать итү җитмәгән, инде тайгага тотындыңмы?
Василь чайкалды, әмма егылмады. Моны күргән Чыпчык аны башыннан этеп җибәрде. Кемдер кул сузды, тотып калырга омтылды — булмады. Василь бар салмаклыгы белән ишектән перронга барып төште. Этләр абалап аның өстенә ташланды. Ул арада Чыпчык та сикереп төште. Вагонның ишеген тартып яптылар.
— Ту-туу!
Паровоз сузып кычкырды. Поезд кузгалды. Кояш кызарып баеган иде инде.

## Бер йотым су

### I

— Даң-доң! Даң-доң!
Вахта каршындагы баганага элеп куелган рельс кисәгенә сугалар.
— Даң-доң! Даң-доң!
Уянырга.
Сикереп тордым — ник кенә күзләремне ачыйм. Аңгы-миңге киләм, башым сыгылып-сыгылып китә. Керфекләрне кузгатып булмый, әйтерсең, җилем белән ябыштырганнар.
— Әйдә инде, ни мыштырдыйсың? — Мәхмүт кулымны тотып өстерәп китте.— Әнә безнең рота тезелеп тә ята.
Бер-ике генә атладым, ниндидер ташка абынып егылдым, күзләремнән утлар чәчрәде. Ниһаять, йокым ачылды. Сикереп торып йөгердем — сафка килеп бастым.
Эңгер-меңгер. Таң алды караңгысы. Шуның өчен арлы-бирле йөгергән кешеләр шәүлә булып кына уза. Салкынча. Тора-торгач телгә килдем.

— Мәхмүт, нигә бу хәтле иртә торгыздылар?
— Күпме монда ятарга була? Юлга.
— Кая?
— Кая булсын, алтын казырга.
— Димәк, Колымага. Шәп.

Мәхмүт тамагын кырып куйды — тынычсызлана. Мин төшенмәдем — нигә бу җәһәннәм оясыннан ычкынуга куанмый? Владивосток шәһәренең Икенче елга районындагы озату лагерена килүебезгә инде өч ай тула бит.

— Лагерьда ашау да яхшырак булыр.
— Булыр! — Мәхмүт тагын тамагын кырды.— Әһе-әһе... Баргач күрерсең.

...Капка алдында зур мәйдан. Менә шунда рота-рота тезелгән мәхбүсләрнең кайсыберсе җилкәсенә биштәр аскан, кайсы чемодан, әрҗә күтәргән — юлга әзерләр. Бөтен мәйдан лык тулган. Бер буш урын калмаган. Әйтерсең, походка әзерләнгән гаскәр. Тик киемнәр генә чуар — кайсы пальтодан, кайсы костюмнан, кайсы күлмәкчән. Ара-тирә хәрби кием кигәннәр дә күренә. Тик якаларындагы петлицалар гына сүтеп алынган — урыннары яшәреп, гимнастеркаларның элекке төсләрен әйтеп торалар. Хәзер инде алар унган, билгесез төскә кергән.

Башка төрмә-лагерьларда колонна дип атыйлар иде. Монда, Владивосток озату пунктында нигәдер хәрби бүленеш — рота, отряд. Паек бүләшер өчен җайлангандыр, бәлки. Ротада ике йөз, отрядта — мең тоткын. Ә монда хәзер ничә отряд! Хода үзе белсен. Һәркөн алмашыну бара — берничә отряд Төньякка китсә, эчке Россиядән яңалары өстәлеп тора.

Ә бүген ниндидер бихисап зур кәрван җыйнала. Лагерьның яртысыннан артыгы кузгалгандыр, мөгаен. Шак-шок! Нәрсә шакылдый дип борылсам, Мәхмүт чакма белән ут «әзли» икән — шак-шок!

— Булды... куга ут кабынды, көйрәт.

Мин дә бушлат кесәсенә үк яшерелгән «кәҗә сыйрагын» иплап алып, төзәтеп көйрәттем, суырдым. Нигәдер чәчәдем — йөткерә башладым.

— Мә.

Мәхмүт әйтеп бетергәнне дә көтмәде — «кәҗә сыйрагын» ашыгып авызына капты. Башкалар түземсезлек белән аңа үрелделәр — тәмәке төтенен исни, суыра башладылар.

Өстәлләр дә җитәрлек иде, өстәл артындагы түрәләр дә аз түгел иде, әмма меңләгән тоткынны чишендереп, аның сәләмәләрен капшап, формулярын дөресләп, тикшереп, лагерьдан конвойга тапшырганчы, кояш түбәгә күтәрелде.

Инде август ахыры иде. Кояш сүрәнләнер вакыт. Әмма монда, Ерак Көнчыгышта, кояш якын икән. Нәкъ бездәге җәй кояшы төсле кыздыра, пешерә. Башта без моңа сөенгән идек, чөнки төн салкынча булып, яхшы ук калтыратты. Беренче нурларда рәхәтләнеп җылындык. Ә соңрак...

Өстәвенә тагын бер җәфа.

Лагерь администрациясе безне — юлга чыгучы мәхбүсләрне тукланудан төшергән. Ә яңа түрә — конвой башлыгы, бер урынга алып барып ябканчы, тоткынныарның ашау-эчүе белән кызыксынмый. Ә соң без кая барабыз? Кайда безне дыңгычлап тутыралар? Әйтмиләр.

Шулай да тоткын төпченә, исная һәм ахырында ни дә булса сизә. Менә безнең арада да хәбәр таралды.

Имеш, портта «Джурма» исемле бик зур океан корабы тора, ди. Безне шул корабка төяп алып китәчәкләр. Кая? Бераүләр Сахалинга ди, ә икенчеләр әйтүенчә — Камчаткага. Димәк, ни булса да диңгезгә, океанга. Ичмасам, бер рәхәтләнеп дөнья гизәбез икән. Минем бит әле

океан корабларында йөзгәнем юк. Нинди икән ул Бөек Тын океан?
Ә шулай да ашыйсы килә, эч борып-борып ала, кычкырып куя.

## II

Лагерь үзенең вышкалары, чәнечкеле тимер чыбыкка уралган биек коймалары белән артта калды. Колонна — ун мең тоткын эреле-ваклы сопкалар арасындагы тар юлдан портка таба агыла — очы-кырые юк.

Тирә-якта җәяүле, атлы конвой, этләр. Алда һәм колоннаның артында, ачык йөк машиналарында пулеметлар.

— Таралмагыз!

— Сөйләшмәгез!

— Тизрәк, тизрәк атла, күтәрәм!

Ак сакаллы, күзлекле бик зыялы чырайлы бер карт чемодан күтәргән, үзе аксый. Ул башта бездән алда иде. Инде кала-кала артка чыкты. Элеккегә караганда да ныграк аксый башлады.

— Тизрәк бул, кемгә әйтәм, картлач!

Конвоир арттан килеп, мылтыгының прикладын белән төртеп кычкырды:

— Атла, контр!

Карт абынып барып егылды. Кулыннан чемоданы ычкынып тәгәрәде, ачылды — китаплар чәчелде...

— Һау-һау!

— Тиз-тиз!

Без үрдән түбән төшеп киттек.

Кояш кыздыра. Шабыр тиргә баттык. Ярый әле бездә чемодан, авыр капчыклар юк. Юкса...

— Ибраһим, кара әле.

— Нәрсәне?

— Әнә юл читенә кара,— ди Ардалион,— әрәм калган дөнья.

Чыннан да, юл кырые чуп-чуар. Чемоданнар, капчыклар, әрҗәләр, кием-салым, одеал, кружка, чәйнекләр. Ташлыйлар...

Кояш кыздырганнан-кыздыра бара. Бөркү. Тузан. Эчәсе килә. Тел авызга сыймый. Иреннәр чатнаган. Ичмаса, төкерек тә җыелмый.

Эчәсе килә.

Инде юл читендә, чемоданнар арасында егылып калган тоткыннар да очрый башлады. Аларны этләр сөйри...

Әле менеп, әле төшеп сопкалар арасыннан бара торгач, кинәт бер урамга килеп чыктык.

Агачтан салынган бер катлы өйләр. Белмим, әллә инде бу Владивостокның бер бистәсе, әллә шәһәргә якын бер поселок. Хәзер бөтен халык, карты-яше урамда, капка төбенә, ачык өйалдына чыгып басканнар. Бала-чагалар койма өстендә, кайбер «батырраклары» өй түбәсенә, морҗа янына урнашканнар. Безне күзәтәләр. Тып-тын, бер тавыш юк. Яшьләр кызыксынып, картраклар борчылып — җәлләп карый.

Урамга килеп кергәч, конвой атлары безне ике яклап кысрыклый башлады. Җәяүле конвой атарга әзерләнеп, мылтыкларын кулга алды.

Кояш инде ерак сопкалар артына тәгәри башласа да, кызу кимеми. Урамга кергәч, тузан тагын да артты. Бигрәк тә атлы конвой бертуктаусыз әле алга, әле артка чаба. Тынчу. Сулыш алып булмый. Инде тәндә тирләрлек тир дә калмады, ахрысы. Аркада ап-ак тоз. Авызда, иреннәрдә тоз. Аяклар көчкә-көчкә генә атлый.

— Тиз-тиз!

— Һау-һау! — этләр абалап өскә ташлана.

Капка төпләрендә җыелган халык, колонна якынлашуга хәрәкәткә килде — кайсы күмәч, кайсы колбаса, кайсы алма ташлый. Сафлар бозылды. Кемдер алга чыкты. Кемдер иелеп аста калды.

— Бух-бух!

Бер-ике тапкыр мылтыктан аттылар, мөгаен, халыкны куркытыр өчен, һавага.

Атлы конвой шашынып чаба башлады. Кемнедер кагып-егып, кемнедер таптап уздылар.

Тагын:

— Бах-бух!

Ә мин төштәге кебек кенә киләм — күрәм дә, күрмим дә, ишетәм дә, ишетмим дә. Күз алдымдагы су я елга булып ташый, я күл булып чайкала. Мин шуларга омтылам... Якынлашуга, алар юк була. Су! Бер генә йотым су! Иреннәрне генә чылатсаң да, хәл керер иде...

Күпме килдек? Тагын күпме барасы бар? Кайда ул шомлы «Джурма»? Беркем белми.

— Тиз-тиз!

— Һау-һау!

Мин саф кырыенда барам. Конвой нигәдер арттарак калды. Алда, мин барган якта почмакта — ике катлы йорт. Өйалды сарыга буялган. Аның баскычында кызыл кыекча бөркәнгән бер хатын басып тора — узучыларны бик җентекләп карый. Кемнедер эзләгән сыман. Менә аның карашы миңа төште — очраштык. Мин соңгы көчемне җыеп башымны күтәрдем, авызымны ачтым һәм, кулым белән ишарәләп, ишетелер-ишетелмәс эндәштем:

— Су, су...

Хатын башын иде дә өйалдының ачык ишегеннән йөгереп эчкә кереп китте. Без инде бу өйне узып барабыз. Бу хатын чыкмас, чыкса да, өлгермәс, дип пошынган идем, нәкъ өйалды турысыннан атлаганда, теге хатын йөгереп чыгып, миңа бер чүмеч мөлдер тулы су сузды...

Салкын су! Мөлдер су! Бөтен тәнем рәхәтләнеп китте — егәрләнеп кулымны суздым. Бер чүмеч су минем кулымда. Туйганчы, туйганчы...

Чүмечне авызыма китерергә дә өлгермәдем, аркама приклад белән китереп тондырдылар. Теге хатын акырып елап ишектән кереп югалды. Чүмеч кулымнан очып китте. Мин баскыч төбендәге ташка барып мәтәлдем...

## Линкольн приискасында

### I

1940 елның көзендә, бутараларда су туңып, алтын юу тукталгач, безнең колоннаны Линкольн приискасына күчерделәр. Колымада Совет заманында Америка президенты исемендәге приискамы? Гаҗәп шул. Үзем дә төшенә алмыйм. Ул вакытта, билгеле инде, безнең башта прииска исемен төпченү кайгысы юк иде.

Колонна Томанлыдан төнлә ай яктысында кузгалса да, Линкольнга җиткәнче күз бәйләнә, караңгы төшә башлады. Ул арада кар да яварга тотынды. Без, бер-беребезгә кысылып, бушлатларның булыр-булмас якаларын күтәрдек. Суык.

Ниһаять, алда, сопка итәгендә манаралар күренде. Күңелгә жылы булып китте — тиздән барак, бәлкем, кичке баланданы да бирерләр...

Алдан җибәрелгән бригада безгә инде ышанычлы урын — ике рәт чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган, озынлыгы биш йөз, киңлеге ике йөз метр чамасындагы лагерь да эшләп куйган. Дүрт почмакта һәм ике як урталыкта манаралары да бар. Анда инде зур ак толыпларга уранып, мылтыкларын безгә таба төбәгән сакчылар да басып тора. Лагерь эчендә бер-берсенә каршы салынган дүрт барак. Әмма, нигәдер, аларның кабыргаларына кар өеп куйганнар. Менә шул инде торагыбыз, без шунда кышларга тиешбез.

Ләкин анда житү әле бик мөшкел хәл. Безнең колоннада ничәмә йөз тоткын. Житмәсә, барысы да илле сигезенче статья белән. Җәзалары да, ким дигәндә, ун ел яки артыграк каты режим. Өстәвенә, һәр тәхбүснең формулярлы өстенә кызыл кара белән «Аеруча хәтәр!» дип язып куелган. Менә шуларның берсен генә югалтып кара — конвой әһеленең башы югалачак.

Машиналар зона алдына килеп туктауга, алдагысыннан беренче булып конвой башлыгы сикереп төште. Ачулы әмер. Сүгенү. Чинап эт өрү, ыгы-зыгы. Машиналарда берәр генә конвоир калдырып, башкаларын камарга җибәрделәр. Ул арада манаралар һәм капка өстендәге прожекторлар кабынды. Конвой башлыгының тавышы яңгырады:

— Тыңлагыз! Машиналардан төшеп, унардан сафка тезелеп тезләнергә боерам! Бер адым читкә атлаучылар, качарга омтылучы исәпләнеп атылачак! Тиз-тиз төшегез!

Кузгалдык. Көн буенча кысылып, кузгалмый утырудан, суыктан аяклар агач булып каткан. Капылт кузгалып, алга омтылуга, атлый алмыйча, бер-беребез өстенә аудык. Машиналарның бортларын ачтылар — карга мәтәлдек.

— Ууф! Аягым...

Минем кырыйда гына берәү җан тавышы белән кычкырып җибәрде. Борылдым. Скульптор карт Алексей Николаевич икән. Кар өстендә мүкәли, тора алмый. Күтәрим дип бөгелгән идем, җиргә сеңеп китә яздым — аркага приклад төште.

— Урыныңа бар!

Гадәттәге процедура башланды.

— «А» хәрефләре, өстәлгә!

Тоткыннар машиналарга фамилияләренең баш хәрефе буенча төркемләп утыртылган иде. Беренче машинадагылар, торып, өстәлгә якынлашты да тагын тезләнде.

— Беренче, өстәл янына кил! Тиз!

Алдагы рәтнең сул як кырында тезләнгән беренче арестант күтәрелде — озын, ябык, әйтерсең лә колга. Аркасында нәни генә биштәр. Ул, абына-сөртенә өстәлгә житеп, үзенең «паролен» кычкыра башлады:

— Александров Александр Андреевич. 1917 елда туган... Унбиш ел төрмә.

Конвой башлыгы кулындагы формулярны лагерь вәкиленә бирде. Капка төбендә тоткынны ике конвоир көтә. Тентү.

— Бушат биштәреңне!

Капчык чишелә. Кар өстенә үзе эшләгән агач кашык, консерва банкасы — котелок, иске-москы чүпрәкләр чәчелә. Бер конвоир шулар өстенә ташлана — актара, һәрбер җөйне капшый.

— Чишен тизрәк! — дип акыра икенче конвоир.— Мыштырдама!

Жил. Ярма булып кар сибелә. Суык. Тоткын шыр ялангач көе кар өстендә сикерә...

Менә шулай сигез йөз арестант сират күперен кичә.

Ниһаять, төн уртасы узгач кына алыш-биреш мәшәкате очланды. Аннан вахтерлар безне икешәр йөздән бүлеп, баракларга камадылар. Инде, ичмасам, бераз җылынырбыз дип атылып-бәрелеп керсәк — ис китте.

Барак дигәнебез киндер чатыр булып чыкты. Тышкы як стеналарга кар өеп чыгуның хикмәтенә дә менә шунда гына төшендек. Җылы булсын өчен икән... Әмма бу чатырда җылы дигәннең торуы чамалы иде. Идән — җир. Стеналар һәм түшәм-түбә — киндер. Палатканың ике як стена буенда икешәр катлы сәкеләр (Такта урынына урталай ярылган каен бүрәнәләр түшәлгән). Сәкеләр арасында, урталыкта — ишек каршында һәм түрдә — таш өстенә куелган ике тимер мичкә. Алар мич хезмәтен башкарачак икән: өстә — морҗасы, алда — утын тыга торган тишеге бар.

Вахтер һәрбер мичкә берәр кочак утын бирде. Ягып җибәрдек. Озакламый мичләр пешерелгән кысла кебек кызарды. Менә кайда ул дөньяның рәхәте — җылынып туя алмыйбыз. Әле ал, әле арт белән әйләнәбез. Бияләйләрдән, бүрекләрдән көек исе чыга башлады. Янынnан һич китәсе килми...

Ләкин бу рәхәт озакка сузылмады — өстән тамчы тама башлады. Мичләр чыж-пыж итә. Каралып-каралып китә. Бу күтәрелә. Әйтерсең лә, беренче тапкыр ягылган кышкы кара мунча. Мич кызган саен палатка түбәсе өстендәге кар күбрәк эри. Тамчы шыбырдый гына. Өске сәкеләрдән түбәндәгеләргә күчтек, ләкин анда да ышыкланыр урын юк. Тышта буран, ә палатка эчендә яңгыр — тып-тып тама.

## II

Бөтен тирә-як ап-ак томан эчендә. Кояш та, таулар да, кәрлә агачлыклар да — берсе дә күренми. Әйтерсең лә, Колыма ак кәфенгә уралган. Шылт иткән тавыш юк. Сулыш алып булмый — тын кысыла. Суык ут кебек көйдерә. Бармаклар бияләй белән бергә катканнар, лом тотарга бөгеп булмый. Баскан җирдә тыпырдыйбыз, юкса аяклар ЧТЗга (Чиләбе заводы тракторының көпчәгеннән укмаштырылган резин ботинкаларга) ябышып, катып калачак.

Борынга төтен исе килә. Ара-тирә, томан арасыннан кызыл ялкыннар күренеп кала. Анда — учак. Учак янында — конвой. Борын кытыклана. Нинди тәмле ис, көйгән ботка исе! Бер генә кашык шул боткадан кабып, учак янында утырсаң... Кинәт томан ярылып китте, нәрсәдер дөп итте.

— Александр! Саша! Нәрсә булды?! — Янымда гына шурф казып торган озын егет Александров, ломын кочаклаган килеш, үзе чокый башлаган шурф өстендә ята. Иелдем. Йөзе күм-күк. Күзләре калайланган. Тарткалыйм: — Саша, Саша! — Эндәшми. Нишләргә? Учак янган якка карап кычкырам.— Гражданин начальник, кеше үлә!

— Хөрәсәннәр! Контрлар, ата-бабагызны...— Конвой башлыгы сүгенә-сүгенә килде.— Монда да корткычлык эшлиләр, кабахәтләр. Менә бит, эшләмәс өчен кырык хәйлә табалар. Ә син аның артыннан сөйрәл,— ул Александрны пимасы белән тибеп әтәреп карады.— Каткан, үләксә. Менә, халык дошманы, үлгәндә дә халыкка зыян итмичә үлми бит ул, сволочь! — Түрә ачуланып арлы-бирле йөри башлады. Мин, юл биреп, арткарак чигендем.— Хәзер менә теләсәң нишлә. Калдырсаң, кичкә хәтле таш булып катачак, җавап бир. Зонага озатсаң, сакчыларның икесен алырга туры килә. Ә монда күзгә төртсәң күренмәслек томан: контрларның көткәне дә шул гына. Ә син нәрсә, бәбәкләреңне миңа терәп каттың?! — Ул, Александрны ташлап, миңа ябышты.— Сиңа әйтәм түгелме? Шурфны кем казый? Пушкинмы? Яле!

Ул сугарга дип кизәнгән иде, таеп китте, мин, тиз генә ломны алып, шурфны чокый башладым.

— Гражданин начальник! — Эш кораллары ташый торган чананы өстерәп, бригадирыбыз Имәнкулов килеп чыкты.— Менә чана китердем.

— Ярар. Салыгыз! Зонага!

Александрны чанага сузып салдык. Бригадир ике тоткынны чакырып алды. Алар чанага җигелделәр.

— Кузгалыгыз.

Бер конвоир алдан, икенчесе — арттан. Егерме өч яшьлек студент Александр Андреевич Александров китте. Томанга күмелде. Мәңгелеккә...

Конвой башлыгына чыннан да мәшәкать өстәлде. Ул бригаданы бер түгәрәккә җыйды. Шурфларны участок буена түгел, божра-божра торып казырга боерды. Камау сызыгы тагын да якынлашты. Учак

жылысыннан аерылганга, этләр чинап, улап өрергә тотынды. Кызык холыклы кеше бу конвой башлыгы. Әле генә ул мине теләгәнчә сүгеп, сугып егарга омтылган иде, хәзер инде учакларны күчерергә кушты. Бу эш ярый калды. Кисәүләрне күчергәндә, арлы-бирле йөренеп, учак кабызып, шактый җылынып алдык. Җитмәсә, учак тирәсендә берике икмәк сыныгы да табылды. Билгеле инде, аны йөгергән арада кисәүдә җылытып-эретеп ашап бетердем. Хәл керде.

Учаклар тагын ялкынланып яна башлады. Этләр хуҗалары белән бергәләп ут янына кызынырга утырды. Мин тагын шурф казырга тотындым. Норманы тутырырга кирәк бит. Бер караганда — нормасы әллә ни дә түгел — диаметры утыз сантиметр, тирәнлеге бер метрлы шурф казу. Башта мин үзем дә пүчтәк эш дип тотынган идем,— юк икән.

Менә бүген иртәдән бирле азапланам, ә шурфның тирәнлеге кырык сантиметрга да җитми. Җир корыч булып каткан. Суккан саен лом зыңлап сикереп китә. Бар көч белән тагын бәрәсең — тагын сикерә. Шулай азаплана торгач кына бер кыйпылчык кителә. Тагын, тагын сугам.

— Я хода, ни өчен мине болай газаплыйлар?!

— Ни өчен?!.

## III

Белмим, әллә инде түрәләрнең рәхиме килде, әллә инде кеше житешмәүчелек — мине «ипподром»га күчерделәр. Монда да кинәнерлек әллә ни юк, шулай да шурф казыгандагы кебек, смена буена бер җирдә кадалып тормыйсың. Ә Колыма шартларында бу инде ярыйсы ук җиңеллек.

Грунт никадәр генә каты булмасын, тоткын шурфны тиешле тирәнлеккә җиткерергә мәҗбүр. Карцер, паектан мәхрүм итү, ору-сугу һәрхәлдә тәэсирсез калмый — мәхбүс я үлә, егыла, я шурфны бер метр тирәнлеккә төшерә. Шуннан соң бу бригаданы башка участокка, тагын шурф-чокыр казырга күчерәләр. Тегендә шартлатучылар килә.

Җир калтыранып китә. Күк күкрәгән сыман гөрселдәү ишетелә. Аннан җир чайкалып, челпәрәмә килеп, күккә атыла.

Менә шушы тар-мар ителгән грунтның бер кыйпылчыгын да калдырмыйча җыеп читкә илтеп өяргә кирәк. Шунда гына бу участок алдагы алтын юу сезонына тулаем әзерләнгән булачак.

Грунтны ташыр өчен махсус чаналар эшләнә. Аларның табаннары бүрәнә. Аркылы агачлар да шул табанлыктан кисеп куелган һәм болтлар белән беркетелгән. Чана өстенә 3-4 кубометр җир сыешлы әрҗә куела. Ул да калын каен такталарыннан җыелган һәм кыршаулар белән тарттырылып ныгытылган. Менә шушы әрҗәле чана «колымашка» дип атала.

Грунт шартлатылган участоктан өемгә хәтле боз юл. Аның озынлыгы ике-өч чакрымга җитә. Бу — үзәк юл. Аңа төрле яктагы участоклардан казылып, чокырланып беткән кушма юллар килә. Безнең участок исә бу үзәк юлның урта бер җирендә. Шулай булгач, безгә колымашканы ике-өч чакрымга түгел, аның яртысына гына илтергә туры килә. Бу да ярыйсы ук отыш.

Һәр колымашкада биш тоткын. Өчәү, аркалыкларга җигелеп, алдан тарта, икәү арттан этеп бара. Менә шулай колымашкага җигелеп җир ташу «ипподром»да эшләү була инде.

Бүген көн аяз, болытсыз, томансыз. Тәбәнәк, соргылт күктә — өч кояш. Өчесе дә кызгылт боҗралар эчендә. Бу кояшлар гадәттәге кояш кебек балкып, нур чәчми, бик сүрән кызарып кына торалар. Шунлыктан көн әле иртә булуга да карамастан, әйләнә-тирә эңгермеңгер, кояш тотылгандагы кебек шомлы. Үзе болай чатнама суык

түгел, кырык-кырык биш градуслар тирәсендә генә булыр. Колыма өчен бу күпмени!

Безнең «бишлек»тә гел яшьләр, кулга алынганчы комсомолның житәкче оешмаларында эшләгән егетләр. Шуның өчен безне кайберәүләр комсомоллар звеносы дип тә атый.

Звено башлыгы — Әбжәлимов Мәхмүт. Аның ярдәмчесе — Николай Васильевич Акимов. Ул Мәхмүткә караганда күп тулы, имән төбе сыман, юантык. Лагерьда аны Поддубный дип йөртәләр. Әйтерлеге дә бар. Бернича тапкыр егетләр көрәшеп карады, ләкин Николайны егучы булмады. Бу бит әле ачлы-туклы йөргән хәлендә. Әгәр туйганчы ашатсаң! Звеноның өченче әгъзасы — Ардалион Михайлович Нижегородцев. Буе-сыны белән Николайга капма-каршы. Озын. Ябык. Коры сөяк. Сөякләренең таралып китмичә укмашып йөрүенә ис китә.

Дүртенчебез — Гений Измайлович Республиканец.[1] Гәүдәгә тәбәнәк, юантык булса да, йөзгә чибәр. Киң маңгай. Тирән утырган зур, соргылт күзләр. Туры борын. Юка иреннәр. Түгәрәк матур ияк. Мөгаен, сезне аның исем-фамилиясе гаҗәпләндерәдер. Чыннан да артык яңгыраулы бит. Юри үзләштерелгән тагылма исемдер яки кушаматтыр, дип уйлый күрмәгез. Юк, тегесе дә түгел, бусы да.

Аның ата-анасы бик күптән ачлыктан үлә. Өч яшьлек малай Казан урамында бер кешесез ялгыз кала. Кемдер аны балалар йортына алып барып бирә. Исеме ничек? Атасы кем? Фамилиясе ничек? Беркем белми. Малай — хәл эчендә. Менә шунда, Казан балалар йортында, коллективның гомуми җыелышында табылдык балага исем кушыла. Җыелыш күпчелек тавыш белән карар чыгара: «Малайның исеме — Гений, фамилиясе — Республиканец булсын. Татар баласы булуы күренеп торсын өчен, атасы исемен Измайлович дип куярга».

Озакламый бу балалар йорты, ни сәбәптәндер, таратыла. Гений Республиканецны Беренче укчы татар полкы үзенә балалыкка ала. Ул шунда тәрбияләнә, үсә, мәктәпкә укырга йөри башлый. Ниһаять, полк улы Гений югары белем алып эшкә чыга. Башта ул Татар академия театрының директоры булып билгеләнә. Анда бернича ел эшләгәч, Гений Измайловичны Татарстан культура идарәсе башлыгы итеп тәгаенлиләр.

1936 нчы елда Казанда Владимир Ильич Ленинның мемориаль музеен оештыру мәсьәләсе күтәрелә. Бу аеруча җаваплы һәм әһәмиятле

---

[1] 1957 иче елны, реабилитациядән соң, мин Казанда Республиканецның хатыны, атаклы җырчы Зифа Басыйрова белән очраштым. Гений Измайловичның соңгы көннәре турында Зифа ханым миңа менә нәрсәләр сөйләде.

«1942 иче елның көзендә мине Эчке эшләр халык комиссариатына чакырдылар. Котым очты. Нишлисең, бардым. Җаным уч төбендә. Мине чакырган кеше, ишектән керүгә, исәнләшеп-нитеп тормады, бик коры гына: «Сез Гений Измайлович Республиканецны беләсезме?» — диде. «Ничек белмәскә, ул минем ирем. Ул кайда, биш ел аның турында бернәрсә дә белмим»,— дидем. «Ярый, хәзер күрешерсез»,— диде. Өнемме? Төшемме? Аптырап калдым. Мине машинага утыртып, Арча кырындагы психбольницага алып килделәр. Бер палатаның ишеген ачып, эчкә керергә куштылар. Янымдагы кешеләр белән бергә кердем. Бер генә карават. Анда баштанаяк одеялга уранган бер кеше ята. Врач килеп одеялны ачты:

— Гений, торыгыз, хатыныгыз килде.

Караваттагы кеше тиз генә одеалын тартып алып тагын уранды:

— Торыгыз!

— Комачауламагыз, зинһар, мин Владимир Ильич белән сөйләшәм.

Тавыш таныш. Гений тавышы... Йөгереп барып одеалны тартып алып кочакламакчы идем, ул мине этеп җибәрде. Егылдым. Мин аягүрә басканда, алдымда коточкыч бер кеше басып тора иде. Бөтен йөзен кара сакал баскан. Күзләре акаеп әле бер, әле икенче якка ташланалар.

— Кем сез? Нигә рөхсәтсез кердегез! Әйттем бит, мин Ильич белән сөйләшәм. Китегез! Китегез!

Ул безне куып чыгарды. Мин аннан соң бу палатага бернича тапкыр килдем. Ләкин ул: «Ильич белән сөйләшәм, вакытым юк»,— дип палатага кертмәде. Бернича елдан соң мин аның үлүе турында хәбәр ишеттем».

эшне — музей оештыруны кемгә тапшырырга соң? Шобага Республиканецка төшә. Чөнки ул инде башка оешмаларда да үзен оештыру эшләренә сәләтле, армый-талмый эшли белүе белән танытткан була. Гений Мәскәүгә Надежда Константиновна янына китә. Владимир Ильичның гомер юлдашы Республиканец кандидатурасына бик риза булуын белдерә һәм мөмкин булган кадәр ярдәм күрсәтергә вәгъдә итә. Республиканец зур дәрт, куаныч белән юлбашчыбызның Казанда торган елларын, беренче революцион адымнарын җанландырып, яңа буын күз алдына бастыру эшенә бирелә. Музейда яңадан-яңа экспонатлар, документлар барлыкка килә. Ләкин бу әле аз, бик аз. Ульяновлар гаиләсе торган йортны нәкъ 1884 елгы хәлгә китерергә һәм шул вакыттагыча җиһазлау сорала. Ә вакыт аз. Октябрьнең егерме еллыгына өлгертергә кирәк. Шул көнне музейның ишекләре ачылырга тиеш! Гений көне-төне йөгерә, эзли, ашыга.

1937 елның җәй уртасында Республиканец Мәскәүдән, Крупскаядан телеграмма ала. «Музей оештыру эшләре буенча тиз арада миңа килүегезне үтенәм. Н. Крупская». Гений шул көнне үк вокзалга йөгерә — билет алып вагонга кереп утыра. Поезд кузгалыр алдыннан гына купега НКВД вәкиле аяк басып, Республиканецны «бер генә минутка» комендатурага кереп чыгарга чакыра ...

Беренче колымашканы тырышып, түбәсеннән өеп төядек. «Ипподром»да норма — участок. Менә шушындагы тар-мар ителгән грунтны җыеп, тазартып, өемгә ташып бетерергә кирәк. Алданрак эшне бетерсәң, учак ягып, ут янында җылынырга рөхсәт ителә. Мондый рәхәткә кем өметләнми соң?

Мин звенога яңа килгән кеше булганга, гадәт буенча урта аркалыкка җигелдем. Унда — Мәхмүт, сулда — Николай. Арттан колымашканы Ардалион белән Гений этә.

— Бер, ике, өч, киттек!

— Яле, тагын бер!

Ә колымашка урынында. Биш арестантның җан-фәрман тырышуына, этүенә ул «эһ» дә итми, кузгалмый.

— Болай булмый, егетләр,— Мәхмүт аркалыктан чыга,— табаннар бозга каткан. Ломнарны алып кырыйдан, астан күтәрегез әле. Әйдәгез, бергәләп, взяли!

Менә бит бәла, колымашканы боздан һич кубарып алып булмый. Өстерәп килгәндә, табаннар кызган, туктагач, бозга ябышып катканнар. Хәзер лом белән дә каерабыз, бишәүләп җилкәләрне куеп этәбез. Кузгалмый бит, ләгънәт төшкере! Ахырда, бик озак азаплана торгач кына чана кузгалды. Аркалыкларга җигелеп тартып киттек... Колымашка чинап, сыкрап көчкә-көчкә генә бара. Иң читене — менә шушы тыкрыктан чыгу, ә төп юлга эләксәң, боздан җиңелрәк шуа.

Чыктык. Ыгы-зыгы — шәһәр урамындагы сыман. Уң яктан грунт төялгән колымашкаларны өемгә этеп-тартып баралар. Сул яктан буш колымашкалар кире кайта. Кычкыру. Сүгенү. Мәхшәр.

Үзәк боз юл барган саен сөзәкләнеп үргә күтәрелә. Очына барып җиткәндә, син инде биек, ясалма тау өстендә буласың. Аста — яр. Менә шунда җиткәч, колымашканы кырые белән борып, йөкне аударасың. Тотып калмасаң, чана үзеңне дә өстерәп алып төшеп китәчәк. Ә инде түбәндә — җәһәннәм чокыры! Юл туктаусыз үргә менә, шуның өчен монда гел арттан этеп, сакланып барырга кирәк. Югыйсә, колымашка ычкынса, туктатам дип уйлама. Ул үз авырлыгы белән басып түбән очачак.

Безнең аяктагы ЧТЗлар бозланып каткан, тимераяк кебек шуа, бер урында басып торып булмый. Без алга омтылабыз, аяклар артка китә. Бер урында таптанабыз шулай. Аптырагач, бүтәннәргә юл биреп, колымашканы читкә чыгарып туктаттык. ЧТЗларны лом белән

суккалап, бозларын ватып җиңеләйтеп алдык. Тагын юлга төштек. Аяклар инде таймый, бар көч белән тартабыз. Бара. Тизрәк! Ашыгабыз. Участокны тазартып бетерергә кирәк бит. Учак янында җылынуы нинди рәхәт!

Кинәт өем ягында шау-шу күтәрелде. Кычкырулар! Сүгенү! Нәрсә булган? Туктап күтәрелеп карарга өлгермәдек, алдыбыздан барган колымашка бар грунты белән чигенеп килеп, безнең колымашкага бәрелде...



## IV

Кайбер кешеләрне бәхет дигәнең үзе эзләп таба. Менә архитектор Алексей Николаевичны алыйк. Линкольнга килгән көнне ул машинадан егылып аягын сындырган иде. Шуның аркасында кышның иң зәһәр суыгында өч ай рәхәтләнеп авырулар чатырында ятты. Инде аннан гына чыккан иде, безнең палаткага кизү итеп куйдылар. Моңа кадәр Колымада ишетелмәгән, булмаган хәл бит, илле сигезенче статьялы кизү булсын, имеш. Иң шәп вазифа ич бу лагерьда. Аны бары чын җинаятьчеләр генә башкара. Бүтәнчә булуы да мөмкин түгел. Кизү торучы тәүлегенә өч тапкыр конвойсыз гына гомуми зонага чыга. Мәсәлән, иртә белән ул чатырдагы тоткыннар саны буенча паек алып кайта. Ничек кенә әйтмә, икмәк тураган җирдә сынык-санык төшмичә, валчык коелмыйча калмый. Кизү менә шуларны җыеп ашый ала. Төш вакытында ул ашханәгә баландага бара. Боларны безгә караганда яхшырак ашаталар. Аларның өстәлендә балык башлары, эчеп бетерелмәгән баланда да кала. Аларны да җыеп ашарга була бит. Кич белән тагын ашханәгә...

Кизүнең эше дә — оҗмах рәхәте. Тышта илле-алтмыш градус суык, ә ул чатырда, мич янында без җилкәгә салып ташыган утынны яга. Төнлә инде аяк киемнәрен, чолгауларны киптерә. Көндезен — искемоскыны ямый, пима, ЧТЗны төпли, яки, чүпрәк тапса, бияләй тегә. Бияләйне сатып, өстәмә бер паек яки бер-ике төрем тәмәке алырга була. Тоткынга тагын нәрсә кирәк?

Дөрес, бу урында Алексей Николаевич түгел, башка берәү булса, аны почмакта кысып, яки аерым бүлеккә чагып күздән җуярлар иде. Ә Алексей Николаевичка һичбер арестант үчекми. Аны барысы да ярата.

Ул үзе болай буе-сыны белән әллә ни күзгә ташланырлык кеше түгел. Тәбәнәк. Ябык. Җитмәсә, аз гына бөкресе дә бар. Бите озынча. Аны тагын да озынайта төшеп ап-ак кәҗә сакал сузылып төшкән. Яше — җитмешләр тирәсендә булыр. Әмма шуңа карамастан, бик хәрәкәтчән, тынгысыз карт.

Ул һич тик тормый, һәрвакыт үзенә бер эш таба. Чатырда берәр тоткын авырый икән, аның янында, һичшиксез, Алексей Николаевич. Компресс куя, яфраклар кайнатып чәй эчерә. Берәү өметсезлеккә бирелеп баш күтәрми ята башласа, безнең карт аңа да җитешә — көлә-көлә эчең катырлык мәзәкләр сөйли, яки утыз ел төрмәдә — коеда утырган атаклы испан язучысы Сервантес һәм бүтәннәр турында гәп башлый. Мәхбүс үзе дә сизмичә күтәрелә, тернәкләнеп китә.

Күптән түгел ул бөтен баракны шаккатырды. Хәйран калдык. Эштән кайтсак, аш өстәлендә ак һәм кара шахмат фигуралары, парадтагы сыман кара-каршы тезелеп торалар. Менә кызык. Буш вакытларда чиратлашып уйный башладык. Күңелле. Үен кызыгына бирелеп, кайда икәнеңне дә онытасың. Ара-тирә бригадалар арасында, аннан чатырлар арасында турнир да оештырырга керештек. Әмма бу күңел ачу озакка бармады. Чираттагы тентүләрнең берсендә шахматларны табып мичкә яктылар. Безнең чатыр өч тәүлек карцер режимына куелды.

Тик Алексей Николаевич бирешми. Тагын да кызыграк яңалыклар уйлап таба. Шуларның берсе тагын бөтен лагерьны куандырды, әмма аның да соңы фаҗигале булды.

## V

Сезнең йолдызлар тавышын ишеткәнегез бармы? Мөгаен, юктыр, чөнки аларның сөйләшкән тавышлары бары төньякта гына ишетелә бит. Тыңлап карагыз әле, алар хәзер менә минем янда сөйләшәләр.

— Тып-тып! Тып-тып!

Ишеттегезме, ә бит минем янда беркем юк. Күктә калтырап торган йолдызлар һәм ярты ай. Ай сөйләшми. Ул ялгыз. Ә йолдызлар, күрәсезме алар никадәр! Әйтерсең лә, күк йөзенә алмаз кыйпылчыклары сипкәннәр. Менә шул куштаннар, кызлар кебек пыш-пыш киләләр, серләрен бүлешәләр:

— Пып-пып! Пып-пып!

Бер урында басып торып булмый, суык. Авыз-борыннан чыккан сулыш — пар бөртекләре һавага таралып китә алмыйча зәһәр суыктан шартлыйлар: «пып-пып». Шушы тавышны якутлар «йолдызлар тавышы» диләр. Менә бүген дә шундый, йолдызлар сөйләшә торган суык кичләрнең берсе. Эш бетте. Ә зонага һаман кайтармыйлар. Торган саен суык көчәя. Әллә инде зәмһәрир учакларына утын өстиләр. Ялкыннары бөтен тәнне ялап, көйдереп ала. Бер урында сикерәбез. Ниһаять, тилмереп көткән боерык: «Тезелегез!» Зонага йөгерәбез. Ян-яктан этләр дә юырта. Өрмиләр. Колаклары салынып төшкән. Баскан саен кар шыгырдап китә. Сулыш тыгыла. Тын алып булмый. Яндыра. Керфекләрдә — боз. Борын агара. Авыз корышкан. Атлаган саен абынабыз. Конвой сүгенә, акыра, егылганнарның аркасына — приклад. Йөгерәбез.

Көчкә дигәндә зонага килеп җиттек. Ярый әле яхшы дежурный туры килде. Тентеп маташмады, тиз генә санады да капканы ачты.

Үзебезнең палаткага якынлашкач, гаҗәпләнеп туктап калдык. Бу ни бу? Кайдан килеп чыккан соң монда Төньяк шаһзадәсе? Туңуыбызны онытып, аның тирәсендә әйләнә башладык. Гаҗәп! Зона эчендә, безнең чатыр алдында, тармаклы мөгезләрен артка ташлап, башын югары күтәреп, һава иснәп, мәһабәт болан басып тора.

— Карагыз әле, иптәшләр,— диде Алексей Николаевич кечке баланданы чөмереп бетереп, шау-шу басыла төшкәч,— әгәр дә вахта капкасыннан чатырларга килә торган юлга аллея эшләсәк, ничек булыр?

— Нинди аллея тагын? — Аптырашып калдык. Әллә инде карт саташа башладымы?

— Ха-ха-ха.

Палатка эчендә бомба шартлаган төсле көлү күтәрелде.

— Туктагыз! Туктагыз әле! — Карт кулларын селкеп, ачулы кыяфәт белән кычкыра башлады.— Нигә көләсез, мин сезнең белән киңәшергә телим бит.

— Иң яхшысы бер чүмеч баланданы ничек артык чәлү турында киңәшик.

— Баланда! Баланданың җитмәгәнен мин үзем дә беләм. Ул — корсакка. Ә менә күңелгә дә азык кирәк бит...

— Баш катырма әле, корсак буш булгач, күңел күзе дә сукырая.

— Әйдә, Алексей Николаевич, сөйлә әле.

— Мин кардан, су сибеп катырып, төньяк хайваннарының сыннарын эшләп куярга уйлыйм.

— Әйбәт ич, нигә эшләмәскә?

— Әйе, әйбәт булыр иде. Ләкин...— Мин икеләнеп калдым.— Аларны эшләргә байтак кар кирәк булыр. Аны кайдан алабыз? Зона-

дагы карны инде эчеп бетереп киләбез ич.

— Менә шуның өчен дә сезгә эндәшүем.

— Булмаса, болай итик,— диде бригадирыбыз Зариф Имәнкулов,— ягарга ботак-санак алып кайтабыз бит. Инде икенче култыкка кар-боз кантары кыстырыйк.

Бу эшкә күрше чатыр тоткыннары да кушылды. Зона бер, урам бер. Аллея да бер булачак бит. Имәнкулов бу турыда лагерь һәм конвой башлыкларына әйтеп рөхсәт алды. Алар өчен дә кызык бит, зонада — җанварлар аллеясы.

Шулай итеп, инде кич белән эштән кайтканда, җилкәгә ботак-санак күтәрсәк, култык астына кар яки боз йомарламын кыстыра торган булдык. Ил төкерсә, күл була, диләр бит, аз-азлап ташысак та, чатырыбыз алдында кар-боз өеме көннән-көн үсә башлады. Алексей Николаевич эшкә тотынды. Төнлә ул кизү вазифасын башкара — мичкә яга, аяк киемнәрен, чолгауларны, бияләйләрне киптерә, ә көндезен палатканы тиз генә себереп-тазартып чыга да сын эшләргә керешә. Баланда, паек алып кайтып өләшкәч, тагын шул эштә.

Башта Алексей Николаевич карны палаткага кертеп, тагаракка сала да су коеп изә. Аннан ул бу измәне өсталгә алып, камыр әвәләгән кебек әвәли, өя. Кар өеме акрынлап сын рәвешенә керә башлый. Баш, койрык, аяклар барлыкка килә. Бәйләүче, ныгытучы материал итеп таяк, чыбык-чабык, чүпрәк-чапракны да файдалана. Менә шушы хәлендә сын чатыр алдына чыгарыла. Ул анда шыкырдап ката. Шуннан соң инде скульпторның төп эше башлана. Җанварга үз киемен киендерергә, күзләрен ачарга һәм тик аңа гына хас бер хәрәкәттә — позада туктатып калдырырга кирәк.

Төньяк җанварлары, кошлары күбрәк ак төстә — буяу кирәкми. Ә менә боланнар, пингвиннар һәм башкалар өчен соргылт, кара төсләр кирәк ич. Оста аптырамый. Аллага шөкер, корым бар, көл бар...

Алексей Николаевич, консерв банкасына борын куеп, комган сыман бер савыт эшләп алган. Менә шушы «тылсымлы» комган бөтен сыннарга җан өрә. Комган эчендә су, кирәк икән ул кара, кирәк икән соры була. Менә шул хикмәтле су сын өстенә бөркелә, сибелә. Көн — суык. Сын өстенә сибелүгә, су бөрчекләнеп катып кала. Менә шул рәвешле тире-йон, кауры барлыкка килә. Барлыкка килә, дип әйтергә ансат. Ә чынында — михнәт.

Сыннарны «терелтү» эше, иң нечкә хезмәт тышта эшләнә. Ә суык кырык биш-илле градустан да ким түгел. Менә шунда су белән, кар белән сәнгать әсәре тудырып кара! Берничә көн ул кулына кашык та тота алмыйча баланданы савыт читеннән чөмереп кенә йөрде — бармакларын өшетте. Ләкин аңа карап, карт эшен ташламады. Каяндыр балык мае табып, бармакларын майлап, чүпрәк белән урап, тагын үзенең «остаханәсенә» чыкты.

Бу эш ике айдан артыкка барды. Һәм, ниһаять, яңа елга — 1940 елның утыз беренче декабренә «мәрмәр сыннар аллеясы» әзер булды.

Бәйрәм бәйрәм инде ул — әзерлек кирәк. Тоткын да аңа әзерләнә. Бер-ике көн кала гына түгел, бер ай алдан.

Безнең тәүлеклек рацион: биш йөз грамм икмәк. Иртә-кичен берәр чүмеч (ярты литр) баланда. Төшкегә баланда һәм ярты чүмеч арыш камырыннан чумар. Чумары әләксә, бик яхшы, күбрәк чумар суы гына була. Менә шушы ризык белән илле-алтмыш градус суыкта уникешәр сәгать лом белән чуер җирне чокырга яки, колымашкага җигелеп, грунт ташырга — норманы тутырырга кирәк. Паекны тилмереп көтәсең, инде кулыңа тигәч, ашаганыңны тоймый да каласың — әллә булды, әллә юк. Корсак һаман буш, һаман сорый... Тагын көт!

Менә шушы паектан бәйрәм өлешен дә чыгарырга кирәк. Кирәк! Бәйрәмдә, Яңа елны каршылаганда, ичмасам бер туйганчы ашарга.

Ә ничек? Ничек булса да! Декабрь башлану белән без, авызыбыздан өзеп, берәр кыйпылчыкны үзебездән үзебез яшерә башладык. Кая яшерергә? Ул икмәк кыйпылчыкларын чатырда калдыру һич мөмкин түгел, аны шундук «сугалар». Кая? Кечкенә янчыкка саласың да күзне йомып, бушлат кесәсенең иң төбенә төшереп җибәрәсең. Юкса — кул калтырый, күз йотып алырга тора. Шулай итеп, янчык иң ышанычлы җирдә — кесәдә. Йөргәндә, утырганда, бөгелгәндә ул тәнгә бәрелеп кытыклый. Авызга су килә, бер генә бөртек, бер генә валчыкны алып кап инде! Рәхәтләнеп китәрсең. Хәл керер! — ди шайтан нәфес, вәсвәсәли. Кайвакытта үз кулыңны үзең кесәдә бурлыкта тотасың. Кулны тартып аласың да ачудан сикереп торып колымашкага җигеләсең.

Яңа елга әзерлектә мин башкалардан уздыра төштем. Әйтмәгәнем булсын: конвой башлыгы ничектер миңа рәхимлерәк карый. Анда-монда йөгерергә, чыбык-чабык җыярга, учак ягарга булса, миңа куша. Мин инде хәл кадәренчә җитез — йөгереп эшлим. Учак та тиз кабына, утын да ярыйсы була. Менә шул чыбык җыйган арада куаклыкта яфраклар очрый. Мин аларны кесәгә, кесәгә. Палаткага кайткач киптерәм. Менә дигән чәй.

Утыз беренче декабрьдә эштән кайту белән безнең чатырларның ишегенә йозак салдылар. Этләрне зона эченә җибәрделәр. Саклык. Кем белә, монда гел «илле сигезләр» ич. Яңа ел алдыннан аларның әллә нинди усаллык эшләүләре дә мөмкин.

Төн. Барак тирән тынлыкка чумды. Һәр тоткын сәкедә — үз урынында. Кайсы яткан, кайсы ярым кыйшайган, кайсы сәкедән аякларын төшереп, башын иеп утырган. Тып-тын. Йоклыйлар. Юк. Мондый төндә йокларга мөмкинме соң? Алда 1941 нче ел... Ул мәхбүсләргә нәрсә алып киләчәк? Амнистия? Яңа срок? Ирек? Кабер?

Тоткын уйлана. Башы чатный, ярыла яза. Уйлана.

...Төрле ашамлыклар, эчемлекләр белән тулы өстәл. Шат күңелле, якты чырайлы дуслар. Балалар. Ата-аналар. Хатының...

— Даң-доң!

Сәгать уникене суга. Өстәл янындагы кешеләр барысы да аягүрә басалар. Шешәләр ачыла. Бокалларда янып торган шәраб.

— Яңа бәхет, яңа шатлык өчен...

Шак-шак!

Тоткын сискәнеп айнып китә, тәмле уйларыннан аерыла.

Ишектә конвой.

— Ятыгыз, үләксәләр, нәрсә көтәсез? Отбой!

## VI

Иртәгесен, яңа ел көнне каравыл башлыгы үзе килеп ишектәге йозакны ачып, иртәнге тикшерү-барлауны үткәргәч, лагерьга чыгып йөрергә рөхсәт итте.

Әкият кебек матур көн. Ашыкмыйча, калгып кына тәңкә кар ява, әйтерсең лә, күктән йолдызлар коела... Алар күзләрне чагылдырып җем-җем итәләр.

Караңгы, тынчу палаткадан чыгуга, күз чагылып, баш әйләнеп киткән иде... Хәзер инде сулап туеп булмый — салкынча хуш ис! Гаҗәп икән ул яңа явып торган тәңкә кар исе — шәраб эчкән кебек тәмле исертә, тәнгә егәр өсти, дәрт өсти. Бар кайгы-хәсрәтең онытыла.

Барыбыз да аллеяга атладык. Юлның ике ягында метр биеклегендәге мәрмәр нигезләр... Алар өстендә — тундраның гүзәл җанварлары, кошлары. Каядыр ашыгып барган-очкан җирдән алар монда бик азга гына ял итәргә туктаганнар, кунганнар.

Вахта капкасыннан килгәндә, сезне беренче булып болан каршылый. Ул чабып барган мизгелдә кинәт сагаеп туктап калган. Зур, тармаклы

мөгезләр артка ташланган, колак шәм булып торган. Аның каршында, арт аякларына басып, тундрага хәйран калып карап торган ак аю. Аннан төлке, бүре, шакал, куян, пингвин, акчарлак, морж...

Һәрберсе үзенә генә хас рәвеш алып тукталганнар. Безнең белән танышырга килгәннәр, хәзер-хәзер күтәрелеп юк булырлар кебек... һәммәсе дә үз зурлыгында, үз төсендә.

Кар һаман ява. Йолдызлар коела. Ул йолдызлар постаментлар өстенә, аларга басып торган сыннар өстенә куналар һәм тылсымлы бер нур белән балкыйлар. Гаҗәеп матурлык.

Арестантлар аллея буенча акрын гына, әле вахтага, әле палаткаларга таба атлый, сыннар алдында туктап кала. Нинди матур, нинди гүзәл бу дөнья!



## VII

Бу аллея лагеребызны жылытып, яктыртып җибәрде. Җанварлар кошлар иртә белән безне эшкә озатып кала, ә кичен алар, еракта үрелеп карап, безне каршы ала. Без ашыгабыз, әйтерсең лә анда безне туганнарыбыз көтә. Аена бер була торган ял — мунча керү көнендә лагерьдагы барлык тоткын шушы аллеяда була.

Берәүләр кайчандыр, кайдадыр күргән зоопаркны искә ала, икенчеләр үзләренең ау мажараларын хәтерләп-сөйләп тыңлаучыларны көлдерә, ә өченчеләр, сынга табынучылар кебек, тукталып башларын иеп торалар.

Мин үзем дә, аз гына буш вакытым булды исә, аллеяга чыгам. Озак, бик озак карап торам бу салкын, әмма күңелгә бик җылы сыннарга. Еракта, Тын океан артында, тайга артында, казакъ далаларында калган туган Күкчәтавым күз алдыма килә минем. Дөнья нинди зур, нинди гүзәл. Анда хайваннарга, кошларга урын бар. Ә кешеләргә? Ә кешеләргә нигә тар бу киң дөнья?

Мин үзем ешрак болан алдына килеп туктыйм. Нигәдер ул миңа бик якын. Аның белән сөйләшәм, иң эчерен, изге серләремне бүлешәм. Уйга, хыялга батам... Менә шушы боланга атланып иреккә, туган җирләргә очсаң иде. Анда барып җитәр өчен ничәмә-ничә диңгезләрне, ничәмә-ничә тауларны, кара-караңгы урманнарны кичәргә кирәк бит. Озын юл. Авыр юл. Куркыныч юл. Син абынмассыңмы? Син арымассыңмы, толпарым? Юк! Юк! Син бит бар җанварлардан түзем, бар йөгерекләрдән йөгерек. Мин ышанам сиңа, җанварым. Оч, алып оч мине, толпарым, туган якларга!

## VIII

Март башында Магаданнан өлкән бер түрә килә икән дигән хәбәр таралды. Чатырларның ертык-тишекләрен ямарга куштылар. Чираттан тыш мунчага алып барып чәч-сакалны кырыктылар, юылган күлмәк-ыштан бирделәр. Ике төн рәттән бараклардан куып чыгарып, зур тентү ясадылар — без-пычак ясарга ихтимал булган тимер кисәкләрен берсен дә калдырмый сыпырып алдылар һәм чатырыбызны ике көнгә карцер режимына куйдылар — кичке аштан соң ишеккә йозак элделәр.

Бу өлкән түрәне каршы алу әзерлегенә Алексей Николаевич та катнашмыйча булдыра алмады. Постаментларны төзәтте, алар өстендәге сыннарның кителгән, кырылган җирләрен ямады-сылады, сыйпады. Ничек кенә әйтмә, бу аллея — сәнгать, иҗат җимеше. Олы түрә, һичшиксез, сәнгатьне белә һәм хөрмәтли торган зәвыклы кеше булырга тиеш.

«...Тиздән зур амнистия була, имеш. Илле сигезләрнең барысын да азат итәләр икән. Монда килә торган түрә, тоткыннарның хәлен, тормышын үз күзе белән күреп, Мәскәүгә барачак һәм бу турыда иптәш Сталинның үзенә доклад ясаячак икән. Паек инде алты йөз граммга җиткереләчәк икән. Умач урынына ботка бирәчәкләр, ди...»

Менә шундый имеш-мимеш белән бөтен лагерь гөж килә. Кемне тыңларга, кемгә ышанырга белмисең. Ә шулай да күңелгә рәхәт. Кем белә бит. Бәлкем? Бәлкем чыннан да хаклык өстенлек алыр. Бәлкем безгә дә ирек килер. Өметсез шайтан, диләр бит...

Ниһаять, унөченче март көнне иртән эшкә чыгармыйча вахтадан кире бордылар. Аврал башланды. Сәке такталарын, дөресрәге, бүрәнә яргакларын ком белән ышкып юдык. Чатыр тирәсен себереп, тап төшкән җирләргә кар сибеп чыктык. Алексей Николаевич үзенең аллеясе белән азапланды. Себерде, сөртте, су бөркеп яңартып маташты.

Зонада ыгы-зыгы. Вахтерлар, бригадирлар йөгерә. Кычкыру, сүгенү — барысы бергә буталган. Кинәт:

— Даң-доң! Даң-доң!

Вахта янындагы баганага асылып куелган рельска суга башладылар. Бу инде һәр мәхбүс өчен аңлаешлы — таныш әмер: «Вахта янына килеп, рота-рота булып (һәр палатка — бер рота) тезелергә!»

Тезелдек. Без — беренче рота. Шуның өчен вахтада беренче булып торабыз. Мин алгы рәттә. Бөтен хәрәкәт күз алдында. Көтәбез. Җитәкчеләр юк. Көтәбез. Аяклар өши башлады. Кузгалырга боерык юк. Көтәргә!

Менә бер вакыт вахта ишеге ачылды. Бер төркем хәрби киемдәге кешеләр безгә таба атлады. Алда — озын буйлы, тулы гәүдәле кеше атлый. Аның өстендә гәүдәсенә сыланып торган өр-яңа шинель. Башында елкылдап торган, алтын төсендәге каракүл папаха. Аллеяга якынлашуга, түрә кинәт туктап калды — төбәлеп боланга карады. Муенын аз гына уңга борды — ак аюга карады. Сулга борды... барлык сыннарга күз йөртеп чыкты.

— Начальник! — диде ул акрын гына калын бас белән. Лагерь башлыгы Иван Иванович, урта буйлы, юантык кеше, аның янына килеп үрә катты. Папахалы кунак кузгалмыйча, ияген кагып кына сыннарга ишарә итте.— Бу нәрсә, Петергоф?!

— Иптәш генерал...— безнең түрә каушап, тотлыгып калды,— монда лагерьда бер скульптор бар...

— Яле, кайда ул скульптор? Күрим әле.

Алексей Николаевич, чакырганны да көтмичә, генерал алдына килеп басты:

— Гражданин генерал!

— Гаҗәп, мин сине Петр I кебек мәһабәт гәүдәле кешедер дип уйлаган идем.

Тынлык. Аптырап калдык. Нәрсә турында сүз бара соң?

— Гафу итегез,— диде карт,— мин сезне төшенмәдем, гражданин генерал.

— Менә мин дә төшенмим,— диде генерал һаман әле акрын тавыш белән. Тынлык. Кинәт нииндидер бер ерткыч тешләгәндәй, генерал кычкырып җибәрде.— Нәрсә?! Сине монда Колымага яңа Петергоф салырга җибәрделәрме? Әллә алтын казыргамы?

Яшен суккандай булды. Сискәнеп, калтыранып киттек.

Генерал муенын безнең лагерь башлыгына таба борды.

— Яле, ныграк бер күсәк китерегез әле!

Лагерь башлыгы үзе вахтага йөгереп керде дә кисәү агачы күтәреп чыкты. Барыбыз да катып калдык. Тын алу киселде. Нәрсә була? Безнең түрә генерал янына килеп, бер кулындагы таякка, бер генералга күз йөртеп, аптырап карады.

— Бу... ничек?..

— Скульпторга бир! — диде генерал ачулы тавыш белән.
Алексей Николаевич кисәү агачы сабын кулына алды да нишләргә белмичә каушап генералга карады:
— Гражданин генерал...
— Җитәр! — калтыранган тавышны калын бас таш булып басты.— Монда нәрсә, тоткыннар лагеремы, әллә ял йортымы?! — Тавыш күтәрелеп, нечкәреп китте. Генерал кызарды:— Яле, син, скульптор булмыш... Хәзер үк бу чучкаларны күздән югалт!
Башыбызга тукмак белән суктылармы — иелеп төштек. Мескен Алексей Николаевич хәлсезләнеп бөгелде, кулындагы таягы төшеп китте.
— Вахтер! — диде генерал ачулы тавыш белән.— Монда!
Вахтер — озын буйлы, таза уголовник егет — йөгереп килеп генерал каршына басты. Кунак, инде тынычлана төшкән сыман, акрын гына эндәште:
— Әнә җирдәге таякны алыгыз да бу хайваннарны күздән югалтыгыз. Лагерь кешеләр өчен, хайваннар өчен түгел. Башлагыз!
Күзләремне йомдым.
Шарт-шорт, шарт-шорт. Әйтерсең лә, башыма сугалар, нелеп-нелеп китәм.
Күзләремне ачканда аллея урынында инде чәлпәрәмә китерелгән ватылган боз кисәкләре генә ята иде...



## Мадрид

### I

Моннан бик күп еллар элек тундрада Калым исемле батыр яшәгән. Аның бөтен гәүдәсе саф алтыннан гына торган. Ул вакытта кояш тундра күгеннән китмәгән, көне-төне нурын сипкән. Шуның өчен дә монда кар яумаган, диңгез туңмаган. Тундра ел тәүлегенә ямьяшел гөлбакча булып, чәчәк атып торган. Диңгез буенда калын-кара урманнар шаулаган. Андагы агачлар тәмле җимешләренең салмагыннан иелгәннәр. Болыннарда кызарып пешкән җиләкләрдән аяк атлар урын калмаган. Урманнарда — кошлар, болыннарда — көтү-көтү хайваннар, өер-өер җәнлекләр, куркуны, ачлыкны татымыйча, рәхәт җәйләгәннәр. Мондагы кешеләр дә кием-салымны, суыкны, кайгы-хәсрәтне белмичә, оҗмахтагы кебек ваемсыз яшәгәннәр. Шуның өчен дә ул вакытта бу җирләр тундра дип түгел, Гүзәл Якут дип аталган икән.
Әмма бу рәхәт озакка сузылмаган. Көннәрнең берендә диңгез артыннан явыз гыйфритлар чыгып, кояшны урлап, котыпка алып киткәннәр, якут җире дөм-караңгы булып калган. Агачлар корыган. Үсемлекләр сулган. Диңгез калын боз катлавы белән капланган. Кошлар, хайваннар, җәнлекләр, кешеләр, суыктан туңып, ашарга азык таба алмыйча ачыгып, кая барырга белмичә аптырап, зар елаганнар. Гүзәл Якут иле кара кайгыга баткан.
Менә шул шомлы вакытта Калым батыр аягүрә баскан. Аның алтын гәүдәсе балкып тирә-якка нур чәчкән. Якут җире яңадан яктырып киткән. Ләкин бу нур кояш нуры кебек җылы түгел, салкын нур булган. Алтын нуры кешеләрне, табигатьне җылыта алмавын күргәч, Калым батыр, кояшны гыйфритлардан тартып алырга дип, котыпка киткән.
Гүзәл Якут тагын дөм караңгылыкка чумган. Ә аның халкы өметләнеп, хәвефләнеп, үзенең батыры Калымны көткән. Якут күгенә уникe тапкыр ай күтәрелгән, җирне яктыртырга тырышкан, ләкин үзе дә суыкка чыдый алмыйча, өшеп-күшеген диңгезгә чумган. Уникe тапкыр чумган. Калым батыр һаман кайтмаган. Халык, өметен югалтып, хәле бетеп егылган. Нәкъ менә шушы фаҗигале мизгелдә, ниһаять, ерак

котыптан Кояш балкып чыккан. Якут җире яңадан яшәреп, матураеп киткән. Халык җыр җырлап, кубыз уйнап, барабаннар сугып, үзенең батырын каршылаган. Якут илендә моңарчы һич күрелмәгән, ишетелмәгән бәйрәм — туй башланган. Иң куәтле шараблар, иң симез итләр, иң тәмле тәгамнәр өстәлгә куелган. Җыр, бию, уен-көлке чиген белмәгән. Халык үзенең батырын хөрмәтләгән, сыйлаган...

Әмма арада Калым батырның данын көнләгән хаин бер җан да булган. Ул гыйфритларга сатылып, Калым батыр эчә торган Якут касәдәге шәрабка агу салган. Унике ай буена гыйфритлар белән сугышып арыган-талган Калым агулы шәрабны эчүгә йоклап киткән. Шуны гына көтеп йөргән гыйфритлар, чатырга кереп, йоклап яткан Калымны суйганнар.

Батыр уянып китеп аягына баскан. Гыйфритлар кояшны диңгез ярына ташлап качкан. Әмма батыр озак басып тора алмаган, киселгән башы аны җиргә тарткан. Калым хәлсезләнеп егылган. Аның башы Аляскага, гәүдәсе якут җиренә, аяклары Алданга төшкән.

Һәр язны, гыйфритлар суйган көнне, Калым батыр егылган җиреннән күтәрелеп баса, туган Якутстанына — тундрасына карый, сокланып, яратып карый һәм... хәле бетеп егыла икән. Менә шул вакытта, Калым батыр аягүрә басып торганда, аның мәһабәт алтын гәүдәсе тирә-якка нур сибеп балкый. Бу могҗизаны белмәгән соңгы заман кешеләре Калым батырның нурлы шәүләсен ялгышып Төньяк балкышы дип атыйлар икән.

Бу легенданы миңа үзебезнең бригададагы карт бер якут сөйләгән иде. Әйтүенә караганда, ул, кулга алынганчы, Якутск шәһәрендә укытучы булып эшләгән һәм Төньяк халыкларының фольклорын җыю белән шөгыльләнгән. Бу легенданың нигезендә, һичшиксез, чынбарлыкка ишарә ята. Дөресендә дә, Төньяктагы алтын тамырлары Аляскадан башланып, бөтен Колыма мәйданы буенча тармакланып, Алданга чыга бит. Моны инде ишетеп түгел, үз күзләрем белән күреп беләм, үз кулларым белән казып беләм. Җиде кат тирең түгелә, җиде тапкыр җаның чыга ул алтын оясын казыганда.

Ниһаять, Калым батыр җирләренә дә яз килде. Кар эреде. Елгаларда бозлар кузгалды. Сопкалар ашыгып яшәрә башлады. Ә кояш, йокысын онытып туктаусыз әйләнә. Әнә ул боз диңгезләре артына төшеп байый. Әмма шәфәкъ нурлары сүнәргә дә өлгерми, капма-каршы яктан, котыптан, шул ук кояш яңадан күтәрелә башлый. Ул үзе кинәндереп кыздырмый да, бөтенләй үк сүнми дә — сүрән, саран.

Менә шушы соры көннәр башлануга, бөтен Колыманың астыөстенә килә, туздырылган кырмыска оясы кебек мыж итә. Тоткыннар, түрәләр, солдатлар, этләр — барысы да зиндан-забойларга чыга. Вахта капкалары янындагы баганаларга асылынган чулак рельсларга да тынгылык бетә.

— Доң-доң! Доң-доң!

## II

Бу нинди музыка? Кем соң уйный болай матур итеп?

— Тор, үләксә!

Билем киселеп киткәндәй булды, сикереп тордым. Каршымда — кулына резина таяк тоткан вахтер. Ә барак ишегеннән һау-һау итеп, тешләрен ыржайтып, бозау хәтле овчаркалар кереп килә.

Абына-сөртенә йөгереп барып вахта алдына тезләндек.

— Бүген илебезнең валюта цехы эшли башлый. Сез монда үзегезнең кара җинаятьләрегезне хезмәт белән юар өчен сөрелгән явызлар, халык дошманнары. Алдыгызда тачка, кәйлә, көрәк, забой, норма! Нор-

маны тутырмау — аңлы рәвештә контрреволюцион корткычлыкны дәвам итү. Экономик диверсия! Ә мондый саботаж өчен халык сезгә икенче тапкыр шәфкать күрсәтмәс. Төшендегезме, контрлар!

Колонна башлыгы — озын, ябык, әз генә бөкрәеп, түбән карап йөри торган капитан — бүген өр-яңа формадан төп-төз басып, калын бас белән әмер бирде:

— Бригадаларны забойга төшерергә! Эшкә!

Менә шулай Колымада алтын бизгәге башлана.

Билгеле инде, бу күренеш миңа яңалык түгел. Мин бу 1941 елның язында инде өченче тапкыр алтын юарга чыгам. Әүвәле бер сезон «Линкольн» приискасында эшләдем. Аннан монда — Сусуманга күчерделәр.

Безнең бүгенге забой Колыма елгасы белән сопка арасында. Бу сопка тундра ягыннан болан мөгезе кебек тармакланып килә дә, Колыма ярларына ике-өч километр калганда, кинәт көньякка борыла. Менә шул аралык — безнең забой. Кыш көне шурфлар казып, шартлатып, забойның өске кат грунтын алып ачып куйган идек. Радиусы ике-өч чакрымга сузылган бу забойның урта бер җирендә биек эстакада — бункер урнаштырылган. Бункер астыннан елга ярыннан ук корылган зур улак үтә. Яр буендагы насос станциясе Колыма суын шул тирән улакка — бутарага коя. Су көчле этем белән туктаусыз ага. Һәрбер забойдан бункерга берничә трап-басмалар сузылган. Алтын комлы грунтны тачкага тутырабыз да трап буенча бункерга ашыгабыз. Норма — йөз тачка. Өлгер! Шул такта трап буенча сыңар тәгәрмәчле «самоходка»ны бар көчкә әйдибез. Забой эчендә әле бик үк тыгыз түгел, бер-беребезгә юл да бирәбез. Ә менә бункерга якынлашканда, югары күтәрелгәндә, кыямәт. Һәркем ашыга — тизрәк менеп җитәргә тырыша. Эстакадага күтәрелә барган саен, тачка авырлыгы артка этә. Ә арттагы тачкалар синең тез астына сугып-куалап киләләр. Аз гына йөрешеңне акрынайттыңмы, артыңдагы тачка тез астына килеп керә дә син тачкаң, грунтың белән түбән мәтәләсең. Ярый әле, тачка бер якка, син икенче якка тәгәрәсәң... Әнә безнең бригадада өч кеше эстакададан авып тачкалары астында да калдылар. Берсе башы изелеп шунда ук үлде. Икесе, аяк-куллары сынып, больницада ята.

Эстакада янында зур мәйдан — забой. Андагы эскәмиядә участок башлыгы утыра. Ул биектә. Бөтен забой аның күз алдында. Ул һәрбер тоткынның ничек эшләгәнен күреп, күзәтеп тора. Әгәр берәр мәхбүс ял итәргә утыра икән, эстакададагы рупор хәзер аны кузгата.

— Фәлән бригада! Штраф!

Димәк, бу бригада нормасына өстәмә рәвештә бункерга тагын ун тачка грунт җиткерергә тиеш! Шуның өчен бригада үзен үзе куалый, берәүгә дә эш вакытында, арыса да, авырса да, туктап торырга бирми — артык ун тачканы кемнең эстакадага күтәрәсе килә, бигрәк тә, смена соңыннан.

Участок башлыгы, бөкрәеп, авыр тачканы көчкә-көчкә эстакадага менгереп килгән тоткыннарны туктаусыз куалый:

— Әйдәгез, әйдәгез! Тизрәк!

Бу каһәр төшкән, «әйдәгез!» йоклаганда да колагымда зыңлап тора торган иде. Әле хәзер дә, берәр кеше ул сүзне кычкырып әйтсә, тетрәнеп китәм. Җан куркып калган, күрәсең.

Бункер астында улак-бутара. Аның ике ягында зур агач көрәкләр белән коралланган бутарачылар. Алар агым су белән этелеп-юылып алга китеп барган ком, балчык, таш кисәкләрен бертуктаусыз арлы-бирле бутап, туктатмыйча агызып торалар. Бункердан төшкән грунт су белән улак буенча агып, чайкалып, юылып бара да, бутара очындагы чүплеккә төшә, тау булып өелә бара.

Тәүлегенә ике тапкыр, көндезге сәгать уникедә һәм төнге уникедә, бирегә аерым бүлек вәкилләре килә. Бу безнең өчен иң кадерле минут-

лар. Вәкилләр бутаралар төбенә утырган алтынны бушата, ә без үлеп забойларга сузылабыз...

Сезонның беренче көннәре безнең бригада өчен ярыйсы ук уңышлы булды. Йомшак комга туры килдек. Һәрберебез норманы арттырып тутыра бардык. Төп алты йөз граммлы икмәк паегы өстенә өстәмә рәвештә Стаханов паегы — өч тапкыр ботка, йөзәр грамм ипи кыерчыгы һәм берәр әчмуха хуш исле махорка бирә башладылар.

Ләкин бу рәхәт көннәр озакка сузылмады. Инде икенче удар декаданы да югары күрсәткечләр белән тәгәллибез — Стаханов бригадасы исемен алабыз, беренче категория тәэминатка күчәбез, дип куанып йөргәндә генә безнең забой «яшел бакага» килеп терәлде.

Менә минем забой яшькелт бака кебек кабарып, күзәнәкләнеп ята. Бар көч белән басып көрәкне батырам да, кыйшайтып яшькелт балчыкны көрәп алмакчы булам. Ә ул күәс чиләгендәге камыр төсле сузылып күтәрелә, өзелми. Аптырагач, «баканың» күзәнәкле күзләренә ике аяклап басып, көрәкне суыра башлыйм — аяклар бата.

— Мадрид! — дип, ярдәмгә чакырам.

Күрше забойда эшләүче бригадир килеп кулдан тарта башлый.

— Я, я, бер кулың белән көрәккә таян.

— Хәзер... Әй, атаңа нәләт төшкере, ЧТЗлар кала бит...

— Калмагае тагын... Әйдә, атла!

Забойдан көч-хәл белән чыгып, тачка артына ышыкка утырабыз. Минем забой чокырда, эстакададагы «рупор»ның күзе төшәрлек түгел.

— Карале, синдә бераз урарлык юкмы? Миндә кичә үк бетте бит... эч поша. Бу бака безнең актык канны суыра инде,— ди авыр сулап Мадрид.

Бушлат кесәләремне кайтарып, кагып-сугып, чүп-чары белән ике «кәҗә сыйрагы» урыйбыз.

Забой нәкъ кырмыска оясы — берәүләр бөкрәеп казый, икенчеләр ашыгып, казылган грунтны тачкага тутыра, өченчеләр өеп тутырылган авыр тачка белән трапка — такта өстенә чыга, йөгерә. Ләкин бераз баруга тачка тәгәрмәче тактадан шуып забойга төшеп китә. Ул тачкасын күтәреп куя алмыйча азаплана. Әнә, ике тоткын тачкаларын ташлап, сугышырга тотынды, мөгаен, узып китәм дигәндә, тачкалары эләгешкән. Шау-шу. Сүгеш. Кычкырыш... Бу тавышларның барысын басып, эстакададан рупор акыра.

— Әйдә, әйдә!

Забой өстендә күгелҗем эңгер, көтү-көтү булып мыжылдап торган сукыр чебен. Ә кояш сопка артына төшеп бара. Бөтен офык кызыл ялкын эчендә. Нindидер бер куе кызыллык белән, шомлы бер шәүлә ташлап яна ул хәзер.

— Да... Испаниядә дә менә шулай янды...— ди күршем Мадрид, баеп барган офыкка карап.

Мин дә шул офыкка текәлеп уйланып утыра идем, сискәнеп борылдым.

Ул битлеген фуражкасына күтәргән дә, «кәҗә сыйрагын» авызына капкан килеш офыкка төбәлеп, хәрәкәтсез калган. Һәрвакыт мин аңа сокланып карыйм — матур кеше. Озынча буй, атлет гәүдә. Менә хәзер ул миңа кырын утыра. Аның профиле аеруча күзгә ташлана — туры борын, нык кысылган юка иреннәр. Түгәрәкләнеп чак кына алга чыккан ияк. Озынча битне ак төкләр баскан. Фуражка астыннан чал чәчләр күренә. Ә Мадрид миннән нибары биш яшькә генә олы бит. Аның чын исем-фамилиясе Максим Петрович Жаворонков. Максим Петрович — очучы. 1936 елда генерал Франко республикага каршы фетнә күтәргәч, ул үз теләге белән Испаниягә китә һәм интербригада составында сугыша. Максим башка совет очучылары белән берлектә Мадрид күген саклый. Ул бик күп тапкыр Долорес Ибаррури белән очрашкан. Һава сугышындагы батырлыклары өчен Испания республикасы ордены

һәм медальләре белән бүләкләнгән. Гвадалахара операциясендә фашист зениткасы аның самолетын яндыра. Максим Петрович парашют белән ташланып котыла. Әмма җиргә төшкәндә аягын сындыра, шуңа ул хәзер дә бераз аксап йөри. Испаниядән яраланып кайтып бер ел торгач аны шпион дип гаепләп, кулга алалар. Хәрби трибунал Максим Петровичны үлем җәзасына хөкем итә — ул бер ай үлем камерасында һәр минут саен үлем көтеп утыра. Верховный Совет Президиумы бу җәзаны унбиш ел төрмәгә алыштыра. Менә шул үлем камерасыннан чыкканда Максим Петровичның чәчләре ап-ак булып агарган була.

Максим Петровичның холкы салмак, һичбер вакыт кызып китми — сабырлыгы, акылы белән җиңә. Кайда булуын белеп алгач, аңа Мадрид кушаматы биргәннәр. Бөтен лагерь — тоткыннар да, ирекләләр дә аны Мадрид дип йөртә, чын исем-фамилиясен белүче, мөгаен, бик сирәк.

«Линкольн»нан бу Сусуман приискасына китергәч, мине өченче бригада чокырына урнаштырдылар да:

— Менә бригадир Мадрид,— дип таныштырдылар. Шул көннән без бер-беребезгә ияләшеп киттек.

«Кәҗә тәпиләребезне» рәхәтләнеп суырып та бетерә алмадык, «рупор» (күреп өлгергән бит, җаһил):

— Өченче бригада бригадиры Мадрид, эстакадага! — дип акырды.

Озакламый Мадрид забойга кайтты. Без барыбыз аның янына җыелып, тынып калдык.

— Иптәшләр,— диде ул акрын гына... Битен сырып алган черкиләрне сыпырды, битлеген төшерде. Аннан борчылып башын күтәрде.— Безне Крутушкага күчерделәр.

Сопка артына төшеп кояш баеды. Шунда ук көньяк кызарды. Таң ата башлады. Этләр өрә. Сүгенгән, боерык биргән тавышлар яңгырый. Нормасын тутырган бригадаларны зонага — ялга алып китәргә әзерләнәләр. Ә без, норманы тутырмаган бригада, Крутушкада тәүлек буе — норманы тутырганчы забойда калырга тиеш.

### III

Менә инде өченче тәүлек Крутушкада әйләнәбез. Көне-төне эшләсәк тә, көнлек норманы тутыра алмыйбыз. Куллар кабарып, канап бетте. Паек алты йөз граммнан дүрт йөзгә төште. Баланда да сыекланды. Менә бит ул каһәр төшкән «яшел бака» ничек канны суыра.

Кояш тагын гадәтенчә сопка артына төшеп, кызарып баеды. Көньякта инде алсуланып таң беленә. Нормасын тутырган бригадалар зонага ял итәргә, йокларга барырга җыена, ә без... Кинәт эстакададан тавыш:

— Өченче бригада, зонага!

Үз колагыма үзем ышанмыйм, саташаммы, дип бригадирга йөгердем:

— Карале, Мадрид, син дә ишеттеңме? Безне дә зонага җибәрәләрме? Чынмы?

Мадрид гадәттәгечә елмаеп забоеннан чыкты.

— Бригада, зонага! Җыелыгыз.

Зонага кайткач, безне ашханәгә алып бардылар. Стаханов сые белән сыйладылар, баракка кайткач берәр әчмуха махорка да бирделәр.

— Бу ни бу? Төшенмим,— дип Мадрид янынарак авыша төштем. Без аның белән бер сәкедә янәшә ятабыз.

— Шаулама!— ди ул пышылдап, аннан үрелеп колагыма гына әйтә:— Мәмәтуглы ике самородок тапкан, өч йөз граммнар чамасында. Шуны акрын гына участок башлыгына тәрткән,— ди.

Без шунда ук үлеп йоклап китәбез.

Дүртенче кичне зонага чакырмадылар. Тагын Крутушка башланды.

— Тагын төпчек эзләргә кирәк,— ди Мадрид.

Аны табып кара! Яшел бака, ләгънәт төшкере, аны тиз генә ычкындырмый. Тирән яшергән. Ә безнең куллар карарга чирканыч: кып-кызыл кан, чеп-чи яра.

Иллә мәзәк тә инде бу тоткын дигән халык. Үзе ач, үзе ялангач булуга карамастан, әллә нинди мәзәкләр уйлап таба, әллә нинди кызыклы кушаматлар уйлап чыгара. Әле менә хикәянең башында әйтеп узган, Колымага җиттем дигәндә, борылып икенче якка сузылган сопканың чат башындагы бераз аерыла төшеп күтәрелгән кыяны «Бәхет төенчеге» дип атаганнар. Яхшы төенчек, казакъ халкының киез өе кебек күтәрелгән тау! Менә шушы «төенчек» эчендә мин дә бәхет эзлим, аз-азлап ул бәхетне таба да барам, ахрысы. Бәхет төшенчәсе төрле шартларда төрлечә үзгәрәдер, күрәсең. Мәсәлән, менә бүген иң зур бәхет туйганчы ашау һәм кесәдә хуш исле махорка булу. Ә алар миндә бар. Миңа Стаханов сые бирәләр. Каян ул дисезме? Аны миңа менә шушы «Бәхет төенчеге» биреп тора әле.

Монда ничек килеп эләктемме? Теге «яшел бака»да инде бер атнадан артык азапланабыз — норма да юк, самородок та күренми. Бригада хәлдән тайды, көчкә йөрибез. Эстакададан рупор бертуктаусыз камчылый:

— Өченче бригада, тизрәк кыймылда!

Арысам да, соңгы көчемне җыеп, забой кырыен кырып, тачканы тутырып трапка чыктым. Мин алга омтылам, хәлсез аякларым артка китә, ә арттан тез астымны сөзеп, бастырып киләләр. Тагын рупор:

— Өченче бригада! Өченче бригада, кыймылда!

Ниһаять, эстакадага якынлаштым, инде соңгы борылышка күтәреләм дигәндә, әллә таеп киттем, әллә арттан этеп җибәрделәр, тачкам тәгәрмәче траптан чыкты, кыйшайды. Авып киттем.

Күземне ачсам — ниндидер ташландык бер забой. Торып китим, дип кузгалган идем, җаным чыгып киткәндәй кычкырып җибәрдем, сул янбашым кузгалырга бирми, хәлсезләнеп тагын яттым. Бит-күзне сукыр черки сырып алды. Кычытынуга, әрнегәнгә чыдап булмый. Өстерәлеп булса да үргә, җил якка чыктым. Черки таралды. Янбаш та әүвәлге кебек сызламый. Утырдым. Кайда мин? Артымда тау күтәрелгән. Бу бит бәхет төенчеге. Аны инде барлык ягыннан кимергәннәр, хәтта, әнә кояш чыгыш ягыннан эченә тишеп кергәннәр, әйтерсең лә Әбүгалисина яшәгән мәгарә. «Бу да бик җайлы забой. Әмма җимерелү куркынычы бар, дип япканнар. Эшләтмиләр», дигән иде бит Мадрид миңа беркөнне.

— Ах син, үләксә, инде монда постыңмы?

Башымны күтәрүгә коелып төштем — түрә!

— Бас аягыңа!

— Гражданин начальник,— көч-хәл белән тордым,— мин эстакададан егылдым.

— Анысын күрдем. Бәлки, син юри егылгансыңдыр?

— Тачка тәгәрмәче...

— Җитәр! Марш забойга!

— Гражданин начальник,— әллә кайдан телемә бу сорау төште,— монда, менә бу ташландык забойда эшләргә рөхсәт итегезче?

Участок башлыгы болай карауга усал күренсә дә, вакыт-вакыт йомшап китә торган гадәте бар иде. Минем соравым фәрештәнең «Амин!» дигән мизгеленә туры килде, ахры. Ул сүгенмәде, аз гына бөкрәя төшеп, күзләремә текәлде:

— Курыкмыйсыңмы?

— Башны югалткач чәч өчен елау файдасыз.

— Молодец!— диде начальник кинәт, көлгән сыман итеп авызын ерып. Мөгаен, бераз спирт төшереп алган.— Туры әйткән кешене яратам. Тик менә нәрсә, үз кулың белән гариза язып, баш инженерга илт. Алай-болай булса, безгә җавап бирерлек булмасын! Төшендеңме?

Икенче көнне баш инженер, минем гаризаның кырыена кызыл карандаш белән: «Үз үтенече буенча «Бәхет төенчеге»ндә эшләргә рөхсәт итәм»,— дип сырлап бирде. Мин шул көнне үк бу забойга күчтем.

Эстакададан егылгач, ничек «Бәхет төенчеге» янына килеп элгүемне бары тик икенче көнне генә белдем. Траптан егылганда өстемә тачка төшкән. Мин аңымны югалтканмын. Артымнан килгән безнең бригада тоткыннары Мәмәтуглы белән Василь Петренко мине култыклап тау итәгенә алып барып салганнар. Анда бит эстакада астындагы кебек су эчендә ятмыйсың, коры җир.

Миңа, казакъ илендә туып-үскән кешегә, бу яңа забой ошап китте. Ул, киез өй кебек, гөмбәзләнеп утыра. Эче дә киез өй кебек киң. Нәкъ түбәдә төнлек кебек, якты төшеп тора торган тишеге дә бар. Иң рәхәте — кайлә белән бер суксаң, бер тачка грунт ишелә дә төшә. Ташып кына өлгер. Бу сопка тулаем боз булып каткан ком тавы. Түбәдәге төнлекне япсаң, ком эчендә ялт-йолт килеп алтын ясмыклары яна.

Эшләрем майлаган арба кебек тәгәри. Казуы да җиңел. Бункер да якында гына. Төшкә хәтле норманы — йөз тачканы чыгарам да ашап алам. Ял иткәннән соң, тагын утыз-кырык тачка стахановча ташыйм. Башкалар исә әле һаман «яшел бака»дан чыга алмый. Иптәшләремә анда-санда үземнән арттырып икмәк, балык һәм махорка бирел торам.

Әле дә хәтеремдә, Колымада сирәк була торган кояшлы, җылы көннәрнең берсе иде. Мондый аяз көннәрдә үзеңне ничектер җиңел хис итәсең, эш тә әллә ни арытмый. Кояш күтәрелгәнче ярты норманы эшләп ташладым. Инде тагын бер рейс илтәм дә тәмәке тартырга утырам, дип тачканы куыштан ук йөгертеп чыгып килә идем — бригадир. Чак кына үзен бәреп екмадым. Ярый әле, ул тачканы ике кулы белән тотып, тераэ калды.

— Тукта!— Үзе башын чайкап көлә.— Кара бу ударникны, әллә инде мотор куйганнар үзеңә.

— Ә ничек уйлыйсың?— Тачкадан кулларымны ычкындырдым.— Стаханов паегы! Әйдә, югары чыгыйк. Нишләп болай бик иртә?

— Беләсеңме,— Мадрид тачка яныннан кысылып үтеп яныма килде дә кулын җилкәмә салды:— Беләсеңме, бездә сөенеч.

— Ничек? Нәрсә булды?

Аптырап калдым. Мадрид — балкып тора. Күзләре зур булып ачылган — зәңгәр чаткылар. Гадәттә тоныклы йөзендә хәзер — алсулык. Сакал-мыек кырылган. Иреннәрендә — елмаю. Бу ни булган? Беренче тапкыр мин аны шундый шат күрәм...

— Нинди сөенеч? Ни булды, әйт әле?!

— Хәзер...— Максим Петрович аксый төшеп куышка таба борылды, мине кулдан тартты.— Әйдә, мәгарәңә керик. Монда нәкъ «карга»ның күз алдында.

Мин тачканы кире куышка тартып керттем — күренеп тормасын. Бәрәрсе килеп тә житәр.

— Кара, монда салкынча икән, рәхәт.

— Я, сөйлә инде, нинди сөенеч китердең?

Ул тачка өстенә утырды. Мин аның каршына ком өстенә кырын яттым. Бу кадәр сузуына эчем поша башлады.

— Я, сузма инде.

— Беләсеңме нәрсә, миндә бүген ике сөенеч. Беренчесе — бер сәгать чамасында өч «төпчек» таптык.

— Әйе,— мин торып утырдым,— кемнәр тапты? Үлчәдегезме?

— Мәмәтуглы, Петренко, соңгысын, иң зурысын, яңа килгән комиссар Габдрахманов тапты. Бизмәнгә аскан идек, биш йөз граммлы паекны басып китте.

— Менә шәп... Димәк, ярты килодан артык. Инде кая куясыз аларны?

— Бригаданы җыеп шыпырт кына киңәштек. Мин дәүләт фондына бирергә тәкъдим иттем.

— Шуннан?

— Шуннан киңәштек. Гомумән, бригада самородокларын дәүләт фондына бирергә каршы түгел. Ничек әйтсәң дә бригадада барысы да элекке коммунистлар. Ләкин куркалар.

— Кемнән?

— Кемнән булсын, участок башлыгыннан. Мәмәтуглы әйтә, әгәр без яхшы забойда булып, норманы тутырып барсак, бер хәл иде. Ә бу «бака»-да инде ике декада норма тутыра алмыйбыз, әлегә теге вакыттагы «төпчек» саклап килә. Әгәр мондый зур калҗаны дәүләткә бирсәк, башлыкның җаны чыгачак. Ул шул көнне үк, үч итеп, алтынны аңа бирмәгән өчен, бригаданы трибуналга тапшырачак, ди. Үзең беләсең ич, былтыр беренче бригада ике йөз грамм булыр-булмас самородокны конвой командирына биргән өчен, «рупор» аларны, норманы тутыра баруларына карамастан, айдан артык штраф паегында тотты.

— Әй-йе... Ул аны эшли алыр.

— Мәмәтуглын башлыкка җибәрдек. Миңа барырга кушканнар иде,— Максим Петровичның йөзе караңгыланып, сул кабагы дерелдәп китте,— баш тарттым. Мин андый шкурниклар белән сөйләшә алмыйм. Алар дәүләтне түгел, үзләрен кайгырта.

— Анысы шулай инде. Я, ә бригада нинди «калым» сорый?

— Нинди булсын, бакадан коткаруны.

Башка забойга күчерсә, анда без үз көнебезне үзебез күрә алабыз.

— Алтын күрсә, фәрештә аза, диләр бездә.

— Ә безнең начальник күптән азган... Бәлкем бригаданың күзе ачылыр. Ә икенче сөенеч?

Максим Петрович җавап бирмәде — тачка өстеннән торып, куыш буенча арлы-бирле йөри башлады.

Гадәттә, болытлы көннәрдә бу куышта караңгы, күз ияләнгәнче тачканы да күреп булмый иде. Ә бүген төнлектән, әйтерсең лә, алтын багана сузганнар. Тирә-як яп-якты булып тора. Ә багана эчендә янып торган тузан, черки, чебен... Максим Петрович арлы-бирле үткәндә багана сүнә, аннан тагын кабынып китә... Аның йөзе тагын яктырды.

— Икенчесе нинди сөенеч дисеңме?— Ул гаҗәеп бер ихлас күңеллелек белән елмайды, каршыма утырды:— Зур сөенеч. Бүген кызым Дилорис төшемә керде. Муенымнан кочаклаган да, әти, нигә мине тәбрикләмисең, миңа бит бүген дүрт яшь тулды, ди. Уянып киттем. Чыннан да бүген аның туган көне бит,— ул авыр итеп көрсенде. Аның әле генә яктырып-сөенеп янган күзләрендә яшь тамчылары. Авыр көрсенү.— Мине кулга алганда аңа әле бер ай да юк иде...— Тынлык. Һәм кинәт сызланып чыккан йөрәк тавышы:— Я алла, кайда ул хаклык?!!

Мин сискәнеп артка чигендем. Максим Петрович акылдан язган кеше кебек сикереп торып, забойның почмагына барып капланды да үксеп елый башлады.

Мин нишләргә белми аптырап калдым.

Бераздан ул аңына килгәндәй булды, куллары белән күзләрен уды, акрын атлап, аксап, тачка өстенә килеп утырды.

— Гафу ит, үз гомеремдә беренче тапкыр...— ул почмакка текәлеп уйга калды. Фуражкасы җирдә ауный. Тырпаеп торган чал чәчләре, утыз биш яшьтәге ирнең чәчләре җем-җем итә.— Яздым,— кинәт Максим Петрович миңа таба борылды: күзләр кызарган, ачу-нәфрәт белән тулган,— Верховный Советка яздым. Сталинга яздым — тикшерегез: мин дошманмы, юкмы? Мин шахтер баласы. Атам каторгада үлгән. Үзем, үз теләгем белән Испаниягә киттем, Республика өчен сугыштым, чак кына үлемнән калдым. Я әйт әле, син дә совет кешесе, язучы бит. Мин совет халкының дошманы була аламмы соң?

Нәрсә диим? Мин үзем дә шундыйларның берсе. Икебез дә башларыбызны идек.

— Беләсеңме нәрсә, дус,— Максим Петрович минем янга, забойга

күчеп утырды, инде ашыкмыйча, үз-үзенә әйткән сыман салмак кына сөйли башлады.— Верховный Совет та, Сталин да минем гаризаларга җавап бирмәде. Белмим, бәлкем аларга барып җитмәгәндер хатларым. Инде беләсеңме, кемгә язарга уйлыйм. Дугласка!

— Дугласка?— Мин аптырап калдым.— Ничек? Америка киноартисты Фербенксскамы?

— Кара әле, мин сиңа генерал Дуглас турында сөйләмәдеммени?

— Юк, беренче тапкыр ишетәм андый генерал турында. Кем соң ул, американмы?

— Юк ла, үзебезнең совет кешесе. Дуглас — кушамат, чыны Яков Владимирович Смушкевич[1]. Авиация генерал-лейтенанты, Советлар Союзы Герое.

— Һаман төшенмим, нигә Дуглас?

— 1936 елда генерал Франко Испания республикасына каршы фетнә күтәргәч, бик күп совет кешеләре үз теләкләре белән Испаниягә барып интербригада оештырдылар. Ә генерал Смушкевич анда хәрби авиация министрлыгында баш киңәшче була. Үзе турыдан-туры сугышларда катнаша һәм җитәкчелек итә. Мин дә аның кул астында, интербригада составында сугыштым. Мадрид янында без Муссолининың атаклы «Кара ялкын», «Алла көче» һәм «Кара каурыйлар» дивизияләрен тармар иттек. Бу операциядәге батырлыгым өчен генерал Дуглас үзе саф алдында мине алтын сәгать белән бүләкләгән иде...— ул сүзен бүлеп почмакка таба атлады һәм борылып килде.— Кара әле, тәмәкең бармы? Миндә бетте, күп тарттым, ахрысы, бүген.

Мин тәмәке янчыгымны чыгарып тачка өстенә куйдым. Ул кесәсеннән, бик пөхтә итеп, өчпочмаклап киселгән кәгазь чыгарды. Икебез дә сүзсез генә «кәҗә сыйраклары» урадык.

— Я, ярый, мин учакка барып кабызып килим. (Тоткынга шырпы йөртү рөхсәт ителми).

— Мадрид!— дидем мин.— Беренчедән, синең аягың авырта. Икенчедән, син минем кунак, өченчедән — мин яшьрәк. Үзем генә йөгерим...

Ул елмайды.

— Алайса бар, йөгер... Мин чынлап та арып торам... Аннан соң бригадир кешегә учактан учакка йөгерү килешмәс.

Мин куышның ишегенә — тишеккә таба атладым.

— Тизрәк, үлеп тартасым килә. Аннан Гвадалахара операциясе турында, Дугласның батырлыклары турында сөйләрмен.

— Хәзер.

Куыштан чыгып Колыма яры буенда төтенләп торган учакка таба йөгердем. Кинәт артымнан нәрсәдер кыштырдаган, төшкән төсле булды. Туктап, борылдым. Эчем җу итеп китте. Пәрәгем тибүдән туктады кебек. Катып калдым. «Бәхет төенчеге» ярылып, ишелеп төшеп килә.

— Мад-рид!..

Җан тавышым белән кычкырып җибәрдем. Ләкин минем тавыш барып җиткәнче, куышның ишеге ишелеп ябылды.

## Кара сакаллы кеше

### I

— Ха-ха-ха!

— Ха-ха-ха!

Сискәнеп, куркып уяндым. Бу нинди тавыш? Чыннан да көлаләрме?

---

[1] Нәкъ менә шушы көннәрдә, Бөек Ватан сугышы башланудан ике атна гына элек, Яков Владимирович Смушкевич — СССР Хәрби-һава Флоты башлыгы кулга алына һәм «халык дошманы» дигән яла белән атып үтерелә.

Әллә! Әллә инде акылдан шашалар? Колыма лагерьларында инде дүрт ел йөреп, беркайчан да болай тавышланып көлүне ишеткәнем булмады иң. Җитмәсә, бу бит әле санбаракта — җыен авырулар арасында? Гаҗәп! Күзләрем ачылыр-ачылмас шул сәер тавыш килгән якка борыла башлаган идем, сыным катты — әле генә (инде ике тапкыр) киселгән сул аягым тагын да чатнап сынгандай булды — аңымны югалттым.

— Ха-ха-ха!

Колакта һаман шул ук сәер тавышлар. Ниһаять, тагын күзләремне ачтым. Маңгайда бөрчек-бөрчек салкын тир! Инде, чүпрәк белән уралган, сулкылдап-чәнчеп бәгырьне телгәләп торган сул аякны кузгатмыйча гына, башымны тавыш килгән якка борып, барак эченә күз ташладым. Чыпта түшәлгән ике катлы сәке-сәндерәләр. Ярымкараңгы озын барак. Каршы як стенадагы ике тәрәзәнең рамнары да күренми, бозланып каткан, хәтта тәрәзә яңакларын кар сарган. Күрәсең, тышта тагын буран-җил ыжгыра. Барак вакыт-вакыт селкенеп куя, менә-менә очып китәр сыман. Уртадагы тимер мич сүнгән, санитарлар бүген утынга бармаган. Суык. Җил тәрәзәгә килеп сугылуга, рамнар дерелдәп, болай да күшеккән тәнне сискәндерде. Менә шушы инде ул Линкольн алтын приискасындагы тоткыннарның җан саклау урыны — санбарак. Суык һәм шомлы. Әмма нигә соң авырулар барысы торып утырганнар да миңа таба караганнар? Барысының да авызы ерылган, әйтерсең, өстемә бер чүмеч ботка чәпегәннәр.

Тагын сискәнеп, калтыранып киттем — зур бер куык шартлагандай булды.

— Ха-ха-ха!

Нәкъ минем каршыдагы сәкедә яткан башкорт егете Фәнун торып утырган да бөгелә-бөгелә көлә, терсәктән киселгән чулак куллары бер күтәрелеп, бер төшеп, буш калган күлмәк җиңнәрен арлы-бирле җилфердәтә, әйтерсең лә, ак әтәч киртәгә менеп канатларын кага. Уң ягымда яткан, ике аягы да бот төбеннән киселгән белорус Гриша — бригадир, мендәренә капланып ук яткан, җилкәсе сикереп-сикереп китә. Бу ни хәл? Нәрсә булган соң боларга?

Ул арада шау-шу, пырхылдау акрынлап басыла төште.

— Әйе... шуннан, — Фәнун чулак куллары белән күзләрен уып, яшьләрен сөрткәләп, кемгәдер сорау бирде.— теге егет нишли?

— Җитәр, шауламагыз,— өстән берәү җикеренеп куйды,— кешегә сөйләргә бирегез, каргалар!

Кемгә эндәшә соң ул? Кемне сөйләргә чакыра? Башымны сул якка бордым да имәнеп киттем,— бу кем тагын? Күршем Герман кайда? Аның урынында бөтен битен кара сакал баскан, тузган кара чәчле таныш түгел ниндидер бер ят кеше ята. Өстенә одеал да ябынмаган, күлмәкыштаннан гына. Ачык күлмәк изүеннән кара йон белән капланган киңкалку күкрәк күренә. Гәүдәсе тулы, гадәти тоткынга охшамый, кипкән балык түгел. Үзе одеал өстенә аякларын бөкләп, көнчыгыш халыкларына хас иркенлек белән утырган. Куллары исән-сау. Аяклары исән-сау! Гаҗәп! Җыен гарип арасына нишләп килеп кергән? Эчем жу итеп китте — «мөгаен, чагучы!» Юри, ни сөйләрләр икән дип, безнең арага ташлаганнардыр. Телне теш артында тотарга кирәк бу хаин янында! Кара, мәлгунь, мәхбүсләрне сатып ничек симергән!

— Шуннан...— теге карасакал, алдында яткан мендәрне изеп-бөкләп терсәк астына салды да, ярым кыйшаеп ятып, миңа аркасы белән әйләнеп, сүзен ялгады. Тавыш көр, яңгырау. Ниндидер чит милләт акценты ишетелеп кала. Ашыкмый, белеп, вәкарь белән, һәрбер сүзен әйтеп бетереп, мавыгып сөйли,— шуннан... Шаһзадә камыш арасыннан үрмәләп, күренмичә генә, яр читенә килә дә, күлдә коенып йөргән теге пәри кызларының күлмәкләрен урлап алып, кире камыш арасына яшерена.

— Вот, егет! — Гриша мендәреннән күтәрелеп, шуышып, сәке кы-

рыенарак килеп утырды,— булдырган, шулай кирәк.

— Бүлдермә әле, нәкъ кызык җирендә!

— Шуннан...— Карасакал бу шау-шуга — сүз атышуга бөтенләй игътибар бирмичә, хикәясен дәвам итте.— Коенып, су чәчрәтеп уйнап аргач, пәри кызлары күлдән чыгып күлмәкләрен калдырган җиргә — камышлык янына йөгерәләр.

— Ә күлмәкләрдән җилләр искән, ә?

— Гриша, бүлдермә әле!

— Их,— Гриша койрыгы өстендә әйләнә,— их, күңел түзми егетләр, кызлар искә төшкәч... Ярый, бетте, сөйләгез.

Тукта, мондый әкиятне кайда ишеттем соң мин? Юк, ишетмәдем, укыдым. Бу мәшһүр «Әлфе ләйлә вә ләйлә» («Мең дә бер кичә») китабындагы гүзәл әкиятләрнең берсе түгелме? Әйе, нәкъ үзе. Кара бу шомны, үзе «чагучы» булса да, кызыктырып сөйли. Тыңларга кирәк. Мин дә карасакалга таба шуыштым. Аяк сызласа да, баягыдай чатнамый әле.

— Шуннан, кызлар чыр-чу килеп, шаулашып күлмәкләрен эзли башлыйлар. Анда йөгерәләр — юк! Монда йөгерәләр — юк. Гриша әйтмешли, күлмәкләрдән җилләр искән.

— Менә, минем сүз дә ярап куйды...

— Әй, бер кыстыбый инде син, Григорий,— Фәнун чынлап рәнжеде,— сөйләргә бир әле...

— Ә, мин нәрсә?

— Шуннан,— теге көр тавыш шау-шуны җиңде,— күлмәкләр табылмагач, кызларның кайберләре елый да башлый. «Җитәр, эзләмәгез дә, еламагыз да!»— ди пәри патшасы кызы Шәмсебану һәм үзе йөгереп кире күлгә керә. Башка кызлар да аңа ияреләр. Шәмсебану су эченә кереп башын гына өстә калдыра да кисәтә: «Тәнегезне күрсәтмәгез, судан чыкмагыз, монда адәм исе килә. Сак булыгыз!» Кызлар, үзе янына җыелып беткәч, Шәмсебану ярга таба борылып, ачулы тавыш белән кычкыра: «Әй син, кызлар күлмәген урлаучы оятсыз адәм, чык монда! Күрен! Я, күрик үзеңне, тагын нәрсәгә хәлең җитә икән, мескен адәм баласы!» Оятыннан җиргә сеңеп китәрдәй булган Шаһзадә яшеренгән җиреннән чыгып, яр читендәге таш өстенә күлмәкләрне куя һәм Шәмсебануны баш иеп сәламли дә сөйли башлый: «Җиһанның гөле, галәмнең тулган ае, еллар буенча илдән ил гизеп эзләгән бәхетем, гүзәл Шәмсебану! Мин һич карак түгел. Мин бишек чүлендә ялгыз калып, әлсерәгән гашыйк бичара. Коткар мине бу җәфалардан, ханым-солтаным!

Айның ундүртенче кичәсе кебек балкыган Шаһзадә йөзен күргәч, кызлар телсез кала. Шәмсебану да горур-тәкәббер башын түбән ия һәм: «Мин җиңелдем»,— ди. Аннан кыюсыз гына: «Сез ир кеше, шәрә тәнле кызларның киенүләрен карап тормагыз, алар оялa»,— ди. Шаһзадә кире камыш арасына кереп китә. Биш кыз үз күлмәкләрен киеп аккошка әверелә. Ә алтынчысы — Шәмсебану күлмәксез. Таш өстендә аның гына күлмәге юк. Шәмсебану: «Күлмәгемне бирегезче», дип елый-елый ялварса да, Шаһзадә аның күлмәген бирми.

— Дөрес эшли, егет,— ди түземе беткән Гриша.

Ишек шыгырдап, чинап ачылды, ургылып кар бураны керде. Бераздан томан эченнән сырган бушлат өстеннән ак халат кигән санитар Тимка-Кадак күренде һәм, гадәтенчә, шундук кычкыра-җикеренә башлады:

— Бу нинди башбаштаклык! Ятыгыз. Обход!— ул өч-дүрт катлы лагерь сүгенүләре белән үзенең караклар өеренннән булуын исбат итеп, түбәнге сәкедә утырган әле бер, әле икенче авыруны этеп-төртеп, кызганнан-кыза барды.— Контрлар, әле монда да корткычлык эшлисезме? М-мин,— ачуыннан тотлыга да башлады,— м-м-мин ссс-езне акылга өйрәтермен... Карцерга!

Әмма ул, ахырынача җикеренеп, авыруларның котын алып өлгермәде — ишек шыгырдады. Барак тагын ак томанга тулды. Тимка, кемгә

дер йодрыгы белән янап, «Тизрәк!» дип акырды да үзе шунда ук сәке кырыена басып үрә катты.

Ишектән, өс-башларын кага-суга, тирә-якка кар-боз чәчрәтеп, ике кеше керде. Алдагысы ак якалы, билле озын туннан, үзе мичкә сыман юан. Ул колакчын бүреген салып, селеккәләп, буранда кунган карны авырулар өстенә чәчте дә кире киде, кесәсеннән яулык чыгарып битен сөртә башлады. Үзе кып-кызыл, әйтерсең, яңа гына мунчадан чыккан. Аның артындагы йонлач постау пальтолы, кара бәрән тиресеннән тегелгән папаха кигән озын, чандыр ир күзлеген салып сөртергә кереште. Калын кара кашлар астында ачуташ күзләр, зур борын, кабарып торган кара мыеклар.

— Гражданин начальник, санбаракта житмеш сигез авыру. Барысы да ята. Бүген өч мәет чыкты! Мин...

— Юләр!— Түрә аның рапорт биреп бетерүен дә көтмәде, ачулы тавыш белән бүлде һәм артында торган күзлеклегә жилкә аша гына эндәште:— Өч тәүлек карцер. Яз! Рапорт та бирә белми.

Әле генә бөтен баракның котын алып йөргән Тимка изрәп төште.

Түрә, аңа игътибар да бирмичә, башын югары күтәреп, күкрәген булдыра алганчы калкытып, акайган хәрәкәтсез күзләре белән авыруларны чәнчеп, баракны әйләнеп чыкты да теге сыны катып басып торган санитар Тимка янына якынлашып туктады; күзлеклегә борылды.

— Бу әрәмтамаклар монда күпме инде хөкүмәт акчасын ашап ята? Забойда эш тукталып тора, доктор, ә?

— Гражданин начальник, болар бит авариядән соң... Аяк-кулсызлар...

— Алай булгач, алардан ни файда?

Врач аптырап жавапсыз калды. Начальник һаман шул ачулы кыяфәт белән арлы-бирле атлады да кинәт минем яндагы, теге кара сакаллы кешегә текәлде, кычкырып жибәрде:

— Ә, Стоянов әфәнде! Нәрсә, син дә монда аунарга килдеңме?

— Юк, гражданин начальник,— күршем торып утырды,— аягыма агач төшеп, яраланган идем.

— Менә... ходай сине каргаган,— начальник, бөтен баракны гажәпләндереп, кычкырып көлде.— Син саран... саран... шуның өчен алла аягыңа суккан, шулаймы, доктор?

— Бик дөрес,— диде артта торган врач нигәдер иелә төшеп.

— Менә... менә... Ишеттеңме, Стоянов! Инде аягыңа баскач алай саранланма.

Күршем Стоянов калтыранып китте. Түрә кинәт башын күтәреп өске сәкегә күз йөртте дә әле һаман катып-басып торган Тимкага борылды:

— Ә, бу ябалак нигә башыннан уранган? Башлыкларны яратмыймы?

Тимка-Кадак сикертмәгә баскандай, сикереп өске сәкегә күтәрелде дә теге авыруның одеалын йолкып алды.

— Тор!— Шундук ап-ак булып кире сикереп төште.— Гражданин начальник, ул инде «каткан».

— Юләр, хәзер үк моргка алып барыгыз. Начальник килмәсә, мәетләрне күрүче дә юк. Бу юләргә тагын ике тәүлек карцер өстә. Калганнарның паегын кыскартырга кирәк. Тизрәк забойга чыгарлар.

## II

Колонна башлыгының санбаракка обход ясау миссиясе икенче көнне үк үзен сиздерде: гадәттә, авыруларга бирелә торган биш йөз граммлы паек дүрт йөз граммга калды. Болай да тамак туймый иде. Ә хәзер? Менә кеп-кечкенә, чиле-пешле арыш ипиен, кош тоткан сыман кысып

торам, кулымны җәйсәм, очып китәр сыман. Чыннан да, бу кыерчыкны авызга якын гына китереп кара, хәзер юк булачак — ачлык түземне белми. Ә аннан егерме дүрт сәгать авызыңны шүрлектә тот.

Ул арада шыгырдап-чинап ишек ачылды да Тимка һәм тагын бер санитар носилка күтәреп керде. Тимканың сөреме коелган, күтәрелеп тә карамый, кичәгедәй җикеренеп кычкырмый да, мөгаен, карцерда йоклап чыккан. Хәзер минә мәетләрне алырга килгән. Тагын кемгә чират? Ишектән кергән суык белән әүвәле бер нәрсә дә күренмәде. Бераздан томан таралды, югары сәндерәдән берәүне өстерәп төшереп носилкага салдылар. Ике ел бер забойда, алмаш-тилмәш бер перфораторда эшләгән дус Морозны алып киттеләр.

Ул минем кордаш иде. Кулга алынганчы Минскида республика комсомол газетасында әдәби хезмәткәр булып эшләгән. Шигырьләр язган... Икебез дә бер забойда ишелгән җир астында калдык. Икебезгә дә бер көнне ампутация ясадылар — минем сул аякны тубыктан кистеләр. Морозның уң аягын — балтырдан. Әмма икенче көнне үк икебездә дә гангрена башланды. Өченче көнне Морозга яңадан ампутация ясап, аягын бот төбеннән кискәннәр иде... Ә мине нинди язмыш көтә? Нәкъ шушы шомлы уйлар белән газапланганда киселгән бот төбем сикереп-сикереп китә. Гүя аякка берьюлы йөзләгән инә кадыйлар.

Гадәттә, Колымада алтын ачык җирдә — прискаларда казыла, шахталар бик сирәк. Кырыгынчы елларда анда нибары ике-өч шахтада гына алтын казыйлар иде.

Гомумән, Колыма шартларында шахтада эшләү тоткын өчен ярты бәхет. Чөнки монда, яз башлану белән кара болыт булып сарылып мәхбүснең җанын өтә торган — соңгы канын эчеп-агулап күбендерә торган комсыз кара чебен-черки юк! Кышын сөякләрне өшетә торган зәмһәрир суыклар тирән забойга хәтле барып җитә алмый. Монда — ышык! Өстә-венә, канга тоз салып, миеңне әйләндереп, туктаусыз «әйдә, селкен!» дип кычкырып торучылар да юк!

Миңа менә шул бәхет көтмәгәндә насыйп булды. Бер төнне йоклап яткан җирдән торгыздылар да безнең бригаданы тулаем машинага утыртып Линкольн прискасыннан Индигарка буйлап алып киттеләр. Кая? Белмибез. Ниһаять, иртә белән машинабыз бер тау итәгенә килеп туктады.

Бу шахта тыштан борын заманда кыргый кешеләр яшәгән мәгарәләргә охшый. Монда, гомумән, материктагы кебек вертикаль түгел, ә горизонталь шахталар. Артык биек булмаган ялангач-соры сопкалар итәгеннән эчкә таба тишеп-казып кергәннәр дә, бераз баргач, уңга-сулга борылганнар. Штреклар. Штрекның туктаган җирендә — лава. Димәк, нәкъ менә шушында инде алтын тамырлары.

Лава — ындыр табагы. Монда көне-төне перфораторлар гөрелдәве, кәйләләр чыңы, вагонеткалар чинавы, сүгенү, тузан-туфрак һәм ара-тирә җыр. Туган илне, еракта калган мәхәббәтне сагыну җырлары яңгырый монда. Өстә — забойда җырлап кара, хәзер карцерга юл тотарсың. Ә монда кем ишетә моңаюыңны.

Билгеле, монда өстәге эштән җиңел түгел, киресенчә, авыр, уңайсыз. Лавалар биек түгел, алтын «тамырларының» катламына хас бер күтәрелә, бер төшә. Гомумән, басып түгел, бөкрәеп йөрергә, бөкрәеп эшләргә туры килә.

Һәр лавада — егерме-утыз кешеле бер бригада. Аның бер төркеме перфораторлар белән катламнарны тишә. Шурф ясый. Шартлатучылар килеп, ул шурфларга запал-амонал сала һәм бикфорд шнурлары белән тоташтырып шартлата. Икенче төркем шушы ишелгән токымны — алтын комын вагонеткаларга тутыра, өченче төркем вагонеткаларга җигелеп, комны өскә чыгара, бутаралардагы бункерларга аудара. Менә шулай унҗиде-унсигез сәгать һәр көн — ай буенча, ел буенча, җаза вакытың тулганчы.

Колымада агачка кытлык! Шуның өчен монда штрекларда да, лавада

да терәүләр сирәк, «тушәм»нәр, менә-менә ишелеп төшәм дип, калтыраныл кына тора. Ләкин аңа игътибар иткән кеше юк...

Мороз безнең бригадага былтыр, көзге юл белән Магаданнан килде. Озын буйлы, чандыр, аксыл чырайлы егет. Ялкауланмый, кайда эш авыр — шунда үрелә. Ял вакытында ул сузып, онытылып белорус җырларын җырлый. Тавышы көр, моңлы. Менә шул сыйфатлары белән ул тиз арада бригадада «үз кеше» булып китте. Ә миңа бигрәк тә. Чөнки ул да, минем кебек, шигырьләр ярата, укый, яза. Мин атаклы украин шагыйре Тарас Шевченконың шигырьләрен бары тик русча тәрҗемәләре аша гына белә идем. Ә үз телендә ул бигрәк тә көчле, аһәңле яңгырый икән. Морозның анасы украин,— шунлыктан егет ике телне дә яхшы белә. Минемчә, ул Шевченко шигырьләрен укымый, шагыйрьнең үзе булып ялкынланып яна иде. Ул да, минем кебек үк, өйләнергә өлгермәгән. Сөйгән кызы Люба Минскида калган — университетта укый. «Их... бер генә тапкыр аның төпсез зәңгәр күзләрен күрсәм, алсу иреннәреннән үпсәм, үлсәм дә үкенмәс идем», ди торган иде ул без икәү калганда уфтанып.

Менә хәзер шул дус егетне салкын алачыкка чыгарып ташладылар. Ә ерак Минскида студентка Люба һаман әле Мороз Петяны көтә булыр.

Гадәттә, күрше лаваларда шартлаулар башланыр алдыннан шахтадан берәүне дә калдырмый чыгаралар иде. Каты шартлау-селкенүдән башка лаваларның да ишелүе мөмкин.

Ә менә теге фаҗигале иртәдә, шахта башлыгы үзе килеп, инде шартлау алдыннан тышка чыгарылган бригадаларны кире — лавага куды.

— План тулмый, алар монда бот күтәреп яталар. Хәзер үк лавага! Бүген эшне тикшерергә комиссия киләчәк.

Без үзебезнең лавага төшеп эшкә тотындык. Мороз перфоратор белән шурф тишә. Мин лавада яткан токымны вагонеткага тутырам. Башкалар кәйлә, көрәк белән казый, көри, тишәләр. Мин вагонеткамны тау токымы белән тутырып бетереп, инде этеп тышка чыгарырга гына керешкән идем, күрше лавадагы шурфлар шартлый башлады. Лава селкенде, ком коелды һәм баш өстендә асылынып торган лампочка «лып» итеп сүнде. Шунда ук аркама, аягыма ниндидер авыр нәрсә ишелергә тотынды, мин егылып аңымны югалттым.

Күзләремне ачуга сискәнеп киттем: ап-якты. Ниндидер сәке өстендә ятам. Кайда мин? Кем китергән? Торып карыйм әле дип кузгала гына башлаган идем, сул аягым, ток суккандай, дерелдәп тартылды, авыртуга чыдый алмый, ыңгырашып күзләремне йомдым.

Яңагыма суккалаганга уянып киттем, каршымда ак халат кигән ике таныш түгел кеше басып тора.

— Бусы әле тере,— диде күзлеклесе, һәм шунда ук икесе дә каядыр юк булдылар.

Ыңгырашкан, кычкырган тавышлар. Ак халатлы кешеләр носилка күтәреп үттеләр. Менә шунда гына үземнең кайда ятканымны төшендем.

Минем хәл артык хәвефле түгел икән, сул аягымның бармаклары изелгән һәм уң кулым бераз яраланган.

Бригада егерме җиде кешедән иде, баракка нибары тугыз кешене китергәннәр. Башкалар ишелгән җир астында күмелеп калган. Әле казыйлар, ди. Бәлкем, тере калганнар да бардыр, кем белә. Була күрсен.

## III

— Күрше, күрше, хәлең ничек? Нигә башыңны күтәрмисең? — Янымдагы карасакал телемне ачарга маташа. Минем хәл белән кызыксына! Беләм мин сезнең халыкны, лагерьда беренче ел түгел. Сез шулай йомшак җәеп, каты утыртасыз. Чагучылар барысы да менә шулай пышылдый, елан

булып янына үреләә. Тукта, менә аягым гына язылсын, синең хаин җаныңны борыныңнан чыгарырмын. Мәхбусләрне сатып ничек симергән, бакамыни, рәтләп борыла да алмый. Әнә бит, кичә түрә үзен әллә кайдан таныды. Әле фамилиясен дә белә. Стоянов, ди. Мөгаен, Болгариядән җибәрелгән шпион, инде безнең хисапка тиресен саклап калырга тырыша.

— Сезнең ашыйсыгыз килмиме?

Кара, адәм актыгы, кай яктан суга. Күрәсең, паекны әйләндереп-әйләндереп каравымны күзәтеп торган. Ачуыма чыдый алмадым. «Юк!» дидем дә борылып яттым. Ачу ташудан аякның авыртуын онытып сузып җибәргәнмен — балта белән чаптылармыни. Сыным катты — тешләремне шыгырдатып-сызланып ыңгыраштым.

— Сезгә кайчан ампутация ясадылар?

Менә бит, һаман канга тоз сала — минем аякта аның ни эше бар?

— Нәрсә, мәетләр әрдәнәсенә өяргә ашыгасыңмы?

— Киресенчә,— диде теге, тигәнәк булып кадалып,— гангрена башланмаганмы, дип хафаланам.

— Булса? Синең ни эшең? Әнә Морозны алып чыгып киттеләр ич, нигә туктатмадың?

— Әйе... — ул авыр итеп көрсенде,— соңга калдым. Булыша алмадым... Ягез әле, аягыгызны күрсәтегез. Карыйм әле.

— Сез кем, врачмы?

— Хирург.

Күрше үзе миңа шуышып килеп утырып, культяны чорнаган бинтны сүтә башлаган иде, авыр ис борынга сукты. Ә аягым киселгән җирендә кара янган.

— Гангрена!

— Нишләргә соң?

— Хәзер үк ампутация ясарга! Хәзер үк! Булмаса, гангрена бик тиз күтәреләчәк.

— Инде бит ике тапкыр ампутация эшләделәр.

— Наркоз беләнме?

— Хлороформ юк, диде баш врач. Наркозсыз гына кистеләр.

— Кабахәт!— күршем кызарып-бүртенеп китте, чынлап ачуланган сыман кылана.— Менә, ике көндә алты кешене моргка чыгардылар. Барысы да ампутациядән соң гангрена белән.

Үз аягымнан килгән искә үзем чыдый алмыйм — күңелем болгана. Җитмәсә, сулкылдап сызлый.

Менә сиңа кирәк булса. Инде нишләргә? Бер кистеләр. Ике кистеләр. Инде өченче киссәләр? Аннан — бот төбеннән. Ә аннан соң? Тәнем чымырдап китте... Күршем Георгий (карасакалның исеме шулай икән), үзен врач дигәч, бераз йомшара төштем. Кем белә, өметсез шайтан, ди бит борынгылар. Барак очындагы фанера белән бүленгән бүлмәдән — медпункттан бер аяк белән сикергәләп барып йод, марля алып килде,культяны йод белән майлап, чиста марля белән яңадан урады. Кара, үзенең кулы йомшак. Марля уравы да теләсә ничек түгел — беренче тапкыр бәйләмәве күренеп тора. Әллә чыннан да врач микән бу карасакал, ә?

## IV

Без төн буе йокламыйча сөйләшеп чыктык. Шул әңгәмәдә мин күршем турында менә нәрсәләр белдем.

Кара сакаллы тоткын — Георгий Стоянов Болгариянең Казанлы өязендә туып үскән икән. Софиядәге медицина институтының хирургия факультетын бетереп төрле шәһәрләрдә, больницаларда врач булып эшли һәм шул елларда Георгий Димитров оештырган яшерен оешмага — коммунистлар партиясе сафларына керә һәм яшьләр арасында монархиягә каршы көрәш алып бара, берничә тапкыр кулга алына, төрмәләрдә дә

утыра һәм ахырында Болгариядән китәргә мәҗбүр була — Германиягә чыга.

Белгәнебезчә, 1934 елда хөкүмәт башына Гитлер килгәч, коммунистларга террор уздыру нияте белән, рейхстаг бинасына ут төрттерә, янгын чыгуны коммунистларга сылтый, Георгий Димитровны һәм аның юлдашларын гаепли. Шушы эш буенча Стоянов та кулга алынган була. Георгий Димитровның ныклыгы, батырлыгы, эзлеклелеге, оста оратор булуы җиңү китерә. Димитровчылар азат ителә һәм Советлар Союзына чыгарып җибәрелә.

Стоянов соңгы елларда Мәскәү больницаларының берсендә хирург булып хезмәт итә. Ә менә 1937 елның башында аны кулга алалар һәм, шпионлык итүдә гаепләп, ун ел төрмәгә хөкем итәләр.

— Менә шулай итеп, мин Колымага килеп чыктым һәм Томанлы прискасында больницада баш врач булып эшләдем.

— Ә монда, Линкольн больницасына ничек килеп эләктегез соң?

— Ишеттегезме, кичә колонна башлыгы мине түрәләргә хөрмәт күрсәтмәүдә, саранлыкта гаепләде.

— Әйе-әйе. Үзем дә сездән сорыйм дигән идем әле. Ул сезне нинди саранлыкта гаепләде соң?

— Спирт аз биргән өчен.

— Спирт? Төшенмим. Нинди спиртны?

— Иң таза, туксан алты градуслыны.

— Төшенмим.

— Нигә төшенмәскә, бер генә операция дә, укол да спиртсыз-дезинфекциясез башкарылмый. Шуның өчен больницада һәрвакыт таза спирт була. Томанлы түрәләре дә кичләрен миңа «авыз чылатырга» килә башлады. Башта мин, яңа кеше буларак, тешне кысып аз-маз койгаладым. Тора-бара алар һәр көн һәм күбәүләп керә башладылар. Ләкин спиртны миңа Магадан больницасыннан норма белән генә җибәрәләр. Бигрәк тә теңкәгә тигәне каравыл башлыгы Волков булды. Ул, хәтта төнлә уятып, авырулар алдында спирт даулый башлады. «Гражданин начальник, спирт инде операциягә дә калмады. Бирә алмыйм»,— дим. Ә ул җикеренә: «Ах, шпион, син әле башлыклар белән шулай сөйләшәсеңме? Мин сине хәзер үк карцерга озатырмын. Бир дигәч, бир. Колымада су җитәрлек. Бер чиләк кушсаң, бер айга җитәр». Мин кызып китеп аны куып чыгардым.

— Шуннан?

— Шуннан ни булсын. Волков әйткәнчә инде. Мине икенче көнне үк врачлыктан алып кара эшкә — утын ташырга кудылар. Ике айдан соң бу прискага җибәрделәр. Өченче участокта колымашка белән җир ташыдым. Үткән көнне колымашка астында калып,сул аягымның тубыгын чыгардым.

Билгеле ки, Болгария бик күп еллар Госманлы төрек империясенең колониясе була.

— Безнең хуш исләр аңкып торган мәшһүр розалар аланы Казанлыкта да төрекләр күп,— диде Стоянов.— Без төрек балалары белән бергә мәктәпкә йөрдек.

— Алайса сез төрекчә дә беләсез?

— Мин төрек мәктәбендә өч ел укыдым. Менә шунда гарәп әдәбияты белән таныштым. «Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир», «Тутыйнамә»ләрне төннәр йокламый укып, хыялланып йөрдем. Беләсезме, авыруны дару белән дәвалау гына аз һәм хәтта ул әле тиешле нәтиҗәне дә бирә алмый.

— Төшенмәдем.

— Борынгы юнаннар: сәламәт тәндә сәламәт рух, дигән. Ә мин аны: сәламәт күңелленең тәне дә сәламәт, дип үзгәртеп әйтер идем.

— Ничек?

— Авыру, үз эченә йомылып, сөйләшмичә, көлмичә ятса, үзен-үзе кимерә, хәлен авырайта гына. Аны чире турында уйлаудан коткарырга кирәк. Сөйләшсен, көлсен... Әйе, әйе, көлсен. Көлү ул сәламәтлекне күтәрүче иң тылсымлы дару. Шифалы.

— Әйтәм,кичә бөтен барак гөр килә иде.

— Монда бит барысы да диярлек «илле сигезләр», нахактан гаепләнгән кешеләр. Җитмәсә, шундый фаҗигагә дучарлар: кайсы аксак, кайсы чулак. Шуңа күрә мин аларның эчке газаплануларын, фаҗигале хәлләрен оныттырырга тырыштым...

Менә бит ул кеше нинчек. Халык азатлыгы өчен көрәшә. Сөрелә. Ахнары, ниһаять, иркен, азат тормыш башлыйм дигәндә, тагын нахак бәлагә дучар була. Шулай да кешелеген югалтмый.

Ә мин шикләндем, шөбһәләндем һәм Георгий Стояновны «чагучы» дип каһәрләдем.



## V

Иртәнге обходтан соң күршем, бер аксактан култык таякларын сорап алып, баш врач хозурына китте. Уф алла, ни генә булыр икән инде? Рөхсәт итәрме? Итсә генә ярар иде! Ә аягым, үч иткән кебек, әллә инде тынычсызланганга, сулык-сулык итеп сызлый, чәнчә. Тышта исә күз ачкысыз буран. Баш очындагы тәрәзәдән суык өрә, дер-дер килэм. Көтәм. Ишек ачылмый. Ичмасам, агач аяк белән булса да, туган илгә, Күкчәтау далаларына кайтырга, ялгыз атамны, дус-ишләрне күрергә насыйп булсын иде. Ниһаять, ишек ачылды — әүвәле култык таяклары, аннан Карасакал күренде... Нинди хәбәр алып килә икән күршем? Йөрәк дөп-дөп итә. Аяк сикереп-сикереп китә, әйтерсең лә, кыздырылган инә чәнчәләр. Так-ток. Так-ток! Таяклар якынлаша... Күршемнең йөзе караңгы. Күзләре миңа карамый.

Так-ток, так-ток. Димәк, баш врач күршемә минем аякны ампутацияләргә рөхсәт итмәгән... Бу өмет тә челпәрәмә килеп ватылды.

Икенче көнне Магаданнан ике хәрби кеше — мөгаен, Гулаг (лагерьларның Баш идарәсе) вәкилләре килеп, безнең санбаракны карап, шахтадагы авария турында сорашып йөрделәр. Алар Георгий Стоянов янында тукталып озак кына сөйләштеләр. Күрәсең, аны электән беләләр.

Менә шушы комиссия рөхсәте белән, Георгий миңа ампутация ясарга әзерләнә башлады.

Георгий санитар Тимка белән дә уртак тел тапты. Ул үзенең ярдәмчесен чакырып килде.

Иң элек алар операция бүлмәсендәге барлык әйберне — өстәл, урындык, шкаф, кушеткаларны чыгарып, бүлмәне эссе су белән юып, стеналарын пешекләп чыктылар. Ә Георгий үзе ашханәдән зур бер бак алдырып, барак уртасындагы плитә өстенә куйды да, су салып, операция вакытында кия торган киемнәрен, җәймә-салфеткаларны кайната башлады. Гаҗәп! Безнең баш врач андый эш белән мәшәкатьләнеп маташмый, бер урынга дүрт-биш авыруны яткырып тураклый бирә иде. Ә бу! Ул гынамы? Иң әһәмиятлесе — шкафны тазарткан вакытта аскы шүрлектән ике шешә хлороформ да таптылар. Этикеткалары гына төшкән булган. Ә бит «хлороформ юк» дип, уяу килеш, тере тәнне пычак белән тунап, пычкы белән кисте бит, мәлгунь. Икенче тапкыр аягымны кискәндә, авызыма капкан чүпрәкне чәйнәп, үземне кушеткага бәйләгән каешларны өзеп, һуштан язган идем ич... Ә хлороформ шунда шкаф эчендә генә аунап яткан булган.

Бак төпе буе бокыр-бокыр кайнады. Георгий плитә белән ике арада әйләнде — эш коралларын кайнатты, урын-җиргә дезинфекция ясады.

Өченче көнне иртәнге баландадан соң Тимка белән Петро мине култыклап операция бүлмәсенә китерделәр. Шаккаттым, бүлмә яктырып, киңәеп киткән. Һавасы да бүтән, җинел.

— Бәхетең бар икән,— дип, Георгий мине көлеп каршылады.— Менә, бер үзеңә туп-тулы шешә. Иләп кенә ят але. Менә шулай. Аякларыңны бәйләп маташмыйбыз. Бу масканы борыныңа салыйк... Исәнә, башыңны боргалама! Сана: бер, ике...

Борынга йөзләгән кырмыскалар керәмени. Кычыттыра, тончыктыра...

— Сана, сана! Өч-дүрт...

— Өч... дүрт... алты... — башым әйләнә, каядыр китеп барам,— ун... егерме... егерме... Артык саный алмадым, онытылдым.

Ниндидер тирән диңгездә йөзәм. Яр — ерак. Мин — хәлсезләнәм. Кулларым күтәрелми. Чумып-чумып китәм. Батам. Батам! Коткарыгыз!

Көч-хәл белән күзләремне ачтым, бөтен нәрсә әйләнә.

— Уян! Уян! Операция бетте инде. Озак йокларга ярамый.— Авырттырмыйча гына, шап-шап итеп яңакларыма сугалар.

Ниһаять, күзләремне ачтым, бүлмә, каршымда торган ак халатлы Георгий Стоянов әйләнеп китте, кушеткага ябыштым.

— Мә, аз гына ром йот.

Кушетка кырында, идәндәге ләгәндә, ярты сыйрагым ята.

— Ярар, борчылмагыз. Мин тездән унбиш сантиметр калдырдым. Озын да түгел, кыска да түгел. Һәрбер протезга ятышлы. Стандарт протез сезгә нәкъ булачак. Әле йөгереп йөрерсез.

Санитарлар мине култыклап урыныма алып барып салдылар. Изрәп йоклап киткәнмен. Ул көнне Георгий тагын өч тоткынга ампутация ясаган.

Бер атнада аягымның ярасы бөтәйде. Мине гомуми баракка чыгардылар. Георгий баракның ишек төбенә хәтле аксый-аксый озата килде. Кулларымны каты кысып хушлашканда:

— Кайгырма! Хаклык бер көнне килер,— дип, соңгы тапкыр кочагына алды.

Менә инде ничә дистә ел бер сыйрагым Колыма җирендә, мәңгелек тунда ята. Ничә дистә ел протезда йөрим. Киселгән урынында бер шеш, яра юк! Һәр көнне иртән торып протез кия башлагач:

— Мең рәхмәт сиңа, ерактагы дус! — дип мин Георгий Стояновны искә алам.

Аны — кара сакаллы күршемне күрәсе, кочаклыйсы, рәхмәт, мең рәхмәт әйтәсе иде. Берничә тапкыр Болгариягә, Софиягә хат язып, аны эзләргә дә җилкенгән идем. Әмма булмый. Артык четерекле, уңайсыз җирдә очраштык шул без аның белән...

Әмма Георгий Стоянов мәңге минем күңел түремнән китмәс.

*Ахыры бар.*

# ПОЭЗИЯ

*Бездә кунакта —*
*Башкортстан шагыйрьләре*

*Май аенда тугандаш Башкортстанда Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре була. Киләсе елда исә бездә — Татарстанда Башкортстан әдәбияты һәм сәнгате бәйрәме узачак. Шушы уңайдан, бу санда без укучыларыбызга Башкортстан шагыйрьләре иҗатыннан кайбер үрнәкләр тәкъдим итәбез.*

## Мостай Кәрим,

Башкортстанның халык шагыйре,
Социалистик Хезмәт Герое

### Билгесез солдат

Һәйкәл тора. Имеш, сөйлиләр,
Бу — билгесез солдат һәйкәле.
Билгесезме шушы бакыр кеше?
Билгесезме, хәтер, әйт әле?!

Атакага күтәрелдек бергә,
Ега сукты әҗәл бер мәлне,
Вакытлыча янә тереләм мин,
Ул — мәңгелек сынга әйләнде.

Каршысында түтәл — түтәл гөлләр
Изге ялкын булып яналар,
Баш өстендә таңнан кошлар сайрый,
Эргәсендә сайрый балалар.

Ә артында аның чал бер хатын
(Ил әнисе — улдыр, мөгаен.)
Ничәмә ел инде өнсез елый,
Салкын ташка бәреп маңгаен.

Җиңү! Кояш балкый бер битендә,
Бер битендә — моңсу ай һаман.
Бер күзеннән шатлык нуры сибелә,
Бер күзеннән әче яшь тама...

## Нәҗар Нәҗми,

РСФСРның М. Горький, БАССРның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты

### Бүдәнә белән тартай

(МӘСӘЛ ТҮГЕЛ)

Бер ел бүдәнә симерсә,
Бер ел — тартай, дигәннәр.
Акыллылар яшәүнең бар
Серенә төшенгәннәр.
Үзгәрә бара акыл да,
Үзгәрә заманалар:
Заманга чыдамый ава
Хәтта таш баганалар.
Кошлар ничек? Аларның да
Гомер заманча ага:
Һәр ел бүдәнә симерә...
Ә тартай?
Тартай теленнән таба.

## Әнгам Атнабаев,

Г. Сәләм премиясе лауреаты

### Буш имезлек

Әгәр бала елый башласа,
Кабаланып,
Ярдәм кулы сузган булабыз.
Ими сорап ачкан авызына
Буш имезлек тыгып куябыз.

Суыра торгач,
ачыгуын йотып,
Йоклап китә — тавыш-тыны юк...
Буш имезлек — коры бушлык инде,
Ни файдасы, ни туклыгы юк.

Әмма ләкин вакытлыча тыныч,
Янәсе дә имә — и, бала!
Артык беркатлы шул,
зурлар биргәч,
Буш имезлек белән юана!

Ә, туктале!
Нигә исем китеп,
Бик җәлләгән булам баланы?!
Безне дә бит
тормыш
мең мәртәбә
«Симез» вәгъдә биреп алдады!
Вәгъдәләрнең йомрыларын алдык,
Күзне камаштырды ялтырау;
Докладлардан көмеш сулар акты,
Карарлардан үсте алтын тау.
План тулмый торса,
нуль өстәдек,
Итәк кисеп җиңне ямадык,
Бишьеллыклар үтәлмичә калса,
«Үтәлде» дип кемне алдадык?!

Хәтта бер чак рәсми алдашуның
Чама тәртәсеннән ычкындык:
Сиксәненче елдан коммунизм
Башлана дип чәүкә очырдык.

Кем узардан мактанышу китте,
Башны әйләндерде «ура»лар,
Рапортларда уңыш арткан саен
Такырая барды буралар.

Төче ялган ышанычны ашый,
Ышаныч юк — димәк, иман юк.
...Һәм бер вакыт
тәмле йокыбыздан
Буш имезлек кабып уяндык.

Бу тормышның яман авырлыгын
Киметеп тә торма,
арттырма,—
Дөресен әйт, мин бит сабый түгел,
Буш имезлек миңа каптырма!

## Рафаэль Сафин

### Табигатьнең кәләш кенә чагы

— Оһо-һо-һой!— дип бер
кычкырсам,
офыкларда кояш уяна.
Уяна да, кияү егетедәй,
таңкаләрен сибә дөньяга.

Җилләр йөри яңа көй чыгарып,
чиртеп кылын язгы кичләрнең.
Табигатьнең кәләш кенә чагы,
уйнап торган чагы хисләрнең.

Ул өләшә бүген бүләк итеп
яланнарның чагу балкышын,
күкнең чыңлап торган зәңгәрлеген,
агачларның яшел алкышын,
җилен, гөлен, җырын, бар кошын.

Табигатьнең кәләш кенә чагы.
Әйе, башка бүген ул, башка:
тетрәнүле кайнар өмет белән
баккан гына чагы кояшка.

Табигатьнең кәләш кенә чагы.
Берүк, абай була күрегез:
яман сүзләр әйтеп өркетмәгез,
кайта күрмәсен, дим, күңеле.

Табигатьнең кәләш кенә чагы...

## Тимер Йосыпов

### Сабый тавышы

Әче җилдән
Авылымның
Йөзе каралган төсле.
Сабый тавышы да чыкмый,
Дөнья картайган төсле,
Авыл үткәнен хәтерли,
Бу галәмгә бага да.
Картлар гына торып калган,
Калмаган бер бала да.
Тавышлары ишетелми,
Зык купмый бала-чага.
Урамында өерелеп
Тик җилләр генә чаба.
Йортларына кагыламын,
Түр башында — сабырлык.
Кочаклашып елашмыйлар
Картлык белән сабыйлык.
Авыл тыныч,
Давыл ерып,
Тансыклары канганмы?
Бер баласыз авылкаем
Бала булып калганмы?
...Әче җилдән
Авылымның
Йөзе каралган төсле,
Сабый тавышы да чыкмый,
Дөнья картайган төсле.

## Равил Бикбаев,

Г. Сәләм премиясе лауреаты

✽

Туган төбәктәге ояларга
Җылы яктан күпме кош кайтты...
Нигә әле кинәт заманымны
Оя баскан кошка охшаттым?

Черем иттермичә,
Сискәндереп,
Күпме көннәр үтә, таң ата.
Туар чебешләре арасында —
Оясында —
Ята...
Граната.

## Айдар Хәлим

### Гади сорау

Нигә әле мин үләргә тиеш?
Олуг кояш, синнән сорадым.
Әйттең, кояш:
— Синең йөрәк белән
Җир җылытам бит мин, туганым.

Нигә әле мин үләргә тиеш?
Чиксез дәрья, синнән сорадым.
Әйттең, дәрья:
— Синең яшең белән
Таш сугарам бит мин, туганым.

Нигә әле мин үләргә тиеш?
Саңгырау таш, синнән сорадым.
Әйттең син, таш:
— Синең түзем белән
Иген үстерәм мин, туганым.

Нигә әле мин үләргә тиеш?
Минсез ничек яшәр бүтәннәр?
Миннән башка матур киләчәк тә
Матур булмас кебек үткәннән —
Нинди мәгънә гомер иткәннән?

Нигә әле мин үләргә тиеш?
Мин бит — кеше, түгел пәйгамбәр.
Мин мәңгегә сезнең белән калам —
Кояш,
Су
һәм Таш
туганнар!

## Кадим Аралбаев

### Таштугай

*Таштугайкай, синең камышыңны*
*Җиз курайкай итеп тартаем.*

Халык җырыннан

Барма кайсы гына почмагына,
Шатлык иле минем Ватаным,
Әмма сине, моңлы чал Таштугай,
Шаттугай дип бүген атадым.

Шаттугай син бүген, әй Таштугай,
Үзәннәрең — бәхет үзәне.
Далаларны — иген иле итеп,
Дөньяларны халкым бизәде.

Шаттугай син бүген, әй Таштугай,
Кешеләрең батыр затыннан.
Тир түккәнгә җиргә
Исемнәре
Йолдыз булып күккә атыла.
Шаттугай син бүген, әй Таштугай,
Актан-ак сөт, гүя, күңелең.
Җәйләүләргә түшеп ак каенның
Яулык болгый, нурга күмелеп.

Шаттугай син бүген, әй Таштугай,
Шатлык ташып дулый йөрәктә:
Башакларың камыш кебек шаулый,
Уңышларың йөри үрнәктә.
Шаттугай син мәңге, әй Таштугай,
Ил кырында сайрар бүз тургай.—
Аңа кушылып, даның яңгыратып,
Уйный бәхет көен җиз курай.

## Фаkиһә Тугызбаева

●

«Танышыек: син Бәхетме әллә?
Мин дә Бәхет. Менә куш булдык.
Алып очыеммы күккә сине,
Очыекмы икәү кош булып?

Синең җаның моңмы? Минеке моң!
Карамыйкчы әле чикләргә!
Күккә күтәрелә бәхетләләр
Моң күтәрә кошны күкләргә.

Мең хәстәре мең хәсрәте белән
Калсын әле җирдә елак көз.
Тирбәлербез айның бишегендә,
Елмаешып кына күзгә-күз»,—
Ничек шулай кыеп әйтергә соң?
Бу сүзләрем — телем очында.
Эндәшмичә генә атлыйбыз без,
Учың тоям тәү кат учымда.

## Риф Мифтахов

### Югалтмыйк!

Берсе бетсә,
иkенчесе туа,
Өченчесе килеп өстәлә —
Йөз мәшәкать...
(Кайда хис-тойгылар!)
Якыннарны хәтта искә дә
Төшерергә форсат җитми кала,
Куа-куа төпсез дөньяны...
Әллә заман шулай җайлап кына
Туганлыкны,
тойгы,
йоланы
Оныттырамы ул — тизлекләргә,
Әйберләргә бәйләп хыялны.
Йөз мәшәкать... Ул элек тә булган,
Тик барыбер туган туганны

Якын иткән, аңа килеп киткән —
Суытмаган таныш тупсаны...
Бер күрешер өчен, атлар мичәп,
Еракларда килгән дуслары.
Юк, сый түгел, акыллы сүз белән
Мәҗлесләрнең чыккан зур даны.
Нигәдер, без хәзер иkенчерәк:
(Әллә миңа шулай тоела?)
Кулны гына түгел, күзне бәйләп,
Әйбер баса адәм юлына.
(Ә байлыкка күңел күзе төшсә,
Кешеләргә ул тиз суына.)
Мәшәкатьсез яшәү булмыйдыр ул,
Тик туктаусыз дөнья кумыйк без —
Саф тойгыны һич тә югалтмыек,
Кеше сөяр
Кеше булыйк без!

## Рәмзилә Хисаметдинова

### Ирәмәл тау кызлары

Таудан чыршы төшеп килә —
балитәкле күлмәктән:
әйтерсең лә, киеп алган
башкорт кызыннан күрмәктән.

Таудан каен төшеп килә —
таңка-кашмаудан тоташ.

Әллә инде сабантуйга
җыенганмы бу туташ?

Каелган алъяпкыч киеп,
килә тауның миләше.
Әллә кемнең балдызыдыр,
әллә кемнең бикәче.

Ак күлмәктән шомырт килә,
үтә тыйнак кыз бала —
чак-чак кагыл, коелып төшә,
сүз әйтергә ояла.

Кем кызлары килгән икән,
төзәнешеп, киенеп?!
Карт Ирәмәл түшен киргән,
мактангандай, сөенеп.

## Таңсылу Карамышева

### Көянтә

Чайкалдырмый, чайпалдырмый, йөгереп
кенә,
вак-вак атлап, иңләп кенә, йөзеп кенә,
суга барам, туып-үскән илгә кайтсам,
көянтәмә уйлар, хисләр элеп кенә.
Чиләкләрнең бер күзендә кояш көлә,
бер күзеннән ай-йолдызлы нур бөркелә;
Бер иңемне кичәге көн тирбәтә күк,
бер иңемдә алдагы көн туып килә.
Көянтәнең бер очында хәтер килә,
үз бәһасен, дәрәҗәсен белеп кенә;
Көянтәнең бер очында өмет килә,
киләчәкне якын, газиз күреп кенә.
Мөлдерәмә тамчыдыр ул — бер элгечтә,
бер элгечтә — күзгә сыяр болытлар бит;
әнә кара: орлыклар бит — бер элгечтә,
бер элгечтә — өлгереп җиткән уңышлар бит.
Бер чиләктә — чишмә генә, инеш кенә,
бер чиләктә — күтәргесез диңгез-дәрья;
Көянтәмдә — тамырлар һәм тажда чәчкә,
туган йортым һәм дә чиксез бөтен дөнья.
Чиләкләрем бит буш түгел, тулы килә,
абайламый, атлап кара ава-түнә:
берсен түксәң, берсе әзер түгелергә —
чиләкләр бит берсен-берсе тотып килә!

## Әсхәл Әхмәтхуҗин

●

Дулкын чайкап, упкын айкап
Ятып та,
Я давыллап, тауны тауга
Атып та,
Басалмасаң күңеленнең
Ярсуын,
Һәм сагынсаң йөрәгеңнең
Яртысын,
Син, син, диеп, илле идел
Кичәрмен,

Син, син, диеп, җитмеш җирне
Гизәрмен,
Тик барыбер килермен мин
Үзеңә,
Килми калмам, бакмый калмам
Күзеңә...
Хыялымда — иң саф зәңгәр
Диңгез син,
Сусыз чатнап ярылган яр —
Синсез мин.

## ПРОЗА

Батулла

# ЮЛ БУЕНДА ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК

ПОВЕСТЬ

## Күк капусы



Ярмөхәммәт мәктәптән кайтып керүгә үк анасы:

— Кәҗә кайтмады,— диде.— Харaплар гына булмагае...

Малай букчасын сәкегә ташлады да чыгып йөгерде. Юлда кимерерсең, дип бирергә каткан кыерчык та юк, кысыр аш әле өлгермәгән, колхоз эшеннән кайтып әле яңа гына учак тергезергә тотынган иде Нурлыгаян, ач баласын кәҗә эзләргә юллады.

— Кәҗәгез бүген көтүгә чыкмады бит,— диде көтүче Мохан.

Каян гына эзләмәде ул газиз кәҗәне. Кемнән генә сорашмады. Ерак болынга да барып карады, яңа басудан да эзләде, ничәмә чакрым юл үтте. Эч әчетеп-әчетеп быгырдыйзарлана. Эчтә бушлык югыйсә, буш булса да нәрсәдер бытырдый шунда. Очраган бер чишмәгә ятып су эчкәләсә дә, өзелеп карын ачканы басылмады.

Юл буйларында, сөрелми калган багана төпләрендәге «чөйләр»дә һиндыба чәчәкләре атынып утыра. Чәчәкләрнең эче тулы гүзәл алиһәләр сагыштан саргаялар. Ярмөхәммәтнең күңел күзе аларда түгел иде шул. Аларның өенә шом инде. Карап торган, бердәнбер ашатучы, киендерүче кәҗәң югалсын әле. Бүре буса? Чегәннәр урлап суйса?

— Тефү-тефү, авызымнан җил алсын...— диде Ярмөхәммәт.

Тамак өчен көрәш бара фани дөньяда.

Матурлыкка күз төшми. Зәңгәр һиндыбалар ятим калды.

Шулай хәлсезләнеп кайтып килгәндә аның каршысына Нәдерша очрады.

— Нәдер абый, безнең кәҗәне күрмәдеңме?— диде Ярмөхәммәт.

— Кәҗәгез нинди ие,— дип сораган булды Нәдерша.— Карамы?

— Ие, кара инде, беләсең бит.

— Ике мөгезле идеме кәҗәгез?

— Ие инде...

— Су буена төшеп китте, юынырга! — диде дә Нәдер әдәпсез итеп көлде.

Ярмөхәммәт аның әшәке шаяртканын әллә кайчан аңлаган иде.

---

Ахыры. Башы 4 нче санда

бер усал сүз әйтергә уйлаган иде дә, бу диванага сүз әрәм иткәнче, дип кузгалды.

Әнгер-меңгер төште. Кичәге яңгырдан соң калган күлдәвекләргә карап, югалган кәҗә хәсрәтен көчкә күтәреп кайтып килә иде ул, аяк астындагы суда якты сызык күреп туктады. Су эчендә утлы таяк каян килсен? Димәк, бу — якты таяк шәүләсенең судагы чагылышы. Ярмөхәммәт кинәт өскә карады. Зәп-зәңгәр күк гөмбәзен тач урталай бүлеп, якты сызык сузылган. Әйтерсең лә алачыкта уттай кыздырылган тимер таяк күкне урталай ярган. Кәҗә дә онытылды, ачлык та узды сыман. Ярмөхәммәт сихерләнеп күккә карый. Якты таяк талгын гына сызып, сүнеп бетте. Нәрсә соң бу? Ярмөхәммәтнең акылы моңа җавап кайтара алмады. Йолдыз атылу дияр идең, аңа охшамаган. Йолдыз ул тиз атыла. Кыска гына эз калдырып, бер сулыш алганчы сүнә дә бетә. Бу яктылык күк касәсен урталай бүлгән. Үзе утыз тапкыр сулыш алганчы балкып торды.

Дөньясын онытып, малай өйгә йөгерде.

Ул кайтып кергәндә Факиһә казаннан кысыр аш бушата иде, әнисе сәке йөзлегендә елап утыра.

— Кәҗәне пуләвәй Хөрми япкан! — диде Факиһә.

— Ун йомырка сорый,— диде ана, күз яшьләрен сөртә-сөртә.— Ун йомырканы каян алыйм мин аны? Карап торган биш-алты йомыркам бар иде, анысын да налукка биреп бетердем...

Ярмөхәммәт бая гына күргән могҗиза турында анасыннан сорамакчы булган иде дә, теләгеннән кире кайтты. Эндәшмичә чыгып китте.

— Кая барасың? Ашарга утыр! — дип кычкырганнарын ишетсә дә кире борылмады.

Хөрмиләр ишегалдында кеше байтак иде. Кайсы бозавын сорап килгән. Кайсысының казы тотылган. Өсте ачык утарда әллә ничә оя каз. Бичаралар ачыкканнар, кибеккәннәр. Казлар талаша, сугыша. Ара-тирә канатларын киң җәеп кагыналар, каңгылдыйлар. Һич чыдар әмәл юк аларның тавышына. Куәтле казлар бер казны чукыйлар. Көзен чыккан бала казмы бу... әллә гарипләнеп, җәй буе мантый алмаган бер бичарамы, әйтерсең лә казларны бу төрмәгә ябуда шул мескен бала каз гаепле. Казның башын чукып, пеләшләндереп, йонын йолкып бетергәннәр. Каз кызганыч тавыш белән кычкыра, ләкин кан кардәшләре аны кызганырга уйламый — чукыйлар да чукыйлар. Әҗәле шунда булыр, ахрысы.

Утыртма читән белән тотылган абзарда ач бозаулар мөгердәшә. Шулар арасында Ярмөхәммәтләрнең кәҗәсе дә бар. Кәҗә арлы-бирле йөренә. Үзе бертуктаусыз мекердәп кычкыра, ярдәмгә чакыра. Чыгар урын эзли, бахыр. Бозаулар илереп мөгерди. Хуҗаларын күргәч, бичара хайваннар, өметләнеп капка янына өелешә. Хуҗам иреккә чыгарыр, су бирер, дип ымсыналар, ләкин шунысын гына аңлый алмыйлар мәхлуклар: ни өчен соң аларны иреккә чыгармыйлар, ни өчен ашатмыйлар, эчертмиләр? Ни өчен болай интектерәләр?

Җәмига апа елый-елый шешенеп беткән, үзе Хөрмигә ялына:

— Хөрмәтулла абзый, зинһар дим, балаларым хакына чыгар казларымны... Бар карап торган шул бер оя казым бар... Әнә, анысының да бер бәпкәсе гарип... Чукып үтерәләр бит, Хөрмәтулла абзый...

— Йа-ак!— дип кычкырды Хөрми.— Булмый, Җәмига, булмый! Каз башына унбишәр сум. Аннан соң ал казларыңны, пажалысты!

— Каян алыйм мин ул кадәр акчаны, Хөрмәтулла абзый? Бар карап торганым шул биш каз, аның да берсе гарип... Үтерәләр бит анысын да... Ичмасам шунысын аерып бир, Хөрмәтулла абзый...

Хөрмәтулла йомшамады, тәмәке тартудан саргаеп беткән бармаклары белән авызыннан төрепкәсен алды да, Җәмига апаның колагына иелеп нидер пышылдады. Аннан соң әдәпсез тавыш белән көлде. Җәмига апа: «И ходаем»нан башка сүз әйтә алмыйча, үксеп елап кайтып китте.

Югароч Рәсүлләрнең бозавы да тотылган булып чыкты.

— Хөрмәтулла абый,— диде Рәсүл еламсырап.— Кабат, валлаһи, басуга кермәс. Биреп җибәр бу юлга гына.

Хөрми тагын төрепкәсен алып, ямьсез итеп елмайды. Күсенеке кебек сап-сары тешләре күренде. Алгы тешләре бар, урт тешләре урынына кара бушлык иде. Хөрминең авызы кабер упкыны сыман тоелды Ярмөхәммәткә. Шул кара упкындагы сап-сары күсе тешләре Ярмөхәммәтнең хәтер түрендә гомерлеккә калыр. Бу — оятсызлык, миһербансызлык, гаделсезлек билгесе сыман тоелыр аңа.

— Әбиең төшсен!— диде Хөрми Рәсүлгә.— Әбиеңне алып кил...

Бу төштә Хөрми кул бармаклары белән әдәпсез хәрәкәтләр ясап күрсәтте дә йөткерә-йөткерә көләргә тотынды.

Ярмөхәммәт зур өметләр баглап, кәҗәбезне чыгармасмы, дип Пүләвайнең чыраена карый. Пүләвайнең авызы ерылып китүгә, Ярмөхәммәтнең миенә хәбәр йөгерде: «Пүләвәй Хөрминең көлүе адәм көлкесе икән!»

Күпме генә ялынса да, Хөрми Ярмөхәммәтләр кәҗәсен чыгармады. Рәсүл дә боек кына кайтып китте.

Альбертның тутасы Зәйтүнә, бик чая хатын, аны-моны уйлап тормаенча:

— Чыгарасыңмы бозауларны, юкмы, чихүткә тәре!— дип кычкырды.— Иманыңны сагынам мин синең, бозауны бирмәсәң, хәерче крис! Гомер буе хәер сорашты атаң, теләнчелектә үлде бабаң. Син сәвиткә чаклы да хәерче идең, хәзер дә хәерче. Кеше асраган малларны ужымга кермәгән килеш тотып, кеше каргышы ашап яшисең син, ата күсе! Мунчала үпкә!

Хөрми аты-юлы белән сүгенеп кычкырды.

Зәйтүнә апа да аптырап калмады, әллә каян гына урак чыгарып, җәһәт кенә лапас капкасының бавын кисте. Бозаулар капканы сизеп, ишегалдына чыкты. Хөрми:

— Талыйлар! Контрлар! Атам!— дип өенә томырылды.

Ишегалдына җыелган кешеләр бозауларны урамга куа башлады. Бозаулар мөгери, казлар каңгылдаша, кешеләрнең мал куган тавышлары ишетелә. Ду килә дөнья. Ул арада Хөрми дә болдырга атылып чыкты, аның кулында мылтык иде. Һавага ата-ата, ул лапас капкасын бәйләде. Чыгарга өлгермәгән маллар: өч бозау белән аягы имгәнгән кәҗә тоткынлыкта калды.

— Пат суд! Бөтенегезне дә өтерманга яптырам!— дип кычкыра Хөрми.

— Алланың әче каһәре төшсен! Җан бирә алмыйча какраеп, интегеп ят, тәмуг кисәве! — дип, Хөрмине каргый-каргый таралдылар.

Ярмөхәммәт тә салмак кына атлап кайтып китте.

Әхнәфләр турыннан узганда Ярмөхәммәт җан өшеткеч авазлар ишетте. Җәмига апа уллары Әхнәф белән Кәримулланы кыйный иде.

— Чукынмыш балалар, кайда йөрдегез? Ни карадыгыз? Нигә казларга күз-колак булмадыгыз?— дип кабатлый-кабатлый Җәмига түти әле бер баласына суга, әле икенчесенә китереп ора.

Кәримулла түзә, дәшми. Әхнәф бичара суккан саен акыра. Ул баш бала, аңа катырак төшә, ахрысы.

— Әнкәй, әнкәй, сукма!— дип өзгәләнә Әхнәф.

Ярмөхәммәт түзмәде, ярсып капканы ачты да кычкырды:

— Җәмига апа! Үтерәсең бит, тимә! Безнең дә кәҗәбез тотылган...

Ярмөхәммәт тавышыннан хатын айнып китте, ахрысы, балаларыннан читкә борылып, алъяпкычы белән битен каплады да, үксеп елый башлады.

Ятим балаларын кыйнаганга үкенеп елавы идеме хатынның? Сезгә генә түгел, миңа да тормыш авыр бит, дип әйтүе идеме? Әллә балалары алдында гафу сорау идеме бу елау — Ярмөхәммәт моның аңлый алмады. Еллар узгач, үзе дә ата булгач кына ул Җәмига исемле тол

хатынның хәлен аңлар. Пүләвәйгә булган ачуын, нахакка ирен төрмәгә утыртып харап иткән Фәрхун белән Сабир үчен, сугыш авырлыкларының әчесен шулай баскан икән ул мескен хатын.

Җәмига Ярмөхәммәткә кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Үзалдына сөйләнгәндәй итеп:

— Кешеләрнең балаларына ичмасам аталары сугышта үлгәнгә пасубие кайта. Сез бәхетсезләргә анысы да юк,— дип берөзлексез илауларга, зарланырга тотынды.

Әхнәф белән Кәримулла, тукмы астыннан чыккач, тавышсыз гына елый калды. Ярмөхәммәт урамга чыкты.

Ул өчесен дә кызгана иде.

Җәмига апа — яшьли тол калган хатын. Сугышка чаклы ук ирсез. Сафиулла абзыйны «халык дошманы» дип Фәрхун Карун төрмәгә яптырган. Сафиулла абзыйны, сугышка кадәр амбар мөдире булып эшләгән, дип сөйли Ярмөхәммәтнең анасы. Ул урынга Фәрхун кызыгып йөргән икән. Аны куймаганнар, Сафиулланы куйганнар. Шуннан соң Фәрхун җае чыккан саен Сафиуллага кадала башлаган. Урлаша дип өсте-өстенә ревизия чакырта торган булган. Барыбер Сафиулла абзыйның гаебен таба алмаганнар. Фәрхун чирлегә сабышып ындырга чыкмый икән. Аның шулай эштән кыяклап йөргәнен сизенеп, Сафиулла абзый:

— Туктале, нигә келәткә эшкә төшми икән бу? Кеше житми бит,— дип Фәрхунның өенә барып кергән.

Керсә ни күрә? Фәрхунның өй түрендә Сталин рәсеме тора, рәсем урталай ертылган.

Фәрхун Сафиулла белән исәнләшеп тә тормый, чыга да йөгерә. Авыл советына барып, милициягә шалтырата.

— Минем өйдәге Сталин рәсемен Сафиулла умырып төшерде! Ул контр! — ди.

Сафиулланы ун елга утыртып куялар. Сафиулла китә дә юк була. Әллә исән, әллә үлгән. Бер хәбәре юк.

Шулай сөйли авыл халкы.

Үләсе көнне Айдаш баба Фәрхуннарга кереп бик озак утырып чыкты. Ни сөйләште икән ул аның белән? Гомеренә Фәрхуннарның келәсенә басмаган Айдаш ни өчен үләр алдыннан аларга керде икән?

Айдаш картны җирләгәннән соң бер-ике көн узгач, Җәмига янына Фәрхун төшкән, имеш. Төшкән дә әйткән:

— Сафиулла күптән вафат... Көтмә син аны... Алабуга төрмәсенә алып барганда Кама бозы ярылып, бик күп тоткыннар батып үлгән. Шулар арасында Сафиулла да булган...

Шул хәбәрне ишеткәч, Җәмига апа бигрәк усалланды, аның бу усаллыгы балаларына төшә.

Сабый Ярмөхәммәт олы кешеләрчә уйлый-уйлый, авыр йөк күтәргәндәй, кайтып керде. Дәшмичә генә ашады. Дәрес карарга соң иде инде. Барысы да сәкегә тезелешеп ятты.

— Шул...— диде Нурлыгаян караңгылыктан.— Соңгы утыз сумны илтерсең, улым...

Ярмөхәммәт җавап кайтармады. Аның уе кәҗә мәсьәләсеннән бая күргән могҗизага күчте. Баягы яктылык аның күз алдыннан китми иде.

Авылга төн төште. Каралты-кураны, өйләрне, кешеләрне йокы басты. Ара-тирә эт өргәне, тоткындагы бичара бозауларның чиратлап мөгерәүләре генә ишетелеп куя. Тилмерә бичаралар... Мич арасында чикерткә сайрый...

— Әни,— диде Ярмөхәммәт.— Әни, мин бүген күктә якты сызык күрдем...

Ул күргәннәрен тәфсилләп сөйләде.

— Әнкәй, ни икән ул, ә?

— Күк капусы ачылганын күргәнсең син, улым,— диде ана.—

Күк капкасы ачылганын сирәк кеше генә күрә ала. Бәхетле кеше генә күрә ала. Син изге теләкләр телә, Ярмөхәммәт. Бүген ни теләсәң, шул кабул булачак.

Кабат сөйләшүче булмады. Факиһә аллә кайчан йоклый иде инде. Ярмөхәммәт дөньясын онытып теләк тели башлады:

— Йа, раббем, кәҗәбезне коткар. Шул мәлгунь Хөрми тоткынлыгыннан бичара кәҗәбезне йолып ал.

Төн урталарында кәҗә тавышы ишетелгәндәй булды. Ярмөхәммәт торып колак салды. Янә кәҗә тавышы ишетелде. Бу юлы Нурлыгаян да торып утырды.

—Ай, алла-ходаем, кәҗә кайткан түгелме соң?— диде ана.

Шик калмады. Кәҗә кайткан.

Ярмөхәммәт әнисеннән алда ишегалдына чыкты, бәләкәй капканы ачты, кәҗә алгы сул аягына аксаклап, әчкә узды. Анасы төн уртасы дип тормады, әзерләнгән сулы ләгәнне чыгарып, тоткыннан кайткан мал алдына куйды.

— Бичаракай, кибеккән шул,— диде ана.— Көне буе ач торган инде ул анда. Кем чыгарды икән кәҗәне?

Ярмөхәммәт тә:

— Ничек чыкты икән? Кем чыгарды икән?— дип баш ватты.

Күк капусы ярдәм иттеме? Ярмөхәммәтнең теләге кабул булды бит!

Җавап таң аткач кына билгеле булды. Кемдер Хөрминең утыртма читән лапасын аралап, юл ачкан, шул ярыктан бозаулар чыккан. Кәҗә берүзе калмас бит инде!

Хөрми Искәндәргә күрсәткән.

— Шул гына абзар басучы контр!— дигән.

Кичкырын силсәвиткә «контр»ларны чакыртып алдылар. «Контр» дигәннәре Зәйтүнә түти, Искәндәр булып чыкты. Әллә каян милиция Бәчели дә килеп житкән. Акт төзеп, Искәндәр белән Зәйтүнәне судка куярга булганнар. Авыл гөж килде. Күпләр пошаманга калды. Уйларга гына асат: Искәндәр белән Зәйтүнә түти өтерманга кереп утырсыннар әле! Уен эшмени? Иң җиңеле дигәндә дә маллар өчен бөтен штрафны алар җилкәсенә салачаклар икән, дигән хәбәр таралды.

Шөкер, эш судка ук барып житмәде. Укытучы Валия кәнсәләргә барып, Хөрминең тетмәсен теткән. Милиция Бәчели күзенә карап:

— Оятсыз ул Хөрмәтулла дигән кешегез,— дигән.— Озимьга кермәгән килеш малларны куып китте. Үзем күрдем. Казлар да овиннарга ерак иде. Хөрмәтулла иптәш бөтенесен бергә кудырганны күрдем.

Шуннан соң Сабир да, Бәчели дә, Хөрми дә йомшап төшкәннәр, имеш.

— Зәйтүнә апайның ире сугышта үлгән, ул нинди контр булсын?— дип Валия бик каты сөйләшкән.— Ике малае сугыштан кайтмаган. Как это сез вдованы, колхозницаны төрмәгә ябасыз? Искандер минем якында тора. Сосед ведь ул минеке. Мин күрдем, ул кичтән үк ятты. Йокларга... И беркем дә алар капкасыннан төнлә йөрмәде... Ә мин аларныкы капкасын тавышын таныйм. Мин төне буе дәфтәр тикшердем. Как это сез аларга без доказательств, ә?

Милиция Бәчели белән Сабир икесе генә калып, бик озак уйлашканнар да, унар сум штраф салып, Зәйтүнә түти белән Искәндәрне кайтарып җибәргәннәр.

Авыл иркен сулап куйды. Урамда булсын, булсын клубта, өйдә туры китерсәләр дә, очрашкан саен һәркем Валиягә рәхмәт укый.

Икенче көнне Валия Җәмига казларын да иреккә чыгарттырды. Хөрми белән Сабир:

— Түләп алсын!— дип мыгырданганнар икән дә, Валия шартлатып әйткән:

— Түләгән ведь инде! Әнә, бер казы үлгән. Шул житмәгәнме сезгә!

Хәлсезләнгән бичара казларны Кәримулла ипләп кенә куып алып кайтты. Үлгән бала казны Әхнәф бакча башына күмде.

Ике туган:

— Әнкәй тагын кыйнар инде!— дип бик нык кайгырышкан иде. Ярмөхәммәт белән өчәү кайтып кергәнгәме, Җәмига түти балаларына бу юлы сүз әйтмәде.

Бераз вакыт узгач, бозау-каз шаукымы тына төшкәч, Рәсүл Ярмөхәммәткә тиште:

— Беләсеңме, Ярмый, бозауларны мин аралап чыгардым аны!— диде.— Төнлә бозауны урларга дип килсәм, тыкрык ягында утыртма читән арасында сезнең кәҗә башы. Кысылганмы, читәнне мөгезе белән аралап чыгарга азапланамы, кызганыч итеп мәэлди: ирекккә чыгарсана, ди кебек. Кәҗәгезне бу якка чыгардым. Читән ярыгына Искәндәрләр бозавы башын тыкты. Берәм-берәм читәннәрне суырып алдым да бозау сыярлык иттем. Барысы да шул ачыклыктан качты...

— Искәндәрне утырткан булсалар?— диде Ярмөхәммәт.— Син дәшмәс идеңме?

Рәсүл төртелеп калды. Ул батырлыгы өчен Ярмөхәммәттән мактау көткән иде, ахрысы, аның шелтәле авазын ишеткәч, аптырап калды.

Кыңгырау тавышы Рәсүлне кыен хәлдән чыгарды.

Ана теле дәресендә Альберт Ярмөхәммәткә пышылдады:

— Ярмый, мин беркөнне күк капусы ачылганны күрдем. Түлке беркемгә дә әйтмә. Әби әйтте, күк капусы ачылганын күргәч, теләк теләргә кирәк, диде.

— Теләдеңме соң?— диде Ярмөхәммәт.

— Теләдем,— дип пышылдады Альберт.— Сугыштан әти исән-сау кайтсын, дидем. Биләсәпитем булсын, дидем. Офицер булсам иде дип, төне буе теләдем.

— Әх,— дип үкенечле әхелдәп куйды Ярмөхәммәт.— Кәҗә кайгысы белән «әти исән кайтсын» дип теләргә онытканмын!

— Һәй, ни пышылдашасыз анда, Альберт Төхфәтуллин белән Ярмөхәммәт Хәйруллин?— диде укытучы Фәгыйлә апа.

— Дәрес турында сөйләшәбез,— дигән булды Альберт.

Ярмөхәммәт уйларыннан аерыла алмады.

— Альбертның атасы да минем әти белән сугышка киткән. Бергә сугышка кергәннәр. Икесе берьюлы хәбәрсез югалган.

Әх, «әти исән кайтсын иде» дияргә онытылган!

Соң булса да Ярмөхәммәт эчтән генә:

— Әти исән кайтсын ие, әти исән кайтсын ие,— дип тели башлады.— И, күк капусы, җанкисәгем, зинһар өчен атам Хисбулла Айдулла улы Хәйруллинны исән-сау кайтар! И, күк капусы...

## Ыргак

Ярмөхәммәтләр өендә актык он бетте. Он димәсәң, хәтере калыр, көрпә иде анысы да. Көрпә булса да ашка тугыларга, алабутага кушарга ярап тора иде үзе.

— Яңа ипи бүләргә ашыкмый әле Сабирҗан абзагыз,— диде Нурлыгаян.

Ярмөхәммәтнең башына уй төште: урылмый калган басудан башак алып кайтырга!

Иртүк торып ул, беркемгә әйтмичә, арыш басуына элдерде. Башта зиратка керде. Зират таллары басу каравылчысы күзеннән саклый. Зираттан агачлыкка йөгерде, таллыкны узгач, арыш басуы. Юлдан читкә, эчкә кереп, иркенләп башак өзмәкче булды ул. Үзеннән бер карыш озын игенне ерып, эчкә-тирәнгә керә башлады. Шулай иелеп байтак

барганнан соң ул: «Менә хәзер Сабир түгел, атка атланган Хөрми дә күралмас»,— дип аякларын бөкләп, җиргә утырды.

Арыш арасы карурман кебек бит ул: серле, шомлы, матур. Янәшәдә генә зәңгәр чәчәкләр, пәйгамбәр гөлләре, күгәрчен күзләре үсә. Чәчәкләре ут яна. Аларга сокланып вакыт түгел. Ярмөхәммәт чәчәкләргә карамаска тырышып, утырган җирдән үрелеп, арыш сабагын аска иде, башагын өзеп, күлмәк арасына тутыра башлады. Башаклар төшмәсен дип, ул билбавын тагын да кысыбрак бәйләде. Башак тутырырга бөрмәле капчык алырга уйлаган иде дә, уеннан тиз кайтты: янчык белән башак күтәреп кайтканыңны теләсә кем күрәчәк. Ә болай күлмәк эчендәге башакларны кем шәйләсен? Үрмәләп, урын күчә-күчә ул шактый башак җыйды.

— Алиһәм, җаныкаем, зинаһар, гафу ит, синең белән күрешергә вакыт тар, өйдә ашарга бетте!— дип пышылдый үзе.

Җитәр, артык юан булсаң да сизүләре бар, дип ул урыныннан кузгалмак булды. Тарантас тавышы ишетеп, борылган иде, егылып үлә язды. Эчкә кергән саен ул аргы юл кырыена килеп чыккан, бер адымда гына юл, юл буйлап Сабир аты юырта.

Куркынычтан ераграк качсаң, куркынычның авызына ук барып чыгасың икән.

Ярмөхәммәт кыргый мәчедәй арыш куелыгына сикерде дә җиргә сеңде. Йөрәк субай сугучы агайларның «баба»сыдай каты дөпелди. Йөрәк тавышын Сабир түгел, бөтен дөнья ишетәдер сыман. Тотыла калсаң — бетте баш. Кәнсәләргә ябарлар. Төрмәгә утыртырлар. Әнисе бу кайгыга түзмәс. Ул Валия күзенә карый алмас. Бу юлы котылсам, мәңге дә мондый эшкә алынмас идем, дип ант итте Ярмөхәммәт.

Тарантас узып китте. Сабир юл кырыена яткан баланы күрмәде. Ат ерагайганын көтеп, Ярмөхәммәт озак ятты. Аннары әрәмә юлыннан таллыкка чаклы йөгерде. Таллыкка күмелгәч, туктап ял итте. Таллыктан зиратка, зираттан бәрәңге бакчасына сикерде. Галимханнар ишегалдыннан өйалдына керде. Инде котылды, шөкер.

— Уф-ф,— диде ул тау төшкәндәй.

Шулай сөйләнә-сөйләнә билбавын чиште. Билбаудан азат булгач, башаклар идәнгә ишелеп төшәргә тиеш. Ярмөхәммәтнең күлмәгеннән нибарысы биш башак төште. Бер-икесе күлмәккә ябышкан, бер-икесе ыштан бөрмәсенә кереп поскан. Шулкадәр күп тутырган иде бит ул арыш башакларын. Кая киткән соң алар? Ярмөхәммәт кабаланып күлмәген салып әйләндерде. Аңа дөньяның тагын бер сере ачылды: җиңнәр буйлап кылчыкларын артка таба каратып, башаклар чыгып качарга теләгәндәй бер-бер артлы тезелгәннәр, күлмәк кыймылдаган саен башаклар бераз алга шуыша... Шуыша түгел, атлый. Кылчыкларын аяк кебек терәп, башак алга таба йөри. Юлда кайтканда әнә шулай кыймылдый-кыймылдый, башаклар җиргә коела барганнар. Алар, җанлы нәрсә кебек, тоткынлыктан качканнар.

Башак алып кайтып, уып, киптереп, кул тегермәне аша тартып, Ярмөхәммәт ярма ясарга уйлаган иде. Ярма ясап, апасы белән анасын сөендерергә ниятләгән иде дә, барып чыкмады. Ул калган башакларны тавыкларга чыгарып ыргытты. Тавык халкы берсен-берсе таптый-таптый талаша башлады. Өлгеррәкләре башакны чукып ала да бар көченә читкә йөгерә. Алар тамак өчен җан талаша.

Тамак тәмугка кертер!

Ни газаплар белән җыйган ризык кул астыннан китте.

Ярмөхәммәтнең китек күңеле күптән тулып ашкан иде инде. Аңа олылар төсе бик иртә инсә дә, ул әле һаман бала; малайның ике күзеннән сыгылып яшь бөртеге чыкты. Кеше-кара күргәнче дип, ул тиз генә күз яшен кул сырты белән селтәп төшерде.

Алдавыч өмет рәхимсез ул. Башта бәләкәй генә булса да бәхет вәгъдә кыла. Вәгъдә үтәлер вакыт җиткәч кенә хыянәт итә. Алдавыч

өмет, вакытлыча гына яшәү ышанычы биреп, ымсындыра, соңыннан рәхимсез рәвештә алдый. Өметләре өзелгәч, адәмнәрнең рухы әнә шулай сына торгандыр.

Ярмөхәммәтнең үз гомерендә беренче һәм соңгы урлашу булды бу. Шушы вакыйганы ул гомере буе онытмас. Гомере буе бу турыда балаларына сөйләр.

— Урлашу теләсә кемгә файда китерми. Хәрәм юл белән кергән мал мантымый. Мантыса да соңра унысы белән чыгып китә. Ә син, Ярмөхәммәт, асат кергән байлык, ялгыш тапкан акча бөтенләй килешмәс. Юлдан ун сум тапсаң, йөз сум югалтырсың. Кызыкма син урлап баючыларга. Кызыкма сулдан кергән акчага. Син, Ярмөхәммәт, иңрәеп эшләп табарга тиешсең хәләл малыңны. Син бәдәнең, умырткаң, шытырдаганчы эшләп җыярга тиешсең маяңны. Синең язмышың шундый!

Юк! Моны сихри көч әйтмәде аңа. Бу сүзләрне бабасы Айдаш карт әйткәндер сыман.

Арыш урлаганы өчен, Василә белән Халисәне милиция алып китте. Бәдигылҗамал түти Ярмөхәммәтләрдә сөйләнеп утырды:

— Урлаганга түгел, кем Нурлыгаянкаем, Сабирга ярамаганга... Караңгы төшсә, Сабир шулар бакчасы аша йөри. Мескен кызларның йөрәге алынып беткән инде Сабирдан куркып. Әллә ничә тапкыр безгә кереп кундылар. Албастыдан куркабыз, дигән булдылар. Нинди албасты икәнен белмиләр, ди... Сабир төпчек кызга темиен сузып йөри... Халисәсенә... Минем белән бер йокласаң, бер пот он бирәм, дип әйткәң икән; билләһи, туймас айгыр булды бу Сабирҗан. Кыш буе ягарга утыннары булмады бичаракайларның. Узган кыш сәке тактасы яктылар. Маллары юк... Өтерманга ябарлар инде, ходаем. Ичмасам, яклар кешеләре дә юк. Аталары сугышта, абыйлары сугышта...

Ятимә кызларның арыш куырып яткан чакларын сагалап, Сабир белән Фәрхун пүнәтәйләр белән басып кергән, ди.

— Сабирның шулай кыланганын Ясиргә язмыйлармы икәнни соң?— диде Нурлыгаян.

— Һи-ии, Нурлыгаянкаем, ахирәткәем,— диде Бәдигылҗамал түти.— Язып нишләсеннәр? Сугыштан аны кем кайтара? Борчылмасын дип, ачка шешенгәннәрен дә язмыйлар алар.

— Шулай инде, шулайдыр...— дип ятимә кызлар өчен ут йотып, озак зарланыштылар хатыннар.

Ике кесә арыш урлауны Василә үз өстенә алган. Халык әйтә, имеш, Василә үзе уып алып кайткан да, үзе куыра башлаган, ди. Куштаннар: икесе дә тотылды, дип бара икән. Шулай да Халисәнең яше җитми дип, кайтарып җибәргәннәр. Василәгә ун ел ясаганнар.

Кеше күзенә күтәрелеп карарга да ояла торган бу ике кызны җәлләп күп кеше елады. Василәсе төрмәдә дә булсын, ди, ә Халисә ялгызы, ярым җимерек йортта ничек яшәсен дә, ничек тормыш итсен, ничек җан сакласын?

Аналары хастадан вафат, аталары сугышта. Хәбәре килмәгәнгә өч ел. Әллә исән, әллә юк. Абыйлары Ясир сугышның иң кайнаган җирендә, ди.

Судтан соң Василәне әз генә салам салынган арбага утыртып алып киттеләр. Һәр капка төбе тулы кеше иде. Бер сүз юк. Әйткән сүзләре үзләренә генә ишетелерлек. Ярмөхәммәт арбадан арттарак Василәне озата барды. Капка төпләреннән узганда аның колагына кешеләрнең пышылдаганнары ишетелә. Ләкин бу сүзләрне бары тик Ярмөхәммәт кенә ишетте.

— И-и бичара, и мескенкәем, исән-сау гына кайта күр инде... Ун ел бит, ун ел, аз гомер түгел,— ди кешеләр.

— Я раббем, үзең сакла кыз баланы,— дип дога кыла әбиләр.

Гарип фронтовиклар дәшми.

Куштан Фәрхун гына чәбәләнә:

— Карап калыгыз! Гыйбрәт булсын! Кул сузмагыз дәүләт милкенә!

Василә мескен ничек утырткан булсалар, кузгалмыйча, артка карагап килеш бара. Ул Фәрхунга да, капка төбендәге мышык-мышык елап калучыларга да карамый. Ул муенын сузып, түбәночка карый. Өч көн моннан элек ирекка чыгарылган сеңлесен, Халисәне эзли ул. Ярмөхәммәт тә Халисәне эзләшә. Ара-тирә каерылып артына борылып карый. Юк, Халисә күренмәде! Авылны чыкканчы шулай эзләнде Василә.

— И-и, бичаракай, бигрәкләр дә күп биргәннәр шул...

— Бер кесә арыш өчен... харап иттеләр кызны...

Василә, сеңлесен эзләүдән ваз кичеп, кычкырып жыр башлады: Ярмөхәммәтнең йөрәге жу итеп китте. Ачынуданмы, әйтер сүзе калмагангамы, әллә Василәнең зиһене чуала башладымы — ни булгандыр, ул бераз күтәрелә төшеп, бар көченә жырлый:

Мин авылдан киткән чакта
Зират талы шаулады.
Мин мескеннең халкайларен
Таллар гына аңлады...

— Тукта! Жырларга ярамый! — диде милиционерның берсе.

Олаучы абзый атка чыбыркы белән селтәнде, ике милиционер арбага сикереп утырды. Алар артыннан тузан болыты гына калды.

Мин авылдан киткән чакта
Зират талы шаулады...

Онытырлар, онытырга тырышырлар бу вакыйганы, әмма шушы жыр мәңге онытылмас.

Онытырлар. Битарафлар, гамьсезләр онытыр!

Онытырга тырышырлар. Гаеплеләр, жинаятьчеләр онытырга тырышыр!

Әмма Василә кызның авылдан киткәндә ярсып, соңгы көченә таянып жырлаган шушы жырын авыл оныта алмас. Киләчәктә Василәнең кем икәнен хәтерләмәсләр дә, бәлки, ләкин жырын ишеткән саен, һәркем бәгыре аша кичерер. «Василә жыры» булып ул бөтен халык күңелендә калыр.

Зират таллары шаулаганын ишеткән саен, зират турысыннан узган саен, Ярмөхәммәт ачынып, Василәне искә төшерер.

Василә шушы китүеннән кире кайтмас. Еллар узар. Амнистияләр дә булгалар, тик Василә турында гына бер хәбәр дә булмас. Шомлы әкияттәге Гыйфрит урлагандай, Василә юкка чыгар. Бар иде кеше. Юк булыр кеше. Аның шундый кара язмышы өчен һичкем жавап бирмәс. Һичкем үзен гаепле санамас. Кайда ул? Тәкъдире ничек? Ни булган аңа? Кыз бала нинди бәлаләргә очраган? Ачтан үлгәнме? Үзенүзе үтергәнме? Беркем дә әйтә алмас. Ун ел үтәр, утыз ел узар, кыз бала хәбәрсез югалыр.

Сагыш, бәхетсезлек, гаделсезлек билгесе булып, «Василә жыры» гына калыр.

Мин мескеннең халкайларен
Таллар гына аңлады...

Ярмөхәммәт Василәне мәңгелеккә алып китә баручы арба артыннан купкан тузан таралганчы басу капкасы янында басып торды. Туп бәрешле уйнарга чакырыпмы, әйдә, кайтыйк инде дипме, кемдер аңа дәште. Ярмөхәммәтнең үе күңел ачуда түгел иде, аның үе түбәночта, япа-ялгыз калган Халисәдә. Василә китте. Ул чынбарлыктан, авыл хәятеннән аерыла. Василә ерагайган саен күңелгә Халисә якыная бара. Ярмөхәммәт ындыр артлатып түбәночка, Халисәләргә томырылды.

Тизрәк! Тизрәк! Халисә янына ашыгырга кирәк. Ашыгырга кирәк. Бәлки әле соң түгелдер. Соң түгелдер!

Ярым җимерек, дөм караңгы, котсыз, ач өйдә япа-ялгыз калган Халисә янында булырга кирәк, ди Ярмөхәммәтнең күңеле.

Тыны капланганчы йөгерә торгач, ул Халисәләрнең бәрәңге бакчасына килеп житте. Җимерек читәнне узганда Ярмөхәммәт каралты-курага карады: Халисә күренмиме, янәсе. Ярмөхәммәт ишегалдына кергәч, тавыш бирде:

— Кы-хым! кы-хым! — янәсе,— кеше бар, керергә ярыймы?

Эчтән җавап килмәде. Урам якта тавышлар ишетелде:

— Өйдәме икән? — диде кемдер.

Ярмөхәммәт Рәүф тавышын таныды. Капка ачылды, ишегалдына Рәүф белән Галимхан керде.

— Бәрәкәт кенә икән! Син мондамыни? — диде Галимхан.

— Без сиңа эндәштек-эндәштек тә, монда чаптык,— диде Рәүф.

Кышкылыкка салам белән тышланган тәрәзәгә бактылар.

— Өйдә юк бугай,— диде Ярмөхәммәт.

Тагын ютәлләштергәләп, җай гына эчкә уздылар. Өйалдыннан ук фәкыйрьлек, мескенлек башлана. Ишекләр калшайган, ябылып бетми. Идән ярыкларыннан, өйалды астыннан җил исә.

Ярмөхәммәт өй ишеген тартты. Алар берәм-берәм эчкә уздылар. Өй эче дөм караңгы иде.

Аларның күзе тышта калган, шуңа күрә алар һични күрмәде.

— Халисә! Син өйдәме? — диде Галимхан.

Җавап юк.

— Халисә, бу без,— диде Ярмөхәммәт.

Бераздан, күз ияләшә төшкәч, күрделәр: идән сайгакларының ярты-сы юк, алар урынында караңгы баз авызы ыржаеп тора. Ташландык өй дә болай ук котсыз булмастыр. Сәке такталары да юк. Ян-якта ике кеше сыярлык кына урын калган. Шунда ертык бишмәт, мендәрсымак бер-ике сәләмә ауный. Өстәл дә юк. Сәкедә бер ярык бадьян, кителеп беткән ике агач кашык.

— Сайгакларны кыш көне утынга якканнар,— диде Ярмөхәммәт.

Рәүф стенадагы чөйләргә тотына-тотына бүлмәгә узды.

— Сак булыгыз, монда да сайгаклар юк!

Бераздан бүлмә эченнән Рәүфнең шомлы тавышы ишетелде:

— Ә-әсс... тәгы-ы...

Ул атылып-бәрелеп бу якка чыкты:

— Анда ... Халисә асылынган...

— Коткарырга кирәк! — диде Галимхан.

— Юк... ул инде... — Рәүф кулларын бутап нидер әйтергә теләде, ләкин сүзен әйтә алмады: ул укшый иде. Рәүф өйдән тышка чыгып китте. Ярмөхәммәт бүлмәгә керде, аның артыннан Галимхан да узды.

Кече як сәке өстендәге бишек ыргагында Халисә асылынып тора. Ул ярым тезләнгән хәлдә. Аның чырае имәнгеч сурәттә иде. Кайчандыр карап туймаслык чибәр кызның йөзе шулай ямьсез булып чалшайган: кызның йөзенә бакмаска тырышып, Галимхан бауны чишәргә дип сәкегә менде.

— Тимә! — диде Ярмөхәммәт.— Ярамый!

Кече як сәке өстендә ат аунаган кебек: ястык сүрүе ертылган, каз мамыгы бүлмәне тутырган. Агач чиләкләр тәгәрәп ята, берсенең колагы китек. Уклау урталай сынык, идәндә. Бүлмә тәрәзәсенең пәрдәсе өзелеп, ерткаланып беткән...

Дуслар якты дөньяга чыкты. Рәүф чирәмгә яткан килеш һаман укшый, коса. Галимхан да ап-ак, хәле китеп, җиргә чүгәләде.

— Авыл советына әйтергә кирәк,— диде Ярмөхәммәт.

Галимхан белән Рәүф, мунчада каты ис тидергән ярым миңгерәү кешеләрдәй, алпан-тилпән атлап, Ярмөхәммәткә иярде.

Василә кызның кара язмышы, әле генә төзәлмәс җәрәхәт булып, йөрәкләргә урнашкан иде. Халисәнең үлеме кинәт килеп керде сабыйлар бәгыренә. Бу үлем Василәне кинәт оныттырды.

Бер кайгыны оныттырыр өчен, олырак кайгы кирәк, ахрысы.

Өчесе дә дәшми генә барганда Рәүф абынып егылды. Ул:

— Алла-лла! — дип чыраен сытты.

Аның тез күмәче ташка бәрелгән иде. Әрнү шулкадәр куәтле иде ки, Рәүф шул әрнүне басар өчен баш бармагын каты итеп тешләде. Шундый каты тешләде, хәтта Рәүфнең башы калтыранып торды. Әрнүе уза төшкәч, карасалар: Рәүфнең теш эзләреннән кан ага. Бармактагы яра белән мәшгульләнеп, Рәүф тезен онытты. Бу авыртулар аны кире үз хәленә кайтарды, аның укшуы бетте. Рәүфкә хәл кергәндәй булды.

— Карале,— диде Галимхан Халисәне җирләп кайткан көнне.— Анда, бүлмә эчендә бөтен нәрсә кырылып беткән. Асылынып үлгән кеше шулай бәргәләнәме икәнни?

Ярмөхәммәт дәшмәде. Ул Бәдигылҗамал түти әйткәннәрне тәфсилләп искә төшерә иде.

— Раюннан чакыртырга кирәк ие,— диде Бәдигылҗамал түти Ярмөхәммәтнең анасына.— Бу Бәчели чуртымны беләмени соң ул? Белсә дә дәшмәс. Әллә үзе асылынган, әллә кеше аскан аны...

— Чү, Бәдигылҗамал,— диде Нурлыгаян.— Үзләре белә торганнардыр. Алар шуның өчен куелган. Тикшерерләр, белерләр...

Бәдигылҗамал түти, өйдә чит кеше булмаса да, алак-йолак карангалап алды да, Нурлыгаянның колагына пышылдады:

— Бу җә Сабир мөртәт, җә Фәрхун тәресенең генә эше...

Шул сөйләшүдән соң Ярмөхәммәт әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта, Халисәнең үлеме турында уйлый. Аның сизгер күңеле нидер тоя. Ни тоя? Үзе әйтеп бирә алмый. Бүлмәдәге әйберләрнең тузып, бәргәләнеп беткәнлеге турында да күп уйлый ул. Асылынган кеше алай каты бәргәләнер сыман тоелмады аңа. Сынык уклау, колагы китек чиләкләр аның сизгер игътибарын тарта.

Милиционер Бәчели, куштан Фәрхун, Сабирҗан, тагын бер ике пүнәтәй килеп, Халисәнең гәүдәсен төшерделәр. Асылынган кешегә ясин да, җеназа уку да тиеш түгел, дип Халисәне тиз генә җирләп тә куйдылар.

— Кайгысыннан асылынган! Асылынган и вчу! — диделәр беравыздан.

Хәтта иң беренче кем күргәнен, кем әйткәнлеген дә сораштырып тормадылар. Ни өчен бик ашыгычлык белән күмәргә теләделәр мәрхүмәне? Шулай тоелды Ярмөхәммәткә.

Олыгайгач, бик күп сулар аккач кына Ярмөхәммәт ап-ачык аңлар: Халисәне көчләгәннәр. Рәхимсез рәвештә яшь кызны талаганнар. Халисә бичара җан ачуы белән, хәлсез-ач килеш сугышкан. Көчләргә килүчеләргә агач чиләкне атып бәргән, уклау алып каршы торган, тырнашкан, тешләшкән, бәлки кычкырган-елагандыр, ялваргандыр, тәрәзә аша качарга омтылгандыр. Аны көчле куллар тәрәзәдән тартып алган. Аның газиз апасын ун елга хөкем иттеләр. Шул кайгыдан хәле китеп ятканда ялгыз өйгә мәкерле ният белән килеп кергән шәүләләрдән куркып, бәлки йөрәге ярыла язгандыр, бәлки кычкырырдай хәле дә калмагандыр...

Шуларны аңлар Ярмөхәммәт.

— Нигә шул вакытта Бәчели бездән сорамады икән? Нәрсәнең ничек, кайда ятканлыгыннан ук аңлап булган бит; ялгыз өйдә көчләү — үтереш булган... үтереш булган...

Ач сабыйны көчләп үтергән кеше җәзасыз калды. Дөньядан җәзасыз китәчәк. Исенә төшкән саен Ярмөхәммәт ачыргаланыр. Иллене тутырып, олы агайлар яшенә җитеп барганда алар тагын өчәү: Рәүф, Галимхан, Ярмөхәммәт дәшмичә генә капка төбендә утырыр.

Мул тормышта яшәгәндә, оныгы туып, Ярмөхәммәт үзе бабай булгач, шулай өчесе бергә утырганда әйтер:

— Сабир белән Фәрхун эше бу! — дияр.— Нигә без теге чакта бу турыда әниләргә әйтмәдек икән?

— Мин беренче күрдем,— дияр илле яшьлек Рәүф.— Халисә ыштанының бер балагы тез турысында әләгеп тора ие... Бала чакта башка килмәгән шул...

— Башыңа килсә, нишләр иең? — дияр Галимхан.

Ярмөхәммәт үз уеның дәвамын кычкырып әйтер:

— Фәрхунның маңгаендагы җөй — уклау эзе бит, җегетләр...

— Дөрес,— дияр Рәүф.— Халисә асылынганнан соң Фәрхун гел башын-күзен бәйләп йөрде. Имеш, урманда ботак тишкән.

Сабирның кырынганда «пәке кискән» җөйләре дә бик озак төзәлмичә йөргәнен хәтерлиләр дуслар. Алары Халисә тырнакларының эзләре. Димәк, алар икәү булган.

Төзәтә алмаслык яра, кире кайтара алмаслык заман, җәзасыз калган җинаятьчеләр турында уйласаң, акылдан язарсың, валлаһи.

Ярмөхәммәтнең уйлары Халисә фаҗигасе тирәсендә булса да, аннан читләшә барды. Чишә алмаслык мәсьәләдән ирекле рәвештә качу идеме бу, әллә фәлсәфи фикернең үзеннән-үзе үсүе, үзгәрүе идеме — билгесез; ул башкаларга да ишетелерлек итеп:

— Гыйсметдин абзый... яңа йортының түшәменә бишек ыргагы какканда... нинди изге, сөенечле уйлар уйлагандыр,— диде.— Якты өметләр белән корган тормышы шулай челпәрәмә килер, дип башына да китермәгәндер. Әле тумаган, хәтта ана карынында да яралмаган, исеме дә билгесез Халисә туар, аннан шушы ыргактагы бишектә тирбәлеп үсәр, чибәр кыз булып, буй җиткезер, шушы ыргакка ук асылынып үләр, дип кем уйлаган?

Өметләр баглап, хәләл көче белән җиткергән йорт-җир бер иясез үз урынында череп, нигезендә туфрак булсын, дип кем уйлаган? Кем каргаган?

Ул ташландык йортка күчеп утыручы да булмады. Утынга ягарга да сүтеп алмадылар. Сабир, Фәрхун әллә ничә тапкыр әйтеп-әйтеп карадылар. Юк! Бу шомлы нигезгә утырырга теләүчеләр дә, тарттырып алып китүче дә табылмады. Еллар узгач, Ярмөхәммәт ул өйгә кереп караган иде. Түшәмнәрне пәрәвез сарган. Сырмалар череп туфракка әйләнгән. Тәрәзләре череп, түшәмнәр җимерелеп төшкән. Бүмәдәге әйберләр ничек калса, шулай черегәннәр. Ыргак та үз урынында. Бавы да җепсел пәрәвезләргә әверелеп, асылынып тора. Коточкыч. Шом. Аяныч. Фаҗига. Барысы да бар. Беркая да китмәгән гаделсезлек эзләре. Ямаулы, ярык казанны гына кемдер урыныннан куптарып алып киткән. Казан урынын тыгыз җепсел сарган. Ярмөхәммәт тузанлы җепселләргә орынырга куркыпмы, сагышлы-фаҗигале өй иясен сискәндермәс өченме, бер урында бик озак басып торды.

Шушы мич авызыннан кайчандыр кап-кайнар бәлешләр, чыжылдап торган табалар көр-ишле гаилә табынына чыга торганнар. Берсеннән-берсе матур кызлары, егет булып җиткән уллары белән бәхетле Гыйсметдин, Сәрбиҗиһан киләчәккә ымсынып яшәгәннәр, мәрхүмкәйләр.

Хәзер нәселләре юк. Нигез корган, тузган.

«Кем гаепле соң?» дигәндәй, кирегә әйләндерелгән сорау билгесе булып, түшәмгә борып кертелгән бишек ыргагы җимерелеп төшәр вакытын көтә...

## Җиңү

Сугышның соңгы кышы бик авыр килде. Йончылган бәндәләр тагы да йончылды. Маллар ачтан интегә, сыерлар күтәрәмгә калды. Бичара-

ларны бау белән бәйләп, ферма өрлегенә асып куйдылар. Малларга түбә саламнарын ашытып бетерделәр. Хуҗалык маллары да тәмам эштән чыкты. Орлыкка дигән бәрәңгеләр ашалып бетте. Киптергән алабута да төкәнде.

Инде өзелдек, беттек дигәндә генә тагын яз килде.

Хайваннар да, кешеләр дә әле генә борын төрткән яшел кыякларга ябырылды.

Күчеп килгәннәр ашый дип, гөмбә ашап, аръякта әбиле-кызлы ятимәләр агуланып дөнья куйды.

Былтыргы арыш чүмәләләре урынында коелган арышны ашап үлүчеләр булды.

Тилебәрән орлыгы ашап, өч малай юләрләнде. Бичаралар үзләренүзләре белештерми, авызларыннан күбек агызып, күз алмалары зураеп, буыннары тота алмыйча йөрделәр.

Җыңү якынайганы сизелсә дә, халык билгесез бер шомлылыкта яши. Ашарга ярамаганны белсәләр дә, тагын берничә бала бүре җиләге ашап, башлары әйләнеп коса-коса күзләре атылып чыга язды.

Ашасаң да үләсең, ашамасаң да үләсең.

Имәнгеч хакыйкать иде бу.

Шул елны Валия белән Фәгыйлә апа районнан «Америкаң паегы» алып кайттылар. Паекны Сабир белән Фәрхун, үзебез бүләбез, дигәннәр иде дә, Валия каты торды:

— Паекны иң башта хәлсез балаларга бирәбез! — диде.

Калай савытлар, матур шарфлар, күлмәк-ыштаннарны укытучылар мохтаҗларга тигез итеп бүлделәр. Консерва дип аталган бу калайларның матурлыгы балаларны шаккатырды. Ялтырап торган кәгазьләргә диңгезләр, таулар, шарламалар төшерелгән. Әллә нинди әкияти дөнья иде бу калай савыт кәгазьләрендә. Балык һәм иттән бушагач, бу матур калай савытлар һәр өйнең түренә гөл савыты булып менеп утырды.

Боз китеп беренче такыр төшүгә кичке уеннар башланды.

Әлсерәп, йончып эштән кайта халык. Үз каралтысында бөтерелә. Көтү кайтып, мал-туар абзарга кергәч, олы апалар, әбиләр кул эшенә тотына: оекбаш, мамык шәл бәйли. Кызлар чигү чигә. Тәрәзә кашагалары, кулъяулыклар, челтәрләр...

Яшь-җилкенчәк таллыкка җыела.

Түбәночта бер уен. Югарочта икенче уен. Аръякта өченче уен.

Аръяк дип Зәйчәнең аргы ягындагы ике урам санала.

Өч уен берьюлы таралганда, Ярмай-Урак авылы шау-гөр килеп тора. Һәр гармунчы гармунын катырак тартып уйный. Һәр җырчы тамагын киеребрәк җырлый. Һәр сызгыручы әчерәк сызгырырга тырыша. Егетләр кочаклашып, зәңгәр тавышлар чыгарып җыр суза. Кызлар чәрелдәшә, егетләр айгылдашып көлә. Уен таралганда хәтта әтәч кычкырган, этләр өргән тавышлар ишетелми. Һава, дөнья, авыл өсте бары тик гармун-җыр, егетләр-кызлар тавышы өчен генә яратылган, диярсең.

Каян килә бу дәрт? Каян килә бу көч?

Тамаклары ярым ач. Өсләре дә ярым-ялангач. Эш белән иза чиккән яшьләр каян ала бу куәтне? Аптыраш!

Кайдадыр дөнья актарыла. Меңләгән кешеләр бер минут эчендә үлеп бетә. Кемнеңдер атасы, абыйсы шушы сәгатьтә үлемгә бара.

Дүрт ел буена бу егетләрнең, бу кызларның юньләп ашаганы, юньләп йоклаганы юк. Иңерәеп эшләү аларның көнен дә, төнен дә ала. Каян килә соң бу дәрт, каян килә бу куәт? Җырлыйлар, бииләр.

Бичара Нәдерша булып Нәдерша да егет хисабында йөри. Түбәтәен колагына хәтле кыңгыр салып, уенга кергән була, бигән була.

Ярмөхәммәт яшендәгеләр дә инде уенга төшә башлады. Буйлыраклары кыз тота, аулак өйләрдә кыз белән йоклый.

Ярмөхәммәт ачык хәтерли, бервакыт кичке уенда Нәдерша Валиягә атап җыр чыгарды. Түгәрәк уртасына Валия чыккач, тамак киереп, Нәдер җыр башлады.

Валия, алия шул,
Гөл яфрагын ия;
Матур кызлар күп дөньяда,
Җанкаем сине сөя...

Валия дә каушап калмады:

Аклы ситса төс яратам,
Ап-ак күлмәк киямен;
Әйтми генә йөри идем,
Мин дә сине сөямен...

Бик матур килеп чыкты бу кара-каршы җыр. Көтелмәгәнрәк булды бу. Нәдернең Валия кебек фәрештәгә җыр багышлавы — могҗиза. Алыптай фронтовиклар да Валиягә сүз катарга кыймый. Нәдер булып Нәдерша аңа җыру багышласын әле! Валиянең кинәт кенә аңа җавап җырлавы: мин дә сине сөямен, дип әйтүе дә могҗиза булды. Кемдер рәхәт итеп көлде. Янәсе, Нәдерша шаярып җырлады, Валия шаяруга каршы шаярды. Кемдер дәшмәде, бәлки, Валиянең чынлап җырлавы булгандыр?

Ләкин Ярмөхәммәт Нәдер белән Валияне янәшә күз алдына китерә алмый. Уен таралды.

Бичара Нәдерша, Валиягә ияреп, Зәйтүнә түтиләр капкасына чаклы кайткан.

— Их, Нәдерша, Нәдерша,— дигән Валия.— Минем ирем бар. Мин аны көтәм, үпкәләмә, Нәдерша...

Чыннан да, Валиянең атна саен солдат хаты алганын бөтен авыл белә. Шуңа күрәдер инде, фронттан кайткан егетләр дә аның янына килергә базмыйлар. Бу — Валияне аеруча сөю, аеруча хөрмәт итү, Валияне изгегә санау билгесе иде. Ире сугышта йөри, үлем эчендә. Көтсен тугры хатын. Моңа сокланырга гына кирәк.

Ярмөхәммәт әнә шулай аңлады Валиянең бүгенгә кадәр ялгыз йөрүен.

Ә Нәдер, бичара, буе җитмәс нәрсәгә тамгысын сузган шул. Ярамаганмы аңа үзебезнең авыл кызлары!

Валиядән шаярып кына булса да шундый җыр алгач, ышангандыр Нәдерша, ә баксаң, Валия ул җырны күрше кызларыннан өйрәнгән булып чыкты.

Валиянең Нәдершага шундый җыр җырлаганын ишеткәч, Ярмөхәммәт гаҗәпләнгән иде. Дөресрәге көнләшкән иде ул.

Валия белән Нәдершаның капка төбендә нәрсә сөйләшкәннәре авылга таралгач, Нәдерша бик нык үзгәрде. Аны танырлык түгел. Авыз күтәреп сүгенүче, тамак киереп акыручы, ямьсез-тәмсез сүзле Нәдершаны алмаштырганнармыни! Иңенә авыр кайгы төшкән ирдәй, салмак, аз сүзле булып китте ул. Рикәкәгә камыт суктырганы өчен Ярмөхәммәт аны бригадир Хәсәнша белән бергәләп бик каты орышкан иде. Җыр вакыйгасыннан соң Ярмөхәммәт аны кызгана башлады. Шул ук вакытта Нәдершаның төп башына утыруы аңа куаныч китерәме әллә?

Еллар узгач, ир уртасы булгач, Ярмөхәммәт тагын бер уйлар бу турыда. Уйлар да тагын бер сөенер. Валия Мәхәббәтнең үзе булган лабаса! Әнә шулай малай килеш укытучысына гашыйк булганы өчен сөенер ул. Бу илаһи мәхәббәт булган икән бит.

Җиңү язы коры килде. Чәчүнең соңгы көне иде бугай. Апалар Ярмай авылының ерак басуында кайтмыйча эшлиләр. Әбәтне шунда ашыйлар.

Валия класска керде. Ни гаҗәп, бүген ул гадәттәгечә исәнләшмәде.

Аның йөзендә шатлык уйный. Үзе елмая, үзенең күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы. Күзен йомса, яшьләр тәгәрәп чыгачак: укытучы апаларының елаганын балалар күрәчәк.

Бөтен класс Валиягә карап көтә: нидер булган, апа нидер әйтәчәк!

Валиянең керфекләре лачын канатларыдай бер талпынып алды: ике яшь бөртеге тукталып та тормыйча, тиз генә тәгәрәп идәнгә тамды.

— Балалар,— диде ул калтыравык тавыш белән.— Балалар, Берлинны алганнар! Полная капитуляция!

Шулай диде дә Валия ике учы белән битен каплады, өстәл янына утырды.

Кемдер кычкырып җибәрде:

— Һур-ра-а! Җиңү-ү!

Һавага түбәтәйләр очты, букчалар чөелде. Малайлар, нишләргә белмичә, бер-берсе белән сугыша, кызлар бер-берсен кочаклый.

Балалар ишегалдына ургылды. Укучылар ташкыны класслардан бәреп чыга. Кемдер быргы акырта, кемдер ярык барабан кага.

Укытучылар нидер әйтә, аларны берәү дә ишетми. Фәрзахетдин абый каты итеп кычкыргач кына, тавышлар тына төште.

— Сафланыгыз, балалар! — диде ул.— Сафланыгыз!

Балалар кыеш-мыеш рәткә тезелде.

— Укучылар,— диде Фәрзах абый.— Бүген безгә җиңү килде. Данлы Совет Армиясе хыянәтчел фашистик Германия гаскәрләрен тулысы белән тар-мар итте...

Тантаналы бу җыелыштан соң бер төркем укучылар ерак басуга җиңү хәбәрен илтә китте.

Ярмөхәммәт җыелышта Валияне күрмәде. Ыгы-зыгы арасында ул класска керде. Валия әле һаман шунда утыра. Кеше кергәнен сизеп, ул тәрәзәгә борылды. Елаудан шешенгән йөзен яшерергә теләде ул. Ярмөхәммәт, юк йомышны бар итеп, парта астыннан нидер эзләгән булды. Юатасы килеп укытучысына эндәште:

— Валия апа, сугыштан кайта башларлар инде,— диде.— Синең ирең Виктор абый да, минем әткәй дә кайтыр...

Валия кинәт борылды, күзен Ярмөхәммәттән алмыйча:

— Кайтырлар, кайтырлар,— диде.— Кайта башларлар... Синең атаң да, минем Виктор да...

Шул мәлне әллә ни булды. Валия Ярмөхәммәтне шашып күкрәгенә кысты, аннан үз яңагын Ярмөхәммәтнең битенә куйды.

— Кайтырлар...— дип пышылдый үзе.

Валия кычкырмыйча гына елый иде. Аның үксеп, аунап еларга теләгәнен Ярмөхәммәт сизде. Ләкин Валия куәт белән бәреп чыгарга теләгән үксү гайрәтен бугаз төерендә тотып торырга көч таба. Ә үзе аның саен Ярмөхәммәтне ныграк кыса.

Ярмөхәммәт бу сәерлекне берничек тә аңлата алмады.

Бөек шатлык — җиңү хәбәре килде. Шатлан, сөен! Шатлык эчендә, шушындый җан сыкравы булып, күз яшьләре тама.

Ярмөхәммәтне кочаклап елаганда укытучы Валия иренең дә, Хисбулла солдатның да исән түгеллеген белгән булган. Белгән — әйтмәгән. Үз кайгысы өстенә Ярмөхәммәтләр ыруына килгән хәсрәтне дә күтәрергә аңа кем кушкан? Вакытында әйтсә, берьюлы үтәр иде. Озак яшереп торкан саен кайгы олая барып, авырая барып, кинәт гаилә өстенә ишелер, дип уйламагандыр шул бичара Валия. Айдаш баба үлемен авыр кичергән гаиләгә тагын ата үлеме турындагы кәгазьне күрсәтергә курыккандыр инде. Шуңа күрә ул берьялгызы ике кара кайгы уртасында калырга ихтыярый риза булган.

Ихтимал, Валия ул чакта Хисбулла солдатның үлеме турында әйтмичә дөрес эшләгәндер. Ул гаиләгә кайгы алып килүче сыйфатында күренергә теләмәгәндер.

Күчеп килгәннәр әкренләп туган якларына китә башладылар.

Күчеп килгәнәрдән берәү генә китмәде. Укытучы Валия — Валентина Галай.

— Туган җирләреңне бер дә сагынмыйсыңмыни? Нигә иленә кайтмыйсың? — дип сораган аннан Зәйтүнә түти.

— Их, апа,— дигән Валия.— Сагынмаган кая! Бик тә сагынам. Ләкин безнең авыл юк шул. Анда хәтта җимерек өйләр дә юктыр инде... Ирем Виктор анда кайтса, мине табалмас. Урамнар да, йортлар да юк. Мин аңа бердәнбер адресым, сезнең авыл адресын җибәреп тордым. Моннан китсәм, ул мине эзләп шушында кайтыр. Очраша алмабыз, дип куркам. Яшим әле. Зәйтүнә апа... Аннан соң... Яраттым мин сезнең авылны... Яхшы кешеләр сез... Ә яманнар тиздән койрыкларын кысар... Сугыш бетәр, алла боерса, җиңүдән соң ирләр кайтыр. Фәрхуннар, Сабирларны алар порядокка китерер...

Шулай булырга тиеш иде. Ләкин әле Фәрхуннар, Сабирлар озак еллар рәхәт сөрер. Озак еллар ятимә солдаткаларга баш булыр. Озак еллар алар колхоз-дәүләт милкен үз милекләре белән бер итеп яшәр.

Авылда карт-коры байтак. Бала-чага да ишле. Хатын-кызлардан күп нәрсә юк. Сугышка алынмаган гарип-гораба, тилемсәләр дә җитәрлек. Шулар өстенә фронттан аксак-туксак, чулак-чукраклар кайта. Авыл күзгә күренеп гарипләнә.

Берьюлы ике йөз илле өч баһадирын озаткан авыл берән-сәрән кайтучыларын көтә. Тол хатыннар, ятим балалар эштә булса, эшеннән аерылып, Чаллы юлына карый. Көннәр буе, җәй буе күзләре күгәргәнче Чаллы ягына каерылып карый бичаракайлар.

Чаллы пристане тулы халык. Кайтучыга караганда каршы алучылар күбрәк. Монда очрашу шатлыгы да, югалту кайгысы да, хәбәрсезлек фаҗигасе дә — бар да бар, бу мохитне сөйләп аңлатырлык түгел. Һәр сабый: минем әти түгелме икән, дип пароходтан чыккан солдатка ташлана. Һәр хатын: ирем түгелме икән, дип солдат киемендәгеләргә өметләнеп карый. Ире кайтканнар, атасы кайткан сабыйлар, бүтәннәрнең кайгысын онытып куана, бәйрәм итә. Өметләре өзелгән сабыйлар салмак кына тарала. Икенче пароход килгәнче, дөнья беразга тынып кала. Борылмада яңасы күренүгә, халык дәррәү урыныннан кузгала. Өметләр тагын пароходка таба сузыла. Бер мизгелгә генә булса да, мондагы кешеләр — барысы да бер тигез. Барысының да өметләре бер дәрәҗәдә. Фронтовиклар төялгән пароходтан да сөекле нәрсә булдымы икән ул чагында? Пароход бәхет төяп килә. Әкрен килә. Ни өчен шулай әкрен йөри икән алар? Түземсезлектән йөрәкләре ярылыр бу кешеләрнең, дип уйламый микәнни соң ул пароход капитаны? Күпме кайгы-хәсрәт, күпме үлем күргән ирләрне төяп, бик тиз йөри алмас шул. Пароход уң якка янтайган, бөтен солдатлар да пристань ягына чыгып, култыксага тотынган. Алар да ашкына, төшеп йөзәрдәй булып кайта торганнардыр, җанкисәккәйләр.

Чаллы элеваторына икмәк китерә килгән Ярмәй авылы хатыннары да мәж килеп торган пристаньга төштеләр. Ләкин Ярмайга кайтучы булмады.

Шау-шулы, кычкырыш-елаш-көлешләре, пароходның моңсу тавышлары белән Чаллы артта калды. Боек хатыннар кул арбасы сөйрәп, дәшмичә генә кайта. Ярмөхәммәтнең анасы Нурлыгаян алда, аның артыннан Зәйтүнә түти атлый. Башка хатыннар әллә кайчан ярты юлга җиткәннәрдер инде. Алар пароход көтмәенчә кайтып китте. Ире кайтканнар, үле хәбәре алганнар пристаньда калмый. Зәйтүнә түти Нурлыгаянга иптәш булыр өчен генә калган. Аның ире сугышның беренче көнендә үк һәлак булган.

Зөләйха да сөйгән егетен көтә. Чаллыга килгән саен пристаньда

озак утыра. Бер-ике пароход каршыламыйча кайтып китми. Зөләйха ашыкмый. Йөк тартып килү дә, ачлык та аның хәлен алган. Бигрәк тә сөйгәненнән хәбәр булмау аны изгән, ахрысы, ул буш арбасын көчкә-көчкә сөйрәп кайта.

— И-и, замана,— диде Нурлыгаян Зөләйхага ымлап.— Бигрәкләр дә өзгәләнеп көтә инде Габделхәен. Булса да булыр икән... Сугыш башланасы көнгә туйлары билгеләнгән ие... Туй табыны озату мәҗлесенә әверелде дә куйды... И бәргәләнде инде бичара Зөләйха! Алмашына дип торабыз. Башта көлде-көлде, аннан Габделхәен кочаклап елады-елады. Габделхәйнең китәр вакыты җитте. Башкалар инде Калдау күпере янында. Бу Габделхәйне җибәрми... Каерып алдылар. Габделхәй дә нишләргә белми. Зөләйхасыннан ычкынып арбага сикерде. Атлар чабып китте. Зөләйха йөгерә... Мин дә сугышка барам, дип елый. Бәргәләнә. Күперга чаклы йөгереп барды... Җитәкләп алып кайттылар. Бигрәк читен аерылдылар, бәгырькәйләрем. Габделхәй арбага басып, Ак Борын тавында күмелгәнче кул болгап китте...

Зөләйха белән Габделхәй мәхәббәте Ярмай халкы өчен генә түгел, тирә-як өчен дә үрнәк икәнен Ярмөхәммәт сабый килеш тә сизенә иде. Аларның сөешеп йөргән заманнарын ул томанлы гына булса да хәтерли. Зөләйханың әтисе сугышка чаклы ук чирләп үлгән. Әнисе белән икәү генә калган. Ихатада ир-ат булмаса да Зөләйханың тырышлыгы аркасында, алар фәкыйрь яшәмәде. Аның уңганлыгы халык теленә күчкән:

— Әнә, Зөләйхага кара, җир җимертеп эшли...

— Әнә, Зөләйха кебек бул, аңа эш җиткезеп булмый...

— Зөләйха кебек ак итеп берәү дә кер юа алмый...

— Зөләйха суккан паласлар кебек паласлар базарда да юк...

Үз эшләрен эшләп бетереп, күрше-коланга ярдәмгә атылуларын кеше сөйләп, мактап туя алмый. Могҗиза инде ул Зөләйха, могҗиза...

Ярмайның иң мактаулы кызы Зөләйха булса, иң кәттә егете Габделхәй санала. Анысы да нәкъ менә Зөләйхадай уңган, ярдәмчел, кече күңелле. Ярдәм сорап килгән кешегә «юк» димәс, үзенә авырлык килсә-килер, әмма барыбер мохтаҗ кешенең сүзен аяк астына салып таптамас. Холык-фигыльләре белән генә түгел, Зөләйха белән Габделхәй төс-битләре белән дә бер-беренә бик охшаш.

— Боларны тәңре үзе никахлагандыр, шулкадәр дә пар килсәләр дә килерләр икән,— ди торган иде Айдаш баба да.

Була шундый затлар, андыйларны һәркем сөя, һәркем аларга хөрмәт белән карый. Зөләйха белән Габделхәй дә нәкъ шундый бәхетле затлар иде. Аларга сокланмаган кеше булмагандыр авылда. Әллә ничек килешеп, матур рәвештә яраклашып яши белә иде бу ике гашыйк. Авылның дорфа кешеләре дә аларга авыр сүз әйтми, алар турында яман сөйләми. Кан-кардәш булмаганнар да аларны үз итә, туганына караган кебек, якын карый. Бу ике саф күңелнең туй мәҗлесенә бөтен авыл чакырулы иде. Урамлап-урамлап туй уздырмакчы булдылар. Муллык бар иде, халыкның күңеле көр иде. Аларның бәхетенә ни дә булса комачаулар, дип һичкемнең уена килмәгәндер.

Шулай да алар турында сүз чыкса, карт-коры:

— Тефү-тефү, әстәгыфирулла, күз тия күрмәсен!— дип әйткәли.

Габделхәй фронтка киткәч, Зөләйха алмашына язды. Ул сагышлы халәтеннән чыга алмады. Эштә дә салмакланды. Элеккеге кебек ут өертми. Сабыр гына эшли. Шулай сагышлана торгач, ул моңарчы беркем дә ишетмәгән җыру җырлый башлады. Авылның колагы торды. Һәр көн, һәр кич Зөләйхалар ишегалдыннан яңа көй агыла. Авылның атаклы гармунчылары, бу көйне тиз арада отып, өздереп уйный да башладылар. Үзе җырлаганда Зөләйха сабыр була, берәрсе гармунда шул көйне уйный башласа, Зөләйханы тыеп булмый, елый. Көпә-көндез: «Габделхәй җаныкаем»,— дип саташа башлый.

Шулай бервакыт Зөләйха белән Габделхәй турында сүз чыккач,

Айдаш баба әйткән иде:

— Җете кызыл тиз уңар... Койрыклы йолдыз да артык якты, тиз сүрелә... Хәерлегә генә булсын инде...

Бабасының яманлап әйтмәгәнен Ярмөхәммәт белә, ләкин бу сүзләргә нинди авыр мәгънә салынганлыгын Ярмөхәммәт коточкыч фаҗига булгач кына аңлар.

Сугыш беткән елның көзе килде. Кама суы шакыраеп катты. Пароход туктады. Авылда хәбәр таралды: имеш, сугышчылар Әгерҗегә хәтле тимер юл белән кайталар икән дә, Алабуга турыннан боз өсләтеп Бәткегә чыгачаклар икән.

Төш вакытларында Зөләйха Ярмөхәммәтләргә керде. Күзләре зур булып ачылган, исәнләшергә дә онытып, ул:

— Нурлыгаян апакаем! Габделхәем, Чугунскига кайтам, Бәтке бозы аша чыгабыз, дигән... Синең дә Хисбуллаң кайтмасмы. Әйдә, зинһар өчен, Бәткегә китик,— дип ярым шашкан кыяфәттә ишекле-түрле йөренә.

Нурлыгаян:

— Төш авышты бит инде, төнгә каршы...— дип сүз башлаган иде дә, Зөләйха аны кочаклап ялвара башлады:

— Нурлыгаян апакаем, түзәрлегем калмады, шашам бит, бармасам, үләм бит мин...

— Чугунскига кайтып җиткәч, монда кайтыр инде ул, алла боерса. Әллә сабыр итәсеңме, Зөләйха?

Шулай дисә дә, Нурлыгаян риза иде инде:

— Әйдә, улым, син дә иптәш булырсың, ул хәтле җирне баргач-баргач, Алабуга базарына да сугылып чыгарбыз. Бабаң ясаган теге чабаталарны алып төш, мин сатарга бияләй алып барырмын...

— Мин сезне тегермән янында көтәрмен!— дип Зөләйха чыгып йөгерде.

Кар салмаган катканаклы юлдан бара-бара чабаталар «чәчәк атты». Эчендә җеннәр утырадыр, валлаһи, Зөләйха аруны белмичә юырта гына.

Ярмөхәммәтнең анасы:

— Ярты юлга җиткәч, Мәләкәскә кереп чәй эчеп чыгарбыз,— дигән иде дә, Зөләйха ишетергә дә теләмәде.

Караңгы төшкәндә Бәтке ярына килеп җиттеләр. Кама өсте шоп-шома — пыяла-боз. Алабуга ягыннан берән-сәрәнләп тә, төркем-төркем булып та солдатлар кайта. Аргы якта кара күч булып солдат җыелган. Барысының да аркаларында биштәр, кулларында чемодан. Бу якта хатын-кызларның чуты-кыры юк. Ат җигеп килгәннәр дә бар, хәтта бер машина да күренә. Кемдер сыерын-үгезен җиккән. Шаулашалар. Теге якта да чуалыш бара, ахрысы. Баксаң, теге яктан да, бу яктан да милиционерлар бозга кертми икән.

— Ярамый! Приказ! Барыгыз, өегезгә кайтыгыз! Караңгы төшә! Иртәгә такталар, баулар алып, коткару отряды килгәч чыгарлар,— дип аңлата нәчәлник.— Барыгыз, бар. Мунча ягыгыз, бәлеш сала торыгыз, иртәгә көндез кайтып җитәрләр...

Ләкин берәү дә кайтып китәргә теләми.

Шулай тарткалаша торгач, караңгы төште. Бәтке урысларына кереп җылынып чыга да, халык янә ярга килә.

Шулчак Зөләйха әче итеп кычкырды:

— Хә-әй! Га-абде-ел-хә-әй-йи...

Аргы яктан да тавыш килде:

— Зөләйха-аа...

Ни булганы да аңлашылмый калды. Милицияләр борыны төбеннән Зөләйха атылып боз өстенә чыкты!

— Га-абдекә-әй-и,— дип кычкыра, үзе тая-егыла каршы ярга таба йөгерә.

Каршы ярдан да бер гәүдә аерылды. Бу, әлбәттә, Габделхәй абый иде.

— Зө-өлә-әйха-а-а...— дип кычкыра-кычкыра солдат бозга сикерде.

Кемдер аны туктатырга теләде. Габделхәй бер селтәнү белән аны читкә этте. Зөләйха артыннан да ике милиционер бозга керде.

— Тукта! Тукта-а!— дип кычкыра бер милиционер.— Анда жылым! Боз юка-аа...

Габделхәйнең дә кирза итекләре таеп китте, ул егылды, үрмәли-үрмәли барды да янә аякланды. Зөләйха да юл уртасында егылды, ахрысы. Ләкин ул тора алмады, боз жимерелде...

— Аах! — дип кычкырды кемдер.

— А-а!— дип ике яр бердән сыкрап куйды.

— Зөләйха-а,— дигән үзәк өзгеч тавыш ишетелде.

Зөләйха боз кырына тотынды, аның шәле боз өстендә калган. Яулыгы жылым өстендә күренә. Габделхәй жылым кырына килеп, Зөләйхага кулын сузды. Ике кул мәңге аерылмаслык булып беректе. Ике якта да кычкырыш, командалар, сүгенү ишетелә. Караңгы куерып килә, боз өстендә ни булганы ачык күренми.

— Бау! Бауга йөгерегез!

— Колга-а, колга кирәк!— дип акыра начальник.

— Назад! Назад!

Караңгы эченнән су чапылдаганы ишетелә. Кара-кучкыл жылым авызын, аның янындагы шәүләне генә бераз шәйләп була.

— Эй, вы! Там живы? — дип кычкыра начальник.

— Помогите-е!— дигән тавыш ишетелде.

— Держитесь, солдат, держитесь! Хәзер бау китерәләр!

Габделхәй тагын бер-ике тавыш бирде дә, тончыккандагы кебек быгырдап, тынды. Жылым янында хәрәкәт бетте. Фонарь да, такта да, бау да килде... Таң атканчы халык таралмады. Кешеләрне кавышу түгел, жылымга жимерелеп төшкән Зөләйха белән Габделхәй язмышы борчый иде... Таң атканда күренде: жылым авызы зурайган. Батучылар тотынган саен кителә барган. Жылым өстеннән жиңел бу күтәрелә. Жылым кырында Зөләйха шәле сузылып ята. Кама буенда шомлы тынлык. Теге яктагы солдатлар да, бу яктагы солдаткалар да катып калган. Һәркемнең жаны елый иде. Сугышның беренче көненнән китеп, Берлинга хәтле барып та исән калган солдатның өенә кайтып житкәч шулай һәлак булуы, дүрт елның елын елга, аен айга, сәгатен сәгатькә санап көткән бичара яшь хатын Зөләйханың шулай мәгънәсез үлүе бөтенесен тораташка әйләндергән иде.

Иң авыры Нурлыгаян жилкәсенә төште. Авылга кайтып ул ни диярә? Фажигаларны күп күрде халык. Үлемен дә, гаделсезлеген дә күп татыды. Афәткә күнегә халык, әмма Зөләйха белән Габделхәй вакыйгасын ишеткәч, тетрәнмәгән кеше калмады.

— Син саклый алмагансың! Син фәлән итмәгәнсең, тегән итмәгәнсең,— дип Нурлыгаянны гаепләүчеләр дә булды.

Дәшмәде Нурлыгаян андыйларга. Бичаралар, ни әйтергә сүз табалмаганнан, акылга сыймый торган фажиганы жиңел генә кичерә алмаганнан әйтелгән сүзләр икәнен Нурлыгаян яхшы аңлый.

Гаепләмәде ул андыйларны. Унар, егерменешәр, утызар ел узгач та:

— И-их, ни караган сакчылар? Авыз ачып кеше батырганнар бит,— дип һәрвакыт уфтаныйрлар.

Үкенечле үлем һәрвакыт артыннан үкенечле сызлану калдыра.

Зөләйханың жырына тагын бәет өстәлде. Аның жырын да, бәетен дә авыл халкы һаман онытмый:

> Соңгы сулышым житкәнгә
> Боз өстенә атладым...
> Кама сулары бик салкын,
> Жылытсана, аппагым...

## Хәмидулла

Ике йөз илле өч ир озатып калган авылга егерме тугызы кайтты. Аларның да яртысы гарип. Сибгатулла абзый исән кайтып ике атна да

яши алмады, мәрхүм, яралары ачылып үлде. Шәяхмәт абзый да, аяк сөякләре бозылып, дөньядан тиз китте. Авыр яралыларны зират берәмберәм үзенә ала торды. Сау-тазаларын саный китсәң, уннан артмас.

Исәннәр үлгәннәр өчен эшли. Анда-санда яңа буралар ялтырый. Кичләрен гармуннар күбрәк уйный. Аулак өйләр, мәчет-клубтагы уеннар кызыграк, шаулырак уза. Кайткан шәпкә егетләр орден-медальләрен тагып, гимнастерка төймәләрен, каеш аелларын көл белән, ком белән ялтыратып, әллә кем булып йөрделәр дә погон-медальләрен салып, гимнастеркаларның җиңен сызганып, кулларына чалгы-балта тоттылар.

Сугыш бетте. Бихисап фаҗигале язмышлар. Җимерелгән гаиләләр. Шатлыксыз узган балачак. Ачлык. Үлем. Гариплек. Тән гариплеге бер хәл, күпме рухны сындырды бу сугыш. Күпме изге гадәтләрне челпәрәмә китерде. Матур-матур йолаларны кире кайтарып ала алмаслык итте каһәр суккан бу сугыш.

Еллар узгач, үзе авылның олпат атасы булгач, Ярмөхәммәт сугыш елларына туры килгән сабый чагын искә төшергәндә шулай уйлар.

Сугышка кадәр булган Ярмай-Урак авылы белән бүгенге, сиксәненче еллар Ярмай-Урак авылын чагыштырсаң, җир белән күк арасы. Аждаһатауга менеп бассаң, авыл үз урынында. Әмма үзгәрде табигать. Үзгәрде гадәтләр. Ямьсезлек ягына таба үзгәрде. Сугышка кадәр... Сугыштан соң...

Халык бай. Утызынчы еллар кулагы көнләшерлек бай яши Ярмай халкы. Кулакның нәрсәсе булган соң аның? Утызынчы елларда Себергә сөрелгәннәрнең малын санап карасаң — көлке. Бер аты, сыеры булса — кулак сыйфатында сөрелгән урта хәлле крәстиян булып чыга. Йорты биегрәк булса — кулак.

Бүген карасаң Ярмайларга: барысында да алты почмаклы таза йорт. Шәп абзарлар. Икешәр сыер асраучылар да бар. Егермешәр баш сарык. Икешәр мотоцикл, машина да машина.

Табигать фәкыйрьләнә, ишегалды байый.

Гасырлар буе камилләшкән йола-гадәтләр нык саклана иде.

Сугышка кадәр...

Сугышка кадәр авылда ир белән хатынның аерылышуы түгел, «аерылышу» сүзенең үзе дә юк иде. Кияүгә чыккансың, тор. Бала үрчет, гаиләңне ныгыт, ир тәрбия кыл. Өйләнгәнсең икән, нигез кор, сәке тутырып бала үстер. Балаларыңны һөнәргә өйрәт. Кияүгә бир, башка чыгар.

Сугышка кадәр ярты меңгә якын ир-ат арасында аракы эчкән кеше юк иде. Урамда авыз тутырып сүгенгән кеше булмады.

Һәр нәрсә картлар, аксакаллар белән киңәшеп, олылар ни әйтер дип, картлардан шүрләбрәк, аларны хөрмәт итеп эш йөртәләр иде. Үсмерләр, егет-җилән аксакаллар алдында авыз күтәреп сүз әйтмәс, акырып сөйләшмәс.

Иң аянычы — хатын-кыз үзгәрде. Бөтен бәла, бөтен олы афәт хатын-кызның хәттин ашуында. Ирләр фронтка китеп беткәч, авылга баш булып хатыннар калды. Алар ат җигә, арбага ике аягын аерып басып, чыбыркы болгап, дилбегәне тотып, ирләрчә сүгенеп җибәрәләр. Бик авыр чакларда аракы да капкалый башлады солдаткалар. Бер карасаң, кызык. Икенче карасаң — бәла. Тупасланды хатыннар. Тормыш авырлыгын алар әнә шулай әче сүгенеп җиңде. Ирләр кайтты. Ә гадәт калды. Дилбегәне хатыннар кире бирергә теләмәде.

Ирләр дә кинәт үзгәрде. Фронтовик егетләр аракы эчәргә өйрәнеп кайтты. Аракы эчү, ата-ана-баба-бала катнашкан сүзләр белән берөзлексез биш минут сүгенү ирләр-үсмерләр арасында дәрәҗә санала башлады.

«Юмарт хатын» төшенчәсе сугышка чаклы булмаган нәрсә. Ярмай авылы кёбек итагатьле, тәртипле авылда да сугыш башланып бер-ике

ел узуга, юмарт хатыннар күбәеп китте. Урам саен шундый «юмарт хатын» берәү. Ирсез бала табу, күп балалы хатыннарын аерып, бозылып йөрүләр гадәткә кереп бара.

Бу хәлләр өчен авылның өч мәхәлләсеннән калган бердәнбер указлы мулласы Шәрифҗан бик борчыла. Ачына-ачына вәгазь укый. Юк! Бу үзгәрешне хәле китеп бара торган мулла гына тыя торган түгел иде шул.

Шулай итеп, авыл сугыштан соңгы авыр чорына кереп китте.

Сугыштан исән кайткан ирләре, уллары шатлыгыннан Ярмай озак гөрләде. Ятим калган балалар да, ирсез калган толлар да, бөтен улларын югалткан әбиләр дә бәхетлеләр өчен шатланды. Бөтенесе өчен уртак бәхет иде бу җиңү.

Ләкин сугыш, агайлар тәнендәге җәрәхәтләр булып, елдан-ел үзен сиздерер. Җөйләнеп бетмәс борын яралар әледән-әле ачыла, сыкрый торыр.

Ерак басуда көлтә җыйганда Альбертка да бәхет килде. Күрше Нәсимә:

— Албирт, атаң кайтты!— дип әйтүгә, Альбертның көлтәсе төшеп китте.

— Ярмый, әйдә!— дип Альберт авылга томырылды.

Ярмөхәммәт соңгы көлтәсен чүмәлә башына куйды да, Альберт артыннан элдерде. Хәмидулла абзый, сугышның беренче көненнән үк хәбәрсез югалган кеше, кинәт кайтты да төште.

«Их, күк капусы ачылганда нигә мин дә Альберт кебек: әти исән кайтсын, димәдем икән?»

Шушы онытылган теләк Ярмөхәммәтнең гомерлек үкенече булып калды.

Хәмидулла абый кайткан көнне үк улына сугышка чаклы алган иске велосипедын көйләп бирде. Альберт белән Ярмөхәммәт велосипедта йөрергә бик тиз өйрәнделәр. Альберт бәхетле иде.

Кабахәт сугыш атлаган саен шул бәхеткә ямьсез чыраен күрсәтә башлады.

Кара гаугалы йортлар артты.

— Син, сволочь, мин фронтта кан койганда себерелеп йөргәнсең!— дип Сөнгать абый хатынын урамга алып чыгып кыйный.

Бу хәл Сөнгать абый эчеп кайткан саен кабатлана. Шундый еш кабатлана, күршеләре дә, авыл халкы да бу гауга, бу кыйнашка күнегеп бара.

Альбертның күктән теләп алган бәхете дә озакка бармады. Атна-ун көн узуга, алар өендә дә кара көннәр башланды. Хәмидулла абыйны сугышка чаклы бик шаян булган, диләр. Сугыштан бик холыксызланып кайтты. Мөхтәрәмә апа да кара коелды. Альбертны да исәп басты.

Сугышның мыскыллы көлүе өй җәнҗалларында гына түгел икән.

Имеш, Хәмидулла абыйны әсир булганы өчен, атна саен чакыртып сорау алалар икән. Ул районга киткәч, Альбертлар кан калтырап тора.

Сугышка чаклы Хәмидулла абый белән Мөхтәрәмә апа башлангычларны укыткан. Мөхтәрәмә апа әле дә булса укыта. Хәмидулла абый да сугыштан кайту белән укыта башлаган иде дә, эшеннән алып, аны мәктәптә ат караучы итеп куйдылар. Имеш, Фәрхун өстеннән язган:

— Пленда булган кеше совет мәктәбендә укытырга тиеш түгел!

Ике арада тарткалаш, нәсел-нигез корытыш байтак елларга сузылды. Ике каршы якны да изрәтте, талкыды... Хәмидулланы кимсетер өчен Сабир бөтен көчен җикте. Оста өйрәтелгән этләр кебек, куштаннар сыныкка сылтау табып, Хәмидулланы талый торды. Ызгышкан чакларда алар:

— Плинни син Хәмит! Халык дошманы!— дип Хәмидулланы җиңә. Шул сүзләрдән соң Хәмидулла абзый хокуксыз бер бәндәгә әверелә да кала. Чигәләре калкып чыкканчы теш казнасын кысып, дәшмичә генә кайтып китә.

— Ә-һә-һә-ә, телеңне аркылы тешләдеңме-е,— дип арттан өреп кала куштаннар.

Калдау җирдән бәрәңге бакчасы бүлеп биргәч, Хәмидулла кәнсәләргә китте.

Сабирҗан сөйләшеп тә тормаган:

— Сиңа калдаудан җир не положено!— дип кычкырган.

— Ни өчен?— ди Хәмидулла.

— Птаму ышто син плинний!

— Минем анам бар, хатыным, балам бар, алар пленный түгел бит.

— Не положено! И вчо!— дип Хәмидулланы кире борганнар.

Ярмөхәммәт еллар узгач, тел шартлатып куяр, ничек түзгән Хәмидулла абый бу изүгә? Барлы-юклы малларын уҗымга кермәс борын пуләвәй Хөрмидән тоттыру, барысыннан да күбрәк итеп ясак түләтү, Хәмидулланың апасы Зәйтүнәне күрәләтә кыерсыту, хәтта гөнаһсыз бала Альбертны эзәрлекләү дисеңме — камыл чабарга баргач, Фәрхун аның чалгысын, текә ярдан тотып аткан иде — түзә икән адәм.

— Фашист тоткынында да түздем, үзебезнекеләргә генә чыдармын,— дип әйткән Хәмидулла абзый Сабирҗанга.

Бу сүзне әйткәне өчен Хәмидулла абзый гомере буе үкенгәндер. Икенче көнне үк аны үзәккә, политотделга чакырып алдылар.

— Безнекеләрне син фашистлар белән чагыштырып сөйләп йөрисең икән! Нәрсә? Совет колхозы җитәкчеләре сиңа фашистмыни? Әллә син безне күз алдында тотып әйттеңме? Пленга төшүең җитмәгән, монда кайтып контр сөйләп йөрисең. Бәлки, син теге яктан шундый задание алып кайткансыңдыр?— дип Хәмидулла абыйны бер атна тотып чыгардылар.

Тора-бара, белеме җитми дип, Мөхтәрәмә апаны да укытучылыктан алдылар.

Фәрхун салган баштан мактанып йөргән, имеш:

— Мөхтәрәмәнең хан кызыныкы кебек кулларына көрәк-сәнәк тоттырдык әле,— дигән.

Сабирҗанның:

— Нигезен корытам, нәселен черетәм Хәмидулланың,— дигән сүзе ешрак ишетелә башлады.

Юк! Хәмидулла нәселенең корырга исәбе юк иде, ахрысы, Мөхтәрәмә икенче баласын тапты. Хәмидулла абый бу сөенечтән бөтен кайгыларын онытып, кая кушсалар, шунда эшләп, алынган эшне җиренә җиткереп башкара. Алтын куллы Хәмидулла, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер инде: ул балта остасы да, тире иләүче дә, матур итеп олтан салучы да, умартачы, балыкчы — барысы да... Бер тапкыр, сабантуй җыенына, Мөхтәрәмә апа белән Хәмидулла абый гел балыктан гына аш әзерләп, кунак сыйладылар. Балык шулпасы... камырга төргән балык... балык «тәкәсе»... табада куырылган балык... кабарга тозланган балык... элеп киптергән балык — нинди генә балык юк анда! Барысы да үзебезнең Зәйчәдән тоткан балыклар.

Хәмидулла абый йорт-җирләрен дә яңартып җибәрде. Балаларының өс-башларын да рәтләде. Хәмидулла токымы корырга түгел, җиргә нык басып, таза тормышта яшәргә исәпли иде.

Вакыт шулай, Зәйчә елгасыдай, җай гына ага торды. Сабирҗан белән Хәмидулла арасындагы низаг сүрелә төште кебек.

Ләкин бу сүрелү вакытлыча гына булган икән...

## Валия

Авыл үзенең яңа гадәтләре белән салмак кына яши. Бар да әйбәт шикелле. Ләкин тулы бәхет өчен нидер җитми. Җиргә, туган туфракка хуҗа булыр өчен дистәләгән ирләр кайтты. Яңа буын үсеп килә. Таллык

тулы яшь-җилкенчәк, сугышка чаклы туган балалар үсмер егет булып җитте. Әкренләп каралтылар да тернәкләнә. Шулай да нидер җитми авылга, кешеләргә, күңелгә нидер җитми.

Аң түрендә юшкын урнашкан, елга тугаеның бавырына урнашкан боз кебек, авыл кешесенең бәгырендә дә нидер бар.

Аз-маз юангач, фронтовикларның байтагы бәхет эзләп читкә чыгып китте. Күпләр паспорты булмаганга торып калды. Кайбер үткеннәре, паспорт-ние булмаса да, авылдан качты. Еллар буе сагынып, авылына кайтырга ясканып яшәгән кеше ни өчен соң туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр? Ачлыкмы аларны куа? Алай дисәң, бу халык ачлыкны күргән-белгән халык. Гомере буе ачлы-туклы булса да туган җирен ташламаган халык утыра монда. Ни өчен җирдән бизә халык? Хәтта авылга нәфрәт сүзләре әйтәләр. Сәбәп нидә?

Ярмөхәммәт элек — бала чакта — күңеле белән генә сизенә иде, хәзер ул аның сәбәбен төгәл белә. Җирдән бизмәде халык. Халыкны җирдән биздерделәр! Авылдан, туфрактан түгел, кансыз, гаделсез, надан вәкилләрдән, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы җитәкчеләрдән качты халык.

Сыеры булмаганнар — фәкыйрь хисабында; сыеры булганнар җан саклый. Сугыш елларында, сугыштан соңгы унъеллыкларда сыер асрау кебек батырлыкны теләсә кем булдыра алмый иде. Юк җирдән курмы табарга! Кышны кышлатырга, яз ке... малны ачтан үтермәскә! Мал асрау — җан асрау.

Бозау, бәпкә, мал карау тулысы белән сабыйлар җилкәсендә. Сабыйларның уйнар вакыты, бәхетле бала чагы әнә шул малларны карап узды.

Ярмөхәммәтләр дә кәҗәләрен сатып, бар булган акчаларын җыеп, тана бозау алды. Бозауны ашатып, сыер итәр өчен Нурлыгаян да, Факиһә дә, Ярмөхәммәт тә бер караңгыдан икенче караңгыгача алны-ялны белмичә эшли. Мәктәпкә хәтле эш, мәктәптә уку, мәктәптән соң тагын эш.

Ярмөхәммәт эш авырлыгыннан һичбер вакытта да зарланмады. Эш — аның өчен яшәү. Аның ике өмете бар. Ул әтисеннән хәбәр көтә.

Нурлыгаян да ире турында Хәмидулладан әллә ничә тапкыр сораштырды, йөдәтеп бетерде шикелле.

— Сез бит бергә сугышка кергәнсез. Хисбулла кайда калды соң? — дисә дә, бәхетсез хатын өметле сүз ишетә алмады.

— Кырык бердә үк сугышка кердек без,— дип Хәмидулла кырык-маса-кырык сөйләгәнен кабатларга мәҗбүр иде.— Безнең полк кырылып бетте. Үлмәгәннәр, яралылар пленга эләктек. Көненә уннарча атака кайтара торган идек. Анда мәхшәр, Нурлыгаян, җәһәннәм бит. Хисбулла белән без гел янәшә булырга тырыштык. Соңгысында немец башта һавадан бомба койды, аннары соң артиллерия белән дөньяны актарды. Баш калкытырга да чама юк иде. Кем үлгән анда, кем исән, шайтан да белми. Шул актарылышта өстә генә мина сызгырганы ишетелде. Бу минем башка гына төшә инде, дип уйлыйм... Калганын хәтерләмим. Аңыма килгәндә әйләнә-тирәмдә фашистлар гына иде. Аякка баскач, мин Хисбулланы бөтен концлагерь буенча эзләдем. Еллар буе лагерьдан лагерьга күчкәндә дә гел сораштыра идем. Юк. Хисбулла пленда юк. Монысы хак.

Үлгән хәбәре килмәгәч, өмет бар. Әнә, үлгән хәбәре килгәннәр дә кайтып төшкәлиләр.

Ярмөхәммәтнең икенче сөенече — Валия. Ярмөхәммәттән дә бәхетле кеше дөньяда юктыр кебек. Бәхетле, чөнки ул көн саен укытучысы Валия белән очрашып тора.

Буыннары ныгып җитмәгән үсмерләр иңрәеп печән чапканда, умырт-ка һәм кабыргалары шытырдаганчы зәһәр салкыннарда урман кискәндә үзләрен нинди өмет белән юатканнардыр, билгесез: ә Ярмөхәммәтнең күз алдында һәрвакыт Валия көч-куәт биреп тора. Дөньяда ул яшәгән

дә, бүген-иртәгә Валияне күрү мөмкинлеге булганда, авыр эшне җиңел була ул. Валия гәүдәсен ерактан күргәләгәндә дә Ярмөхәммәт ләззәт упкынына төшеп киткәндәй була. Җәйге каникулларда Валия каядыр китеп торганда Ярмөхәммәт һиндыба чәчәгенә карый. Чәчәк эченә уза. Дөньясын онытып, әкияти болыннарда йөри. Чәчәк Алиһәсе белән алар татлы шәраб эчә-эчә әңгәмә корып утыралар. Бу дөньяда сөекле Алиһә белән бер утырыр өчен мең җәза, мең авырлыкны җиңәргә риза ул.

Җирне кар каплагач, чәчәкләр кар астында калгач, Ярмөхәммәт озак кына сагышланып йөри. Кышның кыш буе үлем йокысына талган чәчәк Алиһәсе турында уйлана. Чәчәк Алиһәсен кыш буена Валия алмаштыра. Валия дәресендә утыру Ярмөхәммәт өчен чәчәк эчендә утыру белән бер. Дөньяда Валия яшәгәндә дөнья ямьсез була аламыни? Шуңа күрә Ярмөхәммәт җәен дә, кышын да ел әйләнә бәхетле.

— Валия апа сине ярата,— диде Альберт.

— Валия апа барыбызны да ярата,— диде Ярмөхәммәт.

— Валия апа барыбызны да ярата... Ә сине аеруча ярата,— диде Альберт.— Сер! Сер миндә генә, Ярмый!

Шул сөйләшүдән соң Ярмөхәммәт Валиягә сынабрак карый башлады. Чыннан да, Валия аңа аеруча ягымлы елмая кебек тоелды.

Икәүдән-икәү генә калгалаган очракларда Валия, җае чыкса-чыкмаса да зәңгәр чәчәк турында сораштыра башлады. Үзе көлемсери. Серле бу елмаю Ярмөхәммәтнең тынычлыгын ала. Әйтерсең лә Валия барысын да белә. Әйтерсең лә Валия чәчәк эчендәге Алиһәнең үзе. Сынар өчен генә чәчәк турысында сораштыра кебек. Валиянең көлемсерәгәнен Ярмөхәммәт шулай юрады. Белә Валия, чөнки ул үзе Алиһә. Белә, ләкин ни өчендер тел яшерә.

— Дөрес эшли!— диде Ярмөхәммәт үзалдына.— Дөрес эшли... Ярмөхәммәт, бу мин — синең Алиһәң, дисә, бер дә кызык булмас иде.

Валиянең елмаюында алар икесе генә белә торган сер бар.

Беркөнне Ярмөхәммәт калама арба белән камыл тартып кайта иде. Зират кырында Валияне күреп туктады. Җан тиргә батып кайтканда Валияне очратасы килмәгән иде аның. Ләкин Валия аның тир-тузан каткан йөзенә игътибар итмәде дә шикелле. Күрмәмешкә салышты кебек.

— Ярмухамет,— диде Валия.— Әнә, зират буенда никадәр хиндыба чәчәге. Действительно алар бик матур икән... Эчендәге кызның исеме ничек әле? Онытылган... Алияме?

— Алиһә,— диде Ярмөхәммәт.— А-ли-һә!

— А-ли-хэ,— дип кабатлады Валия.

— Син миңа шул Алихэ турында сөйләрсең, яме?

Ярмөхәммәт «ярар» диярга дә өлгермәде, Валия ике учы белән аның битендәге тирне сөртте, Ярмөхәммәтнең егетләрчә итеп үстерә башлаган чәчен сыйпады да мәктәп ягына атлады. Ярмөхәммәт упкынга төшеп китә язды. Ул ирексездән:

— Алиһә-ә,— диде дә арбасын тартып кайтып китте.

Чыннан да, чәчәк Алиһәсе турында сөйләргә уңай вакыт чыкты.

Кышкы әче таңнан аларга Зәйтүнә түти килеп керде.

— Ярмөхәммәт,— диде ул.— Без глубинкага барабыз. Валия төнгә ялгыз калырга курка. Син аңа иптәшкә кунарга керерсең инде. Мин әйтәм, ир бала булган йортка җен иялəшми, дим. Куркытып бетергәннәр аны әллә нинди албасты-пәриләр белән. Җеннән түгел, хәзер бәндәләрдән куркырга кирәк, димен... Син, үскәнем, оныта күрмә инде, җәме. Мин аңа әйтеп куйдым, син керәсең, дидем. Әйдә, Нурлыгаян! Башкалар юлдадыр инде. Алардан калырга ярамый.

Хатыннар кабалана-кабалана чыгып китте. Ярмөхәммәт абзарга кереп, мал асларын караштырды, тизәкләрне бер кырга өеп, юеш тиресне сәнәк белән алып, коры салам таратып җибәрде. Сәндерәгә менеп, тилмереп мөгрәгән башмак танага бер-ике учма камыл ишеп тө-

шерде. Аннан-моннан капкалап, мәктәпкә йөгерде. Соңгы дәрес беткәч, Валия апа:

— Ярмухамет, сиңа Зәйтүнә апа әйттеме?— диде.— Кил, озак торма!

Малларга төнгелеккә камыл ташлап, Ярмөхәммәт Зәйтүнәләргә йөгерде. Капка келәсенә юри каты басып, капканы юри каты ябып, өйалды тактасына аяк каккан булып, юри дөбердәп, ишек янына килде. Бу: «Кеше керә, узарга рөхсәтме?»— дигән сүз иде.

— Әйдә, әйдә, Ярмухамет, кер!— дип Валия ишекне ачты.— Только сразу капканы бикләп куй!

Ярмөхәммәт җәһәт кенә капкага аркылы тәртәне салып керде. Валия аны караңгы өйалдында көтеп тора иде.

— Тизрәк!— диде Валия.— Суык кермәсен!

Ишекне ачуга, аяк астыннан болыт булып салкын керде. Салкын болыт өйгә кергәч, кая барырга белми йөрде дә, таралып, эреп юкка чыкты. Өй эче җылы иде. Борынга тәмле ис бөркелде. Өстәлдә бер коштабак кыстыбый өелеп тора. Самавыр кәттә егетләрдәй, чәйнеген кырын салып, салмак-сабыр гына, эчтән генә әллә нинди матур-дәртле бер көй шыңшый иде.

— Мактап кына йөрисең икән!— диде Валия.— Чишен!

Ярмөхәммәт уңайсыз хәлдә калганлыгын сизде. Мәктәптә ул Валия күзенә туры карый ала иде. Монда әллә ничек. Аның бу халәтен Валия дә тиз аңлады.

— Тартынма, тартынма, сал өстеңне!— дип, Валия Ярмөхәммәтнең бишмәтен салдырып, чөйгә элде.

Валия чәй әзерләп, бүлмә белән өстәл арасында йөргәндә, Ярмөхәммәт каш астыннан гына карап: «Бигрәк җиңел гәүдәле бу Валия апа. Күбәләк кебек. Мәктәптә өс киеме белән юан күренә. Күлмәкчән, алъяпкычтан әнә ничек, тал чыбыгыдай сыгылмалы... Һе, җәй көне гел күлмәкчән йөрсә дә, болай нәзек сыман күренми иде. Пәлтә астында озак яшеренеп ятканга шулай матур булып күренәдер аның гәүдәсе»,— дип уйлады.

— Житеш!— диде Валия.— Кыстыбыйны үзем пешердем. Валлахи, менә! Зәйтүнә апа өйрәтте. Ул миннән повар первого класса ясап бетерде инде. Мин бәлеш тә сала беләм. Токмач та кисә беләм. Башта кулымны кисәрмен дип курка идем, хәзер у-у-у, выжлатам гына.

Ярмөхәммәтнең тарсынуы бетте. Чәй эчкән арада уку хәлләре турында да сүз булып алды. Аннан соң Валия фотоальбом чыгарды.

— Монысы әнием... Күченгәндә... бомба астында калды...

— Бусы абыем... Абыем сугышта үлде...

Валия рәсемнәргә аңлатма биргәндә бөтенләй үзгәрде. Житдиләнде, аны сагыш басты кебек... Аның ерак-еракка, туган иленә, әнисе, туганнары янына кайтып киткәнлеген Ярмөхәммәт сизде. Валиянең җисеме монда, күңеле туган илендә...

— Монысы ирем!— диде ул.

Рәсемнән хәрби кием кигән яшь кеше карап тора.

— Виктор!— диде Валия.— Виктор!

Әллә ул иренең рәсеменә дәште, әллә Ярмөхәммәт хәтерендә калдырсын дип иренең исемен кабатлады, әллә сагынуының тышка бәреп чыгуы идеме — Валия тирән көрсенде дә, Ярмөхәммәтне кочаклап:

— Беләсеңме, Ярмухамет,— диде.— Виктор да вафат!

— Ничек?— дип сораганын сизмәде дә Ярмөхәммәт.— Син бит аны һаман көтәсең... Бөтен кеше шулай ди. Ире кадровый офицер, шуңа күрә һаман кайтармыйлар икән, диләр.

Валия Ярмөхәммәтнең битен үз яңагына кысты да үксеп:

— Юк, Ярмухамет...— диде.— Викторның заставасы сугышның беренче сәгатендә үк юкка чыккан. Берсе дә исән калмый...

— Ә хатлар? Сиңа бит гел хат килеп тора.

— Хатлар...

Валия кечкенә тартмадан бер уч хат алып, сәкегә ташлады.

— Бу хатларны мин үзем язып, районга баргач, үземә сала идем. Укы... теләсәң...

Валия хатның берсен ачты, ачты да Ярмөхәммәткә сузды: хат эче буш, ап-ак кәгазь иде.

— Булды, җитте,— диде Валия кинәт кенә.— Балавыз сыгып утырмыйбыз.

Ул җәһәт кенә фотоальбомны, үзе язган буш хатларны җыеп куйды.

— Ятарга вакыт!— дип тиз генә урын җәяргә тотынды.— Знаешь, Ярмухамет, безнең өй тиз суына. Бревнолары картайган инде... Без сәкегә ятарбыз... Җылы булыр... Мин стенага карап ятам, син миңа арканны терәрсең, ярый? Стена аша җен керә алмый, ә арка яктан син сакларсың, ярый?

Ярмөхәммәт көлде.

— Шайтан керсенме монда? Җеннәр хәзер үзләре кешедән качып йөри...

— А мне нравится, что ты такой храбрый,— диде дә Валия утны сүндерде, ишекләргә келә элде.

Аркага арка терәшеп урынга яткач, Валия:

— Ә хәзер хиндыба чәчәге турында сөйлә,— диде.

Нәрсәдән башларга икән инде, дип Ярмөхәммәт бераз дәшми ятты да, гомумән, чәчәкләр турындагы уен әйтергә булды.

— Дөньяда мең төрле чәчәк бардыр... Кешеләр күзгә кереп торган, иң ачык төслеләрен генә сайлый. Бакчаларда да, өйләрдә дә гел җете кызыл яраннар, баяр гөлләре үсә... Зур чәчәкле гөлләрне өзеп, чүлмәккә утырта халык. Кешеләр күрми торган чәчәкләр дә була. Күрсәләр дә игътибар бирмичә яннарыннан узып китәләр. Күрәләр аларны кешеләр. Күңел күзе белән генә карамыйча узалар... Юл буенда зәңгәр чәчәкләр бихисап. Аларны күрүче дә юк... Күгәрчен күзе дигән чәчәкнең дөньяда барлыгын белмәүчеләр дә күп...

— Шундый чәчәк бармы?

— Бар. Ул чәчәкне берәү дә күрми торгандыр. Күгәрчен күзе ул борчак чаклы гына, борчактан да бәләкәй булыр әле. Үзе нәкъ күгәрчен күзенә охшаган.

— Күгәрченнең күзе нинди була соң?

— Һе, күгәрченнең күзе күгәрчен чәчәгенә охшаган...

Валия, көлде. Ярмөхәммәт тә көлде.

— Кызыл ясмыкка охшаган күгәрченнең күзе. Юк-юк, кызыл ук түгел, матур алсу, уртасы зәңгәрсу... Кешеләр мәшәкатьләр белән каядыр ашыга. Кайгы, авыр эш баскан кешенең күзенә күгәрчен күзе чалынамыни? Шатлыктан шашканнар туктап, һиндыбага карап торамыни? Меңләгән, миллионлаган бәндәләр шул матурлыкны күрми уза. Шулай игътибардан читтә калганнарына бу чәчәкләр бик кимсенәләрдер. Ләкин беркайчан да: менә мине күрегез, менә мин нинди матур, дип күзгә бәрелмиләр. Алар, чыннан да, бик матур. Караган саен карыйсы килә ул кечкенә чәчәкләргә.

«Чәчәкләр... чәчәкләр... гөлләр»,— дип Ярмөхәммәт гел бертөрле тавыш белән сөйли дә сөйли.

Сөйләми ул, ишеттереп уйлый. Ә Валия аның уйларын укый бара. Яшьли олылар төсе иңгән, сабыйлыктан кинәт балигълыкка күчкән, олылар эшли алмаслык авыр эш эшләп, атлау рәвешендә дә олылык күренә торган бу үсмернең башында әнә нинди уйлар кайнаша икән! Валия укытучы түгел бу юлы, бу кичтә Ярмөхәммәт аның остазы. Ачлык-ялангачлык мохитендә кеше күрмәгән гүзәллекне күрергә, дөньяны аңларга, күнегелгән төшенчәләргә, күз күнеккән нәрсәләргә яңача карарга Валияне үсмер өйрәтә түгелме соң? Караңгы шомлы төндә сер-

ле-серле тавыш белән могҗизалар кешесе чәчәкләр турында сөйли. Валия, чыннан да, үзеннән олы кеше янында яткандай хис итте. Ул үзе дә сизмәстән аркасына борылды. Ярмөхәммәт тә түшәмгә карап ята иде. Бераздан ике йөз борынга борын килде. Ярмөхәммәт Валиянең күз алмаларына бакты. Тәрәзә аша кергән сыек яктылык үз эшен эшләде, Валиянең күзләре Алиһә күзләренә әверелде. Ярмөхәммәт янәшәдә ятучы хатынның чып-чын үз Алиһәсе икәненә инанды. Һич тарсынмыйча, борын очын Алиһә борынына тигезде. Алиһәнең күз алмалары зурайганнан зурая барып, Ярмөхәммәтне үз эченә ала башлады.

Алиһә үзе Ярмөхәммәтнең эчкә керүен тели иде.

— Алиһә!— диде Ярмөхәммәт.

— Алай әйтмә,— диде Алиһә.— Алиһәм, диген. Миңа шулай рәхәт.

— Алиһәм!— диде Ярмөхәммәт.

— Ашык-ма-а... са-абыр гына-а...— диде Алиһә.

Чәчәк эчендә бөтен бер гомер кичерде ул. Булса да булыр икән могжиза! Бөтен дөньяда икәүдән-икәү генә. Атналар, айлар узды кебек. Еллар үтте. Алар чынбарлыкны онытты. Алар матдә булудан туктады. Алар бардан юк булды.

Бәлки, алар бардан да баррактыр?

Әнә шундый уй Ярмөхәммәтне чынбарлыкка кайтара башлады. Дөрес, алар бардан да баррак. Торырга кирәк. Ашыгырга кирәк. Эшләр күп. Малларны карыйсы бар.

— Ашыкма-аа...— дигән өн ишетелде.

Ярмөхәммәт, шул өнне ишеткән саен, әллә ничә тапкыр бардан юк булды. Янә йокы сихеренә уранды. Соңгысында ул авырлыгын югалтып, чиксез бушлыкка чумды. Бушлыкта очу бик озакка сузылды, аска таба оча торгач, Ярмөхәммәт бутала башлады, әллә ул аска төшә, әллә өскә оча — билгесез. Шулай бихисап озак оча торгач, аның күңеленә шом иңде. Шушы шомнан куркып, ул кычкырырга теләде. Ләкин тавышы чыкмады. Бары тик ыңгырашу гына ишетелде. Куркудан ыңгыраштымы ул, әллә очу рәхәтеннәнме шулай ыңгырашу катыш ләззәт авазы чыгарды; бушлык төбенә килеп бәрелдем дигәндә генә ул үз тавышына үзе уянып китте. Башта аңламыйча торды. Кай җирдә соң ул? Өенедәме, төшендәме? Әллә һаман чәчәк эчендәме? Аның бите җылы, йомшак нәфисләккә төртелгән. Бу Валиянең ярымачык күкрәге иде. Валия бер кулын Ярмөхәммәтнең муены астына куеп, икенчесен аның битенә салып, изрәп йоклый. Тышта таң атып беткән. Ярмөхәммәт шунда гына чынбарлыкка әйләнеп кайтканлыгын аңлады. Абзарны чистартырга, малларга ашаргаэчәргә салырга кирәк, дип ул иплəп кенә Валия куеныннан чыгарга теләп, билендә ихтыярсыз яткан кулны алып куйды. Валия йокы аралаш нидер әйтте дә ике кулы белән Ярмөхәммәтне кочаклап, күкрәгенә кысты. Мәңге кузгалмас иде ул шушы урыннан, мәңге чыкмас иде ул Валия куеныннан. Ярамый! Эш бар, уку бар, маллар бар.

Валия уянды. Ярмөхәммәт ләззәтле беләкләр коллыгыннан ирекка чыкты.

— У-у, уже светло!— диде Валия, аннан соң берни булмагандай:— Знаешь, Ярмухамет, мин төшемдә синең белән чәчәк эчендә йөрдем,— диде.

— Мин дә,— дип әйтмәкче иде Ярмөхәммәт, тыелып калды.

— Словно, без синең белән мәңгегә чәчәк эчендә икән...

«Бер төшне ике кеше берьюлы күрә микәнни? Гаҗәп, мин дә шуларны ук күрдем бит»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Бәлки, бу төш түгелдер?..

...Зәйтүнә апаны тагын глубинкага җибәрделәр.

Глубинка икмәге беткәч, әле урман кисәргә, әле кәнсәләрдә төнге дежур торырга, чираттан килгән төнге көтүгә йөрттеләр Зәйтүнә апаны.

Бу җәй килгәндә Ярмөхәммәткә тәмам егетләр төсе кунды. Тавышы

калынайды, ул сөйләшкәндә күрше-күлән:

— Әстәгыфирулла, әллә нинди ир-зат кергән, дип торам, гел егет булгансың син, агай!— дип еш кабатлыйлар.

Ярмөхәммәт анасыннан яшереп-посып кына бабасының сакал пәкесе белән кырына да башлады.

Иртә таңнан өй эшләре белән бөтерелә халык. Аннан мал-туарын карый. Сыер сава, көтү куа, тавык ашата. Урак ура. Утын кисә. Тагын өйгә кайта, тагын каралты-кура тирәсендә зык куба. Районнан һәр атнаны вәкил килә. Бәрәңге агенты, заем агенты, недоимка агенты, страховой агенты, хәтта кысырлык буенча да акча җыярга агент килә.

Аулак өйләрдә, кичке уеннарда, утырма кичләрендә әнә шул мәшәкатьләрдән онытылырга тырыша халык. Шуңа күрә иң авыр елларда халык күбрәк күңел ачкан, ешрак шаярган, күрәсең.

Ярмөхәммәт, боларның барысын да үз башыннан кичергән кеше буларак, тук-мул тормышта яшәгәндә сәерсенеп уйланыр: ач, ялангач, ятим чакта кешеләр миһербанлырак, бер-беренә ярдәмлерәк булган икән. Тук, мул тормышта зарланучылар күбрәк. Имәнгеч бер мантыйк барлыкка килә: димәк, тук тормыш кешене боза гына түгелме?

Укытучы Валия кызык кеше булып чыкты ул. Башка укытучылар — читтән килгәннәре дә, мондагылары да — укыту, дәфтәр караудан гайре авыл тормышына катнашуны хупламыйлар кебек. Ә Валиягә бөтен нәрсә кирәк, аулак өйләр дә, кичке уеннар да, утырмалар да — барысы да кирәк.

Ярмөхәммәт, кырыктан узган кеше, «Комсомольская правда»да Валентина Галай язган мәкаләне укып шаккатыр. «Тылда күргәннәрем» исемле бу язмада Валиянең сүзләрен, уйларын укып, Ярмөхәммәт Ярмай халкын тагын бер тапкыр олылар.

Бу нинди кешеләр икән татарлар? Җеннәре өзелгәнче эшләп авыр эштән кайталар да, җеннәре өзелгәнче үз ихаталарындагы авыр эшкә тотыналар. Аннан соң кичке уенга төшеп, җирне селкетерлек итеп биилар. Урамнарны яңгыратып җырлыйлар, әйтерсең лә дөньяда сугыш та булмаган. Әйтерсең лә аларның бер бөртек кайгылары да юк, һәм булмаячак та... Гаҗәп батыр, искиткеч матур халык яши Ярмай-Урак авылында...

Әлбәттә, шулайдыр. Әмма Ярмай халкы үзе генә белә инде ул авырлыкларның ни икәнен.

Кайгысын яшерер өчен көлә иде халык. Бәгыре өзелгәнен кеше күрмәсен дип, шаян такмаклар чыгара иде. Яшәү белән үлем арасында елау ярдәм итми. Кире чыкмас тарлавыкка кергәннәр өчен зарлануның кирәге юк. Кычкырып көләргә, елмаеп үләргә генә кала. Бу халык шулай яратылган, күрәсең. Алар көлә, кызыктан түгел, бәлки, аянычтан көләдер. Кем белә, бәлки бу кешеләр үз тәкъдирләренең әче булуыннан шулай әче итеп көлә торганнардыр? Ихтимал!

## Өрәк

Әнә шундый авыр тормышта, әче язмышта яшәгәндә бөтен кеше теленә керерлек бер яңалык кирәк. Гадәттән тыш бер вакыйга, кеше ышанмаслык могҗиза тели күңел. Койрыклы йолдызмы, гыйбрәтле берәр вакыйгамы — ни дә булса кирәк.

Андый вакыйга булмаса, кешеләр аны үзләре уйлап чыгара...

Сугыш күптән инде бетте. Кайтасылар кайтты. Хәбәрсез югалганнар хәсрәте дә урамнан өйләргә кереп посты. Хәзер гел бертөрле авыр тормыш башланды, рәхимсез көрәш, яшәү өчен көрәш кенә торып калды. Эшнең очы-кырые күренми. Кыен хезмәтнең бетәсе дә юк. Алны-ялны белмичә, шифаханә, курортларны күрмичә иңрәеп эшләр бу халык. Ә күңел үзгәреш тели. Һич югында хәбәр көтә.



А. Тимергалина рәсеме.

Энә шундый чакта бер хәбәр Ярмай халкын тетрәндерде. Имеш, асылынып үлгән Халисәләрнең ташландык өенә җеннәр ияләшкән! Кайсыдыр сөйли: имеш, Халисә белән Василәнең өрәкләре кайткан. Ул өрәкләрне күрүчеләр дә, өрәкләрнең елаганын ишетүчеләр дә булган. Кем күргән, кем ишеткән — төгәл генә әйтеп бирүче булмады. Ике-өч көн узуга, тагын шомлы сөйләшүләр башланды. Халисәләр өе эченнән үксеп елаган тавыш ишетелгәнлеге турында түбәноч халкы чынлап сөйли. Бер генә кеше түгел, бик күп кеше ишеткән. Хәтта өрәкләрнең илаулаганнары аръякка хәтле яңгырап торган, имеш.

Авылда гел шул турыда гына сөйлиләр. Кич утырганда Халисә белән Василә өрәгенә әйләнәләр дә кайталар, әйләнәләр дә кайталар. Бәйләү бәйләүче кызлар шүрләп, тәрәзә янына утырмый. Сәке йөзлегенә, мич катына шуыша. Кайтмый калган мал эзләүчеләр Халисәләр нигезен әллә каян урап үтә торган булды.

Ярмөхәммәт байтак вакыт бу хәбәргә ышанмыйча, курыкканга — куш, койрыгы белән биш дип, игътибар итмәде. Беркөнне кич Факиһә чәчен-башын туздырып, күзләрен акайтып кайтты да сулышына, сүзләренә кабына-кабына сөйләргә тотынды:

— Әнкәй, өрәкләр елаганны ишеттек... әле яңа гына...

— Соңга калып йөрмәссең! — диде Нурлыгаян кырыс кына.— Матри, кызый, кабат болай соң кайтсаң, өрәгеңне күрсәтермен мин сиңа...

— Әнкәй,— диде Факиһә әнисенә елышып.— Котларым калмады... Илаулый-илаулый... аннары «чырр» итеп кычкыра...

Кыз-кыркын куркак та, арттыручан да була, дип Ярмөхәммәт тынычлап йокыга китте.

Әмма икенче көнне өрәкләр турында Рәүф әйткәч, ул ышана язды.

— Төнлә урманнан бәрән себеркесе күтәреп кайта идем,— диде Рәүф.— Халисәләр өе турыннан үткәндә...

Ярмөхәммәт Рәүфкә карады. Рәүфнең күзләре чынын әйтә иде.

— ...Халисәләр турыннан үткәндә җылаган тавыш ишетелде. Җылый, малай, валлаһи...

Рәүф үзе ишеткән тавышка охшатырга тырышып сөйли:

— И-и-и, харап иттелә-әр... яшьли гүргә керттелә-әр, дип җылый... Мин томырылдым гына. Ничек кайтканымны да сизмәдем.

Карар нык булды. Бүген төнлә өчәү: Рәүф, Галимхан, Ярмөхәммәт өрәкне сагаларга барачаклар.

Кичке уен таралгач, гармун-җыр тавышлары тынгач, капка келәләре шалтырамый башлагач, өч шәүлә шыпырт кына түбәночка төшеп китте. Халисәләр каралты-курасына каршы якта карт тупыл бар. Шәүләләр тупыл кәүсәсенә посты.

Тирә-якта чикерткәләр ярыша, буада бакалар чурлый. Малайлар, күзләре бүлтәеп чыгардай итеп, кара-кучкыл йортка карый. Бигрәк шомлы, куркыныч иде бу йорт.

Чикерткәләр дә, бакалар да тынды. Ләкин шомлы өй ягыннан шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Икенче әтәч кычкыргач, өрәк сагалаучылар кайтып китте.

Берничә көн узды. Өрәк шаукымы тына төште. Инде онытылды дигәндә генә, авыл тагын гөж килде. Өрәк тагын төн уртасында елаган. Бу юлы бала-чага белән хатын-кызлар гына түгел, дөнья күргән олы-олы агайлар да пошаманга калды. Ләкин өрәк янына барырга, өрәкне сагаларга берсе дә алынмады.

— Юк-бар белән башны катырмагыз әле,— диделәр.

Өч күрше, поскын булып, тагын өрәк сагаларга китте. Тагын алар карт тупылга сыенды. Ышанычлы иде бу карт тупыл, үзе юан, үзе куе яфраклы. Авыл дөм караңгыда. Төнлә кешеләр йоклый, җеннәр уяна. Котлары табан астында булса да, үсмерләрдә сунарчылык дәрте кытыклана.

Шулчак өч дус өшеп-куырылып килде. Ирексездән алар бер-беренә елышты: ташландык өй эчендә нидер дөберди. Шул ук мәлне җан өшеткеч чинау, авыртудан өзгәләнеп кычкырган аваз ишетелде. Бу хатын-кыз тавышы иде. Аннан соң пырхылдаган, ырлаган, мыраулаган авазлар караңгылыкны ярды.

— Мачылар...— дип үзен-үзе юаткан булды Галимхан.

— Тсс,— дип Ярмөхәммәт Галимханның беләген кысты.

Ташландык ишегалдында ак шәүлә күренде. Шәүлә бер урында бөтерелеп алды да өйгә кереп китте. Сагалаучыларның йөрәкләре, кайнар куыкка эләккән күбәләк кебек, лепердн. Йөрәк бугазга кадәр менгән диярсең.

— Ишек кадакланган...— диде Рәүф. Аның:

— Кадакланган ишектән уза алгач, бу чыннан да өрәк,— дип әйтергә теләгәнен дуслар аңлады.

Шулчак өй эченнән ыңгырашканга охшаш елау ишетелде. Елау илаулауга күчте. Илаулап-илаулап бер хатын-кыз үкси. Бу сагалаучыларга Халисә тавышы сыман тоелды. Тик берсенең дә авыз ачып сүз әйтергә гайрәте җитмәде. Бу тавыштан бала йоннары кабара, чәчләр чымырдап үрә тора иде.

Әрвах тавышы тауларга бәрелде, урамнар буйлап авылга таралды.

— И-и-и, хараплар иттеләр... яшьли гүргә керттеләр...

Шик калмады: бу — Халисә мәрхүмә тавышы. Илаулау артыннан кызганыч җыр җырлагандай аермачык булып, сүзләр ишетелә башлады.

— Сөйләге-езз... кешеләргә сөйләге-езз... мине яшьли харап иттеләр-әр... и-и-и, ай-и-и...

— Әйдәгез ишегалдына! — диде Ярмөхәммәт.— Якыннан карыйбыз.

— Зәхмәте кагылса,— диде Рәүф.

Ярмөхәммәт белән Галимхан кузгалгач, Рәүф тә кыяр-кыймас аларга иярде. Кылшайган капканы этеп, Ярмөхәммәт ишегалдына керде. Капка тавышы ишетелүгә, елау туктады. Егетләр өчесе дә бергә елышып капка янында калды.

— Һәй! — дип кычкырды Ярмөхәммәт.— Һәй, кем сине харап итте, Халисә өргге? Кем сине вакытсыз гүргә кертте, әйт!

Өйдән җавап ишетелмәде. Кемдер, ишеттермәскә тырышып, өйалды идәне буйлап йөри сыман.

— Гөнаһсыз Халисә өргге! Әйт, кем сине харап итте? Без монда өчәү! Курыкма, без сиңа тимибез, чык, Халисә!

Җавап булмады.

— Әйдәгез, эчкә керәбез! — диде Ярмөхәммәт.

Шулай әйтеп тә бетермәде, өй ишеге ачылып китте, баскыч өстендә ап-ак кәфенле, чандыр өрәк пәйда булды. Үсмерләр бар белгәннәрен укый башладылар.

Ярмөхәммәт тагын кычкырды:

— Кем сине харап итте?

Өрәк артбакчага атылды. Алабута баскан сукмак буйлап ул ындыр артына таба элдерде.

Сагалаучылар бәрәңге бакчасына атылып чыкты. Алар мыштырдаганчы өрәк бакча башына җитте, җәһәт кенә читәнне сикереп узды, бәпкә саклый торган чирәмлек аркылы йөгереп, зиратка кереп китте. Өрәк куучылар чирәмлекнең яртысына җиткәч, туктадылар.

— Берсе шаярта-а,— диде Ярмөхәммәт.

Шулай да, өрәкне эзәрлекләп, зиратка керергә кирәк, димәде.

Шаяртуын шаяртадыр, әмма мондый шаярту өчен ат башы чаклы йөрәк кирәк. Олы кеше бу эш белән шөгыльләнмәс. Бала-чага куркыр. Ә кем соң бу өрәк?

Әлеге сорау җавапсыз калды.

Икенче көнне бу вакыйганы бөтен авыл тәмләп, тәфсилләп, әле

Рәүфтән, әле Галимханнан сөйләтә башлады. Бары тик Ярмөхәммәтне генә сөйләргә кыстамадылар. Кыстый башласалар, ул: юк белән баш катырмагызсана дигәндәй, кул селтәп китеп бара.

Өрәк турындагы хәбәр, өреп кабарта торган шар кебек, зурайды. Зурая торгач, имеш-мимешләр чынга әйләнде:

— Җәй беткәнче төн уртасында килегез, шунда мине кем харап иткәнен әйтермен! — дигән өрәк.

Имеш, өрәк өч егеткә үтерүче турында җентекләп сөйләгән, хәтта исемен әйткән.

Болганды халык. Кырыкмаса кырык төрле итеп сөйләделәр. Өрәк сагалаучылар үзләреннән чыкмаган сүзләрнең чын «хакыйкать»кә әйләнүен күреп шаккаттылар. Шаккаттылар да дәшмәс булдылар.

Өрәк дулкыны тынычлана төшкәч, Ярмөхәммәт дусларына әйтте:

— Теге әрвах килми калмас, егетләр, — диде.

Аның бу сүзләреннән дуслары шуны аңлады: әйдәгез, тагын сагалап карыйк, дигән мәгънә ята иде Ярмөхәммәтнең тел төбендә.

Ике төн сагалаганнан соң, өченчесендә өрәк тагын килде. Ләкин бакча артыннан түгел, тау ягыннан. Бу өрәк ак кәфен бөркәнмәгән, җир белән, караңгылык белән бер төстә иде. Егетләр аны мышнавыннан гына шәйләп алдылар. Кара өрәк ишегалдына үтте. Ярмөхәммәт егетләргә ишарә ясады: алар өчесе дә шыпырт кына җимерек йорт коймасына барып сыенды. Эчке якта кара өрәк көчәнә-көчәнә, мышный-мышный нидер эшли иде. Өрәккә иелүе кыен, бүксәсе комачаулый, ахрысы, дип уйлады Ярмөхәммәт. Бүлт-бүлт итеп, шешәдән сыеклык аккан тавыш ишетелде.

— Керәчин! — диде Галимхан.

Шырпы кабы кыштырдаганы колакка керде. Борынга керосин исе килеп бәрелде.

«Ут төртә бит бу мәлгунь», — дигән уй чәнчеде Ярмөхәммәтнең миен. Янәшәдә генә башка йортлар. Бөтен авылны себереп китәчәк бит янгын.

Кара өрәк шырпы сыздым дигәндә генә Ярмөхәммәт:

— Тукта! — дип кычкырды.

Алар өчесе дә ишегалдына кергәндә кара өрәк кыргый мәчедәй житезлек белән алабута арасына сикерде. Тирән кар ярып баручы поши сыман хырылдап сулыш ала-ала, котырып үскән алабута урманы аша тау ягына таба китте. Дөм караңгылык кара өрәкне тиз йотты.

Бу турыда картларга сөйләгәч, бот чабып, сызгырып куйдылар.

— Ыш-ышш-ш-шш, мәнә син агай, ә... Төн уртасында кычкырып янасы булганбыз икән... Кайсы җен эше булыр икән ул?

Бу яңалыкны да төрлечә юрадылар. Өрәкләрне качырыр өчен кемдер ятим өйгә ут төртергә булган. Бер уйласаң, бу яхшы ният. Балаларны куркытып тормасын ул шомлы өй, янәсе. Икенче караганда, ут төртергә азапланучыны эттән алып, эткә салып сүктеләр. Ут элгән булса, Халисәләр өе бер үзе генә янмас иде, ярты урамны алып китәр иде.

Нияте яхшы булгач, ут төртүче ни өчен соң өрәк сагалаучылардан качып киткән?

Икенче көнне Ярмөхәммәт, Фәрхунны очратырга теләп, юри урамда йөрде. Фәрхун кәнсәләрдән кайтып килә иде. Сиздермәскә тырышып, Ярмөхәммәт аның өс-башына карады. Ул-бу күренмәде. Фәрхун узып китү белән Ярмөхәммәт артына борылды: Фәрхунның чалбар төбендә, балак артында сырлан белән ике баш тигәнәк бар иде. Хәер, басуда йөргән кешеләрнең барысына да тигәнәк ябыша инде ул, дип уйлады Ярмөхәммәт.

Бу өрәк мәсьәләсендә хатыннар Шәриф муллага да барып карадылар.

— Һай, балалар, әрвахлар рухына коръән укытырга кирәк... Изге

айда әрвах иясенең рухына атап корбан чалу кирәк. Бигрәк тә Халисә мәрхүмәнең үлеменә сәбәпче адәмнең корбан чалышы, коръән чыгарышы кирәк,— дигән мулла абзый.

Корбан аена бик ерак иде шул. Ятим йортны өрәкләрдән саклар өчен, өй борынча чиратлап, шакылдавык белән каравыл йөрергә кушылды.

Шакылдавыклы каравылчылар йөрсә дә, өрәк сагалаучы үсмерләр үз белдекләре белән ак өрәкне байтак ауладылар. Ярмөхәммәт урам як капканы, Рәүф белән Галимхан артбакча сукмагында, өрәкнең зиратка чигенү юлын сакларга булды. Аларның тырышуы, йокысыз төннәр үткәрүе файдасызга китте: ак өрәк кабат килмәде. Каравылчылар булмаганда да ташландык өйдән өрәк тавышы яңадан ишетелмәде. Каерылып ачылган өй ишеген, урам як капканы кемдер юан-озын кадаклар белән кадаклап куйды. Өрәк шаукымы бетте.

Ул җәй шулай узды.

## Валия

Яз житеп килгәндә Сабирҗан «тәкәбберлеге өчен» Валиядән үч алды тәки.

Ярмөхәммәт, уяна алмыйча, йокы белән өн арасында аңгы-миңге булып ята иде, Зәйтүнә түти тавышына кинәт өнгә кайтты. Зәйтүнә түти лапырдап өйгә керде дә, аны-моны уйлап тормыйчан:

— Нурлыгаян,— диде,— бүген мине төнге көтүгә чыгаралар. Ярмөхәммәткә әйтерсең инде, безгә кереп йокласын...

— Тсс! — дип пышылдады Нурлыгаян.— Йоклый. Мал саклаудан арып кайтты.

— Ә-ә, шулаймыни...— дип тавышын әкренәйтте Зәйтүнә.

Үзе таң тишегеннән торырга күнеккәч, бар кеше дә аяк өстендәдер, дип уйлый инде ул.

— Бибизәйтүнә,— диде Нурлыгаян ишетелер-ишетелмәс.— Ярмөхәммәт бүген керә алмас шул... Нигә дип сорама... Тузган аяк киемнәренә олтан саласы бар аның. Итекләрне чормага урнаштырасы булыр. Башка эшләр дә бетмәгән дигәндәй...

— Бәрәкәт,— диде Зәйтүнә.— Эшен алып керер. Кич утырырлар Валия белән... Валиянең дә дәфтәрләр тикшерәсе бар.

Хикмәт олтан белән солтанда түгел иде, ахрысы, Нурлыгаян тынычсызлана башлады.

— И-и, ахирәткәем, килешми аңа хәзер анда куна йөрергә... Валия яшь хатын... ялгыз хатын дигәндәй...— Нурлыгаян бөтенләй пышылдауга күчте: — Күрмисеңмени, Ярмөхәммәткә сакал-мыек чыкты. Кырына бит инде ул хәзер. Аллам сакласын...

— Әстәгыфирулла,— диде Зәйтүнәсе.— Син ни сөйлисең? Ул бала гына бит әле.

— Баласын бала...— диде Нурлыгаян.— Кеше сөйли, Бибизәйтүнә... Сабир исерек чакта әйткән, Зәйтүнә үз өендә әллә ниләр оештырып ята икән, дигән.

Ярмөхәммәт өчен бу сүзләрне ишетү иманеч иде. Алга таба тагын да күңел кайтаргычрак сүзләр булмасын, дип ул ютәлләргә, киенергә тотынды. Чыш-пыш киселде. Хатыннарның тавышы кинәт үзгәрде.

— һи-һи-һи, Нурлыгаян, быелгы язны әйтәм, бигрәкләр дә иртә килде инде...

— Э-э... Хәерлегә генә булсын инде, Бибизәйтүнә...

Ярмөхәммәт ни өчендер кыенсыну халәте тойды. Әйтерсең лә аны ярамаган эш өстендә тотканнар. Ул тиз-тиз генә киенде дә чыгып китте.

Абзар чистартканда да, малларга салганда да гел ишеткәннәре турында гына уйлады. Мәктәпкә дә ул бик иртә китте. Бүген нидер була... Бүген нинди дә булса хәбәр килер сыман, дип аның күңеле борчыла башлады.

Дәрестә дә ул игътибарсыз утырды.

— Яз килә, яз! — диде Фәгыйлә апа.— Бөтен игътибар тәрәзәдә! Шулаймы, Ярмөхәммәт?

Фәгыйлә апа аннан дәрес сорап тора икән, ә ул ишетми дә. Аның уе әллә кайларда. Болай булгач, Валия апа белән кич утырулар бетте. Әнисе кертмәячәк. Хәзер Валия белән очрашу бары тик чәчәк аша гына булачак. Чәчәкләр чыгарга күп калмады инде. Умырзая күптән чәчәк атты. Тышта инде күптән җәй кояшы. Тургайлар чатырдаша. Сыерчыклар очына. Юллар чатнап такырайды.

— Ярмөхәммәт тәрәзәдән аерыла да безгә үткән дәресне сөйләп бирә,— диде Фәгыйлә апа, үзе ни өчендер бик хәйләле елмая.

Ярмөхәммәт белгәнен сөйләде, авызы сөйләде, фикере һаман яңалык ягында иде.

— Игътибарсыз сөйләдең, Ярмөхәммәт! — диде укытучы.

Укытучы тавышында Ярмөхәммәт әллә ничә төрле мәгънә барын тойды. Соңгы дәрес уртасында ишек ачылып китте, ишектән мәктәп мөдире Фәрзахи башы күренде.

— Галаева! Сезне бик ашыгыч районга чакыралар! — диде мөдир.

— Дәрес бетсен инде! — диде Валия.

— Ашыгыч!

— Гафу итегез, балалар,— диде Валия.— Күрәсез, бик мөһим эш чыккан, ахрысы. Калганын үзегез укып бетерерсез инде...

Кыңгырау шалтырау белән бар да чыгып йөгерде. Ярмөхәммәт, букчасына кирәк-ярак тутырган булып, класста калды. Парта кырыннан узганда Фәрдия канчык тавыш белән Ярмөхәммәткә атап:

— Һы-һы-һы, тәти кашык! Киявең килә, киявең килә, арт капкаңны ач та кач! — диде.

Альберт бөтенесе чыгып беткәнне көтте.

—Ниләр генә күрми ир-егеткәй белән ат башы,— диде Альберт.

Ярмөхәммәтнең Фәрдиягә дә, әнисе әйткәнгә дә бу кадәр ачуы килмәгән иде, Альбертка усал итеп:

— Син дәмени? — диде.

— Кабарма! — диде Альберт дусларча.— Дәшмә син... Игътибар итмә!

Алар ишегалдына чыкканда укытучылар бүлмәсе янында Фәрзахетдин абый белән Валия кызып-кызып сөйләшә иде.

— Бу кәгазь хәрби комиссариаттан,— дип нидер исбат итә Валия.— Мин абыемны эзләтәм. Димәк, нинди дә булса хәбәр бар! Иптәш Гыйлфанов, зинһар, мәктәп атын бирегез!

— Беләсезме, иптәш Галай,— диде Фәрзахетдин.— Мәктәп атын бирермен дә, ә кем барыр ат җигеп. Миндә бит олаучы юк.

— Ярмөхәммәт! — диде Валия.

— Ярмөхәммәт мәсьәләсе турында сезгә ронода җавап бирергә туры киләчәк әле, иптәш Галай!

— Бер урында мин ике җавап бирермен, иптәш Гыйлфанов! Комиссариаттан соң мин үзем ронога керәчәкмен!

Ярмөхәммәт белән Альбертны куып житеп, Валия тынына каплана-каплана:

— Яр...муха-мет... мәктәп атын җик, зинһар... хәзер үк районга китәбез,— диде.

Ярмөхәммәт букчасын Альбертка биреп, әнисенә кая киткәнлеген әйтергә кушып, ат җигәргә китте.

Юл буе ул һични сорашмады. Валия һични әйтмәде. Ул бик ярсыган, таушалган кебек күренә. Кемгәдер ул бик ачулы иде, ахрысы,

әллә комиссариат чакырганы өчен бик нык уйланамы?

Ярмөхәммәт Валиянең аттан төшеп йөгерердәй булып, алгысып барганын сизә. Булдыра алганча ул атны куа. Егерме чакрым араны үтеп, район үзәгенә керделәр.

— Роногамы? — диде Ярмөхәммәт.

— Юк! Башта комиссариатка,— диде Валия.

Комиссариат капкасына житәр-житмәс, Валия арбадан сикереп төште дә, яулыгын да бәйләмичә, комиссариатка таба йөгерде. Ярмөхәммәт аркалыкны бушатып, атка печән салды. Валия озак тормады. Беркемне күрмәс дәрәжәдә шашкын кыяфәттә чыгып, арбага утырды. Кулындагы кәгазьне кат-кат укыды... Комиссариаттан алар туры ронога киттеләр. Роно дигәч тә бөтен укытучылар кан калтырап тора. Ни өчен икән? Ә Валия апа роно турында уйламый да кебек. Аның уйлары һаман еракта, комиссариатта, кулындагы кәгазендә.

— Ярмухамет, син көтеп тор,— диде Валия.

Валия ронога кереп китте. Ярмөхәммәт атны эчертеп килде. Валия чыкмаган. Эш югыннан Ярмөхәммәт роно эченә керде. Тар коридорның як-ягында берничә ишек. Берсенә «Башлангыч мәктәпләр бүлеге» дип, икенчесенә «ТБУМ» дип язылган: тулы булмаган урта мәктәп. Өченче ишектә «Роно мөдире» диелгән. Шул ишектән тавышлар ишетелә.

— Мин кем сүзенә ышаныйм соң, иптәш Галаева Валентина Михайловна? — дип кычкыра берәү.— Ул коммунист! Уважаемый колхоз председателе...

— Коммунист? — дигән тавыш ишетелде. Бу Валия иде.— Коммунист булса, ялган сөйләмәсен!

— Юк, иптәш Галаева! Коммунист ялган сөйләргә тиеш түгел!

— Тиеш түгел! Ә ул сөйли! Димәк...

— Димәк, ул уважаемый колхоз председателе,— дип Валияне бүлдерде мөдир.— Бюро члены... Әнә, хәзер электростанция төзеп ята. Кайсы колхозда бара мондый эшләр? Ә? Сездә генә! Ягъни «Совет Татарстаны» колхозында гына... Бу кыланышыгыз өчен сезне эштән азат итәргә кирәк иде дә... Ярый... укытучылар житешмәү сәбәпле...— мөдир төртелеп калды, кәгазь кыштырдаган тавыш ишетелде.— Нәрсә бу? Бу нинди грамота? — диде мөдир.— Аңлатыгыз, иптәш Галаева!

— Мин китәм... Гаризам шушы булыр...— диде Валия.

Ярмөхәммәт бераз аңгерәп торды да урамга чыкты. Мәктәп аты язгы кояшка чыгып рәхәт кичерә иде. Чебен-кигәвен юк чакта кызынып кал, малкай. Ярмөхәммәт эш тапкан булып, арба тирәли әйләнеп чыкты. Чәкүшкәләр дә урынында, тәжеләрне бераз тарттырасы бар, дип Ярмөхәммәт тәже чөен бер-ике кат борып куйды. Камыт бавы бераз озая башлаган... Ашханәгә кереп, ул дүрт котлет белән дүрт кисәк ипи алды. Янә арба янына әйләнеп кайтты.

Байтактан соң Валия чыкты. Аны танырлык түгел иде. Төз, жыйнак, кызлар кебек балкып торучы Валияга әллә ни булган. Чәче талгәшләнеп бер якка ишелгән, яулыгы иңенә эленер-эленмәс. Бер уч кәгазьне ул сумкасына салып, арбага утырды. Ярмөхәммәт сүзсез генә дилбегәне тартты.

— Һа-а, әйдә, бахбай! — дип чөңгереп, чыбык белән кизәнде. Ат бар күгенә юырта башлады.

— Кума! — диде Валия.— Хәзер беркая да ашыгасым юк...

Ат үзе теләгәнчә кайта. Ара-тирә пошкырып танавын чистарта. Туктап-туктап «печ» итә. Хайван! Мондый эшне сөекле укытучы апа янында эшләмәсәң, кайткач өлгермәс идеңме? Мәхлук!

Арба шылтык-былтык итеп салмак кына тәгәри. Сөйләшү юк. Авыр юл иде бу Ярмөхәммәт өчен.

Әнә теге кара болыт безне куып житеп ясын иде, әй, ясын

иде яңгыр... Яшьнәсен иде яшен. Чатырдатып суксын иде, актарылсын иде дөньясы. Бер-бер хәл булсын иде. Кешеләрнең кайгы-хәсрәтен, җирдәге бөтен пычракны, күңелләрдәге авыр юшкыннарны юып алып китсен иде бу яңгыр.

Ярмөхәмм әтнең юраганы юш килде. Кара болыт үзе артыннан дөньяны каплардай болытлар өере ияртеп, юлчылар карурманга кергәнче үк куып җитте. Ярмөхәммәт тиз генә күлмәген салды, чалбар кесәсеннән чакматаш белән куны алып, күлмәк җиңе белән тыгыз итеп төреп, астына салып утырды. Валия артка карап утырган иде, Ярмөхәммәтнең бил тиңентен чишенгәнен күрмәде.

Яшен күкләрне ялмап-ялмап ала. Чатыр-чотыр күк күкри. Яңгыр коя. Коймый, күк ишелеп төшә сыман. Валия кәгазьләр салынган сумкасын куенына тыкты да тагын хәрәкәтсез калды. Ярмөхәммәт атны әйдәкләргә тотынды. Ни мәгънә ат куалаудан? Кире борылып, үзәккә кайтып өлгерә алмыйлар, алда озын юл, алда карурман. Бу яңгырдан качып котылып буламыни?

Ярмөхәммәт дилбегәне бушатты. Ат тагын рәхәткә чыкты. Үз ихтыяры белән атлый.

— Чыланасың бит, Валия апа,— диде Ярмөхәммәт.

— Чыландым инде,— диде Валия.

Аның көрсенеп, әйткән сүзе чылану аянычыннан идеме, әллә ул мәгълүм бер мәгънә салып әйттеме бу сүзләргә? Гайбәт белән чыландык инде, дигән сүзме әллә?

Юл бик тиз пычранды. Үзле балчык атка комачаулый иде. Чиләкләп коя торгач, юл җиңеләйде. Арба пәчтер-почтыр тәгәри, атка җиңел. Урманга кергәч, яңгыр туктагандай булды. Яфракларга дуга тиеп киткән саен, өскә шыбырдап су коела. Ун чакрым урманны чыкканчы бер генә җеп бөртеге дә коры килеш калмаячагы көн кебек ачык иде. Урман авызында чүнник бар. Бәлки шунда кереп ышыкланып торыргадыр?

Ат чүнник юлына борылды.

Ярмөхәммәт коры күлмәген култык астына кыстырып, чүнниккә керде. Валия аңа иярде. Чүнник өендә кеше юк иде. Әллә ташлап киткәннәрме бу умарталыкны? Умарталар да сирәк күренә, алары да күчсез бугай. Чүнник өе кара мунча кебек тәбәнәк, караңгы, төтенбалавыз исе бүрәнәләргә мәңгегә сеңгән. Бер-ике соры корт кына чүнник өенең бердәнбер тәрәзәсендә бызылдый. Күшегеп беткән Валияне бердәнбер агач караватка утыртып, Ярмөхәммәт өйдән чыкты.

Умарталар өелгән ачык лапаска кертеп, ул атны тугарды. Алдына печән салды. Тезгенне дилбегәгә, дилбегәне арба аратасына бәйләп, эчкә узды.

— Туктарга исәбе юк бу яңгырның,— диде Ярмөхәммәт өйгә кергәч, чәч-башыннан су саркыта-саркыта.

Валия үзалдына гына сөйләнеп әйтелгән бу сүзләргә җавап кайтармады: ул да киемнәрен сыга иде. Ярмөхәммәт аны эчке күлмәкчән күрде. Юеш ак күлмәк аның тәненә чат ябышкан. Күзе тышта калганлыктан, Ярмөхәммәт Валиянең бу кыяфәтен башта шәйләмәгән иде. Чәче дә маңгаена, җилкәсенә төшеп яткан. Ярмөхәммәт күзе ияләшә төшкәч, бөтен нәрсәне ачык күрә башлады. Ул ишеккә таба борылды.

— Валия апа, менә минем күлмәкне ки! — диде Ярмөхәммәт.— Коры ул.

Борылып карамыйча гына ул коры күлмәген Валиягә суздьы. Валия җәһәт кенә күлмәкне алып:

— Эх, җылы-ы... Хәзер борылсаң да була,— диде.

Ярмөхәммәт каршында тез тиңентен аның күлмәген кигән Валия йөри. Ул сыгылган киемнәрен эләр урын эзли. Рамнарны алып, буш кадакларга киемнәрне элеп чыктылар.

— Син туңасыңдыр ялангач,— диде Валия.— Миңа җылы... Син

каян алдың бу коры күлмәкне?

— Таптым инде,— диде Ярмөхәммәт.

Караватта иске сырма белән фуфайка бар иде. Валия шуларны җәеп урын җайлады.

— Юк, болай булмый,— диде Ярмөхәммәт.— Әчкә салкын төшерер хәл юк.

Ул ярым җимерек мичкә аяк астындагы йомычкаларны, ватык кәрәз рамнарын тыкты. Пәкесе белән коры рамнан юка чыра телде дә чакмасы белән куга ут төшерде. Куга төшкән утны өреп, җилпеп юка йомычкаларга тигезде. Йомычкалар дөрләп кабынып китте. Валия аның бик тиз ут кабызып җибәрүенә сокланып карап тора. Ялкын тиз генә элеп алды. Ут — яктылык та, җылылык та. Ут кабынгач, күңелләргә җылы йөгерә, миһербан иңә. Ярмөхәммәт юеш киемнәрне учак янына җайлаштырды. Тыштан камытны, дуганы, ыңгырчакны алып керде. Шулар өстенә бөтен юеш киемнәрне элеп куйды.

— Вә-әт,— диде ул канәгать тавыш белән.— Киемнәр дә, дирбияләр дә кибә.

— Син таш гасыр кешесе кебек,— диде Валия.

— Чакма-ку булганда өшеп үлмәбез.

Хәзер аларга берни дә куркыныч түгел иде инде.

Ярмөхәммәт аннан-моннан гына эшләнгән өстәлне яшел үлән белән сөртеп, әрекмән яфрагын эскәтер итеп җәеп, өстенә кәтлитләр белән ипи чыгарып куйды.

— Син гениальный егет, Ярмөхәммәт,— диде Валия.

Салкын кәтлитләр белән ипидән дә тәмле әйбер юк иде алар өчен.

— Музыка гына җитми,— диде Валия.

— Нигә җитмәсен,— диде Ярмөхәммәт.— Яңгыр тавышыннан да матур музыка юк хәзер. Күптән кирәк иде инде бу яңгыр.

Яшен яшьнәү, күк күкрәү аларны якынайта гына. Яшьнәсен яшен, күкрәсен күк, койсын яңгыр!

Ярмөхәммәт ярым шәрә килеш яңгыр астына чыкты. Ат лапас ышыгында рәхәтләнеп печән чемчи. Аның да бер кайгысы юк. Урыны ышык. Алдында печән. Ярмөхәммәт ары барды, бире килде, тәки эзләгәнен тапты. Ташландык кое капкачсыз иде. Аның каравы ямьшәеп беткән калай чиләге бар. Чиләккә дилбегә бәйләп, ул су алды. Чиләкне үлән сабаклары белән ышкып, чайкап чистартты. Янә су алып өйгә керде.

— Кое суы,— диде Ярмөхәммәт.

— Оһо, шикарно живем мы с тобой,— диде Валия.

Күктәге ялмавыз утлы теле белән бар дөньяны ялмап алды. Валиянең йөзе Ярмөхәммәт күзендә сурәт булып калды. Чатырдатып күк күкрәде, әйтерсең лә, йөз еллык имән урталай ярылды. Салават күперennән меңләгән атлар чыга башлады.

— Яшьнә, яшен! Күкрә, күк! Кой, яңгыр! Чистармасмы фани дөнья!

— Догамы син шулай укыйсың?— диде Валия.— Әллә яшеннән куркасың?

— Дога түгел,— диде Ярмөхәммәт.— Бабай шулай әйтә иде.

Төтенле булса да, өй эче җылынды. Әлгән киемнәр дә кипте. Камыт, ыңгырчаклар да коп-коры. Тышта коеп яңгыр ява. Яумый яңгыр. Күктән ишелеп төшә. Әйтерсең лә күк мохитенең кавызын киереп ачканнар. Валия нидер уйлый. Уе авыр. Авыр уйның шәүләсе аның йөзенә сирпелгән. Ярмөхәммәт кипшергән дирбияләрне учактан читкәрәк күчерә. Валия аның эшен күзәтеп утыра. Ләкин үзенең уе әллә кайларда.

— Ярмухамет, яңгыр туктаганчы монда торыйк...

Ярмөхәммәтнең үз уйлары да бик җиңел түгел иде. Аның болай да исәпле башына бүген өч уй төште. Кеше теләнә кергән сүз. Фәрдиянең төрттереп такмаклавы, энисе әйткән сәер ишарәләр. Комиссариаттан нинди кәгазь алып чыкты Валия? Ике. Әмма да ләкин бик шатлыклы

хәбәр тугеллеге көн кебек ачык. Ни өчен Валия ул хәбәрне һаман әйтми? Роно мөдиренә ул: мин китәм... бөтенләйгә, диде. Шул дөресме? Ни өчен ул китә? Дөрес булса, аның китүе комиссариатка бәйлеме? Әллә роногамы? Әллә Ярмөхәммәт аркасындамы? Валия китә калса, Ярмөхәммәт нишләр? Валия китсә, Ярмөхәммәт кенә түгел, бөтен Ярмай авылы ятим калыр бит. Үзе әйтмичә, Ярмөхәммәт Валиядән мәңге дә сорамаячак.

Болай да караңгы урман өенә дөм караңгылык иңде. Ярмөхәммәт тышка чыгып, атына карады, ике чиләк су эчерде. Күп итеп фураж салды. Өйгә кергәч, учакка утын өстәде. Ут-фәлән төшмәсен дип, мич алдын яхшылап себерде.

Кипкән киемнәрне, чыбылдыкны юрган итеп йокларга яттылар. Таң алдыннан өй суынган, чыбылдык ачылган.

Алар уянганда таң аткан иде инде. Болытлар, бар яңгырны сусаган җиргә агызып, әллә кайларга киткән. Урман-җир күктән иңгән дымны эчеп рәхәтлек кичерә. Учактагы утын янып, хәлсез көлгә әверелгән. Тәрәзәдәге соры кортлар пыяла буйлап үрмәлиләр дә, теләр-теләмәс кенә канат кагып, быжлап алалар. Ат алдындагы фураж беткән. Бахбай канәгать бер изрәү кичереп, аягүрә оеган.

— Жаль, таң аткан да инде,— диде Валия.

Кое суы белән юынып, коры киемнәр кигәч, атка су эчергәч, кайтыр юлга чыктылар.

Ярмайга кайтып керер алдыннан Валия әйтте:

— Матурым,— диде ул.— Мин китәм бит...

— Беләм,— диде Ярмөхәммәт.

— Бөтенләйгә китәм сезнең авылдан...

— Гайбәт өченме?

— Юк!.. Мин ул сүзләрдән курыкмыйм. Эш башкачарак, Ярмухамет...

Валия туктап көрсенде. Ярмөхәммәт аны ашыктырмады, сүз кузгаткач, барыбер үзе әйтеп бетерәчәк.

— ...Все шиворот на выворот получилось... Исән дип торган абыем үлгән икән. Батырларча һәлак булган ирем Виктор исән.

— Виктор дәдәй исән? Ничек?— дип сораганын Ярмөхәммәт сизми дә калды.

— Шулай,— диде Валия.— Исән минем Викторым...

Ярмөхәммәт аңламады: сөенчеме аңа ире турындагы яңа хәбәр, әллә... бердәнбер абыйсын югалту кайгысы белән ирен табу шатлыгы бер-берсен юкка чыгарамы? Валиянең бу сүзләре гамьсез генә әйтелде кебек. Ә гамьсезлек кайгы белән тәңгәл.

— Ике аяксыз, уң кулсыз Виктор исән... Ярты кеше...

— Үзе хәбәр салганмы?

— Юк! Гарип калганын белгәч үк, иптәше исеменнән: ирегез Виктор Галай чик буенда батырларча һәлак булды, дип үзе язган. Хаты кыеш-мыеш иде... Сул кул белән язган булып чыга...

— Нишлисең инде?

— Китәм, Ярмухамет, обязательно китәм... Ронодан увольнение алдым. Аңлатып биргәч, роно мөдире ачылып китте. Бик шәп характеристика язды. Мин талантлы да икән, белемле дә икән. Балалар, ата-аналар арасында абруйлы да, әхлак яктан фәрештә дә икәнмен... Китә генә күр, янәсе!

Валия көлә.

«Фәрзахетдин абый кирәкне бирә инде хәзер»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Ул уйлаганның киресе булды. Фәрзах мәктәп капкасына чыгып каршы алды аларны. Мөгаен, роно мөдире Валиянең китүе турында авылга шалтыраткандыр.

— Бу яңгырда кайтып йөрмәсәләр ярар иде, дигән идем аны...

— Фәрзахетдин абый,— диде Валия.— Зинһар, кичерегез... кичерегез, мин сездән башка гына увольняться иттем инде...

— Зыян юк,— диде мөдир.— Тик минә чыгарылыш елы... Жиденчеләрнең...

— Ә мин үз фәнемнән имтихан алып бетергәч китәм...

— Котлыйбыз, Валентина Михайловна, ирегез исән килеш табылган икән,— дип башка укытучылар да җыелды.

Валия сагышлы елмаеп, аларның котлауларына рәхмәт әйтеп, укытучылар бүлмәсенә узды.

Гайбәт яралганда ук юкка чыкты.

Ни гаҗәп бу кешеләр? Әгәр Валия бөтенләйгә Ярмайда калса, ничек әйләнер иде икән дөнья куласасы? Имзасыз хатлар, Сабир ронога житкергән сүз Валияне изәр идеме икән? Әллә аны декретка чыккан хатыннар урынына авылдан-авылга куып йөртерләр идеме икән?

Шөкер, тамырдан корыды гайбәт.

Китәсе көнне иртүк Валия өйдән-өйгә кереп, һәр кеше белән аерым-аерым саубуллашып чыкты. Аны озатырга дип, Калдау күпере төбенә бик күп кеше төшкән иде. Укытучылар, укучылар, хатыннар, яшьләр. Бар да елый. Валия каушаган. Уңайсыз елмая. Аны сөяләр икән бит. Аны туган иткәннәр икән бит. Ул Ярмайның иң кирәкле кешесе икән ләбаса...

— Җаныкайларым,— диде дә Валия тыела алмыйча, елый башлады.— Балакайларым,— дип укучыларны кочаклады.— Апакайларым, рәхмәт сезгә,— дип хатыннарны үбеп чыкты.

Аны озатырга Ярмөхәммәт белән Альбертка кушылган иде. Ярмөхәммәт дилбегә тотып, алга караган. Альберт аңа аркасы белән утырган. Ярмөхәммәт, елаштан ерагаясы килеп бугай, атка чөңгерде. Бераз баргач, әрәмә тавына җиткәч, Ярмөхәммәт атны туктатты.

— Күпер төбе Сабантуй кебек,— диде Альберт.

Ярмөхәммәт борылмады, озата төшүчеләргә карарга теләмәде. Ул тырнаклары белән салам тураклый иде.

Валия үзен кешеләрдән ирексезләп аерды кебек: үзен кочаклаган укучыларга, хатыннарга кул болгады да арба артыннан йөгерде. Бераз баргач, борылып, артка чигә-чигә, янә кул болгады.

— Сау булыгы-ыз! Рәхмә-әт! До свидания-а... Прощайте-е!

Халык биргән күчтәнәчләр бер олау. Валия алмаска тырышса да, хатыннар: ату үпкәлибез, дип ирексезләп хәзинәләрендә барын төреп, арбага салганнар иде.

Олауга җиткәч, Валия тагын артына борылды. Төркемнән ике хатын аерылды.

— Бибизәйтүнә түти белән Нурлыгаян апа!— диде Альберт.

— Бәгырькәйләрем,— диде Валия.— Җанкайларым, Зәйтүнә түти, Нурлыгаян апа... Алтынкайларым, сау калыгыз!

Кычкырмады ул бу сүзләрне. Үзалдына әйтте. Әйтерсең лә ул дога кыла, әйтерсең лә изге саналган хатыннар өчен ул теләк тели.

— Кадерлеләрем минем... Сау булыгыз... Теге дөньяда оҗмах булса, сез керми, кем керсен ул җәннәткә. Изге җаннар, батыр халык бит сез...

Үр менгәч, Валия туктап, арбага менде, аягүрә басып яулык болгады.

Сугыш башлангач, дүрт ел буена шушы үрдән солдатлар соңгы тапкыр кул изәде. Дүрт ел буе Ярмай хатыннары, Ярмай балалары күпер төбендә газизкәйләрен шулай озатты. Инде менә тагын, тыныч елда белорус кызы Валентина Михайловна Галай соңгы тапкыр аларга яулык болгый. Хатыннар да, балалар да Валияне соңгы тапкыр күрүләрен күңелләре белән сизенеп елый.

Валия кинәт иелеп, төенчекләр өстенә капланып, тарсынмыйча, рәхәтләнеп үкси башлады.

Ярмөхәммәт дилбегәне тартты. Озатучыларны үр каплады.

Егетләр сөйләшмичә генә бара. Ни сөйләшсен алар? Юатсыннармы укытучыларын? Ачулансыннармы? Мәгънә юк. Еласын әйдә. Бушансын. Эчендә әче күз яше булып калмасын.

Борындык үренә чаклы һич тыела алмыйча елады ул. Үргә җиткәч, өчесе дә арбадан төште. Валия арткарак калып, яулыгы белән битен каплады.

Ни өчен шулай өзгәләнә ул? Аны үз иткән кешеләрне кабат күрә алмаячагын сизенеп сыкрыймы аның күңеле? Күз алдында бинһая авыр газапларны җиңгән, әче тулы кара сагыш, әче тулы әче хәсрәт булса да, үзләре ярым ач булса да, читтән килгән бәхетсезләргә җылы куыш, актык сыныкларын биреп башка милләт кешеләрен тәрбия кылган, бәхет-рәхәт, ял дигән нәрсәләрне ишетә генә белгән шушы фидакарь халыкны кызганып елаумы бу? Туганнары кебек кадерле кешеләрдән аерылу өчен ачыргалану идеме бу? Аның ире табылып та, күпер төбендә калганнарның күбесенең ирләре, абыйлары, аталары мәңге кайтмаячагы турында уйлавы идеме?

Чаллыга җитеп, пароходка билет алгач, әйберләрне дебаркадерга ук ташып куйгач, Валия:

— Барыгыз, егетләр, сез кайтыгыз... Кайчан килә әле ул пароход?— диде.

Егетләр кайтабыз да, кайтмыйбыз да димәде. Олыларча, дәшмичә генә Валия янында басып калдылар.

— Яхшы егетләр сез, Альберт,— диде Валия.— Рәхмәт! Кайтыгыз инде.

— Пароход күрәсе килә-ә,— диде Альберт.

Кызык әйтте, нәкъ вакытында әйтте. Сагышлы мохит йончыткан иде. Валия көлә. Ярмөхәммәт тә пырхылдап куйды.

Читтән күзәтүчеләр: нинди шат компания, дип уйлый торганнардыр инде. Ә боларның әче тулы аерылышу моңы.

Пароход төнлә генә килде. Егетләр елгыр гына кереп, әйберләрне урнаштырдылар. Валияне әйберләре янында калдырып, саубуллашу сүзләре әйтеп, дебаркадерга чыктылар. Валия аларны озата килде. Ләкин дебаркадерга төшмәде, пароход култыксасына ике кулы белән тотынып, эчтә калды. Ыгы-зыгы, этеш-төртеш, чаң сугу тавышлары, капитанның боерык авазларын ике генә кеше ишетми иде: Валия һәм Ярмөхәммәт. Аларның бер-берсенә карап торганнарын сизеп, Альберт юкка чыкты.

— Мин ат янында булам,— дип әйтте бугай ул. Ләкин Ярмөхәммәт анысын тәгаен генә хәтерләми.

Гудок озын итеп, сагышлы итеп кычкыртты да, өч тапкыр кыска тавыш бирде:

— Ту-у-ут! Тут-тут-тут!

— Убрать носовой!— дигән тавыш ишетелде.— Быстрее убрать!

Шулчак Валия басма аша атылып чыкты да Ярмөхәммәтне үтерердәй итеп кысты. Яңакларыннан үпте-үпте дә кире басмага сикерде. Ул басманы алып маташучы матроска бәрелде, тегесе һәйбәтләп кенә сүгенеп алды. Пароход кузгалды. Пароходның үзәк өзгеч моңлы тавышы Чаллы ярларына, элеватор тауларына бәрелеп, Идел өстеннән Затон урманнары арасына кереп югалды.

Алиһәнең күзе ераклаша. Алиһәнең йөзе ераклаша. Алиһәнең гәүдәсе ераклаша. Пароход ераклаша.

Пароход, Кама өстендә түгәрәк ясап, агымга уңай борылды. Озын итеп, саубуллашу гудогы яңгырады. Ярмөхәммәтнең тамагында әче төер урнашты.

Төрле-төрле матур утлары белән пароход китеп бара. Кара-куч-кыл су өстендәге шул утлар арасындагы гүзәл Алиһә мәңгегә ераклаша. Ул инде күренми. Пароход кына күренә. Ләкин ул белә: Валия һаман

пароход култыксасына тотынып бара.

Альберт дилбегәне кулына алып, Ярмөхәммәтне көтә иде.

Пристань тавы өстенә менгәч, Ярмөхәммәтнең теләген сизгәндәй, Альберт атны туктатты. Ярмөхәммәт арбага басып, Кама өстенә бакты. Альберт та аягүрә торды. Маяк утлары, катер утлары арасында гүзәл пароход аска таба йөзә. Су өстендәге сагышка сагыш өстәп, талгын гына тагын пароход кычкыртты.

Пароход әкрен генә елга борылмасына кереп югалды. «Чаллы күздән югалгач, Валия төенчекләре өстенә капланып, тагын елый башлагандыр»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Үсмерлектән чыгып килә торган бу ике егет сүзсез дә бер-берсен яхшы аңлый иде. Алар юл буе сөйләшмәделәр. Альбертның кеше күңеленә рөхсәтсез керәсе килмәгәндер. Ярмөхәммәтне үзенең сагышлы уйлары белән ялгыз калдырырга теләгәндер. Ярмөхәммәтнең дә сөйләшәсе килми. Ә шулай да Альберт белән аңа җиңелрәк. Юк-барны сораштырмаганы өчен ул эчтән генә Альбертка рәхмәт укый.

Ярмөхәммәт үсмерлек чорын узып, балигълык чорына кереп бара иде.

## Иң чибәр кыз

— Минемчә, безнең класста иң матур кыз Бибинур!— диде Рәсүл.

Чыннан да, Бибинур — класста гына түгел, язылмаган кагыйдә буенча «Мәктәп гүзәле» дигән исем яулаган кыз.

Альберт бу фикер белән килешмәде, Рәсүлгә кырт каршы төште:

— Юк! Бибинур матур түгел!— диде ул.

Егетләр бу сүзне шаяру дип аңладылар, Альберт шаяртмый иде.

— Бибинур артыннан бөтен тугызлар, бөтен унынчылар йөри,— диде Рәсүл.

— Бибинур бизәнә, шуңа күрә генә күп егетләр аның акшарлаган битенә карый. Онга төшкән таракан!— диде Альберт.

Сабакташлар көлешеп алды. Альберт Бибинурның матур түгеллеген исбатлау өчен «онга төшкән таракан» белән генә чикләнмәде, яшьтәшләренең көлүе аңа илһам өстәде, ул:

— Бибинурга карасам,— диде,— аның ун мыскал иннек сылаган иреннәрен күрсәм... чүплектән кайтып килүче эт авызы искә төшә...

Бу охшату егетләргә әшәке тәэсир итте. Көлүче булмады. Кемдер «фу-у», дип читкә борылды. Кемдер чагыштыруны башында эшкәртеп бетерә алмыйча, тын гына уйлый иде, иң чибәр саналган Бибинур иреннәре белән... чүплектән кайтып килүче эт...

Альбертның үзе сөймәгән әйберне иң әшәке нәрсә белән чагыштырып сөйләве, үзе ошатканны күккә чөеп мактавын һәм һәр ике очракта да тыңлаучыларны үз сүзенә ышандыра алуын Ярмөхәммәт яхшы белә. Күп кешеләр күзенә чалынмаган вак нәрсәләрне ул күреп ала да, купайтып күрсәтә, башкаларның дикъкатен шуңа юнәлтә белә. Бу юлы да ул теләгенә ирешге. Байтак кына егетнең Бибинурдан күңеле кайтканлыгы алгы көннәрдә үк сизелде. Дөрестән дә, егетләр Бибинурның артык бизәнүен күрделәр. Бу бизәнү үзеңне пөхтә тоту теләгеннән түгел, ә бәлки егетләр игътибарын күбрәк аулау өчен эшләнгәнлеген дә аңладылар.

Кызларның чибәрлеге хакында сүз чыкса, бөтен егетләр Альбертка текәлә, аның фикерен көтә. Бу мәсьәләдә Альберт Төхфәтуллин абруйлы бәһадар, ягъни кызларга бәя бирүче булып китте. Һәркем яшерен генә ошатып йөргән кыз турында кактырып-суктырып кына аннан сорый:

— Әминә үзен әллә кемгә куйган була,— диде Зәкинур.

Альбертның җавабы әзер:

— Әминә үзен чибәр саный. Сез дә астан гына аңа күз атасыз... Ә миңа ошамый Әминәгез... Өченки Әминә елмая белми.

— Нишлә-әп?— диде Зәки.— Гел көлеп кенә тора...

— Көлеп кенә тора, ә елмая белми.— диде Альберт.— Ул башын артка ташлап көлә. Авызы ерылып китә дә үпкәсе күренә.

— Хактан да шулай,— диде егетләр.

— Анатомия дәресендә кешенең сулыш әгъзаларын өйрәнергә Әминә күргәзмә әсбап булып тора ала.

Альбертның бу үтергеч чагыштыруы Әминәгә булган тартылуны кисте дә ташлады. Бигрәк тә Зәкинурның борыны төште. Ул гашыйк булып, изгегә санап йөргән кызны тетте дә ташлады Альберт. Әминә көлә башласа, егетләр аңа карый. Карыйлар да Альбертның хаклы икәненә тагын бер кат ышаналар. Әминә бу карашларның асылын төшенмичә, үзенә сокланалар, дип тагын авызын ера.

— Ә кем соң синеңчә иң чибәр кыз?— дип сорады Рәсүл.

Альберт серне тиз генә ачарга теләмәде. Ул бер Ярмөхәмммәткә, бер егетләргә карап, мәгънәле генә йөреп килде дә, дәрес аңлатучы остаздай, бераз бөкрәя төшеп, ике бармагын һавага төртте:

— Һы, иң чибәр кыз?— дип юри кайтарып сораган булды.— Сез тышкы чибәрлек таптырасыз миннән. Мин тышкы чибәрлекне чибәрлеккә санамыйм бит. Вәйт мәсьәлә кайда, шәкертләр. Шуңа күрә, сез «чибәр» дип әйтү белән, мин ул кызның житешсез якларын эзли башлыйм... Һәм, кичерегез, әфәнделәр, ул кимчелекне мин тиз табам.— Альберт кинәт кенә:— Лүтсия!— диде.

— Во!— дип кычкырды Рәсүл.— Мин дә әйтим генә дигән идем: Лүтсия иң чибәр кыз!

Альберт мәкерле итеп, ирен кырыйлары белән генә елмаю кыяфәте ясады:

— Хе-хе-хе, Лүтсия чибәр кыз, әлбәттә. Дөрес, әмма дә ләкин...— Альберт сүзләрне шундый итеп бозып әйтә, укытучылардан, әбиләрдән ишеткән китап сүзләрен ул үз максатына, дәлилләүгә жигә белә.— Әмма дә ләкин Лүтсиянең атлавы, бигрәк тә йөгерүе, кичерегез...

Физкультура дәресе егетләргә зур ачыш китерде... Йөгерү-сикерү, рекорд кую, БГТО үтәү түгел иде аларның кайгысы, кызларның йөгерүен, атлап йөрешен күзәтү иде аларның максаты. Альберт, астыртын эш йөртүче кебек, укытучыга, кызларга сиздермичә генә кемнең нәфис матур йөрешле, кемнең үшән икәнен белгертә торды: Люция гәүдәсен жыеп бетерә алмый иде шул.

Көннәр үтә торса да, Рәсүл куйган сорау һаман жавапсыз калды. Альберт та бу турыда онытмый кебек. Аның жавабы бәлки әзердер дә. Ихтимал аның өчен иң чибәр кыз юктыр да. Ул һаман күзәтә. Аның очлы күзеннән кызларның бер генә хәрәкәте дә читтә калмый. Әбәткә алып килгән ипи ашыйлармы алар, кружкага салып су эчәме... Дәрес вакытында кеше күрми әле дип, берәр кыз бик бирелеп борын чистартамы, мәктәпкә килеп тырнак астын тикшереп утырамы, урындыкка утырыш рәвешләре — барысы да сизгер, усал, күзәтүчән Альберт күзе аша уза һәм үтергеч бәя ала.

«Иң чибәр» дигән сүз чыккач, Ярмөхәммәт күз алдында Алиһә жанланды. Алиһә, гүзәллек үлчәме буларак, аның аңында кабына да сүнә. Алиһә — ул хыял. Алиһә ул күзаллау. Алиһә ул кул житмәс ераклыкта. Ярмөхәммәтнең уйлары Алиһәдән мәктәп кызлары янына кайтып төшә. Альберт жүнсез «кем соң иң чибәр кыз?» соравына жавап бирмичә йөрүе белән бөтен егетләрне хафага салды. Укулар бара инде ул. Гел отличник булмасалар да, төшеп калганнардан түгел. Эш тә качмый, һәр үсмер егет хужалыкта үз өлешенә тигәнен башкарырга мәжбүр. Әмма һәр үсмерне биләгән бер уй — кызлар турындагы уй көннән көн ныгый, тыгызлана барды. Һәр егет үзенә ошаган кызны эзли, таба, күзәтә, бар ягын да Альберт калыбына куеп тикшереп карый. Жүнсез Альберт күзен йомсаң, күз алдында сиңа ошаган кызны яманлап торадыр кебек. Каян табасың аны бар ягы да килгән кызны? Кемдер жавапны китаптан эзли, кемдер Альберт авыз ачканны көтә. Ярмөхәммәт тә бу яшерен

уенга катнашып китте. Күп тә узмады, Ярмөхәммәт җавапны тапты. Альберт та астыртын гына Ярмөхәммәтне гел күзәтә. Кая карый Ярмөхәммәтнең күзләре? Валия белән аерылышкач, Ярмөхәммәтнең сагышта йөргәнен белсә дә, ул сүз катмады. Беркайчан да ул Ярмөхәммәтнең бу ләззәтле сагышына кагылмады. Ярмөхәммәт тә аның сизенгәнен аңлый һәм дәшмәве өчен эчтән генә Альбертка рәхмәтләр укый. Еллар уза торгач, ләззәтле сызлану юыла барды. Валия Ярмөхәммәтнең күңелендә, зиһенендә тормышка ашмаслык әкияти бер хыял булып кына калды. Әйтерсең лә Валияне Ярмөхәммәт үзе уйлап чыгарган да, үзе шуңар гашыйк булган да, үзе оныткан да. Ярмөхәммәт бераз вакыттан соң аңлар: Альберт шаян, аны хыяллардан аеру өчен, бер Валия белән дөнья бетмәгән бит, яшәргә кирәк, сөяргә-сөелергә кирәк, дип, үзенең хәйләле шушы уенына сөйрәп керткән икән.

Ярмөхәммәтне тораташ хәленнән чыгарып, Альберт әйләнә-тирәдәге кайнап торган яшәешне, кызларны күрергә этәргән.

Бервакыт аларның классын ындыр табагына җибәрделәр. Ярмөхәммәтне олы эшкә куйдылар: ашлык суктыргыч машинага көлтә биреп торырга. Бу эш гаять катлаулы. Күзлек киеп, авызга чүпрәк бәйләп һәр көлтәнең билбавын урак белән кисеп, машина авызына тыгарга кирәк. Көлтәне кинәт ташласаң, суктыргыч машина тыгыла да, трактор сүнә яки каеш өзелә. Тракторны сүндерсәң, бер тапкыр гына сүгәләр. Кайнар тракторны кабызып була. Ә менә каеш өзелсә — беттең. Монысы өчен сүгеп кенә калмаслар... Көлтәне әз салсаң, машина барабаны ярылырдай булып үкерә башлый. Суктыргычка көлтә бирү өчен осталык кирәк. Көлтә бирүче Учавыл картының күзе шешеп, эренләп, килә алмаган бичара. Алыштырырга башка ир-ат юк, алыштырырлыклары да каядыр киткән булып чыкты. Ярмөхәммәтнең бу эшкә маһирлеген белгәч, тиз генә аны куйдылар. Бабасы янында өйрәнгән һөнәр ярап куйды тагын. Кызлар тезелешеп басканнар да, кулдан кулга күчереп, Ярмөхәммәткә көлтә бирә. Көлтәне машина барабаны урап алып кереп киткәч, Ярмөхәммәт чак кына уң якка борыла төшеп, тезмәдәге беренче кыз сузган көлтәне ала, ала да барабанга тыга. Молотилка көлтәне башаклы башыннан ашый башлый, әкренләп ашап-суырып бетерә дә «вию-у-уң!» итеп уларга тотына. Шулчак Ярмөхәммәт суккычка яңа көлтә каптыра. Машина янында тузан, кибәк, кылчык: кызлар бераз эшләгәч, урын алмашалар. Шулай эшләгәндә Ярмөхәммәт һәрвакыт көлтә бирүче кызның кулына карый. Тиз тотып алыр өчен шулай көлтә бавына карарга туры килә. Кызлар алмашынганын ул кулларыннан белә. Һәр кулның аерым билгесе бар. Кайсысы ябык, сөякчел, кайсысының бармаклары кып-кыска. Кайсысының кулы яңа пешкән күмәч кебек... Төрлесе уза аның күз алдыннан. Шул төрле куллар арасында Ярмөхәммәт бер кулга аеруча игътибар итте. Бу гаҗәеп бер матур кул иде. Көлтә сузган арада кул бер мизгелгә генә күренеп ала да юкка чыга. Бу кулга караган саен карыйсы килә. Аннан алдарак эшләгән кызларның кулларына әллә ни игътибар бирмәгән Ярмөхәммәт ни өчен соң монысына шулкадәр игътибарлы? Шушы кулның иясе Ярмөхәммәтне бик уйландыра башлады. Әз генә борылып караса, Ярмөхәммәт кул иясен танып алачак. Битендә яулык бәйләп эшләсә дә ул аны кыяфәтеннән таныр иде. Ләкин Ярмөхәммәт борылмады. Борылыр да кулның иясен таныр, иясе аңа ошамас. Бармаклары шундый нәфис, әйтерсең лә ул бармакларны кыру станогында ясаганнар. Башкаларның бармак буыннарында сөякләре калкып тора, ә бу кызның буын урыннары батынкы, бит очындагы чокырлар кебек. Кулга кылчык-кибәк ябышкан, ләкин Ярмөхәммәт тузанлы кулдан кимчелек эзләргә уйламады да. Көлтәне алганда Ярмөхәммәт серле бу кулга кагыла ала. Кул үзе кайчакларда Ярмөхәммәт тәненә тиеп-тиеп китә. Ярмөхәммәт аныcына каршы түгел. Бик риза. Кызның аңсыз хәрәкәтләре аңа ләззәт бирә. Кулның беләккә тоташкан урында яшь балаларныкы кебек буын бар. Шик юк, беләге дә кулы ке-

бек матур, беләге матур булгач, бу кызның бөтен җире матурдыр...

Тәнәфес җиткәч, кызлар чыр-чу килеп ындыр табагы куләгәсендәге көшелгә утырдылар. Кызлар аралашып, буталып беткәч кенә Ярмөхәммәт түбә астына узды. Кул иясен танудан курка иде ул. Могҗизаны озаккарак сузарга, кулны аерым гына күреп, озаграк ләззәт алырга иде аның исәбе. Тотарга иде шул кулны, яңакка куеп, рәхәтләнеп торырга иде. Иреннәргә тидерергә иде шул эшчән-матур кулны.

Кызганыч, тәнәфестән соң башка кул көлтә бирә башлады. Серле кул яңадан күренмәде.

Сабакташ егетләр бердән сизә: бүген бер-бер хәл булачак. Я күк капусы ачылачак, я койрыклы йолдыз атылачак, я җир тетрәр яки Альберт бүген үзенең хөкемен чыгарачак. Кызлар югында егетләр турник янына җыелды.

— Я кем?— дигәндәй ике дистә үсмер Альбертка карап катты.

Альберт үтә җитди иде. Ул һәр кешенең йөзенә карап чыкты.

— Егетләр, мин шундый нәтиҗәгә килдем...

Ул сүзен юри әйтеп бетермәде кебек. Тынлык эчендә иркенләп сулыш алды да:

— Рәйсә!— диде.

Алдан сөйләшеп куйгандай, егетләр шартлау тавышы чыгарып, көлде. Шартлау айгылдауга әверелде. Бу шаяруның кызыклыгын расларга теләгәндәй, тәгәрисе килмәсә дә, берничә малай җиргә ятып, эчләрен тотып, тәгәрәп көлә. Ике егет кенә көлүгә катышмады. Альберт үзе, икенчесе Ярмөхәммәт.

Көлү авазларын кыңгырау тавышы өзде.

Рәйсә Учавылга бик ерактан килеп укый иде. Кормашбаштан бөтен мәктәпкә ике укучы — Фатих белән Рәйсә.

Рәйсәнең тышкы кыяфәте дә, атна буе ашап торырга алып килгән ризыклары да, кызның очын-очка ялгап бара торган гаиләдән икәнлеген әйтеп тора иде. Пинҗәгендәге ямаулары гаҗәп пөхтәлек белән, тигез-матур итеп салынган булыр. Әйтерсең лә алар ямау түгел, чигелгән бизәк. Авыр сүз әйтүчеләр булса да, үзе гаепле кебек, дәшмәс, гафу үтенер... Такта янына чыгып җавап биргәндә дә башын кырын салып, идәнгә карап сөйли. Дәресен белсә, йомшак тавыш белән җавап бирә. Белмәсә, башкалар кебек ыкы-мыкы килеп, этләшеп тормый, такта янына чыкмый, урыныннан торып:

— Укымадым, белмимен,— ди.

Аның бу тыйнаклыгы ярлылыктан түгел. Ярлылар күп. Берәү дә бәрхет-атлас киеп мәктәпкә йөрми. Барысы да бәрәңге кырган яки ала-бута катыштырган ипи ашый. Ямьсезлегенә күрә, Рәйсә боек кебек. Житез-чая, матур кызларга карап, ул елмая. Көнләшеп түгел, яратып елмая: кара ничек чибәр бу Банат, и килешә дә соң аңа кычкырып көлү, дип кеше бәхете өчен сөенеп елмая ул. Күрәсең, өендә дә, үз авылында да аны үз ямьсезлегенә ышандырып бетергәннәр инде. Ул үзенең матур түгеллегенә ышанган, шул килеш, һичкемгә үпкәләмичә яшәргә йөз тоткан. Шуңа күрә ул тәнәфесләрдә, бик хаҗәте булмаса, ишегалдына чыкмый, уеннарга катнашмый. Я укыр, я уйланып утырыр, һич югында бияләй бәйләр. Егетләр өчен ул, әйтерсең, юк. Кызлар аны күрми дә. Ул шуңа риза. Чибәррәк кызларны малайлар тотып шар акырталар — бу үзенә күрә «мәхәббәт» аңлату инде. Тыштан бик сукрансалар да, эчтән генә кызлар моңа шатлана. Рәйсә ярым караңгы почмакта, иң арткы парта арасында берүзе китап укый. Энеләренә бияләй бәйли.

Ярмөхәммәт ул көнне парта арасында тимер каләмен алмаштырып утыра иде. Алыштырасы яңа каләм идәнгә төшеп китте. Шулчак аның яныннан Рәйсә узып бара иде. Рәйсә кинәт иелде дә читкә атылган каләмне алып, Ярмөхәммәт алдына, парта ырмавына куйды.

Ярмөхәммәт көлтә бирүче матур кулны таныды! Каләмне куеп, кул парта өстеннән әз генә шуып барды да юк булды. Рәйсәдәме шундый

нәфис кул? Рәйсәдә! Шундый матур кулның беләге ямьсез була аламыни? Шундый матур беләкнең иясе ямьсез була аламыни?

— Рәхмәт, Рәйсә!— диде Ярмөхәммәт.

Рәйсә сүзсез елмайды. Ярмөхәммәт, биле сынгандай, тораташ кебек катты да калды. Рәйсә бик матур булып күренде аңа. Рәйсә гүзәл икән бит! Нигә моңарчы күренмәгән ул чибәрлек? Нигә эчкә яшеренгән ул матурлык? Юк, яшеренмәгән. Без күрмәгән, без ишетмәгән, без сукыр булган! Рәйсә үзгәрмәде. Ярмөхәммәт үзгәрде бу мәлдә. Ярмөхәммәтнең күңел күзләре ачылды. Рәйсә, серле фәрештәдәй, матурлык бөҗрасы эчендә балкый. Аның нуры үзенә ияреп йөри. Ярмөхәммәт шул нурны күрә. Ни гаҗәп! Башкалар, бернинди дә могҗиза булмагандай, ипи чәйни, китап актара, котыра-котыра шаяралар. Бу нурланышның аларга күренмәвен, бары тик үзенә генә күренүен аңлады Ярмөхәммәт.

Менә шуннан соң Ярмөхәммәтнең бөтен теләге, яшәеше, гел Рәйсәгә бәйле була башлады.

— Иң чибәр кыз Рәйсә!— дип Альберт әйткәч, егетләрнең айгылдау сәбәбе әнә шул иде: ямьсезлек.

Ямьсезлек мәсьәләсендә егетләрнең фикере уртак булды.

Хаталык! Бик зур ялгышлык! Ямьсез түгел ул Рәйсә... Дөрес, ул әллә ни матур да түгел, тик ямьсез дә түгел. Кызык, сәер фәлсәфә. Матур булмагач, ямьсез булырга тиеш бит инде югыйсә. Юк! Рәйсә ямьсез түгел!

Егерме үсмер-егет арасыннан бары тик ике егет көлмәде: Альберт белән Ярмөхәммәт. Альберт әйткәндәй:

— Өченки көлүчеләрнең күңел күзләре ачылмаган иде!

Туганда бөтен адәмнәр дә ике маңгай күзе белән туа. Ә күңел күзе үсә-үсә ачыла. Яңа туган көчекләр тома сукыр була. Тора-бара аларның күзе ачыла. Туганда адәмнәрнең күңел күзләре көчек күзләредәй тома сукыр була. Кайбер адәмнең күңел күзе бик иртә ачыла, кайсыларының гомер уртасында, гомер азагында. Ә була шундый бичаралар, аларның күңел күзе бөтенләй ачылмый. Шулай күңел күзе сукыр килеш яшәп, сукыр килеш үлеп тә китә андыйлар.

Альберт белән Ярмөхәммәтнең күңел күзләре бик иртә ачыла барды. Табигатькә олы рәхмәт инде, бу ике егеткә ул мул итеп сиземләү биргән, киң карашлы күңел бүләк иткән.

Күңел күзе ачылмаган кеше тулысы белән шәхес булып өлгерә алмый. Ул бары тик бәндә булып кына кала. Шәхес булыр өчен өч баскыч узарга кирәк. Бәндә, Кеше, Адәм. Дөньяның бөтен әшәкелеге бәндәләрдән чыга. Кайда гына укып, зур белем алмасын, кайда гына зур урынга утырмасын, бәндә кешеләргә игелек кыла алмый. Ул бәндә дөньяга маңгай күзе белән генә карар. Ул тышкы рәвешләрне, өстә ялтыраган нәрсәләрне генә күрәчәк. Ә эчтәге катлаулы үзгәрешләрне үсешләрне, артка китешләрне күрү сәләте аңарда булмаячак. Ул бәндә, яхшылык эшлим дип, үзе дә сизмәстән яманлык кылачак.

Бу егетләрнең дә күңел күзләре ачылыр. Ни кызганыч, бөтенләй ачылмаганнары да шактый булыр. Дөнья бит. Аттан ала да туа, кола да туа.

Шушы көннән соң, ягъни сабакташлар Рәйсәдән көлгән вакытыннан соң, Альберт Төхфәтуллин беркайчан да кызлар турында сөйләмәде. Сорасалар да дәшми. Дәшсә дә ачулана. Башкалар өчен теге сорау җавапсыз калды. Сорауга җавап бирү эшенә башкалар алынып-алынып караганнар иде, ләкин алар сайлаган гүзәлләр чибәрлек тәхетендә озак утыра алмадылар. Альберт үтә житдиләнде. Хатын-кыз турында беркайчан да үз фикерен әйтмәс булды. Яманларга да теләмәде, мактарга да атлыгып тормады.

Шуннан соң Ярмөхәммәтнең күңеленә Альберт тагын да якынайды. Гомерлеккә сузылган ышанычлы дуслыкка ныклы нигез салынган иде...

...Лэйлэ Фэһимовна җилтерэп класска килеп керде дэ, исэнлэшкэнче үк, аягүрэ баскан укучыларга, «утырыгыз, балалар» диясе урында, кул гына изэде дэ:

— Без бүген профессиялэр турында сөйлэшэбез...— диде.— Кем кем булырга тели?

Укучылар көтелмэгэн бу сораудан каушап калды. Укытучы, нэрсэ авызыгызны ачып каттыгыз, дигэн сыман:

— Эллэ шул турыда уйлап та караганыгыз юк?— диде.

Мондый очракларда укытучыларга һэрвакыт Мирвэли ярдэмгэ килэ.

— Мин командир булам, Лэйлэ Фэһимовна!— диде Мирвэли.

Лэйлэ апаның йөзе ачылып китте.

— Офицер булу бик тэ яхшы, Исламов! Утыр!

— Э мин көй чыгаручы булам,— диде Һабул.

Лэйлэ аны да хуплады. Кемдер укытучы булырга телэвен эйтте, кайсыдыр мал духтыры булырга хыяллана икэн. Ду килде укучылар. Лэкин берэү дэ: мин колхозчы булам, мин эшче булам, димэде.

— Укыгыз, балалар, укыгыз,— диде Лэйлэ Фэһимовна.— Укымасагыз, энэ Тыйтак Лука кебек көтүче булып калырсыз. Укымаган кешегэ сан юк хэзер. Яки энэ Зөби җиңги сыман идэн юарсыз...

Альберт белэн Ярмөхэммэт кенэ кем булырга телэүлэрен эйтмэде. Лэйлэ алар ягына шелтэле карап:

— Э сез? Ике дус! Сез нигэ дэшмисез, э? Эллэ телегезне йоттыгызмы? Төхфэтуллин, сөйлэп җибэр, син кем булырга телисең? Бас, бас!

Альберт телэр-телэмэс кенэ калыкты.

— Сөйлэ, Төхфэтуллин!— дип кабатлады укытучы.— Эллэ синең беркем дэ буласың килмиме?

— Мин Исмэгыйлнең очучы булырга хыялланганын гына белэм,— диде дэ Альберт рөхсэттэн алда утырды.

Класс шымып калды. Укытучы Лэйлэ апа бер сүз эйтмэде. Мирвэли: «Бу тэрбиясезлеге өчен Лэйлэ апа ни өчен Альбертны ачуланмый инде»,— дигэндэй эле укытучыга, эле Альбертка борыла.

Лэйлэ Фэһимовнаның иреннэре бөреште, ук төзэп азапланучы мэргэннекедэй, күз кабаклары кысылды, җиз керфеклэре бер-берсенэ тиеп, күзлэре йомыла язды. Класс яшен яшьнэвен көтэ иде.

— Мин синең турыда сорыйм, Төхфэтуллин,— диде Лэйлэ апа сабыр булырга тырышып.— Син кем булырга телисең, дим.

— Белмим, мин сайламадым эле,— диде Альберт.

Ярмөхэммэт Альбертның хыялын белэ иде. Альберт шагыйрь булырга тели.

— Нигэ сайламадың, Төхфэтуллин? Башкалар сайлаган бит! Бас! Мин сиңа утырырга кушмадым бит эле, оятсыз!

Альберт янэ басты!

— Кем булырга телисең?

— Исмэгыйл очучы булырга тели иде, самолетлар йөртергэ...

Кемдер көлеп куйды. Мирвэли тагын башын алак-япак боргаларга тотынды. Лэйлэ бу юлы түзмэде, бармак сөяклэре белэн өстэлгэ каты итеп сукты.

— Төхфэтуллин! Хэзер үк класстан чыгып кит!

Альберт, эйберлэрен җыеп букчасына салды да, дэшмичэ чыгып китте. Шулчак Ярмөхэммэт тэ торып басты.

— Э син кая?

— Өйгэ!— диде Ярмөхэммэт.— Мин дэ Солтангалиевнең очучы булырга хыялланганын белэ идем.

— Барыгыз, бар, лэкин соңыннан ни буласын уйлагыз! Хулиганнар!

— Безабарзие,— диде Мирвэли.

Альберт, мине Ярмөхэммэт куып җитсен дигэндэй, юри салмак

атлап кайта. Ярмөхәммәт аның белән тигезләште. «Син ник киттең?» — дигән сорауның кирәге юк иде.

Алар сүзсез дә бер-берен яхшы аңлый.

Альберт ни кылганына үкенмидер. Шулай да аның кәефе юк. Ул әле генә булган бәхәсне яңабаштан кичерә иде, ахрысы. Ярмөхәммәт тә класстагы вакыйгадан аерылып бетмәгән.

— Син кем буласың?— дип сорасалар, Ярмөхәммәт ни дияр иде?

— Белмим,— дияр иде.

Ярмөхәммәт белә кем буласын. Ул очучы булырга да, шагыйрь, җырчы булырга да хыялланмый. Бер уйлап баксаң, аның хыялы хыял да түгелдер әле. Бары тик теләк кенәдер. Аның авылда каласы көн кебек ачык. Авылда, әнисе янында. Факиһә апасы кияүгә чыкса, Ярмөхәммәт авылдан китсә, анасы берүзе нишләр! Юк! Ярмөхәммәт авылныкы. Аның язмышы, гомере, кабере авылда булырга тиеш. Колхозда эш бетмәгән. Сукачы булыр. Ат җигәр. Дөресрәге, Ярмөхәммәт хыялын үзенә дә әйтергә шүрли. Әйтсә, хыялы куркып качар сыман. Аның хыялы — Әхсән абый кебек шофер булу. Узган җәйне генә Әхсән абый авылга беренче машинаны алып кайтты. Бик матур машина. «ГАЗ-51», ТИ-54-18 номерлы.

Туктале, Рәйсә кем булам диде соң әле? Ә-ә, Рәйсә ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Филшер,— диде.

Икенче көнне Альбертны, Ярмөхәммәтне укытучылар бүлмәсенә чакыртып, бик каты «мунча керттеләр». Бик каты шелтәләр, бик каты янаулардан соң гына чыгарып җибәрделәр.

Һөнәр сайлау вакыйгасыннан соң байтак вакытлар узды. Класс тормышы үз агымына кайтты кебек.

...Альбертның атасы Хәмидулла абыйны, көлтә урлауда гаепләп, чак кына төрмәгә утыртмадылар. Сабир аңа:

— Җә төрмә, җә авылдан китәсең!— дигән.

Китте Хәмидулла абзый борынгы ата-баба нигезен бөтенләйгә ташлап. Китте түгел, китәргә мәҗбүр булды, ата-баба нигезен ташларга аны мәҗбүр иттеләр.

Альберт Төхфәтуллин уку елы уртасында, ата-анасына ияреп, чит-ят җирләргә сәфәр китте.

Калдау күпере төбендә машина көткәндә Хәмидулла абый гел бер җыр җырлаган диләр. Васил́ә җырын җырлаган ул.

Без авылдан киткән чакта
Зират талы шаулады;
Мин мескенең халкәйләрен
Таллар гына аңлады...

Унсигезен тутырыр-тутырмас Факиһә апасы кияүгә чыгып, Урта Азиягә киткәч, Ярмөхәммәт тә күп уйлап тормады, укуын ташлап, колхозда эшли башлады.

Төп сәбәп шофер Әхсән абый сүзендә иде.

Беркөнне ул Ярмөхәммәткә:

— Кер миңа ярдәмче булып!— диде.— Башта йөк төярсең. Аннан соң мин сине машина йөртергә өйрәтермен! Шофер булсаң, югалмассың!

Ярмөхәммәт шул җәйне үк Әхсән абыйның «стажуры» булды.

Ул гомерлеккә авылда, җирдә калып, механизатор булып эшләячәген белә иде инде.

## Чакматаш

Алга таба тормыш уңай килде Ярмөхәммәткә. Әхсән абзыйдан алган һөнәре — машина белән җенләнүе — аңа армиядә дә ярдәм итте. Ярмөхәммәт Хәйруллинны «танковый часть»ка яздылар.

Армия Ярмөхәммәт өчен бәхет иде.

Ул ныклы һөнәр алачак. Танкист бит ул тракторчы да, шофер да, комбайнчы да — менә ни сөендерә иде Ярмөхәммәтне.

Яратты ул танк дигән куәтле машинаны. Дәҗҗалдай көчле тимер айгырга ул сокланып карый. «И-их, моның белән җир сөрергә!» — дип куя ул эчтән генә.

Йөртүче механиклар арасында ул иң алдынгысы булды. Маневрларда, өйрәнү машиналарында полковник Ковалев һәрвакыт Ярмөхәммәт танкысында утыра. Бу — бөтен мактаулардан да өстен горурлык иде.

Ләкин ул бәхетнең бер ягы китек иде шул. Күңел түрендә аның борчуы бар. Борчу гына түгелдер ул. Кайгы-хәсрәт дисәң дә дөрес булмас. Кайгы бит фаҗига нәтиҗәсе. Җитлеккән ир-егетнең сагышы иде ул борчу. Мәхәббәтне юксыну солдат хезмәтендә бигрәк тә көчле була. Хат язышырдай кызы булса, солдат рухы көр була.

— Мине сөйгәнем көтә! — дигән уй солдатны каһарман итә, әллә нинди авырлыкларны да җиңәргә көч бирә.

Солдатка бик тә кирәк кыз белән хат алышу. Шуңа күрә күп кенә солдатлар, хезмәттәшләре биргән адрес белән, таныш булмаган кызларга хат язарга атлыгып тора.

Кешеләргә хат күп килә. Ярмөхәммәткә дә килә. Рәүфтән. Рәүф артиллериядә хезмәт итә. Галимхан сирәк-мирәк кенә яза.

Ә Рәйсәдән хат юк.

Ант кабул иткән көнне төшкән фоторәсемен салган иде ул Рәйсәгә. Ай көтте, ел көтте, бәлки хат барып җитмәгәндер дип, янә язды. Аның зарыгып хат көтүе барыбер юкка булды.

— Кияүгә чыккандыр,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Буш вакытында ул шахмат та уйнамый, бильярд та сукмый. КПП-дан ерак түгел генә, часть территориясе аша инеш ага. Спорт залыннан туп-туры ул инешкә китә. Инеш буйлап йөри, үлән-чәчәкләр арасында нидер эзли кебек.

— Странный человек наш Ярый!— ди икән аның турында сержант Ястребов.— Все время што-то ищет в траве, у речки...

Ярмөхәммәт инеш ярында чуерташ эзли. Чуерташның да катысын, ут чыгара торганын. Урманга барса, ул агач гөмбәсе карый. Каен кәүсәсенә ябышып үскән гөмбәнең куы шәп була. Дары-бензин кебек гөлт итә дә кабынып китә.

Учениедән кайткач, солдатлар ялга ятты. Ярмөхәммәт кухняга кереп, әлеге каен гөмбәсен кайнатып йөрде.

Кайнатып киптергәч, гөмбә эченнән ку алып, чуерташ астына куеп, чуерташка тимер кисәге белән суксаң, очкын куга төшә дә чытырдап кабынып китә. Солдатларда шырпы да, зажигалка да бар. Ярмөхәммәт ни өчен шулай борынгы заманча ташка бәреп ут чыгара? Моны берәү дә белә алмас иде. Ярмөхәммәт үзе дә бу эшне кирәктән эшләми шикелле. Җирсүен басу өчен, эчендәге сагышын онытыр өчен эшли кебек.

Чәчәкләр арасында йөрүнең хикмәтен дә Ярмөхәммәт үзе генә белә. Эш югыннан эш табып йөри, дип ялгышалар. Ярмөхәммәт ялгыз җанын кая куярга белмәгәннән үзенә шулай шөгыль таба.

Ни өчен Рәйсәдән хат юк? Хатлар әллә барып җитмәдеме? Әллә ул кияүгә чыктымы? Әллә ул хат алышырга теләмиме?

Полигонда автоматтан, танктан ату ярышлары булса, ул сөенә. Вакытлыча булса да Рәйсә онытылып торыр. Ремонт килеп житсә дә ул сөенә. Машина янында аңа җиңелрәк. Марш чыгуларны да ул көтеп ала торган булып китте. Эш, хәрәкәт, авыр хезмәт кирәк аңа.

Ял көннәре, увольнениеләр килеп җитсә, Ярмөхәммәт өчен бәла. Кая куярсың ул буш вакытны? Ни белән үткәрерсең? Җәй көне чәчәк, урман тирәсендә юанып була, ә кышын үзеңне кая куярга соң? Шуңа күрә, ул спорт залында хәле беткәнче күнегүләр ясый. Тренер да гаҗәпләнеп:

— Вот Ярый! Как упорно тренируется,— ди.

Шуннан соң аңа «Ярый» кушаматы тагылып калды. Хәтта командирлар да аңа «Ярый» дип кенә дәшә.

Спорт ярышларында җиңеп чыгу өчен тырышмый ул. Рәйсәгә барып тоташкан сагышын онытыр өчен ул үзен шулай җәфалый.

Ястреб та, башкалар да кеше үртәргә ярата. Ярмөхәммәтнең бу сәерлекләреннән дә алар көләргә азапланганнар иде.

Янәсе:

— Ярый в речке потерял колечко!

Янәсе:

— Ярый агач гөмбәсе ашый!

Ярмөхәммәтнең андый үртәүләргә әллә ни исе китмәде. Үртәлгәнне генә үртиләр бит алар. Карантинда ук башланган бу үртәүләрдән бер кызык та тапмагач, Ястреб көлке угын Стариковка күчерде.

— Да-а, Старик, нишләптер синең Надюхаң хат язмый әле... Әллә мәйтәм, туйлап ятамы синең Надя!

Солдатларга житә калды, әдәпсез көлә башладылар:

— Кәнишне, күптән башка берәү кочагында инде ул...

— Нигә әле шундый чибәр кыз замухрышка рядовой Стариковны көтеп ятсын.

Бичара Стариков уңайсыз елмайган була, үзенең эчендә ут. Аның бу халәтен сизенеп, үртәүчеләр Надяның ничек итеп кияүгә чыгуы, ничек итеп ире белән беренче төн узгаруларын тәфсилләп сөйлиләр, үзләре оятсыз итеп көләләр. Шулчак Стариковның йөзе үзгәрә. Аның елмаюы елап җибәрергә әзер бала чырае кебек чалшая.

Аңа карап Ярмөхәммәтнең үзәге өзелә. Әче үртәү бу. Гаделсез, рәхимсез гадәт. Андый чакларда Ярмөхәммәт:

— Айда, погуляем,— дип Стариковны казармадан алып чыга.

— Ышанма син аларга!— ди.— Алар юри үрти бит... Көтә сине Надяң... Хатыннар турында алар юри шулай начар сөйли... Баксаң, аларның берсе дә әле хатын-кыз татып караганы юктыр...

Стариков дәшми.

Солдатлар үртәшеп туйгач кына, алар казармага кереп йокларга ята.

Их, бу ярату дигән нәрсәниләр генә кыландырмый солдатны! Сөю ул юаш кына солдатны да батыр итә ала. Мәхәббәт ул өрлектәй егетне аяктан ега ала.

Үртәүчеләр арасында иң үҗәте Кавказ егете Оган, аны солдатлар карантинда ук «Огонь» дип йөртә башлаганнар иде, менә шул Огоньны да кешелектән чыгарды ул сөю дигән нәрсә.

Оганның еракта калган кәләше барлыгын бөтен рота белә. Аниз исемле кыз. Анизның рәсеме Огоньның тумбочкасы өстендә тора. Гаҗәп чибәр кәләш. Оган үзе казармада булмаганда, егетләр шыпырт кына аның караваты янына килеп, Анизга карап-карап торалар. Егетләр Анизның матурлыгына соклана. Бу вакытта һәркем:

— Их, минем дә шундый кәләшем булса иде,— дип уфтанадыр.

Оган һәрвакыт кызы белән мактана.

— У-у, дэвочка! Красавитса всем Дагестани! Дагстан гына түгел, бөтен Россиядә, бөтен дөньяда минем Аниз кебек кыз юк. Эта драгатсинный камень, да!

— Әгәр Аниз кияүгә чыкса!— дип шаярта Ястреб.

Оганның кинәт кенә чырае җимерелде, ул Ястребның якасыннан умырып тотты.

Оган күзләрендә усал ут уйнаганын күреп, Ястреб берни әйтмәде. Аниз-фәрештә турында сүз бетте. Үртәү янә Стариковка күчте. Әле яңа гына сугыша язган Огонь белән Ястреб, сүз берләшкәндәй, Надяның «хикмәтләрен» тозлап-борычлап сөйли башладылар.

Шул төнне Ярмөхәммәтне нидер уятты. Солдатлар тирән йокыда

Кемдер гырлый. Кем икәне билгеле инде — Зотов гырлый. Сабирҗанов саташа.

Ярмөхәммәт гырлаганга гына уяна торганнардан түгел. Саташкан тавышлар гына аның йокысын бүлә алмый. Нигә уянды соң ул?

Кемдер елый.

Ә менә елау гадәттән тыш хәл.

Кайсы солдат өеннән яман хәбәр алды икән? Берәрсенең сөйгән кызы кияүгә чыктымы әллә?

Елау тавышы Стариков караваты ягыннан ишетелә иде.

Ярмөхәммәтнең йокысы качты. Ул Стариковның хәлен бик яхшы аңлады... Авыр кичерә шул егет әшәке үртәүләрне. Бәлки, чыннан да, Надя белән бер-бер хәл булгандыр? Әллә төшеп юатыргамы икән? Юк, башкалар уяныр...

Ул төнне алар икесе дә күз йоммады. Ә ике кешене тәмле йокыдан аерган Оган белән Ястребов рәхәтләнеп йоклый. Алар Стариковның кайгысына битараф.

Икенче төнне дә шул ук хәл кабатланды.

Надядан озак хат килмәгәнен бөтен рота белә. Бәлки, Стариков шуңа елыйдыр?

Ярмөхәммәт урыныннан төшеп, Стариковны юатырга уйлады. Шулчак Стариков елаудан туктады да бераз яткач, урыныннан торды, ашыкпошык киенеп, автоматлар тезелгән җиргә китте. Ярмөхәммәт терсәгенә таянып башын калкытты, ишек катына карады. Стариков бер автоматны алды да шыпырт кына казармадан чыкты. Дневальный башын тумбага салып йоклый иде.

Ярмөхәммәтнең хәтере кинәт яктырып китте. Ату кырында алар Стариков белән янәшә ята иде. Кыска очередь белән автоматтан атып, өч карачкыны аударырга кирәк... Стариков өч карачкының берсен екты да, магазинны алып, нидер маташтырды кебек.

— Рядовой Стариков стрельбу закончил! — дип рапорт бирде ул.

— Тройка тебе, рядовой Стариков! Плохо стреляешь, — диде капитан. — Патроны все?

— Все! — диде Стариков.

Ул чакта нигә игътибар итмәгән икән Ярмөхәммәт. Стариков патроннар яшереп калды бит.

Ярмөхәммәт өске караваттан аска сикерде, тиз генә бәдрәфкә чыкты. Стариков магазинны автоматка беркетеп маташа иде.

— Степан! — диде Ярмөхәммәт салмак кына.

Стариков сәчрәп китте. Ярмөхәммәт җәһәт кенә ыргылып, автоматка тотынды.

— Син нишлисең! — диде Ярмөхәммәт.

— Отдай, Ярый! — дип кенә әйтә алды, бер мизгелдә Стариков идәндә, автомат Ярмөхәммәт кулында иде.

— Не мешай мне, Ярый, не мешай! — дип Стариков елый башлады.

— Тихо! — диде Ярмөхәммәт. — Шулай ярыймыни? Төкер син аларга! Алар юри шулай котырта бит. Надя сине көтә. Ә син ахмаклык эшләргә маташасың. Кайтырыңа ел ярым гына калды бит инде. Иң авыры артта... Мине дә кызым бөтенләй ташлады... Бер дә автоматка тотынмыйм...

Ник әйтте ул бу ялганны? Ташлар өчен, вәгъдәләшкән кызың булуы кирәк бит әле. Бәхетсез Стариковны юатыр өченме? Аңа иптәш, кайгыдаш булыр өченме ул шулай әйтте?

Стариковка җан керде.

Ярмөхәммәт магазиннан ике патрон алды.

— Әйдә, кешеләр уянганчы автоматыңны урынына кертеп куй да кереп ят! — дип Ярмөхәммәт казармага узды.

Бу турыда беркем дә белмәде.

Нишләргә уйлады Стариков? Үзен үтерергә булганмы? Әллә үртәү-

челәрдән үч алырга идеме аның исәбе? Бусы сер булып калды.

Җаен туры китереп, Ярмөхәммәт Огонь белән Ястребка:

— Үртәмәгез сез Степанны! Ярамый!— диде.

— Ты што, Ярый, мы же пошутили!— дип карасалар да Ярмөхәммәт сабыр гына, тегеләргә үтәрлек итеп:

— В шестой части такие шутки кончились трибуналом,— диде.

Үртәшүләр әкренләп Стариковтан башкаларга, яңа килгәннәргә күчте.

Бу яман үртәшүләр турында Ярмөхәммәт күп уйлады.

Бер карасаң, Оган да, Ястребов та начар егетләр түгел бит. Ә каян килә соң бу рәхимсезлек? Каян килә кешенең изге хисләреннән көлү? Каян килә соң шәхесне мәсхәрә итү теләге? Юлга чыксаң, Оганнан да яхшы иптәш табалмассың. Җанын ярып бирердәй ярдәмчел кеше ул. Ястребов та кыюлык, ярдәмчеллек мәсьәләсендә егетнең егете. Ә менә солдатлар бергә җыелса, һәр икәвесе үзгәрә дә куя. Тотыналар әдәпсез мәзәкләр сөйләргә, хатын-кызлар ул мәзәкләрдә иң мәкерле, иң начар зат. Яшьләр аларны йотлыгып тыңлый. Ә төннәрен һәркем үз кызы турында уйлап, шикләнеп ята.

Арзан шөһрәт казанырга теләү бу, дип уйлады Ярмөхәммәт. Взвод, рота алдында данлы булу теләгеннән килә ахрысы мондый усал шаярулар.

Аларның бу гадәтләрен өнәмәсә дә, тегеләр Стариковны үртәүдән тукталгач, Оган белән Ястребка якынайгандай булды Ярмөхәммәт.

Гадәттән тыш булган бер вакыйга аларны тагын да дуслаштырды.

Ике ел хезмәт иткәннән соң булды бу хәл.

Танктан ату күнегүләре үткәргәндә Оганны, Ястребны, Ярмөхәммәтне Стариков белән бергә сакка җибәрделәр.

Коры суык көн иде. Бронетранспортер шушы дүрт егетне еракка илтеп куйды. Бронетранспортер киткәч, егетләр икешәр-икешәр бүленеп, патруль сымак әрле-бирле йөренә башладылар. Аларның вазифасы — кеше-фәлән, киек-җанвар полигонга кермәсен, дип күз-колак булып тору. Авыллар полигонга бик ерак, егерме-утыз чакрымлап булыр, әмма инструкция юлларга күз-колак булырга куша.

Мондый чакта сөйләшми торганнарның да теле ачыла. Вакытны ничек уздырмак кирәк. Юанырга кешеләр дә килеп чыкмый ичмасам.

— Стой, керергә ярамый, әйләнеп узыгыз!— дип вакыт уза торыр иде. Кыз-кыркын, хатыннар килеп чыкса, Оган белән Ястреб бик озак сөйләшергә ярата. Бүген поши да күренмәде, базарга баручы, шәһәрдән кайтучылар да булмады.

— Мин синең турыда Надяга язып торам,— диде Стариков.— Сиңа сәлам әйткән...

— Миннән дә күп итеп сәлам яз!— диде Ярмөхәммәт.

Ярмөхәммәт төнлә булган вакыйга турында сораштырмакчы иде дә, яхшысынмады. Стариков бик озак йөргәннән соң үзе башлады:

— Мин соңыннан гына, икенче көнне йокыдан торгач кына аңладым,— диде ул.— Төштәге кебек... Стрельбищеда алган ике патрон барлыгын беләм. Ә патроннар юк... Шуннан соң гына мин нәрсә булганын искә төшердем... Син алдың бит ул патроннарны...

— Кемгә атарга уйлаган идең соң?— диде Ярмөхәммәт.

— Белмим!— диде Стариков.

Сүз шунда өзелде.

Бер көнгә бирелгән азыкны ашап бетерделәр. Көн кичкә авышкач, аларны килеп алырга тиешләр иде. Билгеләнгән вакыт күптән узды инде. Егетләр бергә җыелып, бронетранспортер килгәнне көтә. Күпме генә көтсәләр дә, машина күренмәде. Егетләрнең күңеленә шом инде.

— Әллә оныттыларммы икән?

Бер урында тору туңдыра башлады. Оган үзенчә мыгырданып алды да:

— Караңгы төшә бит инде, әллә җәяү китәбезме?— диде.

— Көрт ерыпмы? — диде Ястребов.— Ике чакрымнан егылырсың. Болай да ашыйсы килеп үтерә.

Килсәләр дә төнлә аларны ничек табарлар икән?

Солдатлар сукмак буйлап йөгереп-йөгереп киләләр. Ярмөхәммәт урманга кереп торырга кирәклеген әйтте, урманда ышык та, җылырак та.

— Юк!— диде сержант.— Урман янында без күренмәячәкбез. Транспортер безне каян тапсын аннары.

— Учак ягарга шырпы да алмаганбыз,— диде Оган.

Дүртесенең берсе дә тәмәке тартмый. Каян килсен шырпы. Төн житте. Урманга елышырга кирәклеген Ярмөхәммәт тагын кабатлады.

— Юк! — диде сержант.— Моннан кучмибез. Аймыл булырбыз. Алар безне шушы урыннан эзләячәк.

Йөгереп килүләр бетте. Адымнар салмакланды. Карын өзелеп төшәрдәй булып ашыйсы килә. Стариков бөтенләй хәлсезләнде. Ашамаса, ул түзә алмый инде, бичара. Стариков калкып торган кар катламы табып, аркасын шул катламга терәп, кырын ятты да тезләрен шинель итәге белән каплады.

— Ятма,— диде Ярмөхәммәт.— Ятма, Степа, оеп китәрсең.

Күңелләргә өметсезлек инде. Ачыгу, салкын үз эшен эшли.

Стариков янына Оган чүгәләде. Бераздан Ястреб та алар, янына елышты. Ярмөхәммәт әле һаман йөренә, сикергәли.

— Онытты лар,— диде Оган.

— Шушында кәкрәеп катарбыз микәнни? — диде Ястреб.

— Юк,— диде Ярмөхәммәт.— Оныт салар да, казармага кайткач, исләренә төшәчәк.

— Исләренә төшәр вакыт узды бит инде, транспорт әллә кайчан монда булырга тиеш...

Ялкау гына әйтелгән бу сүзләр тора-бара бетте. Ярмөхәммәт:

— Торыгыз! Оешып катасыз бит,— дип аларны берничә тапкыр селкетеп карады.

Егетләр салкынны сизми, ачлыкны онытты: аларны арыганлык басты. Егетләрнең тәне генә түгел, зиһеннәре дә ойый иде, ахрысы.

— Болай булса, катып үләбез,— дип Ярмөхәммәт урманга таба китте, ара-тирә артына борылып карый-карый урман авызына җитте. Буран чыкмаса, ул иптәшләрен югалтмас. Килгән юлдан кире кайтыр.

Урманда бил тиңентен көрт ера-ера ул коры куак җыйды. Күтәрә алган кадәр утын алып, ул янә иптәшләре янына кайтты. Солдатлар ничек калган булсалар, шул хәлдә ята. Алар үлем исереклеге белән йоклый иде. Стариков уртада, ян-якта Оган белән Ястреб.

Танк тавышы ишетелмәсме, фара-искатель яктылыгы күренмәсме, дип Ярмөхәммәт әледән-әле күтәрелеп карый. Үзе учак кабызырга маташа.

Ул вак-нечкә чыбыкларны сындырып өйде. Бүрек колакчынын тешләре белән ертып, күп итеп мамык алды. Куен дәфтәрен вак кисәкләргә тураклап, нечкә чыбыклар өеме астына куйды. Кесәсендәге чакматашны алды. Чакматаш күн янчыкта иде. Чакматаш астына коры-җылы ку куеп, тимер кисәге белән ташка сукты. Бераз маташканнан соң, очкын куга төште. Ярмөхәммәт кар өстенә тезләнде дә, ике учы белән каплап, утны сүндермәскә тырышып, салмак кына өрә башлады, ку кабынды. Ку ялкынын кәгазьгә тигезде, кәгазьгә ут капты. Кәгазьдән мамыкка, мамыктан нечкә коры чыбыкларга күчеп, ялкын үрли башлады. Ярмөхәммәт ялкынга вак чыбыклар бирә, кәгазь кисәкләрен каптыра, мамык өсти. Хәзер учакны җилгә тапшырырга кирәк. Кар даласы уртасында дөрләп учак яна. «Болай булгач катып үлмибез, алла боерса»,— дип сөйләнә-сөйләнә, Ярмөхәммәт тагын урманга, утынга китте.

Икенче кайтканда Ярмөхәммәтнең җеп өзәр хәле калмаган иде. Сүнә язган учакны тергезеп, бар утынны ут өстенә өеп, ул егетләр янына елышты. Аркасын учакка куеп ятты.

Хәзер ул битараф. Катып үләрбез, дип тә уйламый. Учак уты төшеп, янарбыз дип тә борчылмый. Аларны алырга килерләрме, юкмы, дип тә хафаланмый. Аның бер генә максаты бар: йокы. Үлеп арылган. Үтереп йокы килә. Изелеп, таралып китәсе килә.

Ул бала кебек бөрешеп ятты. Яту белән йокыга киттеме, аңын югалттымы, әллә үлем исереклегенә чумдымы? Ул бардан юк булды.

Аларны икенче көнне төш авышкач кына эзләп таптылар.

Ярмөхәммәт төшендәме, өнендәме ишетте ул тавышларны: танк гөрелтесе, шау-шулар әллә кайдан җир астыннан килә кебек.

— Иптәш капитан! Монда-а!

— Живы? Живы они?

— Кажется, живы! Вон костер они развели...

Госпитальдән алар тиз чыкты. Ярмөхәммәт икенче көнне үк аягүрә йөреп китте. Ястребов өч көн тәне кызышып ятты да терелде. Оганның сул терсәге өшегән, ул атна чамасы дәваланды. Стариковның ике аягы да өшегән иде. Ике аягының да бармакларын киселәр. Бу хәбәр бөтен ротаны тетрәндерде. Стариков госпитальдән култык таяклары белән чыкты.

Степан Стариков икенче группа белән хәрби хезмәттән азат ителде. Аны бөтен рота озатты. Ястребов, Оган, Ярмөхәммәт вокзалга чаклы барды.

Барысы да Ярмөхәммәтне мактый.

— Ярый булмаса, өчесе берьюлы катып үләселәр икән... — диләр.

Хикмәт мактаудамыни? Кеше әнә сөйгән кызы янына култык таягы белән кайтып китте. Надясы аны ничек каршылар? Болай да юаш Степан гарип килеш ничек яшәр?

Мактаулы ротадагы бу хәл нәтиҗәсез калмады. Капитанны башка частькә күчерделәр. Егетләрне барып алырга тиешле танк командирын рядовойга төшерделәр.

Солдатлар:

— Шул кирәк аларга,— дип сөйләнсәләр дә, Ярмөхәммәт сүзгә катышып, гаепләләрне сүкмәде.

Алганнар, төшергәннәр, күчергәннәр... Степанга шуннан ни юаныч? Башкаларга сабак булсын, дисәләр генә инде.

## Кавышу

Хәрби хезмәттән соң бер ай ял итәргә уйласа да, Ярмөхәммәт атна чамасы йөргәч, тракторга утырды. Шылтык-пылтык йөри торган тракторны рәтләп, үкертеп эшли башлады. Эше җайлангач, ике утырып бер уйлады да өйләнергә булды.

— Әнкәй, мунчаңны ягып, бәлешне сала тор,— диде Ярмөхәммәт.

— Ни булды, улым? — дип сорады анасы.

— Кыз урларга киттек! Сиңа килен апкайтабыз! — дип Ярмөхәммәт чыгып китте.

— И ходаем, кешечә кылан, улым,— дип калды әнисе.

Нурлыгаянның:

— Кеше баласын рәнҗетә күрмә, балакаем,— дигән сүзләре ишетелеп калды.

Кияү егетләре — Рәуф белән Галимхан... Караңгы төшә башлау белән өчәү бригадир атын җигеп, кыз урларга киттеләр.

Аз сүзле бу өч ахири арасында иң телчәне Галимханның сорарга кыюлыгы житте:

— Кая барабыз?

— Кормашбашка! — диде Ярмөхәммәт.

— Килен кем?

— Рәйсә!

Сораулар тукталды. Кормашбаш Рәйсәсен егетләр белә. Фермада сыер сава. Яшьтәшләре үрчеп ята. Ул утырып калырга йөз тоткан сабыр гына, ямьсез генә бер кыз иде.

Ярмөхәммәт егетләрнең уен укып бара иде.

— Миңа Рәйсәдән башка бер генә озын чәч тә кирәк түгел! — диде Ярмөхәммәт.

Егетләр дәшмәде. Рәүф үзенчә мыгырдый башлады. Җырлавы идеме егетнең, зарлануы идеме, берәү дә аңламады. Дилбегә тотып утыручы Галимхан, атны куалаган булып, чөңгерә башлады.

— Фиют, әйдә, алаша-а! На-а...

Ат, койрыгын селтәп, ризасызлыгын белдерде дә, көр тавыш чыгарып, йөрәк кага-кага юыртып китте.

Ярмөхәммәт армиядән Рәйсәгә ике хат язды. Берсендә фоторәсемен салды. Ике хатның берсенә бер җавап килмәде. Ярмөхәммәт, Рәйсә кияүгә чыккандыр, дип өметен өзде.

Кичә учетка басарга дип хәрби комиссариатка баргач, Кормашбашның бер егете белән сөйләшеп киттеләр дә, Ярмөхәммәт сак кына Рәйсә турында сораштырды. Беленде ки, Рәйсә фельдшерлыкка да укырга бармаган, кияүгә дә чыкмаган, ата-анасы янында яшәп ята икән.

Кормашбашка җитәрәк, «хәрби киңәш» уздырылды.

— Хәзер үк Рәйсәләргә барсак, сизенерләр,— диде Рәүф.

— Егетләр уенда чакта барыйк! Риза булса, егетләр шәйләми кала,— диде Галимхан.

— Уен таралганны көтик мәллә? — диде Рәүф.

— Юк, ярамый,— диде Галимхан.— Уен таралгач, капка төбе саен өер була. Тәртә башын әләктерерләр. Тәртә башын гына әләктереп калсалар ярый, үзебезгә әләктерүләре дә бар... Кормашлар алар гел йодрык төйни торган халык.

— Анысы куркыныч түгел,— диде Ярмөхәммәт.— Без дә өч солдат.

— Һәй,— диде Галимхан.— Рәйсә өчен кем сугышсын!

Рәүф терсәге белән Галимхан-ачыгавызның бөеренә төртте. Галимхан «һык» итеп куйды. Ул дәшмәде. Хатасын аңлап алган иде. Ярмөхәммәт тә аның тел төбен бик яхшы сизде: утырып калган ямьсез Рәйсәнең кемгә кирәге бар. «Андый кызны урлаганыбыз өчен Кормашбашлар рәхмәт кенә әйтергә тиеш!» — дигән мәгънә ята иде Галимхан сүзләрендә.

Ярмөхәммәт караңгыда рәхәтләнеп елмайды. Сукырлар, күзле бүкәннәр бит сез, дип уйлады ул.

Хәл ителде. Күп уйлап тормастан, туп-туры Рәйсәләргә барып керергә. Ат янында Рәүф кала, Галимхан белән булачак кияү өйгә уза.

Йокларга әзерләнеп беткән хуҗалар ишекне озак ачмады. Башта Рәйсәнең атасы, аннан анасы берни аңламыйча:

— Без кунарга кертмибез, әнә кызсыз кешеләргә барыгыз! — дип ишекне ачмадылар.

— У-һу,— диде Галимхан.— Кызларын каты саклый болар.

Бераздан өйалдына Рәйсә чыкты.

— Кем бар анда? — дигән тавыш ишетелде эчтән.

— Рәйсә, бу мин, Ярмөхәммәт... Ярмай авылыннан Хәйруллин...

— Әстәгыфирулла,— дип сөйләнә-сөйләнә, каушый-каушый ишек келәсен алды да Рәйсә үзе тиз генә өйгә кереп китте.

Күрәсең, ул эчке күлмәкчән генә булгандыр. Өйдә ут кабызмадылар. Рәйсә каушый-кабалана шәл бөркәнеп, бүлмәдән чыкты.

Ата белән ана:

— Һи-и, танышларсыз икән алайса, узыгыз, утырыгыз, солдатлар,— дип самавыр хәстәрли башладылар.

Янар-янмас калтырап торган җиделе лампа яктысына күз ияләшкәч, Галимхан Ярмөхәммәткә төртте. Ярмөхәммәт дустына карады. Дусты тәрәзә кашагасына таба ымлады. Кашага өстендә Ярмөхәммәтнең солдаттан җибәргән рәсеме эленеп тора иде. Рәсем матур чигелгән чүпрәк кыса-

га урнаштырылган. Рәйсә Ярмөхәмммәтнең карашын тотып алды. Кыз оялды кебек. Ата белән ана да тәрәзә өстендәге рәсем белән Ярмөхәммәт арасындагы бәйлелекне күптән сизгәннәр иде, ахрысы.

Сүзне Галимхан башлады. Ул погонсыз гимнастеркасын билендә рәтләп, уң аягын алгарак сузып, күнитеге өстеннән чыгарылган чалбарына ишарәләгәндәй:

— Абый кеше... ие, апа кеше... — дип каккалап-суккалап кодалау эшен башлап җибәрде. Ул үзләренең кем икәнлекләрен, Ярмай-Урак кешеләре икәнлеген әйтеп, Ярмөхәммәтнең нәсел-нәсәбен мактап бетергәнче чәй дә өлгерде.— Салихҗан абзый, сезнең кызыгыз Рәйсәне, менә шушы Ярмөхәммәткә сорап килдек. Ие... фатихагызны бирәсезме?

Рәйсә кинәт торып, янә бүлмәгә кереп китте. Ана белән ата сүзсез калды. Ана кеше кызы янына таба атлады. Ике егет каршында ата кеше ялгыз калды.

— Алай икән... — диде хуҗа.— Әллә ничек була бит әле бу... Рәйсә дә бу турыда колакка төшермәде дигәндәй... Ул үзе дә... ни бит... кызым, анасы, чыгыгыз әле...

Аралыктан тын гына Рәйсә чыкты, аны әйдәләгәндәй, анасы күренде. Хатын-кызлар мич янындагы эскәмиягә утырды. Ярмөхәммәт кызга карамаса да, аның елаганын сизде. Тик ни өчен Рәйсә елый, шуны гына аңламады. Үзенә кияү табылганга елый идеме ул? Әллә ата-анасыннан аерыласын уйлап елый идеме? Ярмөхәммәт бу сорауга җавапны байтак гомер узгач кына, иске мәктәп янында уйланып торганда гына аңлата алыр. Моңа кадәр бер генә яклы мәхәббәтнең икенче яртысы табылуга сөенеп елау булган икән ул.

— Кызым,— диде ата.— Анасы... Менә бу егетләр бик олы эш белән йөри икән бит. Син соң... үзең ничек дигәндәй... — хуҗа егетләргә борылып: — Мин синең атаң Хисбулланы да, бабаң Айдулланы да яхшы белә идем... — диде.— Дөнья бәһасе кешеләр иде, мәрхүмнәр... Кызым, анасы... ничек уйлашыйк соң инде?

Читен тынлыктан чыгар өчен Ярмөхәммәт җай тапты:

— Мин бит сиңа хатлар яздым, Рәйсә... — диде ул.

Ярмөхәммәтнең язган хатларын Рәйсә чынга алмаган икән, чөнки аңа кадәр кемдер шаяртып биргән адрес белән солдатлар аңа мәхәббәт хатлары язганнар. Кормашбаш егетләренең рәхимсез шаяруларыннан соң Ярмөхәммәт хатлары да җавапсыз калган.

— Кызыбыз риза,— диде ана.

Ата-ана ярәшүне йола буенча башкарырга теләделәр.

Ярмөхәммәт эшне коры тотарга уйлады.

— Бабай,— диде ул, кинәт чын кияүгә әверелгәндәй.— Буш кул белән кайтып булмас. Йоласын соңыннан эшләрбез. Мин, Рәйсәне, рөхсәт итсәгез, урлап качам.

Аннан соң ул Рәйсәгә якын килеп, серле, мавыктыргыч итеп:

— Киен, Рәйсә, берни алма! Бер төенчек! Юкса хәзер егетләр уеннан тарала.

Рәйсә берсүзсез киенде дә әштер-өштер төенчеген төйнәде.

Ата-ана:

— И балакаем, хурлар була күрмә,— дип шөбһә сүзләре әйтте.

— Бабай! — диде кияү.— Айдаш бабаның Ярмөхәммәте Ярмай авылына тап төшермәс!

Китәсе кешеләр арбага менеп утыргач, Ярмөхәммәт:

— Әйдә, Рәүф, ку айгырыңны! — дип кычкырды.

— Һәйдә, бахбай! — дип сызгырып, чөңгереп, дилбегә белән кизәнеп, Рәүф атка сукты. Дөм караңгы, җәйге җилсез төндә арба тавышы коега кычкыргандай яңгырый.

Уен тарала, кемдер җырлый, кемдер сызгыра.

Арба дыңгырдый. Уеннан таралучы яшьләр шаулаша-шаулаша арба кырыннан уза. Кинәт кемдер кесә фонаре белән арбадагыларны яктыртты.

— Кемнәр бу? — дип сорады яктылык артындагы кеше.

Рәүф атны тагын да ныграк куаларга тотынды.

— На-а, әйдә-ә!

Әче итеп сызгырган тавыш ишетелде. Кесә фонаре бер янып, бер сүнеп, кемгәдер сигнал бирә башлады. Кайсысыдыр:

— Һа-а, җәмага-ә-ә-әт... Майбәдәрне урладыла-ар-ррр... — дип бугазы ертылганчы акыра.

Кормашбаш урамында шау-шу купты.

— Давай, Рәүф! — диде Галимхан.— Киленсез дә, кабыргасыз да каласың килмәсә, айгырыңны куала.

Бригадирның печелгән айгыры, хәлнең мөшкеллеген аңлап, бар көченә чаба. Басу капкасына җиткәндә ат төртелгәндәй туктады. Кемдер:

— Трр.— дип ат башын тотты.— Кыз сезнеке, мал безнеке, Тәртә башы — бер ярты,— дигән тавыш ишетелде.

Галимхан җәт кенә арбадан төшеп, күренмәгән кешенең кулына бер шешә аракы тоттырды. Ат янә алга ыргылды.

— Монысыннан котылдык,— диде Галимхан.

Ул арада куа чыгучылар тавышы якыная башлады. Кемдер мотоцикл кабызды.

— Каһәр икән,— диде Галимхан.— Матайлары да бар икән. Бай авыл, чукынчыклар.

Ярмөхәммәт белән Рәисәгә әллә бар дөнья, әллә юк дөнья. Ике кочак печән, ике кат ястык өстенә кырын ятып ни турындадыр пышылдаша, көлешәләр.

— Атыңны әрәмәгә таба ку! — дип кычкырды Галимхан.— Матасикллары ут кабызып килә. Узып китсен.

Ат, ыргылып сөргән җир өстенә килеп керде. Ул бер-ике талпынып карады да, авыр пошкырып туктады. Рәүф һаман аны чыбыркылый.

— На-а, на-аа...

— Кума! — диде Галимхан,— камыт бавын өзәрсең.

Егетләр сикереп төште, ат янә юлга чыкты. Мотоцикл уты якыная. Мотоциклдан алда ике җайдак чаба. Сызгыралар, кычкыралар, этләр өрә. Ду куба Кормашбаш. Ут чыкканмы, әллә яу килгәнме?

— Егетләр,— диде Галимхан.— Эш кыза. Ярмый, тор! Сиңа да өлеш чыгар монда, парин.

Ярмөхәммәт барысын да аңлап алды. Ат әрәмә күперенә кергәндә арттан куып җиттеләр. Мотоцикл яктысында калып, күзләр сукырайды. Тавышларына караганда, яктылык артында егермеләп кеше бар иде шикелле.

— Ах, анагызга с-сабак буласы нәрсәләр! — дип кычкырды ат өстендәге егет. Ул арада җәяүлеләр дә килеп җитте. Арбадагылар камалышта калды.

— Егетләр, без... — дип Галимхан аңлата башлады.

Аның аклануын тыңлап тормадылар. Кормаш егетләре сугышырга алгысып тора. Рәүфне арба башыннан бәреп төшерделәр. Галимхан:

— Кагылмагыз, ата-аам! — дип яшел тавыш белән акырды.

Ләкин күзләре акайган Кормашбашлар бу тавышны ишетмәделәр дә. Бер төркеме Рәүфне караңгыда әвәли, бер төркемгә каршы Ярмөхәммәт үзе сикерде. Галимхан кызны саклап, арбада аягүрә калды, арттан килеп кемдер аның аягыннан кискен итеп тартты. Галимхан аска тәкмәрләде. Кинәт мотоцикл уты сүнде. Чалтырап пыяла коелганы ишетелде. Дөм караңгыда калып, сугышчылар кайда үзләренеке, кайсы якта дошман икәнлеген дә белми. Соңыннан аңлашылды: Кормашбашлар үз кешеләрен тукмаган булып чыкты.

Рәисә колакларны без белән тишкәндәй, әче итеп «каравыл» кычкыра башлады. Кешеләр әллә арды, әллә хатын-кыз чинавына айныды, сугыш туктады. Анда аһ, монда вах... Авыл ягыннан фонарьле кешеләр килеп җиткәндә, ыңгырашучылар арба янына җыелган иде.

— Кая? Кем? — дип кычкырды фонарь тоткан абзый.— Кая Майбәдәр? Нишләп Майбәдәр булсын бу?

Абзый ястыкка капланып елаучы Рәйсәнең башын калкытты, фонарен күтәрә төште.

— Рәйсә бит бу! — дигән сүз бер авыздан чыккандай ишетелде.

Баш түбәләре күпсә дә, яңаклары каймыккан булса да, бер-ике кешенең күз төпләре күгәргән булып, тешсез калучылар да берьюлы тагын:

— Рәйсә-ә? — дип гаҗәпләнде.

Урланган кызның авыл гүзәле Майбәдәр булмавы бер шатлык булса, урланучы кызның Рәйсә булып чыгуы икенче шатлык иде, ахрысы. Егетләр айгылдап көлделәр.

— Урлаучысы кем, кайсы авылныкы? — дип кычкырды берәү.

— Мин — Ярмайдан, Ярмөхәммәт Хәйруллин,— диде кияү.

Ирене калынайган, өс-башы пычранган бер егет яктылыкка чыкты.

— Ярмый-ый, ахири-и, синмени бу? — дип әлеге егет Ярмөхәммәтне кочаклап алды.— Бу бит минем сабакташ, егетләр. Учавылда бергә укыдык.

— Исәнме, Фатих,— диде Ярмөхәммәт.

Рәүф тә, Галимхан да табылды. Галимхан аксый, Рәүф әледән-әле чигәсен капшый. Чигәсен капшый да чыраен сыта.

— Егетләр,— диде Галимхан.— Тәртә башы тотканга тагын бер яртыбыз бар, шуны алыгыз да безне җибәрегез инде сез.

— Кормашбашлар! — диде Фатих.— Безнең авыл кияве Ярмөхәммәтнең туй арбасын Чалбаш күперенә чаклы озата барабыз.

— Барабыз! — дип кычкырдылар.

Чыннан да, ике җайдак, берничә җәяүле егет аларны байтак җир озата килделәр.

Әле яңа гына дошманнарча сугышып яткан егетләр кочаклашып аерылыштылар.

— Рәйсә! Ярмай авылына яхшы килен бул! — дип калды егетләр.

Егетләрдән ерак киткәч, чиратлашып ыңгырашучы Рәүф белән Галимханга карап, Ярмөхәммәт тыела алмый көлә башлады. Рәйсә дә аңа кушылды. Отыры Рәүф белән Галимханга да көлү шаукымы йокты.

— Уеннан уймак, табадан коймак чыгара яздык бит,— диде Ярмөхәммәт.

— Мин шундый нык курыктым,— диде Рәйсә.

Соңыннан өстәп куйды:

— Берәрегезне имгәтерләр дип...

Ярмөхәммәт капшап, Рәйсәнең кулын эзләп тапты. Җылы, йомшак кул Ярмөхәммәтнең кулын сизелер-сизелмәс кенә кысты да, зур кул эченә кереп, песи баласыдай йомарланып ятты. Ярмөхәммәт мәктәптә укыганда күргән кулны аермачык итеп күзаллады.

Ниһаять, ул матур кул аныкы!

— Туйга хәтле төзәлер әле яраларыгыз,— диде Ярмөхәммәт.

— Өчәү егермегә каршы тор әле син,— диде Галимхан.

Рәүфнең көлемсерәгәне ишетелде.

— Нигә көләсең, тишек чигә! — диде Галимхан.

— Икәү дин... Мине санга сукма син... — диде Рәүф.— Чигәгә берне оруга ук мин егылып төштем дә ат астына кердем.

Галимхан көлә.

— Ике Ярмай егете, Кормашбашларның егерме егетенең тешен коеп, кызларын урлап качкан, дигән хәбәр иртәгә үк бөтен Рәчәйгә таралмаса, исемем... үй... минем дә бер теш какшаган бит, егетләр... — диде Галимхан.— Исемем Галимхан булмасын!

— Ут сүнгәч алар үзләрен үзләре тукмады бит,— диде Ярмөхәммәт.— Мин бер-икесен сөргән җир өстенә алып ыргыттым. Зыян булмас, йомшак анда. Түшәккә төшкән кебек булгандыр.

...Кыз урлау вакыйгасы әкият-риваять, мәзәк хәл рәвешендә тагы да

купайтылып, арттырылып, телдән телгә күчеп озак еллар яшәячәк.

Рәйсә әби булгач, бу төнге маҗара турында аңардан яшьләр, оныклары сораштырачак. Имеш, Рәйсә әби кыз чагында гаҗәп чибәр булган. Төбәктә генә түгел, бөтен Татарстанда данлы матурны ун тапкыр сораткannар, Рәйсә берсенә дә чыкмаган. Ярмайның Айдаш баба оныгы Ярмөхәммәт гүзәл Рәйсәне Кормашбашларның борын төбеннән урлап качкан. Куа килүчеләр белән кыз урлаучылар арасында сугыш чыгып, Кормашбаштан биш, Ярмайдан ике егет үлгән икән...

Чибәрлек мәсьәләсенә килгәндә, ул чыннан да шулай. Кияүгә чыккач, Рәйсә күзгә күренеп үзгәрә башлады. Аның гүзәллеген, эчке бер сөйкемлелеген, Ярмөхәммәттән башка ике генә кеше белә иде — Альберт, анасы Нурлыгаян. Яшеренгән бу матурлыкны шигъри күңелле, күзәтүчән кеше генә күрә ала.

Килен чишмәсенә беренче көнне үк китте Рәйсә. Ерактан тулы чиләкләр күтәреп кайтканда Нурлыгаян капка төбендә утыра иде. Ярмөхәммәт тә шунда. Һәр капка төбендә карчык-корчык, хатыннар, кыз-кыркын утыра. Яшь килен карарга чыкканнар. Шулчак тыкрык почмагыннан берничә яшь киленчәк белән Рәйсә дә күренде.

— Сөбханалла,— диде Нурлыгаян улына.— Күз генә тия күрмәсен. Бигрәк сылу. Атлаулары бигрәкләр матур.

«Һе, матурлыкны аңлый әнкәй»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Баладан соң Рәйсә күзгә күренеп сөйкемлеләнә барды. Тора-бара Рәйсәнең сылулыгы турында бөтен авыл сөйли башлады.

Килен төшкән көннең икенчесендә үк яшь-җилбәзәк егетләр:

— Җә, кыз куйнына керү ничек соң? — дип шаяртсалар да Ярмөхәммәт бу турыда авыз ачып сүз әйтмәде.

Яшьтән үк ул хатын-кыз турында уртага салып сөйләшергә яратмады. Кеше сөйләгәннәрне дә тыңламый иде.

Фәлән кыз белән йокладым, төгән иттем дип, булса-булмаса да лаф орган ир-егетләрне ул якын итмәде. Бу мәсьәләдә Альберт, Рәүф, Галимханга карап сөенә. Бу егетләр өчәвесе дә беркайчан да хатын-кыз турында яман сүз ычкындырмады. Начар хатыннар турында сүз чыккан-да да алар дәшми калуны мәгъкуль күргәннәрен Ярмөхәммәт яхшы белә. Юкса кеше сөйли, кеше мактана дип, тотыналар да гайбәт сөйлиләр. Хет җир тишегенә кереп кит.

Хатын-кыз белән булмаганны булды дип сөйләү — бер кабахәтлек. Шапшаклык. Гөнаһсыз хатынны кимсетү. Теге дөнья була калса, шушы гөнаһысы өчен бу мактанчык егетне тәмугның иң кызу җирендә яндырачаклар. Гөнаһсыз кызга шул пычракны ягып, дөньяда ничек саф яшәмәк кирәк?

Булган очракта да, шул турыда малай-шалайга сөйләп утыру унлата түбәнлек, унлата хыянәт. Ул хатын-кызны бер түбәнәйтсә, шулай сөйләгән кеше үзен йөз тапкыр пычрата түгелме соң? Шул түбән, бозык, юмарт хатын белән йоклагач, син үзең кем буласың соң?

Ә үз хатыныңның изге серләрен башкаларга сөйләү — мең тапкыр хыянәт!

Кыз алып кайткан төнне алар бишәүләп кенә таң атканчы чәй эчтеләр. Рәүф, Галимхан, Ярмөхәммәт, Рәйсә, Нурлыгаян. Бәлешнең дә төбенә төштеләр. Егетләр Рәйсә белән Нурлыгаянга күрсәтмичә генә мунчада әз-мәз кәгеп кerделәр. Кыз урлау вакыйгасын кайта-кайта сөйләп, көлә-көлә арып беттеләр. Көлгән саен Рәүф чигәсен, Галимхан балтырын тотып чырайларын сыткаладылар. Кыз урлау корбансыз гына булмый икән шул.

Зөфаф кичәсе, кыз куйнына керү төне шулай йокламыйча узды.

Ярмөхәммәт Рәйсәнең үзенә ияләшеп беткәнен көтәргә булды.

Рәйсә килен булып төшкәч, унбиш көннәр узгач, бик каты яңгыр яуды. Рәйсә бик шәплән мунча якты. Коймак пешерде. Иң башта каенанасы Нурлыгаян керде мунчага. Аннан соң Ярмөхәммәт белән Рәйсә китте.

Аларның беренче тапкыр гына баруы түгел инде. Ләкин Рәйсә һаман ире алдында чишенергә кыенсына. Аның шулай оялуы Ярмөхәмматкә бик тә ошый. Шуңа күрә ул ашыкмый. Ләкин бу эшне озакка сузарга ярамаганлыгын да ул яхшы аңлый... Ярмөхәммәт форсат көтә.

Урманга бардылар, утын әзерләделәр. Печән өстендә дә, каралтыкура тирәсендә дә гел-гел бергә эшлиләр, җае чыккан саен, Ярмөхәммәт Рәйсәнең үз кеше икәнлеген, якын зат икәнлеген, аларга бер тән, бер җан булырга кирәклеген аңлаткандай, кочаклаштыргалый, кайчакларда җиңелчә генә, яратып-сөеп кенә, сак кына үбә.

Яңгыр яуган көнне, мунчадан соң алар келәткә ятты. Чәй эчеп, тәннәр корып-шомарып беткәч кенә икесе юрган астына чумды. Алар бер-берсенең тыннарын сулап ята. Каен себеркесе, мәтрүшкә исе тәнгә сеңгән. Хушбуйларың бер читтә торсын. Тыгыз тәннәр ефәк кебек шома. Бу ике тән бер-беренә күнегеп беткән иде инде. Ярмөхәммәт вакыт килеп җиткәнен сизде.

Күк күкрәмичә генә, утырып яңгыр ява. Яусын.

Яңгыр, болыт, кояш — ир затыдыр.

Җир, туфрак, болыннар — ана.

Уртасында чәчәк, кош-корт, киек-җәнлек,— балалар, нәсел, токым.

Яусын яңгыр...

Алар өчен яңгыр да юк, алар өчен вакыт та туктаган, алар өчен дөньяның матдилеге югалган. Алар башка вакыт белән яши, алар башка галәмдә — үз дөньяларында. Галәмдә галактикалар салмак кына берберенә кереп аралаша. Бер галактика икенчесен үз эченә ала. Бу мең, йөз елларга сузыла.

Җирнең, галәмнең уртасы шушы келәттә.

Кыштыр-кыштыр чабышып йөрүче төнге тычканнарның чикылдавы да ишетелми. Почмак җырчысы чикерткәнең дә тавышы юк бүген. Бөтен табигать тынын кыскан. Яңгыр гына туктарга исәпләми, шыбыршыбыр ява да ява.

Олы мәхәббәтнең иң изге сере, яшерен сере бүген Рәйсәгә ачыла бара. Бер җан иясе дә бу изге серне белергә, карап торырга тиеш түгел. Ишек өстендәге пәрәвезгә эләккән юан чебенгә дә исе китмичә, үрмәкүч-патша да оясыннан чыкмый, итагать саклый.

Алар икесе дә, яңгыр озаграк яусын иде, дип тели иде. Аларның теләге кабул булды. Икенче көнне дә яңгыр туктамады. Яңгырның гел бер төрле шыбырдап түбәгә яуганыннан вакытны тою хисләре йоклаган иде. Алар тирән йокыга чумды.

Уянганда икесе дә бөек бер дәрт, яңа көч-куәт сизделәр. Алар янартылган мунчага китте.

Рәйсә ятактагы җәймәне мунчага алып китәргә исәпләгән иде, ахрысы. Ул җәймәне җыя башлауга ук Ярмөхәммәт:

— Тимә! Шунда калсын! — диде.

— Нигә? — диде Рәйсә.

— Йола-а! — диде ире.— Шулай кирәк. Озакламый аңларсың.

Алар мунчага керер-кермәстә, Бәдигылҗамал түти дә, Маһипәрвәз апа да төлкедәй елгырлык белән келәткә шудылар.

Мунчадан соң чәй эчкәндә Ярмөхәммәт хатынының йөзенә бакты. Аның алдында алсу чәчәк алиһәсе утыра иде.

— Рәйсә, син бит Алиһә, син чәчәк кызы! — диде.

Чәй ясаган җиреннән туктап, Рәйсә иренә карады.

— Ни әйттең? — дип сорады ул.

— Син бит Алсу чәчәк кызы! — диде Ярмөхәммәт.

Рәйсә чәй ясавын онытып, байтак кына Ярмөхәммәткә карап торды да елмайды. Ярмөхәммәт:

— Ие, мин Алсу чәчәк алиһәсе! — дигәнне көткән иде, ләкин Рәйсә бер сүз дә әйтмәде, елмайган килеш, сөтле чәй белән мөлдерәмә чынаякны Ярмөхәммәткә сузды.

*1986*

# ПОЭЗИЯ

## Зәки Нури

### Тезләнүләр

Тезләндем мин, дуслар, бик-бик сирәк,
Изге антым санап барсын да:
Сәфәрләргә киткән-кайткан чакта —
Башым иеп әнкәм каршында.

Бер тезләндем, кысып үбәр өчен
Байрак читен учка алдым да,—
Ватаныма тугры булырмын, дип,
Вәгъдә бирдем полкым алдында.

Ә бер чакны тәүге гыйшкым төшкән
Гүзәл кызга чәчәк өзәргә,
Кайнар сулап, янә бер тезләндем —
Тормыш юлын, димәк, бизәргә.

Тезләндем мин һәм тезләнәм һаман
Саф чишмәләр суын эчәргә —
Туры килсә юлда, арып-талып,
Ерак араларны кичәргә.

... Тезләнү ул чүгеп алу түгел,
Чүккән сыман бию остасы.
Тезләнү ул — кыйбла сайлый белү
Адашмаулар өчен, кыскасы.

### Үткәнгә төбәлә күзләр

Учаклар, учаклар!
Һәр җирдә учак бар!
Учаклар якканнар,
        күр, язның түренә:
Утлары сикерешеп
        биеккә үрелә,
Ерактан — алтынсу
        томандай күренә.

Һәммәсе янында
        кайнаша балалар —
Зур утка я чүп-чар,
        я салам салалар...

Азса һәм тузса ут,
        тыяр көч җитәрлек!

---

ЗӘКИ НУРИ *(1921) — шагыйрь, «Шигырьләр», «Лирика, юмор, сатира», «Күңел яктысы» һ. б. татар һәм рус телләрендә басылган күп санлы шигырь китаплары авторы. РСФСРның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

Учакның гайрәте
чамасыз артканда:
Дымсу җил сарыла,
салкын җил тырыша
Ут — төлке койрыгын
өзәргә тарткандай...

Ә күктә торналар
таныш җир өстенә
Ләйсәннәр сибәргә
ашыга шикелле...

Таныш җыр тавышын
каршылау күңелле:
— «Саумы син, туган җир,
кадерлем, сөйкемлем!»
... Һәм тагын үткәнгә
төбәлә күзләрем,
Һәм тагын кинәттән
кысыла сулышым —
Газаплы яу кыры
исемә төшә дә,
Утларын уйлыйм да
каргалган сугышның.

## «Үлемгә — үлем!»

*Муса Җәлилгә*

Ил чиген узып дошманнар атлый,
Туган туфракны илбасар таптый...
Ярсу үчеңне канат иттең син.
Озатты халкың, озатты илең:
— Дөрләсен ялкын! Үлемгә — үлем!

Автоматыңнан үчле ут аттың,
Утлы җыр җырлап окопта яттың.
Мең үлем белән янады дошман,
Утлы боҗрага камады дошман.
Канатың сынды туган ояда,
Бөркеттәй бәрелеп булмый кыяга.
Пышылдый халкың, пышылдый илең:
— Тагын бер талпын! Үлемгә — үлем!..
Чәнечкеле киртә. Күренми юллар...
Фашист куана: «Сез инде коллар!»
Ә син, ышанып иң якты көнгә,
Көрәш башлыйсың караңгы өндә.
Синең сүз — байрак кыю дусларга:
«Нәфрәт утлары яусын дошманга!»
Йөрәктә — халкың, йөрәктә — илең:
— Сүнмәсен ялкын! Үлемгә — үлем!
Синең сулышны таш зиндан буды.
Синең йөрәктә кайнар җыр туды.
Ялкынлы ул җыр — үлемнән көчле.
Дуска бүләк ул, дошманга үчле.
Айкап күкләрне, узып җилләрне,
Синең үлмәс җыр гизә илләрне.
Кабатлый халкың, кабатлый илең:
— Яшәсен ялкын! Үлемгә — үлем!

## Һәр яктагыча

Фашистлар шашынып бомбага тотканда,
Курыкмады музалар котырган уттан да:
Музалар булдылар җирдә күк күкрәве,
Музалар булдылар күктә җир тетрәве.

## Ерактан аваз

БИЛГЕСЕЗ СОЛДАТ МОНОЛОГЫ

«Кай адымда, кайда ауганымны
Мин дә белмим, сез дә белмисез.
Әллә бомба, әллә пуля екты,
Анысы да төгәл билгесез». —
Кыю тавыш, күптән тынган тавыш
Ишетелә һаман ерактан —
Фонтан булып гүя атыла ул
Җир астында калган йөрәктән. —

Ут ташкыны безгә каршы акты,
Кайнар җилләр каршы истеләр,
Фашист килде бик күп ялкын алып...
Минем юлны шулар кистеләр.

Юк, мин әйтмәм: «Үлдем... ятып калдым...
Авыр юлда аяк талды»,— дип.
Тел күтәреп дошман әйталмасын:
«Минем җирдә ятып калды» дип.

Чөнки бит мин үзем «атып калдым»,
Чөнки шундый халкым мәкале.
Бик күп фашист төшкән чакны күрдем
Яр читеннән суга мәтәлеп!..»

... Таныш тавыш. Кырык беренче елда
Үлгән илдәш, сине җир тыңлый.
Җирдә әле, дустым, һаман давыл,
Җирдә әле һаман җил тынмый.

## Өлкәннәргә рәхмәт сүзебез

Рәхмәт сезгә, безне үстергәннәр,
Безнең өчен яшәгәннәргә,
Безнең өчен утлар-сулар кичеп,
Безнең өчен яшьнәгәннәргә.

Әйдәп әйткән сүзләр өчен рәхмәт:
«Атлагыз,— дип,— безнең юллардан!»
Киләчәккә бару путевкасын
Без бит алдык сезнең куллардан!

## Горький

... Аның йомшак чәчен җиләс җилләр тарый,
Идел шаулый. Ул — иркен һәм тирән сулы.
 Япь-яшь малай көн дә шунда килеп карый:
Гүя Идел халык яше белән тулы...

Кем уйлаган, күреп аның бала чагын:
Иделдән дә киңрәк юллар салачагын,
Бик күп буын аны телгә алачагын,
Маяк булып Горький мәңге яначагын.

Халыкларның тирән хисен җырлады ул,
Һәм халыкның турылыклы улы булды.
Иҗатында азатлыкны зурлады ул,
Үткән юлы — бөек көрәш юлы булды.

## Кыңгыраулар үксеп чыңлый

Куе үлән баскан үзән
буйлап үтәм.
Монда Хатынь сабыйлары
уйнап үскән.

Болын тутырып күпме
чәчәк исе аңкый!
Җир җиләге алсу
төймә төсле балкый.

Кайберләре яна
уттай кызарып ук...
Ник җыймыйлар? Чөнки
Хатынь кызлары юк.

Күпме алан —
ерагы һәм якыннары...
Йөри анда ләкин
Хатынь хатыннары.

Юл буена чыгып
баскан күпме гөмбә!
Тик аларны килеп
өзмәс монда кем дә.

Әнә болын — Хатынь
печән чапкан җирләр.
Инде монда чалгы
чыңлатмыйлар ирләр.
Үләннәрне еккан
сагыш җиле, исеп...
Тик кыңгырау чыңы
кайта монда, үксеп.

## Шундый булмасын йөрәк

Үзәк өзгеч зәһәр салкын,
Теш камаштырган җимеш,
Җылысы булмаган ялкын,
Сулары кипкән инеш...

Нурсыз яз, яңгырсыз болыт,
Чәчәк атмаган гөлләр,
Былбылның калуы тынып...
Айсыз-йолдызсыз төннәр...

Җир күрми тутыккан көрәк,
Караңгы һәм ерак юл... —
Ярата белмәгән йөрәк
Менә нинди йөрәк ул!

## Чишмә

Юкка түгел бу шатлыгым.
Таптым йөрәк чишмәсен.
Беләм анда су сафлыгын,
Беләм аның кипмәсен...

Чишмәм минем күпкә җитәр —
Эч кенә һәм эч кенә!
Безне зур да, нык та итәр
Шушы үлмәс хис кенә.

## Дуслык бүләге

Бүләк алдым мари дустымнан:
Яңа китап миңа җибәргән!
Килде шаулап яшел дулкыннар,
Сәлам килде җиләс җилләрдән...

Йөрәк аша, тагын яңарып,
Сузылдылар урман юллары,
Килде гүя алсу таңнарның
Җемелдек һәм уйнак нурлары.

Кулым тиде ап-ак шомыртка,
Чыршыларны сөеп сыйпадым.
Әйтә алар гүя: — Онытма,
Бер килеп чык безгә,— дип, — тагын.

Килде уйнап кышкы бураннар,
Агач өйгә барып кердем мин.
Иркен мәйдан, туры урамнар... —
Йошкар-Ола төнен күрдем мин.

Тулды гүя минем өемә
Сагыз исе аңкып нараттан.
Күңел җырлый, күңел сөенә,—
Шулай бит ул дусны яратсаң!

«Һичнәрсәне онытып калдырмый
Алып килдем сиңа», — ди китап.
Чамасыз зур бүләк алдым мин,
Һәм шатлыгым минем бихисап!

## Гамил Афзал

# БИЕК ҮРДӘН ТОРЫП

❁

Мин сүземне сөйләп бетермәдем:
Йолдызлар сибелгән төннәр булыр,
Айлы төндә минем тавыш кебек
Ымнар булыр, өннәр булыр.

Мин сүземне сөйләп бетермәдем:
Минем тавыш килер искән җилдән,
Ул аланда кыштыр-кыштыр итәр
Сынган ботак, кипкән үлән.

Мин сүземне сөйләп бетермәдем:
Шаулап-үкереп агар агым сулар,
Кара төндә урман култыгында
Минем тавыш белән бер җан елар.

❁

Казан сөйли: — Җәяүле буран...— ди.
Мәскәү сөйли: — Юлларда томан,— ди,
Фәлән-фәлән метр җил исә, ди,
Өйдә генә утыр, югыйсә, ди.
Утырыр ла идек, эч поша шул,
Мәшәкатьле заман эш куша шул,
Ил байлыгын табу — безнең һөнәр,
Борчылулы көннәр һәм төннәр...
Кемнең кай җире авырта —
Безне дә кемдер кайгырта.

❁

Кеше җаны — кара урман, дигән,
Тирән диңгез, дигән кемнәрдер.
Кеше җаны кыргый, кара төннән
Якты таңнар эзләп килгәндер.

Кеше җаны — чакма ташы, дигән,
Йөзек кашы, дигән кемнәрдер.
Кеше җанын изгелекләр иңгән
Бәхет илләрендә кинәндер!

❁

Бу татарның, мескен бүрек киеп,
Балаларга китап өләшеп,
Белем биргән шагыйрьләрен сөеп,
Биек үрдән торып сөйләшик!

Биек үрдә биек урман үскән,
Бүрек салып карап торырлык...
Бабайлар да батыр булган икән,—
Безнең шатлык, безнең горурлык.

---

ГАМИЛ АФЗАЛ *(1921) — шагыйрь, «Дөнья матур», «Ышаныгыз», «Айлы кичләр» һ. б. исемдәге егермедән артык лирика, сатира-юмор китабы авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

Адәм баласына игътибар ит,
Ярдәм итмәсәң дә елмаеп кит,
Һәркемнең тормышы чыр-чулы,
Һәркемнең көннәре борчулы.

Сәламеңә якты чырай өстәп,
Бер яхшылык, бер изгелек күрсәт,
Гомерләр — бормалы су юлы,
Һәркемнең йөрәге моң тулы.

Талгын гына талгын —
Һава дулкыннары.
Дәртле шау-шу тынган,
Басу-кырлар сары.

Хәсрәт чигү түгел,
Арганлыктан бары
Күңел төшүләре,
Күңел кайтулары...

Чыр-чулы мәсьәлә чишәбез
Борчулы гомерләр кичәбез,
Күңелдә чеңләгән кыллар бар,
Үзең дә белмәгән моңнар бар.

Йолдызлар елмая биектә,
Җилләре ягымлы кебек тә,
Таңнарда тирбәлә тал-тирәк,
Заманга иң матур җыр кирәк!

Дәртләндерде әле, җилкендерде
август иртәләре.
Чәчләремне уңга-сулга сибеп
җилләр иркәләде.

Һәр яфракта җилбер-җилбер итеп
яхшы хәбәр поскан.
Бер шатлыклы сәлам килер кебек
ерак-ерак дустан.

Агач сука белән җир сөргәндә
Кеше бик тә гади булгандыр,
Кара мунчаларда әкият сөйләп,
Җен-пәридән куркып торгандыр.

Читән артларында кубыз чиртеп,
Ул иң гүзәл көйләр чыгарган,
Заман түрләрендә фикер йөртеп,
Без илһам алабыз шулардан.

Елларга карап яңардык:
Елмаеп йөргәнең бар.
Йөзек кашына язарлык
Ялкынлы сүзләрең бар.

Ярсулы яңа агымда
Яшәреп, сулар әчкәч,
Заманның зәңгәр тавында
Моңаеп торма, иптәш!

Дәвер чатларында туктап,
Матур дип туган илем,
Мең ел онтылмас бер китап
Язасым килә минем.

Җыр булып барсын минем җан
Киләчәк заманнарга.
Иң матур гөлләр — идеал,
Иң биек үрләр алда.

Халыкның күңелендә йөреп тә,
Сүз итеп әйтмәгән уйларын
Каш итеп куябыз йөзеккә,
Акыллы, зиһенле оланым.

Эзләнгән күнелне җилкетә
Хезмәттә бәхетен тапканнар...
Тәгәрәп төшәләр чүплеккә
Акчага намусын сатканнар.

Я бетәбез, я калабыз, диеп,
Куркыныч сүз йөри телдән-телгә.
Җәһәннәмнән тәмуг утын чөеп,
Агулы җил исә илдән-илгә.

Тын кылларга ай шәүләсе төшә,
Шигъриятле уйлар уйлагандай.
Кошлар сайрый, арыш, бодай үсә,
Берни булмагандай...

Карурман бу...
Кайда былбыл, кайда ябалак.
Һәр адымда хәвеф көтеп тора,
Караңгырак яктан сагалап.

Карурман бу.
Күсәк, хәнҗәр тоткан
Юлбасарлар чоры узса да,
Җәһәннәмнән алып агу йоткан
Атом чоры тора тупсада.

Сәгать әйтә: вакыт, вакыт, вакыт...
Вакыт үтә, ягъни мәсәлән.
Ярты гомер ил алдында балкып,
Артистлар да төшә сәхнәдән.

Артистлар да лаек ялга китә,
Аның белән китә хисләр, төсләр...
Яшь талантлар йөгереп килеп җитә,
Алар инде нишләр?

Сандугач сайрый тирәктә
алкышлар көтми генә.
Сандугач сайрый кирәккә,
уйламый-нитми генә.

Сере сыяр ярын тапкан,
кауры соры гына,
Туган урманына кайткан
мәхәббәт җыры гына.

Әллә кайчан юкка чыккан халык
Исемнәре калган ташларда.
Тарих чоңгылыннан моңнар алып,
Бер хикәят сөйли башларга
Кыенсынам.
Үткән-беткән, диләр,
Төтеннәре искән җил булып,
Каберләрен күмеп күчкән чүлләр.
Көчле халык калган ил булып.

Кубәләкле, мең чәчәкле болын,
Шомлы шаулап торган карурман.
Суларда йөз, тауларга мен, улым,
Туган илгә карап горурлан.

Таштан-ташка сикереп сулар аккан,
Зәңгәрләнеп яткан тау булыр,
Бөек эшләр көтә изге ватан,
Син тырышсаң, ватан сау булыр...

Сиваш сазлыкларын кичкән кебек,
Тездән пычрак ерып бардым да,
Яңа тормыш чәчәкләрен сөеп,
Басып торам заман алдында.

Якты өмет, тапсыз намус белән
Сулар сибәм нәфис гөлләргә.
Арып-талып яңа чорга киләм,
Ак чәчләрем сибелә җилләргә.

Мунча пәриеннән алып
Ходай тәгаләгә чаклы
Ялын чөеп, хәйран калып,
Хыял аты чапты.

Уйчан-уйчан эңгер ятты,
Көлә-көлә таңнар атты,
Елга кебек еллар акты...
Туган яклар якты!

Туры юл булмый ул тормышта,
Бормалы юл була, бормалы.
Бормалы юлларда тырыш та,
Алга бар, күтәрел югары.

Ут белән, су белән ярышта,
Әй, адәм баласы, ялгышма!

Күңел күзен төбәп еракка рак,
Дәрдмәндне укыйм кабат-кабат.

Бу әрнүле, серле юлларда
Әйтеп булмый торган моңнар бар.

Исә генә җилләр, ага сулар,
Искерми дә, онтылмый да шулар.

Күпме вәхшәт,
күпме кара давыл
Дулап үткән җирнең өстеннән!
Бар матурлык кояш нурыннан ул,
Бар изгелек — ана сөтеннән!

# ПРОЗА

## Марат Әмирханов

# ИР ХАТЫНЫ

**хикәя**

Мәшәкать арты мәшәкать чыгып, кич житте. Юлга кояш баегач кына кузгала алдылар. Яңгыр әле һаман сибәли иде. Тик төн урталарында көчле жил кузгалып, баш очындагы ястыктай калын болытларны Агыйдел аръягына куалап бетерде. Күк йөзе юып чыгарылган өй эче кебек яктырып калды, йолдызлар жемелдәшергә тотынды.

Трактор, кара төтен бөркеп, капшана-капшана, алга шуыша. Әйе, әйе, чын мәгънәсендә шуыша. Чөнки аяк асты тәмам жебегән, урыны-урыны белән шактый зур күлдәвекләр жәйрәп ята. Әйтәсе дә юк, юл авыр. Мондый чакта туктап калмаска кирәк, тәгәрмәчләр жир чокый башладымы, батып каласыңны көт тә тор.

Зәйтүнә алдында көлкегә каласы килмәгән Зөфәр тракторын бик сак алып барды — руль бора-бора, беләкләре талып бетте. Игене жыеп алынган басу өстенә килеп чыккач кына, бераз жиңеләйгәндәй булды. Хәер, авылга да ерак калмаган иде инде. Зөфәр күз кырые белән генә кибетче кызны күзәтеп ала. Ә аңа юлың, пычрагың бармы да юкмы, башын утыргыч артына терәгән дә йокыга талган. Трактор сикәлтәгә эләккән арада йомшак иңе белән егеткә орынып-орынып ала. Бу мизгелләрдә Зөфәрнең тыны кысыла, ул хәтта үзенең авырлыгын да сизми башлый, әйтерсең лә каз мамыгы. Әле ярый тотынырга руль бар, югыйсә, янәшәсендәге чибәркәйнең чәченә күбәләктәй очып кунар иде.

Егетнең күңелендәге хисләр моңга әверелә башлады. Даладагы казах шикелле, ул шулай уй-хыялларын жырга салырга күнеккән иде. Чөнки тракторда гел ялгызы, сөйләшергә, киңәшергә янында кеше юк, ә жыр һаман агыла да агыла ул. Бу жырулар, кагыйдә буларак, ниндидер таныш көй, таныш шигырь калыбына салына.

Бу минутта исә алардан үзгә, кызны шаккатырырлык, аны үзенә каратырлык искиткеч моңлы көй чыгарасы килә иде Зөфәрнең. Их, көйдерәп аласы иде шушы Зәйтүнәкәйнең йөрәген...

Кинәт кенә аның уйлары ярты юлда өзелеп калды, куллары руль бөжрасына ныграк ябышты: трактор алдыннан пумала койрык — төлке элдертә иде. Ут яктысыннан ничек котылырга белми, үрле-кырлы сикерә. Читкә генә ыргыласы да соң, юк, шуңа да акылы житми мәхлукның, ә үзенең хәйләкәр дигән даны чыккан бит әле.

Зөфәр фараларны сүндерде. Шул вакыт аның беләгенә бер йомшак нәрсә килеп сарылды. Егетнең йөрәге ут сызыгыннан чыга алмыйча азапланган әлеге төлке кебек үрсәләнеп тибәргә тотынды: мөмкин хәлме бу? Ә нигә, шайтаны гына өметсез диләр түгелме әле. Зөфәр сул кулын сак кына шул якка шудырды. Ләкин өмете акланмады, ике арада утыргыч өстеннән шуып төшкән сырмадан

---

МАРАТ ӘМИРХАНОВ *(1933)— вакытлы матбугатта һәм «Беренче лауреатлар», «Таш һәйкәл» жыентыкларында дөнья күргән байтак проза әсәрләре авторы. Татарстанның атказанган культура работнигы, республикабыз журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты.*

башка бер нәрсә дә юк иде. Ул сырманы ачу белән беләгеннән алып ташлады.

Кызыл кар яуса да, тракторчыга карый торган кыз түгел бу дип сызланды ул, зоотехникка да артык әле, ә теге ничә карама, кибет тирәсендә чуала Колга!

— Сез бик мәрхәмәтле егет икән, Зөфәр.

Зәйтүнәнең сүзләреннән ул сискәнеп китте: хәйләкәрлеген күр бу кызыйның, йоклаганга салышып, юри сынап кайткан икән, минә бу төлке ичмасам. Шулай да кызның мактау сүзләре аны очындырып җибәрде, гәп корып, кызның кылын тартып карарга моннан да кулай вакытны эзләп тә табасы юк иде югыйсә. Тик Зөфәр форсаттан файдалана алмады, ниндидер дуамал елмаю белән тракторның ян тәрәзәсен сөртергә тотынды, аның тышкы яктан пычранганлыгын да аңлар хәлдә түгел иде ул. Моны күреп торган Зәйтүнә үтә бер канәгатьләнү белән елмаеп алды да үпкәләгән атлы булып:

— Зөфәр, сез нигә мине олыгайтасыз?— дип сорады.

— Нигә дип... ни...

— Укыган кеше димәкчесеңдер инде, шулаймы? Безнең авылда да укымышлы кешеләрне зурлап «абый», «апа» диләр, ә минем уку ташка үлчим, хәзерге заманда техникум бетерү әллә ни зур мәртәбә түгел.

Зөфәрнең мәхәббәте менә шушы сәяхәттә кабынып китте.

* * *

Атна-ун көннән яшьләр күрше авылга концерт карарга барды. Концерт ошады, күңелләре булды егет-кызларның. Кайтканда, Сөн ярына килеп җиткәч, Зәйтүнә генә, көйсезләнеп, бераз кәефләрен бозды.— Су ерып чыкмыйм дип белдерде. Суы салкын, янәсе. Юмалап та, куркытып та карадылар — юк булгач юк, сүзеннән грамм да кайтмый. Нишлисең, чибәр кызлар шулай назлана, күрәсең.

— Хисам, нәрсә җибеп торасың,— дип чыелдашты кызлар. Әмма зоотехник егет үзе дә аптыраштарак калган иде.

— Чулак Фәйзинең көймәсен сорап торыймммы соң?— диде ул икеләнеп кенә.

— Бәлки Аю пристаненнән буксир алып килерсең?— дип үртәде Зәйтүнә.

Барысы да инде ни булыр икән дип тынып калды. Якындагы күлдә парын югалткан кыр үрдәгенең үрсәләнеп кычкыруы вәсвәсәне тагын да көчәйтә шикелле иде.

Шулчак төркем арасыннан таза гәүдәле бер егет аерылып чыкты да Зәйтүнәне күтәреп алды. Һәм кыз чәбәләнергә дә өлгермәде, лаштыр-лоштыр атлап, суга ук кереп китте. Аһ иттеләр.

— Менә мышты-ы-ым,— дип сузып куйды кайсыдыр.

— Зөфәр бу тәвәккәллегенең серен үзе дә аңлатып бирә алмаган булыр иде. Табигате белән йомыкый, оялчан иде ул. Өстәвенә, ятим үскәнгәме, үзен башкалардан ким санап йөри иде.

Ә атна-ун көннән соң киң ябалдашлы өянке ышыгында Зөфәр беренче мәртәбә сөйгәненең биленә үрелде, ләкин кыз:

— Синең кебек егетләр башта яучы җибәрә, абзыкаем,— дип, яшь боландай читкә тайпылды. Кәлә-кәлә!

Агач мылтыктан ату дип, мөгаен, шушы халәтне әйтә торганнардыр: бу сүзләрдән Зөфәрнең йөрәге актарылып, кысылып, әллә ничек сабырсыз тибә башлады. Ул арада Зәйтүнә җалт кенә ишегалларына ук кереп юкка чыкты.

Ниһаять, егет аңына килде һәм калын имән капканы дөбердәтергә тотынды. Тимер келә сынып җиргә очты, әмма кызны ишегалдыннан табу мөмкин түгел иде инде.

— Зәйтүнә, Зәй-тү-нә-ә-ә!

* * *

Зөфәрнең йорты да, абзар-курасы да килен төшерерлек хәлдә түгел иде. Колхозда алдынгы механизаторлардан санала, анысы хак. Тик үз ихатасында кыл да кыймылдатмый. Әбисе Фәхерниса карчык та, кем әйтмешли, яшен яшәгән, бу фани дөньяда әллә ни гаме юк иде. Килен төшкәч тә холык-фигылен үзгәртмәде карчык. Фәкать: «Сыйраклары арасыннан песи баласы чыгып

йөрерлек икән моның»,— дип үзалдына сөйләнеп куйды. Озын үкчәле туфлиләре ошамадымы киленнең, әллә башкасымы, берәү дә белмәде, чөнки карчык тиздән дөнья белән мәңгегә хушлашты.

Зәйтүнә беренче эш итеп өйнең яртысын диярлек биләп торган бинһаяв зур мичне акшарлады, ямьшәеп беткән тимер караватка бизәкле япма япты, чыбылдык корды, тәрәзәләргә ак челтәр элде. Йорт эче бердән яктырып китте.

— Таптың чыгар егет, хәллерәк булса иде ичмасам,— дип дус кызы аны битәрләп тә алды.

Яшь хатын: «Байлык кешене боза ул»,— дип кенә куйды.

Сүз дә юк, матур киенергә, пөхтә йөрергә ярата иде Зәйтүнә, тик ни сәбәпледер, биек йортларга, буяулы коймаларга артык исе китми иде аның. Дөресрәге, боларның барысын да үз көчең белән, гомерлек юлдашың белән бергәләп булдырырга мөмкин дип саный иде ул.

Зәйтүнә гашыйклар игътибарын күп күрде. Бал исен сизгән умарта кортларыдай кайнаша иде алар аның тирәсендә. Назлану аның үзенә дә ошый, масаеп та куя иде ул бу хәленә. Ләкин тора-бара шуны ачык сизенде Зәйтүнә: аның тирәсендә бөтерелүен бөтерелаләр, тик тәкъдимне икенчеләргә ясыйлар. Бер фырт Казан егете исә турысын ярып салды:

— Син гаилә өчен яратылмаган, җаный, типтереп калыйк!

Зәйтүнә шунда беренче мәртәбә үзенең чибәрлеген каһәрләде, гарьлегеннән үксеп-үксеп елады. Егетләрдән үчен кайтарды анысы, күпләрне акылга утыртты. Очрашырга сүз куешса да, бармый җәфалады үзләрен.

Зөфәр бөтенләй башка кеше иде. Хатын-кызларга гына хас бер үткенлек белән аның тормышта ныклы таяныч булачагын сиземләп алды Зәйтүнә. Зөфәр кебекләрнең мәхәббәткә хыянәт итмәячәген чамалады.

Ялгышмады сатучы кыз. Зөфәр өчен ул чын мәгънәсендә кояшка әверелде. Шул ук вакытта үзенең дә иренә булган ихтирамы тупыл бөреседәй көннән-көн үсә, шикәрләнә барды, күңеле әле моңа кадәр беркайчан да татып карамаган ләззәтле хис белән тулды. Борчылу да, кайгыру да, ярату да бар иде анда.

* * *

Урып-җыю тәгәлләнгәч, Зөфәрне чылбырлы тракторга утырттылар. Көннәр аяз чакта туңга сөрүне тизрәк тәгәлләргә кирәк иде. Сентябрьнең азагы булуга карамастан, кояш төшен җәйге челләдәгечә кыздыра. Бала-чага янә Сөн буена ябырылды, рәхәтләнеп су коеналар. Күк йөзе чалт аяз. Җир тәмам кипшенде, тавык артыннан да тузан болыты бөркелә башлады.

— Сулыш юллары тыгылып бетте монда,— дип зарланып торды Зөфәр беркөнне,— кодрәтеңнән килсә, яңгыр яудыр син, Зәйтүнәкәй, яңгыр.

Зәйтүнә, башын артка чөеп, бераз иренә карап торды да искәрмәстән генә чиләктәге суны аның өстенә койды:

— Менә сиңа яңгыр, менә сиңа кодрәт...

Чиләк артыннан чиләк бушады. Зөфәрнең дә сабырлыгы бетте ахры, хатынын күтәреп алып, сулы мичкәгә китереп утыртты.

Китте чыр-чу, китте көлешү — чыланышып беткәнче су сибешеп уйнадылар. Тик аңа карап, күктән яңгыр гына таммады.

Икенче көнне кичке якта басу башында Зәйтүнә пәйда булды. Куркуыннан агарып китте Зөфәр: димәк, нидер бар, Зәйтүнә бер сәбәпсез монда килеп йөрмәс. Ул тракторын сүндереп хатынына каршы йөгерде.

— Ни булды, Зәйтүнә?

— Бер пәп ит, аннан соң әйтермен,— диде тегесе шаянланып.

— Уф, котым калмады,— дип Зөфәр тузанлы йөзен кул аркасы белән сыпырып алды.

— Их, син, куян йөрәк. Ә мин үзеңә менә нәрсә алып килдем,— диде Зәйтүнә һәм сумкасыннан противогаз суырып чыгарды,— киеп кара әле, ярыймы?

Зөфәр сызгырып ук җибәрде: менә сиңа иренмәс җан, шукмын дигәч тә... Ләкин шул ук минутта аның йөрәген нинди дер ярсу моң да сызып алды, күзләрен иреексездән яшь элпәсе каплады. Ул хатынын назлап кочагына алды да:

— Зәйтүнә, Зәйтүнәкәем минем,— дип пышылдады.

— Үзең үпкәгә тузан утыра диден ич...

Зәйтүнә противогазларны базага товар алырга баргач күреп кайткан иде. Ишек катындагы почмакта аунап яталар шунда. Хуҗалыкларның исе китми, орлык агулаганда бик кирәк әйбер югыйсә дип зарланып торган иде мөдир.

* * *

Язга таба Зөфәр хатынында ниндидер үзгәреш сизә башлады. Аны әле өздереп кенә әйтүе дә кыен, чөнки хатынының кайнарлыгы, назлары кимемәде, тик барыбер үзгәреш сизелде. Зөфәр, моның асылына төшенә алмыйча, шактый вакыт борчылып йөрде.

Бер вакыйга аның күзләрен ачты. Ремонтка туктаган чагы иде. Мондый чакта әле тегесе җитми, әле монысы. Склад исә тап-такыр. Шуңа күрә кирәк әйберне ике-өч бәясенә кеше кулыннан сатып алырга туры килә. Зөфәр дә көннәрдән беркөнне шундый кәсеп белән районга чыгып китте. Йомышын тиз йомышлады һәм шунда ук, башка җиргә сугылмыйча, кайту ягына борылды. Шунда авылдашы Земфирага очрады. Тәтелдек телле бу хатынны бик өнәп бетерми иде Зөфәр, тик аны җиде юл чатында ничек калдырасың инде? Утырта кайтты, хәтта өенә кадәр илтте.

Җитмәсә, бер касә әче балын авыз итеп чыкты. Ә ул шайтан суы бик тиз әсирлеккә ала иде аны. Дөрес, хатынына сиздермәскә тырышты бу әллә-мөлле халәтен. Әмма сәер балкып торган йөзе, ялтыравык күзләре барысын да фаш итте, күрәсең. Зәйтүнә аның кочагына ташланырга бер дә ашыкмады, озын керфекләрен битараф кына бер җилпеп куйды да машинасын келтердәтүен дәвам иттерде. Зөфәрнең җәелгән калын иреннәре шундук җыелды:

— Ул-бу юктыр бит, Зәйтүнә?

Тегү машинасы келтердәвендә булды.

— Зәйтүнә, үпкәләттемме әллә?

Хатын чекрәеп иренә карады.

— Хыянәтче син, менә кем.

— Ни сөйлисең, тәүбә ит.

— Чит хатын белән типтерүне тагын ничек итеп атарга соң?

Зәйтүнәнең тавышы кылы өзелгән скрипкадай ярты юлда киселде. Моны күреп торган Зөфәрнең тыны кысылды, әйтерсең лә өстенә таш ордылар. Ләкин бераздан сулышы җиңеләеп, ачылып китте. Күр, Зәйтүнәсе көнләшә түгелме соң? Әйе, әйе, көнләшә! Кемнән диген әле, кисеп ташлаган тырнагына да тормаган кешедән!

Зөфәр хатынының аякларына барып сарылды да:

— Чибәр кеше көнләшә белми дигән булалар тагын, дөрес түгел икән,— диде.

— Мин сине кем беләндер бүлешермен дип уйламаган идем,— диде Зәйтүнә, читкәрәк тайпылып.

— Алайса китик Земфираларга, үзеннән сорарсың.

— Син яратканыңны башкача исбат ит.

— Ничек?

— Икебез гел бергә була торган эш тап.

Зөфәр авыз чите белән генә елмайгандай итте:

— Син сатучы, мин механизатор...

— Без фермада эшли алыр идек.

— Җә, ярар, мыскыл итәм дигәч тә.

— Кайчанга кадәр шушы җимерек өйдә яшәрбез соң без, ә!

Зөфәрнең иң авырткан җире иде бу. Гаиләле булгач, бу хакта шактый уйлана иде. Шулай да уйланудан ары узмады. Әлбәттә, кассадагы ике мең акчага юньле йорт-җир кору мөмкин түгел. Шул ук вакытта Зәйтүнәнең көтүче булуын да күз алдына китерүе кыен иде Зөфәргә.

* * *

Көтүгә чыккач, Зәйтүнәнең элекке тынычлыгы кайтты. Эшкә дә бик тиз күнекте, әйтерсең лә, гомер буе мал карау белән шөгыльләнгән.

— Зөһрә йолдыз түгел син, җир бәндәсе икәнеңне онытып бетермә,— дип төрттерде аңа бер көнне зоотехник Хисам. Ул Зәйтүнәгә ачулы иде әле.

— Йолдыз булмасам, йолдыз тагучы булырмын,— диде яшь хатын,— әмеңә синә мактау кәгазе дә эләкмәве ихтимал.

Зәйтүнә бу сүзләрне шаяртыбрак әйтсә дә, хаклык бар иде аларда. Чөнки һәр җыелыш саен диярлек, эшен өстән-өстән генә башкаруы өчен, Хисамны гел тәнкыйтьләп торалар. Дөрестән дә, сыерларның сөте артмый, ферма районда иң арттагылардан санала, шулай булгач, аның югары белемле булуыннан ни файда?

Зөфәр белән Зәйтүнә эшне үзгәртеп корудан башлады: көтүлекне кишәрлекләргә бүлделәр дә берсеннән икенчесенә үләне тәмам ашалып беткәннән соң гына күчә башладылар. Төш вакытында сыерларга читтән печән чабып китерүне дә юлга салдылар. Шуннан соң, син күр дә мин күр, чиләкләр авырая башламасынмы!

* * *

Җәй урталарында Зөфәр, бура юнәтер өчен, Идел аръягына чыгып китте, исәбе — урып-җыю бетеп, колхозда эшләр бераз саеккач, осталар яллау иде. Зәйтүнә иреннәрен турсайтып:

— Нигә шулай куыра торгансыңдыр, аңламыйм,— дип сукранып калды.— Житешер идек әле, арттан кумыйлар ла.

Зәйтүнә өстенлеккә омтылмый, бу уй хәтта аның башына кереп тә чыкмый иде. Тик барыбер Зөфәрнең аңа һәр нәрсәдә юл куюы, ташламага баруы аны ниндидер дәрәҗәдә үсендереп җибәрде. Бу хис, әлегә яралгы халендә генә булса да, гаилә өчен куркыныч нәрсә иде. Әмма юл йөреп кайткан ире каршысына ул яшь боландай атылып чыкты. Зөфәр дә хатынын, бер кешедән дә тартынмыйча, урам уртасында кочагына алды.

Зөфәр төне буе бастырылып, саташып чыкты. Тынычланып йокыга китәргә өлгермәде, тузга язмаган манзаралар дәрьясына килеп эләкте. Соңгысы бигрәк тә шомлы булды. Имеш, трактор белән Уфа юлына вак таш ташый. Ә карьер ниндидер биек тау башында, кепкаңы салмыйча карап та булмый. Тауның нәкъ уртасында тракторының двигателе кәҗәләнә башламасынмы: өстеннән пар бөркелә, бизгәк тоткан кешедәй калтырана. Күп тә үтми, бөтенләй туктап та калды бу. Тәгәрмәчләр хәтта кирегә әйләнә башлады. Зөфәр тормозга басмакчы иде, ни хикмәттер, аяклары авырайган, кузгатып та булмый үзләрен. Һәм менә трактор, кыя-ташларга бәрелә-сугыла, түбән тәгәри башлады.

— Коткарыгыз, кот-ка-а-р...

Ярга чыгарылган балыктай әрле-бирле сугылучы ирен Зәйтүнә көч-хәл белән уятты.

Зөфәр гамәлдән чыккан бер «Беларусь» тракторын үзе төзәтеп аякка бастырган иде. Малкайларга сусыл печәнне шуның белән үзе ташый башлады. Бу исә эшне күпкә җиңеләйтте. Чөнки кемгәдер ялынып-ялварып йөрисе юк, кирәк чакта үзең кабызасың да элдертәсең генә.

Бу юлы Зәйтүнә иренең тракторга утыруына теш-тырнагы белән каршы төште:

— Синең эшең — мал багу, сөтне бик арттырасылары килсә, тиешле әһелләре кайгыртсын, зоотехник бар, ферма мөдире.

— Башка чакта үзең тыкырдата идең, ни булды сиңа, карчык?— дип шаяртты аны Зөфәр.

— Әллә нигә эчем поша минем, Зөфәр,— диде яшь хатын.

— Ярар, ярар, күңелеңне бер дә төшермә, килешми ул сиңа, күр, көне әнә нинди якты.— Зөфәр, сокланып, хатынына карады. Бу минутта аеруча чибәр, ягымлы иде ул. Агыйдел якларында сирәк очрый торган озынча аксыл йөз, үзе ефәктәй шома, кыл шикелле нәзек кашлары астында зур зәңгәр күзләр балкый, тешләре гүя мәрҗәннәр, тулы иреннәре арасыннан сөттәй ак булып күренеп торалар. Тик кагыйдәгә туры килеп бетмәгән яклары да бар аның. Әйтик, аксыл йөзле кешенең чәчләре гадәттә саргылт була, ә Зәйтүнәнеке сумала кебек кап-кара. Ак йөз, кара чәч, зәңгәр күз.

* * *

Зөфәр бик тиз әйләнде, печәннең әйбәтен төяп кайткан иде, кәрешкә генә. Үзенең авызы колагына җиткән.

— Әбүгалисинадай уңган да, тапкыр да бу ирение бер «әп» итмәсәң, гомер бакыена риза-бәхиллегем юк,— диде ул хатынына.— Күрче, нинди күчтәнәч алып кайтты абзаң.

— Акылың алтын икән, күчтәнәч нәләре «әп» итсен әнә.

— Бик хикмәтле бер бүләк әзерләгән нем, болай булгач, үтүт инде, бигайбә,— дип, Зөфәр яңа кабина эченә үрмәләде. Тик Зәйтүнә шунда ук аны чабуыннан эләктереп, җиргә тартып төшерде.

— Жә инде, җаный, шаярттым гына бит мин,— диде ул иркәләнеп,— җә, иел инде, буем җитмәгәнне күреп торасың ич!..

— Ә-ә, хәзер җаныймыни?!

— Зөфәр дим, ялындырмачы, зинһар, алайса бөтенләй әйтмәскә иде аны...

Хатыны, күзге алмадай тулы иреннәрен турсайтып, читкә борылды, үпкәләде, янәсе. Ә Зөфәр түзмәде, кабалана-кабалана, атна-ун көн куен кесәсендә йөрткән кәгазь кисәген иркәсенә сузды:

— Аманәтем бар ие, тик көлештән булмасын, яме!

Бу Зөфәрнең Зәйтүнәсенә атап чыгарган җыры иде. Зәйтүнә аны бик озаклап, кат-кат укыды, укыган саен, йөзе тагын да яктыра, нурлана барды: бу дөньяда үзенең берләнбер мәңгелек яр икәнен тоючы хатын-кыздан да бәхетлерәк тагын кем бар икән?!

Зәйтүнә иренең яратуын белә иде, әмма бу мәхәббәтнең җыр, моң булып яңгыравын хыялына да кертеп чыгармаган иде.

* * *

Сыерларны бүген соңгарак калып чыгардылар. Көтүне яңа кишәрлеккә кертергә кирәк, тик анда әле эш төгәлләнеп бетмәгән, сугару җайланмаларын төш чагында гына күчереп өлгерттеләр.

Мал-туарны яңа урынга ияләштерү шактый четерекле, аларның да күнеккән сукмакларыннан читкә каерыласы килми иде. Шуңа күрә Зөфәр тискәрерәк сыерларның юлын бүлеп көтүнең уң кырыеннан барды. Тик бу кадәр ишле малны тыеп бетереп буламы соң, кайберләре чыбыркы шартлатуны колакларына да элми. Зөфәр, туп өстендә биюче мәзәкчедәй, әле бер, әле икенче якка сугылды, тирләп бетте үзе, тик барыбер ике мүкләк күл буена сыпыртты. Көтүче чыбыркы сабын кысыбрак тотты: ярар, хәзер үзегезгә үпкәләгез!

Ләкин Зөфәр үчен кайтара алмады, чөнки сыерларның берсе барган җиреннән кинәт кенә чирәмгә тезләнде, икенчесе исә гөрселдәп ук төште. Әһә, элэктегезме, дип көлемсерәп куйды көтүче, шул кирәк сез мәлгуньнәргә.

Үзе шулай уйласа да, күңеле никтер тынычсызлана иде, хәтта тәне калтыранып куйды. Ник дисәң, мүкләкләр әле һаман торып китәргә ашыкмый, киселгән агач шикелле җансыз-көйсез ята бирәләр. Юк, абынып кына егылганга охшамаган болар, сәбәбе башка моның. Нәрсә булыр бу?

Зөфәрнең гаҗәпсенгән күзләре тирә-якны капшап алды. Әмма бурадай сөтбикәләрне аяктан егардай берни дә күренмәде. Инде ни хәл итәргә? Озын-озак юанып торырга да чут-чамасы юк бит аның. Әнә сыерлар, элекке сукмакка төшеп, һавадагы торналар шикелле, тезелешкәннәр дә әлеге хәвефле урынга якынлашып киләләр. Бу серле фаҗиганең кабатлануына һич тә юл куярга ярамый. Ярамый!

Зөфәр йөгерә-атлый лычтырдама юеш җиргә килеп керде, аяклары таептаеп китте, бер-ике урында сөрлегеп, куллары белән үлән камылына да таянып алды. Аңа ничек тә көтүне бүлеп алырга кирәк иде. Кабалануыннан ул электр линиясенең өзелеп җиргә төшкән чыбыгын шәйләргә дә өлгермәде. Кинәт ниндидер көчле дулкын аның гәүдәсен туп кебек һавага чөйде, шушы ук секундта эремдәй эче тимер тәме телен өттереп алды, күз алдыннан аксыл төстәге ут шары елкылдап үтте. Шуннан соң барысы да тынды, дөнья салкын караңгылыкка чумды...

* * *

Зәйтүнәнең хискә бирелүчән, нечкә күңелле, үтә дә тәэссоратлы хатын икәнен бөтен авыл белә иде. Шуңа күрә, иренең үлемен күтәрә алмас бу, я түшәккә егылыр, я акылын җуяр, дип юрады кайберәүләр. Хатын исә, Зөфәрнең өчесен үткәрү белән, эшкә чыкты. Аның уенча, шатлык кына уртак була, кайгыны һәркем үз башыннан ялгыз кичерергә тиеш иде. Кешеләр арасында оны тылыбрак торасың, эшкә йөрү мең өлеш әйбәтрәк. Әйе, үз йөрәгең белән генә тоя торган, фәкать үзең генә кичерә торган хис тә була. Аны беркем белән дә, җөмләдән, газиз әниең белән дә бүлешү мөмкин түгел. Мәхәббәтең пар канатлы икән, бу — бәхет, канаты сынган икән, дәвасы бер генә — вакыт.

Ихтимал, вакыт теләсә нинди авыр хәсрәтне дә дәвалыйдыр, тик хәзергесенә ничек түзәргә? Таш кебек каткан бәгыре аны ниндидер тимер кыршауда тота, бар дисәләр — бара, кит дисәләр — китә, бернәрсәдә гаме юк иде Зәйтү-

нәнең. Кешеләр, тирә-як мохит гүя рамга алынган зур бер картина: җансыз, өнсез.

Бу халәтеннән аны Хисам йолкып алды.

Беркөнне Зәйтүнә соңгарак калып кайтты. Җыелыш булган иде. Узган айга йомгак ясадылар. Аны да мактап телгә алдылар, премия дә бирделәр әле.

— Зөфәрчә эшлисең, рәхмәт сиңа,— диде аңа колхоз башлыгы.

Чит кеше авызыннан иренең исемен ишетү сискәндереп җибәрде аны. Кара, ул үзе Зөфәрен онытты түгелме соң инде? Чыннан да, көне буена ник бер хәтеренә төшереп карасын!

Башы чуалып китте Зәйтүнәнең. Рәхмәт әйтергә дә онытып, оялчан кызчыктай, йөгерә-атлый урынына барып утырды. Бите яна, тәне калтырый, әйтерсең лә эчке күлмәктән сәхнәгә чыгарып бастырганнар.

Бу талпынуының сәбәбен бераздан гына төшенде ул: Хисам аннан күзен алмый икән ләбаса, йотардай булып карап утыра.

Ут алгач, өйгә үк килеп керде зоотехник. Зәйтүнә урын җәеп йөри иде. Кулындагы ак җаймәсен күкрәгенә кыскан килеш катты да калды. Хисам аны кымтырыклый ук башлады, борын тишекләре гөбе авыздай булып киерелгән, мыш-мыш килә үзе.

Зәйтүнә һичнәрсә аңламый, ул хәтта карышып, чәбәләнеп тә карамады, тик басып тора бирде.

Хатынның боздай салкынлыгы Хисамны да айнытып җибәрде. Ул ярга сыланган көймә кебек, мич кырыена килеп сөялде. Ләкин күп тә үтми, идәнгә тезләнде һәм Зәйтүнәнең шәрә балтырларын үбәргә тотынды. Шунда гына хатын телгә килде:

— Кеше бул зинһар, җәфалама мине.

Хисам, ялагай эт кебек, муенын алгарак сузып, Зәйтүнәгә текәлде:

— Кума, Зәйтүнә, синсез яши алмыйм, аңлыйсыңмы, яши алмыйм мин!

— Җитте!

— Телисеңме, бөтенләйгә...

Зоотехник, нәрсәнедер хәтеренә төшереп, капыл гына тукталып калды һәм кабалана-кабалана өйалдына чыгып китте дә аннан бер төргәк алып керде. Төргәктә кара җимеш иде. Хисам аны өстәл өстенә куеп:

— Бәләкәй генә күчтәнәч, Зәйтүнә,— диде.

— Үзең дә, күчтәнәчең дә кирәкми, зинһар күземнән югал.

Хисам янә мескен кыяфәткә керде:

— Зәйтүнә сүзләремә колак сал, кызарып пешкән алма кебек чагың бит әле синең, үлгән артыннан үлеп булмый, күзләреңне ач, йөрмә болай әлсерәп, яшәп калырга кирәк, дуслашыйк әйдә, тол хатынга, үзең беләсең, очынчочка ялгау җиңел түгел.

Зәйтүнә, каерып, ишекне ачты. Хисам исә аның үзсүзлелеген хатын-кызларның күбесенә хас назлану дип кенә саный иде. Чөнки аларның иң җилкуар дип саналганнары да сүз катуга кочакка атылмый, кәнфитләнмәсәләр, сәер дә булыр иде әле. Зәйтүнә кебек иркә хатыннарның түземлеге, гомумән дә, озакка бармый, парсыз яши алмый алар: җиңү аның ягында булачак!

Ышанычы зур иде зоотехникның, әмма киерелеп ачылган ишек өметен чәлпәрәмә китерде. Хәзер инде аны икенче бер уй борчый иде: кешегә чәчелмәсме бу?

— Зәйтүнә, син алай-болай... теге... сөйләнеп ташлама инде, миңа да, сиңа да дигәндәй...

Хисамның тонык тавышы теш арасыннан гына сөзелеп чыкты. Ул шулкадәр ялварулы иде, ирексездән Зәйтүнәнең йөзләренә елмаю чаткылары йөгерде. Ул төнге кунак артыннан:

— Бөтенләйгә дигән була бит әле, хәчтерүш,— дип көлеп калды.

* * *

Зәйтүнә иртәгәсен савымчы кызларны зоотехник алып килгән кара җимеш белән сыйлап кына калмады, төнге мажараны да сөйләп бирде. Бу хәбәр сәгате-минуты белән, әлбәттә, яңа бизәкләр белән баетылган хәлдә, Хисамның хатыны Исламиягә дә барып иреште.

Ул почтада эшли иде. Бөкедәй йомры гәүдәле, ордым-суктым хатын. Кыз чакта бераз дуслашып та йөрделәр, ләкин аралары тиз суынды, нигәдер яратып бетерми иде аны Зәйтүнә.

Почта хезмәткәре көндәшенең эштән кайтуын авыл очындагы күпер янында сагалап тора иде инде.

Зәйтүнә очырып алып китәрдәй искән көчле җилгә яны беләнрәк атлый иде. Шуңа күрә, кисәк кенә каршысына чыгып баскан Исламияне күргәч, куркып китте.

— Абау, котымны алдың,— диде Зәйтүнә,— пычранып та беткәнсең.

— Пычрак синдә ул, себерке, ир кирәк булдымы, мә, тот!

Зәйтүнә эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алган иде инде:

— Тырнак очы кадәр дә гаебем юк, Исламия, үзе килеп керде.

Хатын Зәйтүнәне тыңлап та тормады, чәтелдәвен белде:

— Хәмерләр алып чакыргач, керә инде, кермичә, тик кара аны, райкомга җитәрмен, Казанына барырмын, барыбер авылдан сөрдерермен, аң бул!

Зәйтүнәне моңа кадәр әле беркемнең дә болай мәсхәрәләгәне юк иде. Шуңа күрәме, бу дорфа хатын алдында, җитлекмәгән борыч кузагыдай, бөреште дә төште.

Иртәгәсен алар су юлында тагын очраштылар. Зәйтүнә көндәше яныннан шыпырт кына үтеп китмәкче иде дә, Исламия юлын бүлде.

— Борыныңны бик чөеп йөрмә, себерке, беләбез кем икәнлегеңне,— дип, күзләрен чекерәйтте.

Бу сүзләрне ишетүгә, Зәйтүнәнең чиләкләре, шалтырап, җиргә тәгәрәде. Шул ук секундта, үзен-үзе белешмичә, Исламиянең сүс аркандай калын толымнарыннан эләктереп алды да, башын артка каерып, йодрыгын аның итләч ияге астына китереп тондырды.

Шуннан соң Хисамның хатыны айга якын сөйләшә алмыйча йөрде. Ә Зәйтүнәне алыштырып куйдылармыни: элеккедән дә затлырак итеп киенеп йөри башлады, киносын, концертын калдырмый, бер кешедән тартынмыйча озатып килүчеләр белән койма буенда озын-озаклап гәп кора. Гайбәт учагына шулай итеп үзе үк бензин сибә иде.

Тиздән аны җилбәзәк хатыннар чутына керттеләр. Кушаматы да табылды— «Кара җимеш».

Көннәрдән бер көнне өйләдән соң көтүлеккә колхоз председателе килеп төште. Нияте «юлдан язган» хатын белән ачыктан-ачык сөйләшү, аны, үзе әйтмешли, утлы табага бастыру иде. Тик уйлаганча килеп чыкмады.

Зәйтүнә, кәүсәсе яртылаш корып, эче куышланып беткән колач җитмәс юан тирәккә сөялеп, уйга талган иде.

Бу урында Сөн, кисәк кенә юнәлешен үзгәртеп, элмәк ясый. Кайчандыр бөркетләр оялый торган каршы як яр инде күптән сөзәкләнгән, ашалып беткән. Елга исә барыбер сабырсызлана, ак күбекләрен чәчә-чәчә, элмәкне ермакчы булып үрсәләнә.

Зәйтүнә дә үзен элмәккә эләккән елгадай хис итә. Башында кырыкмаса кырык уй, нишләргә аңа хәзер, бу авылда төпләнеп калыргамы, әллә күчеп китәргәме? Күчеп китсә, яраткан кешесенә хыянәт итү булмасмы?

Председатель аның янында хәтсездән басып тора, бимазаларга гына кыймый, чөнки Зәйтүнәне мондый басынкы, мондый мескен кыяфәттә беренче тапкыр күрә иде. Ә хатын исә аның үзен күптәннән шәйләп алган иде инде.

— Бүген өч йөз туксан җиденче көн, Галимулла абзый,— диде ул,— әйтергә генә ансат, өч йөз туксан җиде көн...

Председательнең тамагына ниндидер төер килеп тыгылды, шактый озак әйтәсе сүзен әйтә алмый торды.

— Сиңа өеңне эшләтергә иде, сеңелем, озак торган бурада хикмәт булмый,— диде ул, ниһаять. Әйтерсең лә шуның өчен генә эзләп килгән иде Зәйтүнәне.

— И Галимулла абзый...

— Ярдәм итәрбез, син чит кеше түгел лә.

Колхоз башлыгы сүзендә торды. Малларны утарга алып кайту белән, осталар җибәрде. Зөфәр шактый зур бура юнәткән булган икән, бүрәнәләрнең барысы бер иш, төзләр, нәфисләр, балта тиюгә зеңләп куялар.

Бер ай дигәндә, йорт әзер иде инде. Зәйтүнә эш бетү хөрмәтенә аш-су әзерләде, осталарны җиз комганнан җылы су агызып юындырды, ай-вайларына карамастан, иңнәренә чигүле тастымаллар салды. Арада кайсыдыр чалымнары белән Зөфәргә тартым Ирек исемле бер егет тә бар иде. Кыю үзе болай, тик Зәйтүнәне күрүгә, ирексездән кызара да чыга, аптырады тәмам, ә иптәшләре көлә, мыскыл итә. Эш төгәлләнгән көнне егет башкалардан аерылып калды.

Зәйтүнә аның ниятен күптәннән сизенеп йөри иде инде. Нарат исеннән, са-

гыз исеннән яшь хатынның күнеле болай да тынгысызлана иде, Ирекнең күз карашы аны бөтенләй хәлсезләндерде, назга сусаган тәне буйлап рәхәт дулкын йөгерде.

Ләкин бу халәт озак дәвам итмәде, уты сүрән иде әле аның. Шулай да егеткә бик рәхмәтле иде Зәйтүнә, итагатьлелеге өчен рәхмәтле иде.

— Ирек, үскәнем, бар кайт,— диде ул,— минем белән яманатың чыкса, каләш тә тәтемәс үзеңә.

Егетнең чигенергә исәбе юк иде күрәсең, ул яшь хатынның ут кебек янган кулларыннан эләктереп алды:

— Зәйтүнә...

Калтыранган тавыш ярты юлда өзелеп китте. Чөнки Зәйтүнә аңа сүзен тәгәлләргә ирек бирмәде, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кирәкми, Ирек, әйтә күрмә, мин — ир хатыны, беләсеңме, ир хатыны!

— Мин чынлап, Зәйтүнә...

— Алай булгач, бигрәк тә...

* * *

Зәйтүнә төне буе Ирек белән саташып чыкты. Ниндидер бик матур аланлыкта җитәкләшеп йөриләр, имеш. Җир өстенә бизәкле чаршау япканнар диярсең, әйләнә-тирә чуп-чуар, хәтта күзләр камаша. Шунда Ирек бер чәчәк өзеп алды да:

— Син, Зәйтүнәкәй, шушы чәчәк, мин — чәчәккә кунган бал корты,— диде.

Уянып киткәч, Зәйтүнә бик озак үзен-үзе битәрләп ятты. Янына Зөфәрнең рамлы карточкасын алып килеп куйгач кына, бераз тынычланды.

Агыйдел аръягыннан кояш күтәрелеп килгәндә исә, ул колхоз идарәсендә иде инде.

— Зөфәрнең эшен дәвам иттерәм, механизатор булам дисең инде алайса?— дип уйланып торды председатель.

— Шулай кирәк, Галимулла абзый!

— Кирәк икән, кирәк, алайса укырга җыен, Зәйтүнә!

# ПОЭЗИЯ



*Каләмдәшебез, 1984 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы шагыйрь Булат Вәли улы Сөләйманов 1938 елның 28 маенда Төмән өлкәсенең Вагай районы Сопра авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлауга, аның хезмәт юлы башлана: ул Ом, Салехард шәһәрләрендә, Төмән өлкәсендә яши — йөкче, бетончы, маляр, китапханәче була... Экстерн тәртибендә урта мәктәп тәмамлаганнан соң, Казанга килеп, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә; аннары укуын бүлеп, Фрунзе, Сургут, Баку, Казанда төрле эшләрдә эшли. Читтән торып укып, 1974 елда А. М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый...*

*Б. Сөләймановның Себер, аның гади хезмәт кешеләре, үзенчәлекле табигате турындагы беренче шигырьләре алтмышынчы еллар башында «Казан утлары», «Ялкын» журналларында, «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкта, шулай ук рус телендә «Юность», «Сибирские огни» журналларында, «Литературная Россия» газетасында дөнья күрде.*

*1980 елда Казанда аның «Таңнар фонтаны» исемле мөстәкыйль китабы басылып чыкты. Укучыларыбызга бу санда тәкъдим ителә торган яңа шигырьләрендә дә шагыйрь туган ягына — Себер һәм аның кешеләренә мәхәббәтен җырлый.*

## Булат Сөләйманов

### Фронтовиклар

Язлар җиткәч,
җылы яктан
җылы җилләр искәч,
туган-үскән илләренә
кошлар кайткач,
үләннәр калыккач,
чыгалар да утыралар
өй түренә,
бүрәнәгә,
карлыгачлар сыман тезелешеп,
безнең авылның картлары.
Мәңге эремәс тау түбәсен хәтерләтә
ап-ак кар башлары,
бер уч тотам сакаллары.
Монда һәркем белә дәрәҗәсен,

ашыкмыйча, уйлап әйтә
ни әйтәсен.
Берәү башлый
борын-борын заманнардан,
телгә килә легендалар:
«Тәвеш мәргән»,
канатлы кеше, канатлы атлар...
(Тын да алмый
тыңлый бала-чага:
бүген ишеткәнне алар
мәңге исләрендә саклар.)
Аннан гәпне күчерәләр чит илләргә.
Гүя алар утыралар
илләрара киңәшмәдә.
Әфганстанда килешү бара,
яхшы, диләр,
ә Ливанда әле һаман кан коялар,
үтерелә хатын-кызлар, бала-чага;
Рейганны тәнкыйть уты пешереп ала,
Иран белән Гыйракны да мактамыйлар:
«мөселманнар берсен-берсе ник кыйныйлар?»

Сугышның ни икәнлеген белә алар,
фронтовиклар.

Илдә барган үзгәрешләр, яңалыклар
килеп баса аннан нәкъ уртага.
Кем килешә, кем килешми,
һәркем үз фикерен әйтә ала.
Әнә күпме йортның
морҗасыннан чыкмый төтен.
Тәрәзәләре кадакланган,
ишекләре бикле...
Елгаларда балык бетте,
урманнарда җәнлек бетте,
авылларда халык бетте.
«Әй, бу нефте, нефте!»
Алар борчылмыйча кем борчылсын,
шушы урман-сулар исән-имин торсын, дип,
танк асларына яткан алар,
фашистларның тамыры корысын! — дип...
Кырык бердән кырык бишкә кадәр
алар үткән юлны
санап чыксаң әгәр,
меридианнар сыман уратып
чорнарга була бөтен җир шарын.

Өй түрендә,
бүрәнәгә,
карлыгачлар сыман тезелгән дә
сөйли картлар,
күпне күргән, күпне белгән
фронтовиклар.
Яннарында елтыр күзле оныклары
тын да алмый тыңлый:
бабайлардан ишеткәнне алар
мәңге исләрендә саклар!

## Төньяк. Тундра.

Төньяк.
Тундра.
Поляр төннәр.
Караңгылык хакимлеге.
Иксез-чиксез кар иле бу,
монда дөнья иркенлеге.

Даламыни, җәйрәп ята,
ник очрасын хет бер агач.
Яңа туган бала кебек
бу кар иле шыр-ялангач.

Җилләр йөри кар себереп,
я кинәттән чыга буран,
ак күбекләр күккә чөйгән
диңгездәге давыл сыман.

Кояш офык аръягында,
күренмидер нур чаткысы.
Киләчәккә өмет сыман —
сүнми бары
кар яктысы.

Сукыр көннәр,
сукыр төннәр...
(Минем дә бит
андый көннәрем бар иде.)
Әй, кар иле,
ак кар иле!

## Җирсү

Җирсүләрем
чиктән арткан ахры,
туган якка кайттым төшемдә;
Тик бер генә йоттым
саф һавасын,
исердем мин кайтып төшүгә.

Әллә кайдан
күреп алдылар да —
исән-саулык сорый алмадым,—
«Булат, Булат кайткан»,
сөенчегә,
яланаяк чапты талларым.

Кайчан да бер
кеше кайта, диләр,
бабалары яткан җиренә.
Килеп кердем
туган авылыма,
сагынуларым салып иңемә.

Яраланып кайткан
солдат кебек
яши идең, Сопра, күңелдә.
Кая киткән
култык таякларың? —
Таныш та күк,
таныш түгел дә.
Мин тезләндем
туган нигеземә,
туган йортым, саумы, бишегем.
Мин бер улың,
кире кайттым менә,
шыр ачып куй нарат ишегең.

Шушы йортта
әнкәм назы сеңгән,
туган телем сеңгән күңелгә.
«Һаваларда очкан аккошларның»
туган йорттан моңы сибелә.

Читтә үткән
ялгыз гомрем кебек
басып торам нигә моңаеп?
Кайтуыма, күрәм,
шатланалар,
тәрәзәләр карый елмаеп.

Бу кадәрле
сагынырлар диеп,
һич кермәгән иде уема.
Көтү көтеп йөргән
болыннарым
яшел keләм җәйде юлыма...

Җирсүләрем
чиктән арткан ахры,
туган якка кайттым — төшемдә.
Тик бер генә йоттым
саф һавасын,
исердем мин кайтып төшүгә.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Шаһинур Мостафин

# МАТРОСОВЧЫЛАР

Ел саен чираттагы ялым вакытында СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге (Мәскәү өлкәсе) Үзәк архивына барам. Дары исе сеңгән, читләрен ялкын өткән, канга манчылган хәрби документлар сугыш каһарманнары турында күп нәрсә сөйлиләр. Барган саен Бөек Ватан сугышының моңарчы исемнәре ачыкланмаган билгесез батырлары, каһарман якташларыбыз белән очрашкандай, үзләрен күреп сөйләшкәндәй булам. Эзләгән саен яңа батырлар табыла, тарих сәхифәләренә яңа исемнәр языла. Алар арасында матросовчылар аерым урын били.

Һәркем белә, «матросовчылар» дип без, сугышчан дусларына аяусыз үлем куркынычы янаган хәлиткеч мизгелдә утны күкрәкләре белән каплап, башкаларга җиңүгә юл ачкан, легендар Александр Матросов батырлыгын кабатлаган каһарманнарны атап йөртәбез. Искиткеч батырлык, фидакарьлек бәяләмәсе булган әлеге сүз беренче мәртәбә моннан 45 ел элек яңгырый.

1943 елның 23 февралендә — Кызыл Армиянең туган көнендә — 56 нчы гвардияче укчы дивизиянең 254 нче укчы полкы рядовое, унтугыз яшьлек комсомолец Александр Матвеевич Матросов Псков өлкәсенең Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган авыр сугышта, гранаталары һәм автоматында патроннары беткәч, үлем сибүче дошман дзоты амбразурасына күкрәге белән ташлана, үз гомерен биреп, йөзләрчә иптәшләрен котылгысыз үлемнән коткарып кала. Җитди хәрби задание үз вакытында үтәлә.

Архивларда кат-кат эшләү, илебезнең төрле төбәкләрендә матросовчы батырларга багышлап оештырылган «Сугышчан Дан» музейлары белән элемтәгә керү, каһарманнарны белүчеләрне күреп сөйләшү, алар туган һәм һәлак булган җирләргә махсус экспедицияләр оештыру нәтиҗәсендә, шактый кызыклы һәм бай мәгълүмат тупланды. Аларның кайберләре белән уртаклашасы килү кулга каләм алырга этәрде дә.

Иң беренче сорау — матросовчылар күпме?

Үзәк архив мәгълүматларына караганда, Советлар Союзы Герое Александр Матросов үрнәген кабатлаучылар хәзер илебездә 428 кеше исәпләнә. Моннан ике дистә ел элек кенә алар ике йөзгә якын дип санала иде. Әнә шулай, галиҗәнап Вакыт һәм Тарих матросовчылар исемлеген яңадан-яңа төзәтмәләр кертеп тора.

Эзләнүләр барышында дулкынландыргыч фактларга тап булдык: Бөек Ватан сугышы елларында А. Матросовка кадәр үк инде совет сугышчыларыннан илле җиде кеше күкрәкләре белән дошманның ут нокталарын томалаган! Шулардан беренчесе — танкист Александр Константинович Панкратов. Ул — Бөек Октябрь социалистик революциясе яшьтәше. Тумышы белән Вологдадан. Коммунист. Рота кече политругы. 1941 елның 24 августында Новгород янындагы Спасс — Нередица торак пунктында хәрби машинасы сафтан чыккач, Александр Константинович сугышчан иптәшләрен атакага күтәрә һәм дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплый. Бу батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә. Легендар политрук турында 1941 елның 20 ноябрендә «Правда» газетасы язып чыга...

Җыеп кына әйткәндә, 1941 елда — сигез, 1942 елда утыз тугыз сугышчы нә шундый тиңдәшсез батырлыкны кабатлый.

Иң сокландырганы, горурландырганы шул: мондый батырлык Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, Советлар иле өчен көрәш елларында туа. 1919 елның июнендә «революция бишеге» — Петроград янында, Керестенево авылы тирәсендә генерал Юденичның акгвардиячеләренә каршы барган көрәштә комсомолец Пелевин күкрәге белән дошманның ут ноктасына ята. Кем белә, бәлки аннан башка да шундый каһарманлык үрнәге күрсәткән сугышчылар булгандыр?! Бары тик күңел биреп эзләнергә, тарих сәхифәләрен зур игътибар-түземлек белән өйрәнергә генә кирәк...

Батырлык статистикасыннан тагын берничә сан китерик. Матросовчыларның 250 гә якыны утыз яшькә җитмәгән яшьләр. Ростов өлкәсеннән коммунист Александр Кириченкога, Донецк өлкәсеннән Леонтий Кондратьевка, Татарстанның Аксубай районыннан Филипп Мазилинга исә тиңдәшсез фидакарьлек күрсәткәндә илле яшь чамасы була. Якташыбыз Филипп Николаевич 1944 елның 1 мартында Гомель өлкәсенең Жлобин районындагы Мормаль авылын азат итү өчен барган сугышларда командиры — коммунист Николай Жуйков белән берлектә дошман дзоты амбразурасын каплый. Хәзер Гомель шәһәренең бер урамы аның исемен йөртә.

Белоруссия комсомолы Үзәк Комитеты элемтәчесе унҗиде яшьлек рус кызы Римма Шерстнева — хатын-кызлардан бердәнбер матросовчы. Советлар Союзы Герое Николай Гастелло исемендәге партизан отряды составында туган җире — Гомель өлкәсендә фашистлар гарнизонын тар-мар иткәндә, кыю комсомолка, үтә авыр бер мизгелдә, күкрәге белән дошманның ут ноктасын томалап, җиңүгә юл ача. Әлеге батырлыгы өчен ул Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Матросовчыларның йөздән артыгы — коммунистлар, өч йөзгә якыны — ВЛКСМ члены. Алар арасында илебездә яшәүче барлык милләт вәкилләре дә диярлек бар. Шуларның 169 ына Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелгән, калган батырлар Ватаныбызның төрле дәрәҗәдәге орденнары белән бүләкләнгән.

Дошманның ут нокталарын пехотачылар да, диңгезчеләр дә, танкистлар да, чекистлар да каплаган. Ленин шәһәрен саклап калу өчен барган сугышларда гына да 54 кеше шушы соңгы чарадан файдаланган. (Кызыклы тәңгәллек — бередә батырларча һәлак булган матросовчылар даһи Ильичның яшәгән еллары санынча!)

Матросовчыларның кайберләре икәү яисә өчәү берьюлы амбразурага капланган. Мәсәлән, 1942 елның 29 январенда борынгы рус шәһәре Новгород янында коммунистлардан — сержант Иван Герасименко, рядовойлардан Леонтий Черемнов һәм Александр Красилов иптәшләр төнге һөҗүм барышында берьюлы дошманның өч дзотын күкрәкләре белән каплап, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ачалар... 1942 елның 18 августында Сталинград өчен барган сугышларда комсомоллардан политрук Петр Гутченко белән взвод командиры Александр Покальчук иптәшләр дә шундый ук каһарманлык күрсәтәләр.

1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Остров Юрьев пункты өчен барган сугышларда татар халкының гаярь улы — гвардия кече сержанты комсомолец Бари Шәвәлиев белән украин егете — гвардия лейтенанты Иван Ильченко икәүләшеп дошманның бер үк ут ноктасын күкрәкләре белән каплыйлар...

Пелевин — Панкратов — Матросов иптәшләр үрнәгендә, шундый олы батырлык кылучылар тугандаш Болгария һәм Вьетнам армияләре сугышчылары арасында да очрый. Мондый фидакарьлекне Америка сугыш чукмарларына каршы барган көрәштә Төньяк Корея патриотлары да күрсәтә. Әлеге өч илдән ундүрт матросовчы мәгълүм.

Күзәтүләрдән чыгып, без, әлеге фидакарьлекне кешеләрдә социалистик җәмгыять тәрбияләгән күркәм сыйфат бу, дип раслый алабыз.

Татарстан улларының үз-үзләрен аямыйча сугышулары турында Советлар Союзы маршаллары, зур хәрби җитәкчеләрнең мактау сүзләре күпләргә мәгълүм. Инде матросовчыларга килсәк, аларның саны егерме дүрт кешегә җитте. Каһарманнарыбызның дүртесе — рус, берсе — чуваш, калганнары татар халкы вәкилләре. Аларның саны күбрәк булу да ихтимал. Эзләнүләр дәвам итә.

Каһарман якташларыбызның туган җирләре — Аксубай, Арча, Әлмәт, Әлки, Баулы, Буа, Балык Бистәсе, Биектау, Бөгелмә, Лениногорск, Тәтеш, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Югары Ослан, Чүпрәле районнары. Дүрт батыр — Казаннан. Аларның изге каберләре Витебск, Гомель, Кировоград, Курск, Ленинград, Смоленск, Одесса, Орел, Псков, Ростов өлкәләрендә, Новороссийскида, Карелиядә, дүрт каһарман исә Венгрия, Германия, Польша җирләрендә мәңгелек йокыга талган.

...Алдыбызда — Татарстанда төзелгән 352 нче укчы дивизия командиры исеменә язылган политдонесение. Анда 1162 нче укчы полк сугышчысы — коммунист-сержант Әхмәт Мөхәммәтовның Смоленск өлкәсендә 1942 елның 12 июле иртәсендә фашист позицияләренә сугышчан разведка ясаганда күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплап, батырларча һәлак булуы турында әйтелә.

Легендар Александр Матросов күрсәткән тиңдәшсез батырлыктан җиде ай элек үлемсезлеккә атлаган әлеге каһарманның искиткеч фидакарьлеге турында дулкынланмый уку мөмкин түгел. Аның турында мөмкин кадәр күбрәк белергә теләү табигый хәл. Архивларда актарыну-эзләнү нәтиҗәсендә, Казан егете Ә. Мөхәммәтовка кагылышлы тагын ике документ табылды.

Аларның беренчесе Орша исемендәге Кызыл Байрак һәм Суворов орденлы 352 нче укчы дивизия сугышчыларының Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе Г. А. Динмөхәммәтовка адреслаган хаты. Билгеле булганча, 1943 елның 5 мартында «Правда» газетасында татар халкының фронтовик татарларга мөрәҗәгате басылып чыга. Республикабыз хезмәт ияләре әлеге патриотик хатта халкыбыз сугышчыларына дошманны аяусыз тукмарга, тар-мар итәргә ныклы наказ бирәләр. Шул уңайдан дивизиянең барлык частьларында-подразделениеләрендә әлеге хатны ныклап өйрәнү оештырыла. Һәм ул сугышчылар күңелендә киң яклау таба, рәхимсез дошманга каршы үч ялкынын тагын да көчлерәк дөрләтә. Күңелләрендә кайнаган уй-хисләрен белдереп, алар Татарстанга хат җибәрәләр.

«...Фронтка киткәндә без фашист-илбасарларга каршы көрәштә Сезнең дә, үзебезнең дә йөзгә кызыллык китермәскә сүз биргән идек. Бүген исә, без, кадерле якташлар, сезгә шатланып рапорт бирәбез: беренче сугышлар алдыннан Татарстан хезмәт ияләре тапшырган байракларны без мәңгелек данга күмдек.

Илебез йөрәге Мәскәүне — һәркемнең күңеленә үтә якын, сөекле, искиткеч гүзәл башкалабызны саклап калу, дошманга бирмәү өчен без, Кызыл Армиянең башка частьлары белән берлектә, батырларча көрәштек. 1941 елның салкын декабрь көннәрендә без нәгъләт төшкән фашистларны артка таба кудык. Алар бик нык каршылык күрсәттеләр. Әмма безнең ярсу, безнең омтылыш барысыннан да көчлерәк булып чыкты. Без актив сугыш хәрәкәтләре ярдәмендә туган илебезне дошманнан азат итә-итә, алга таба юл ярдык.

Сержант Әхмәт Мөхәммәтов үзенең гәүдәсе белән дошман дзоты амбразурасын каплады. Герой үлде, ләкин ул үзенең шушы каһарманлыгы-фидакарьлеге белән безнең частька җиңү яуларга ярдәм итте...»

Әнә шулай, әлеге тарихи документта Ә. Мөхәммәтовның исеме беренче итеп зурлап телгә алына.

СССР Оборона министрлыгы Үзәк архивында табылган икенче документ та гаять кызыклы. 352 нче укчы дивизиянең «Вперед, на Запад!» дигән газетасында — 1943 елның 27 июнь санында капитан Пискунов «Сержант Мөхәммәтов үзенең хәрби антын ничек үтәде?» дигән материал бастырган.

«Яшь сугышчылар! Сержант Мөхәммәтовның кем икәнлеген беләсезме икән сез? Туган илебез дошманнары белән ул ничек көрәшкән? Изге хәрби антын ничек үтәгән?

Курку белмәс сержант безнең частьта хезмәт итте һәм ул аны мәңгелек данга күмде.

Туган ил сержант Мөхәммәтов өчен барысыннан да кадерлерәк иде. Фашист илбасарларга каршы көрәштә ул сигез мәртәбә яраланды. Әмма сигезендә дә, терелүгә, яңадан үз ротасына әйләнеп кайтты һәм дошманны аяусыз тукмавын дәвам итте.

Җәйге кыска төннәрнең берендә, таң атканда, безнең солдатлар дошман позицияләренә сугышчан разведка ясадылар. Иң беренче рәттә, коммунист

Мөхәммәтов барды. Аның кыюлыгы, куркусызлыгы, тәвәккәллеге башкаларга да күчте — фашистларның көчле ут яңгыры аша алга ыргылдылар.

Көтмәгәндә моңарчы тын торган ут ноктасы телгә килде. Дзоттан — эре калибрлы пулеметтан аталар иде. Сугышчылар ятарга мәҗбүр булды. Шулчак сержант Мөхәммәтов, шуыша-шуыша, дзотка якынрак килеп, гранаталар ыргытты һәм:

— Алга, иптәшләр! — дип кычкырып, торып басты. Аңа сугышчылардан Андрианов, Газадитов, Койкенов, Морозов кебек батыр йөрәклеләр иярде.

Әмма ут ноктасы яңадан җанланды. Фашист ядрәләре сержант Мөхәммәтовның аяк-кулларын тишеп-яндырып үттеләр. Ул соңгы минутында, барлык көчен җыеп, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын капларга өлгерде...

Сержант Мөхәммәтовның якты исеме, үлемсез батырлыгы безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр. Ватан-анага биргән хәрби антына ахыргача тугры калган герой бит ул!»

Ә. Мөхәммәтовка кагылышлы эзләнүләрне без әле дә дәвам иттерәбез. Бәлки, журналны укучылар арасында аны белүчеләр бардыр?! Редакциягә хәбәр бирсәләр, автор бик рәхмәтле булыр иде.

Республикабызның икенче матросовчысы — рус егете А. Л. Панарин. Тумышы белән Баулы районының Кырым-Сарай авылыннан. Комсомолец. Лейтенант. 112 нче укчы дивизиянең взвод командиры.

Афанасий Леонтьевич тиңдәшсез батырлык үрнәген 1943 елның 26 мартында — А. Матросов һәлак булганнан соң бер ай үткәч күрсәтә. Курск өлкәсенең Романово, Ефросимово авыллары янында була бу. Дошманның гаять әһәмиятле, яхшылап ныгытылган терәк пунктын алу өчен барган бәрелештә Афанасий Панаринның танкка каршы ата торган артиллерия взводы арысланнарча сугыша. Әмма көчләр тигез түгел. Пушкалар да, кешеләр дә берәм-берәм сафтан чыга. Афанасий Леонтьевич, яу кырында һәлак булган иптәшләре урынына басып, орудиене үзе кора, үза ата. Ахырдан пушкасы ватыла, үзе яралана, уң кулы чәрдәкләнеп бетә. Батыр комсомолец югалып калмый — сул кулына танк шартлаткыч граната тотып:

— Ватан өчен, халкым өчен алга! — дип кычкыра һәм дошман дзотына ташлана.

Көчле ут көлтәсе һәм шартлау безнең сугышчылар өчен һөҗүмгә чакыру булып яңгырый. Исән калганнарның барысы да, бердәм күтәрелеп, соңгы — хәлиткеч һөҗүмгә ташланалар. Шулай итеп, терәк пункт кулга төшерелә.

Каһарман якташыбыз Афанасий Панаринга бу вакытта нибары 19 яшь кенә була. Аның гәүдәсен, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, Ефросимово авылы уртасына күмәләр. Авыл кешеләре 1964 елда үзләре җыйган акчага батыр матросовчыга һәйкәл куялар. Шул вакыттан авыл Панарино дип рәсмиләштерелә, урта мәктәпкә герой исеме бирелә. Күренекле кинорежиссер һәм язучы Александр Очкин (ул үзе дә — исән калган матросовчы!) полкташ дустына багышлап «Үлемсезлеккә атлаган батыр» дигән китап язды.

Буа районының Әлшәй авылында туып-үскән чуваш егете комсомолец Арсентий Карташов, Днепр буенда тиңдәшсез фидакарьлек үрнәге күрсәтеп, төп-төгәл 18 яшь тулган көнендә һәлак була. Аның белән бергә Арча районының Шушмабаш авылы бөркете Кәрим Исхаков та каһарманлык күрсәтә. Әлеге матросовчыларга багышлап, күренекле чуваш язучысы Антип Николаев «Ак каеннар мәңге уяу» дигән документаль повесть төгәлләде.

Архив документлары белән танышканда Новороссийскида дүрт кешенең дошман дзоты амбразурасын каплаулары мәгълүм булды, аларның өчесе — татар егетләре. Матросовчы якташларыбызның беренчесен — Сәләхетдин Вәлиуллинны без Самат Шакир китабы буенча яхшы беләбез.

Кечѐ Җир каһарманнарының икенчесе — кызыл флотчы Сәйфулла Иосыпов. Ул — диңгез пехотасының 143 нче аерым батальоны разведчигы. Заманында Казан, Уфа, Ленинград шәһәрләрендә эшләгән. Танылган язучы Юрий Стрехинның 1974 елда «Московский рабочий» нәшриятында басылып чыккан «Отряд Бороды» дигән китабында 1943 елның 7 августында һәлак булган матросовчы батыр турында күп кенә кызыклы мәгълүматлар бар.

Ниһаять, өченче каһарман — Мансур Вәлиуллин. Гаять үзенчәлекле шәхес буларак, бу батырга киңрәк тукталып үтәсе килә.

Сугышка кадәр Мансур Алиевич Татарстаннан китеп, Бакуда, нефть

чыгару промыселларында эшли. Бөек Ватан сугышы чорында 318 нче укчы дивизия составында Кече Җирдә сугыша, коммунистлар партиясенә кабул ителә. Архив документлары сөйләвенчә, коммунист сержант яу кырында күрсәткән каһарманлыклары өчен, 1943 елда «Батырлык өчен» медале, бераз соңрак, армия командующие приказы нигезендә, Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Әлеге зур бүләккә ул Новороссийск янында күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплап, иптәшләренә җиңүгә юл ачканы өчен лаек була. Тик герой әлеге орденны үз вакытында ала алмый, аны бик авыр хәлдә госпитальгә озаталар. Шунда сигез ай дәваланып яңадан сугышчан сафка баса...

Халкыбызның данлы улы Мансур Вәлиуллин — исән калган сигез матросовчының берсе. Бүген без үлемне җиңгән матросовчылар — рус халкы вәкилләре: Октябрь революциясе яшьтәше коммунист Александр Удодов, КПСС членнары Степан Куликов, Александр Очкин, украин Владимир Майборский, грузин Георгий Майсурадзе, казах Сабалак Оразалинов, еврей Товье Райз исемнәрен әйткәндә якташыбызны да горурланып телгә алабыз, чиксез хөрмәт белән алар алдында баш иябез.

Легендар якташыбыз бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яши. Тыныч хезмәт фронтында да сынатмаган ул. 1948 елда «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен», 1952 елда «Хезмәттәге батырлык өчен» медальләренә, 1966 елда «Почет билгесе» орденына лаек була. Сугышчан бүләге исә аны шактый еллар үткәч кенә эзләп таба...

1980 елда Мәскәүдә СССР Оборона министрлыгының Хәрби нәшриятында дөнья күргән «Үлемсез батырлыклар» («Бессмертные подвиги») дигән китапта матросовчы якташларыбыздан Советлар Союзы Герое Алексей Исаев турында кыскача язма һәм тагын тугыз кеше турында белешмә бирелгән иде. Без әлеге китапны төзүчеләр белән элемтәгә кердек һәм Татарстан матросовчылары турында яңа мәгълүматлар һәм фоторәсемнәр туплап җибәрдек. Тиздән китапның тулыландырылган икенче басмасы дөнья күрәчәк.

Соңгы вакытта СССР Оборона Министрлыгы Үзәк архивында җентекле эзләнүләр нәтиҗәсендә безгә тагын бер каһарман якташыбызны ачыклау мөмкин булды. Ул — республикабызның элекке Бондюг (хәзерге Менделеев) районында 1908 елда туган гвардияче өлкән лейтенант, рота командиры коммунист Котдус Габдрахманович Габдрахманов (хәрби документларда аның исеме «Кутуз» дип язылган).

58 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 175 нче гвардияче укчы полкның 1942—1945 еллардагы сугышчан хәрәкәтләре турында сөйләүче журналда каһарман якташыбызның батырлыгы турында түбәндәге юллар язылган:

«...8 февраль, 1944 ел.

Рота командиры, гвардияче өлкән лейтенант Габдрахманов туган ил хакына үзенең газиз гомерен корбан итте. Ул, Кызыл Армия офицеры, аяусыз ут яудыручы дошман дзоты амбразурасына ташланып, аны күкрәге белән каплады. Фашист пулеметы, коммунист Габдрахманов канына тончыгып һәм ул ыргыткан гранаталардан тәмам эштән чыгып, бөтенләй тынып калды... Сугышчан дуслары яраткан командирларының вакытсыз үлеме өчен дошманнан аяусыз үч алдылар һәм, җиңү яулап, алга таба юлларын дәвам иттеләр...»

Матросовчы Котдус Габдрахмановны кемнәр яхшы белә? Хатыны, балалары, туганнары, дуслары исән-саумы? Безне шундый сораулар, шулай ук республикабызның башка матросовчыларына кагылышлы һәр мәгълүмат кызыксындыра.

Батырлык елъязмасын, әйдәгез, бергәләп тудырыйк! Атаклы чех язучысы — кырык яшендә фашист төрмәсендә гомере киселгән ялкынлы патриот Юлиус Фучик сүзләрен һичкайчан хәтеребездән чыгармыйк:

«...Мин батырларның билгесезлектә калмавын, аларны һәр кешенең дә белүен телəр идем. Аларның һәркайсының үз исеме, карашы, үй тойгылары, ышанычлары булган һәм шуңа күрә аларның, хәтта иң билгесезләренең дә, газаплары тарихка мәгълүм шәхесләрнекеннән ким түгел. Сугышта корбан ителгәннәр Сезгә дусларыгыздай, туган-тумачаларыгыздай һәм үзегездәй һәрвакыт якын булсыннар!»

## Барлас Камалов

# ЮЛЛАР, ЮЛЛАР...

Аның белән без үткән көздә очраштык.

Озаеп барган төннәрдә йолдызлар мул атыла, таңнар суык һәм мул чыклы иде инде. Елның бу фасылы бизәкләре дип тагын көннән-көн салкыная барган җилне, болытларның өзлексез агылуын, яфракларның дерелди-дерелди коелуларын, кошлар җырының тынып калуын, киек казларның җылы якларга сәфәр чыгуын әйтергә мөмкиндер. Табигать-рәссам үз пумаласыннан сары буяуны кызганмый тамыза башлаган чак иде.

Рәүф Абдуллович Әһлиуллин Буа май-сыр комбинаты директоры кабинетында, түр өстәл буенда утыра. Бүлмә ишеге ачык. Мин кергәнне искәрмәде дә бугай, сәлам биргәч, сискәнеп киткәндәй булды, урыныннан күтәрелде, күрешергә кул сузып, каршыма атлады.

Хәл-әхвәл сорашып утырганда да аның производство мәсьәләләре тәэсиреннән тулысынча арынып җитмәгәнен абайладым. Уйлары бүтән үзәннән агыла иде шикелле. Мин аның йончыган йөзенә, арыган күз карашына, маңгаена гына түгел, авыз-борын тирәләренә сарылырга әрсезләнгән сызыкларга, чигәләрендәге көмеш җепләргә дикькать иттем һәм ирексездән: «Безнең буынның да көзе җиттемени соң инде? — дип уйлап куйдым.— Яшьтәшемнең килеш-килбәте шундый фикергә этәрә. Ә безгә нибары... нибары илле сигез яшь. Хәер, пенсияне тикмәгә генә алтмыштан бирмиләр ич инде...»

Ул да булмады, комбинат директоры Рәүф Әһлиуллин үз хәтеренең әллә кайсы почмагыннан бергә үткән яшьлек елларының мәзәк хәлләрен, гыйбрәтле вакыйгаларын актарып чыгарды. Шул чак аның тавышына яшьлек чыңы кайтты, коңгырт кара күзләрендә күкрәп яшәү очкыннары кабынды, гәүдәсе тураеп, егетләрчә тәзлек тапты. «Юк әле,— дип дәртләнеп фикер йөртә башладым мин дә,— безнең дары мичкәләрендә дары бар әле, бар! Алтмышка гына түгел, җитмешкә җиткәндә дә сафта булырбыз. Ә без җитмешне тутырасы ел, беләмсез, 2000 нче ел булачак!»

— Юллар теңкәгә тия,— диде директор, янә җитдиләнеп.— Шуларны рәткә китерү өчен ниләр кылып була дип утыра идем...

Сүз колхозлардан ашлык, бәрәңге, яшелчә, ит, сөт китерә, авылларга төзү материаллары, шәһәр кибетләрендәге товарларны кайтара торган гади, мәгәр үтә зарур юллар турында иде, ә мин кордашымның тормышы һәм хезмәтенә бәйле гомер юллары турында уй йөртә башладым.

...Рәүф Әһлиуллин юллар хакында әле балигъ булганчы ук өлкәннәргә хас җитдилек белән фикерли иде инде. Әтисен — колхоз төзү активистын, күмәк хуҗалык башлыкларыннан берсе булган Абдулла агайны — Бөек Ватан сугышына озатканда юллар чатында торып калгач, юл-сукмакларның кешеләр язмышына тыгыз бәйләнешле икәнен аңлады ул.

Фашистларга каршы көрәшкә киткән җиреннән әтисе әйләнеп кайта алмады. Гаиләдәге өлкән малай өчен күрше Килдураз авылындагы урта мәктәпкә юл өзелеп торды: әнисенең кул арасына керергә, энеләре Рифкать белән Мөнирне үстерешергә, укытырга кирәк иде. Аннары ир-егет өчен изге дә, авыр һәм җаваплы да юлга кузгалырга туры килде: Рәүф Әһлиуллин Хәрби Диңгез флотына хезмәткә чакырылды. Юллар, юллар...

Туган авылы Кыр Тәүгелдесенә кайткач, күрше авыл белән ике арадагы басу юлын атнаның һәр тумыш алты көнендә ун ай буе таптады ул. Үзеннән яшьрәкләр белән янәшә утырып, парта кысанлыгына игътибар итмичә, унынчы классны тәмамларга тиеш булды. Шуннан соң авыл клубын җитәкләде, колхоз комсомолларының таянычына әверелде, исеме районга мәгълүм булды һәм кешеләр белән аралаша да, уртак тел таба да белгән озын буйлы, кара туткыллы чибәр егетне ВЛКСМның Буа райкомына эшкә чакырдылар. Әүвәле ул — инструктор, аннары икенче секретарь булды.

Рәүф Абдуллович белән якыннан һәм ныклап танышып китү 1956 елның көз азагына туры килде. Мине дә, ВУЗда комсомол эшендә булгангадыр дип беләм, ВЛКСМ райкомының бюро члены итеп сайладылар.

Ул чактагы беренче секретарь, шулай ук диңгезче офицер Наил Зарипов белән киңәштек тә, табигатьнең соклангыч почмагындагы Толымбай авылына киттек. «Коминтерн» колхозы оешмасының эшен җайга салуда хәл-халенчә булышырга кирәк иде. Карлы суын кичкәндә дә, ылыс исен куе-тыгыз аңкытып торган урман аша чыкканда да оешма башлыгын бик тиз очратырбыз, комсомолларны җыеп, эшлекле сөйләшербез кебек тоелган иде. Чынлыкта авыл Советы башкарма комитеты председателе белән беравык сөйләшүдән уза алмадык. Кирәксенгән яшьләрне очратырга туры килмәде, алар тылсымлы балдактай юкка чыкканнар иде.

Әмма Рәүф бу оешмага атна-ун көн буена сукмакны суытмады. Аннары да керешкән эшеннән чигенмәде, яңа сайланган комсомол комитетының җиң сызганып эшли башлавына, атаклы колхоздагы яшьләр оешмасының электәге даны республика күләмендә яңгыравына ирешми торып тынгы тапмады.

Тагын бер хатирә. Протопопово авылыннан партия райкомының агитация-пропаганда бүлегенә дә, ВЛКСМ райкомына да зар хатлары ишәеп китте. «Клубыбыз юк, үзешчән сәнгать түгәрәге эшләми, лекцияләр укылмый. Халыкара хәлләр белән бик кызыксынабыз, лектор җибәрсәгез иде»,— дип язалар.

Киттек велосипедларга атланып райүзәктән егерме чакрымдагы әлеге рус авылына.

Кич. Көтү керде. Сөт исе катыш тузан урам чирәменә ятты. Райкомол секретаре яшен-картын иске чиркәү буена җыйды. Халыкара вакыйгалар турында ачык һавада тыңланган лекция бер сәгатькә барса, сорауларга җавап бирә-бирә өч сәгать үтеп китте. Ай яктысында район үзәгенә кайтабыз. Велосипед көпчәкләренең барып төртелүләре ешаеп киткәч, мин сукранып куйдым.

— Их, безнең юллар!

Алдан элдертүче Рәүф артка борылып әйтте:

— Юллар дигәндә, Чувашстан белән ярыша алмыйбыз шул әле! Кешеләр күңеленә юл салу хакына чыдарга туры килә...

Мин аның ул көнге эшебездән канәгать булуын аңладым...

Шул хәлләрдән соң уйлап куйган идем: бу егет тырышлыгы белән таш ярырга дип туган. Тик аңа югары белем кирәк! Хуҗалыкта тиеннәр саный белгән яшь ир-атка, өлкәннәр белән — өлкәннәрчә, яшьләр белән заманча сөйләшә һәм киңәшә алган яшь җитәкчегә, кешеләр күңеленә ачкыч табарга сәләтле булдыклы оештыручыга югары белем ашар ризык, эчәр су кебек, сулар һава сыман зарур! Үзе моны ул теләсә кемгә караганда да яхшырак төшенә иде. Югары партия мәктәбенә читтән торып укырга керде һәм аны кызыл диплом белән тәмамлады.

Язмыш юлы Рәүф Әһлиуллинны комсомолия хезмәтеннән партия эшенә алып китте, Рәүф Абдуллович башта — Ленин исемендәге, соңрак «Ватан» күмәк хуҗалыгында партком секретаре булды.

Карлы авылы клубы эшчесе, чибәрлеге белән тирә-юньдә дан тоткан Сания белән гаилә корып җибәрделәр. Хәзер инде Сания ханым югары белемле педагог, яше түгел, хезмәт стажы бүген үк хаклы ялга чыгарга хокук бирә. Шулай булмый ни, уллары Илдарның медицина институтын тәмамлап, республикабыз башкаласында хирург булып эшли башлавына да өченче ел китте. Сер итеп кенә әйтик, өлкән Әһлиуллиннар оныклар сөя алулары белән дә бик бәхетлеләр.

Халкыбызда: «Бер тарыдан ботка булмый»,— дигән әйтем бар. Партия оешмаларын җитәкләгәндә, Рәүф Әһлиуллин нәкъ менә ялгызы булмады, коммунистларга таянды, авыл халкы белән киңәшеп эш итте. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул елларда бу колхозлар үр менде. Тәҗрибәле председательләрнең эш серенә төшенде Әһлиуллин, белмәгәнен сорады, хуҗалык җитәкчесе азаккача ук чамалап җиткермәгәнне үзе киңәш итте. Икеләнми-тартынмый әйтергә мөмкин, «Ватан» колхозында ул Әгъзам Гыйлаҗ улы Хәсәновтан күп нәрсәгә өйрәнде. Әгъзам абый тыныч кына торып, тиеннәрне дә әйбәт саный, кеше күңелен дә күрә, әйле-шәйле йөрүчеләрне һич тә тавышын күтәрми генә «тәртә арасына» кертә белә иде. Шул сыйфатларга ия булганга, хуҗалыкны чирек гасырдан артык җитәкләде бит ул, илебезнең югары бүләкләренә лаек булды. Үзенең зирәклеге, күпне белгәне, аңлаганы, килер көннәргә күз төби алганы өстенә «Хәсәнов дәресләре» ул чагындагы яшь җитәкче Әһлиуллинга бик файдалы булды. Аның каравы соңыннан Рәүф

Абдуллович үзе күпме яшьләрне өйрәтте!

Буа төбәгенең «Память Ленина» колхозы... Монда коммунист Әһлиуллинның биографиясенә яңа юллар, яңа сәхифәләр өстәлде. Әлеге күмәк хуҗалыкка председатель булып сайлангач, күпме йокысыз төннәр кичергәнен, чигәләрендәге көмеш җепләрнең шунда күренә башлавын Рәүф Абдуллович үзе генә белә. Ә менә колхозның текә күтәрелүен, игенчелектә һәм терлекчелектә моңача күрелмәгән үрләр яулаганын, күпме кешеләрнең талантлары һәм сәләтләре ачылып китүен йөзләр, меңнәр бик яхшы хәтерли. Әһлиуллин җитәкчелек иткән елларда колхозның әйбәт даны республика чикләрен үтеп чыкты. Шундук монысын да әйтергә кирәк: колхоз тормышын төпкә җигелеп тартучы кешеләрнең аңа булган ышанычы һәм ихластан ихтирамы Әһлиуллинның үзен дә Татарстан АССР Верховный Советы депутаты да, СССР Верховный Советы депутаты да итте. Алай гына да түгел әле, Рәүф Абдулла улы Әһлиуллин бу колхозда көч куйган чорда Социалистик Хезмәт Герое дигән бөек исемгә лаек булды. Беренче карашка, баш әйләнерлек чама да бар иде кебек. Тормыш уңышлардан башлары әйләнгәннәрне дә белми түгел. Рәүф алай булмады. Ник? Җавапны мин шунда табам төсле: ул үзенең шәхси казанышларын колхозчылар белән уртак уңыш дип дөрес бәяли алды. Халыктан башка каһарман юк! Әһлиуллин ир акылы белән шуны дөрес бәяләргә сәләтле булды. Ул бүген дә үзенең таянычтерәкләре булган механизатор-аксакал Зәйдулла Хәсәнҗановны, комплекслы бригада башлыгы Федор Емельяновны, техника остасы Садри Ильясовны, сөтчелек фермасын озак еллар җитәкләгән Афанасий Киргизовны, дистәләрчә башка фидакарьләрне йөрәк җылысы белән искә ала. Шулар ярдәме, шулар тырышлыгы белән зур сикерешләр гамәлгә ашты ләбаса: 1960 елда бөртеклеләрнең уңышы гектардан уртача 10,5 центнер иде, һәр сыердан ике мең килограмм сөт савылды. Хуҗалыкның акча кереме 400 мең сум булды. Инде 1973 елның нәтиҗәләрен хәтердә яңартыйк: бөртеклеләрнең гектарыннан 31 әр центнер уңыш җыеп алынды, акча кереме 2 миллион 900 мең сум, саф табыш 1 миллион 156 мең сум тәшкил итте. Ул елларда «Память Ленина» колхозы авыллары төзелеш мәйданына әйләнде. Үзәк утарда — культура йорты, 320 урынлы урта мәктәп салынды. Мулланур Вахитов авылында яңа клуб төзелде. Бер бишьеллык дәвамында корылышка миллион сумнан артык акча тоту үзе генә дә күпне сөйли иде.

Минем аның колхозчыларны төрле мәсьәләләр буенча кабул иткән чакларында күп күргәнем булды. Төчеләнмәс, язса — язга, килешсә — күзгә дигәндәй, буш вәгъдәләр бирмәс. Вәгъдәсе көненә-сәгатенә тикле конкрет булыр. Кешеләрнең ышанычын шул цементлый. Абруйлы җитәкченең өзеп әйткән сүзен ишеткән колхозчының җаны тыныч, эше күркәм була. «Кеше факторы» дип бик еш кулланырга күнегеп киткән сүзләребезнең асыл мәгънәсе шунда шикелле бит!

«Память Ленина» колхозыннан Рәүф Әһлиуллинны районның иң зур хуҗалыгына — исеме җисеменә ябышып торган «Гигант»ка председатель итеп күчерделәр. Тугры сүз дәверендә яши башлагач, ачыктан әйтергә кирәк, бу адым ул чактагы район җитәкчелегенең уйлап җиткермәве иде. «Память Ленина» колхозында да эшләр хөртиләнде, «Гигант» та әллә ни сикереш ясамады. Рәүф Абдуллович та яңа урында үз туфрагыннан ят җирлеккә күчереп утыртылган куак сыманрак калды. Гаиләсенең район үзәгендә яшәргә мәҗбүрлеге дә үзен сиздермәде түгел.

Соңгы елларда, белгәнебезчә, Рәүф Әһлиуллин май-сыр комбинатын җитәкли. Әмма, әүвәлгечә үк, җирнең чын хуҗасы булырга тиешле авыл кешесе турында өзлексез уйлана.

Җиргә ябышып ятучы крестьян нигә кимеп калды? Игенченең ихласы ник чикте?

Рәүф Абдуллович белән әңгәмә корганда, ул бу сорауларга үз җавапларын биреп, мәсьәләне азаккача ачыкларга омтыла. Аның белән килешми мөмкин түгел.

Чыннан да, Бөек Октябрь революциясенең икенче көнендә үк Советларның II съезды Владимир Ильич Ленин доклады буенча Җир турында Декрет кабул итеп, алпавыт җирләрен крестьяннарга бирүне гамәлгә ашырырга кереште. Җирсез интеккән, бөлгенлектә яшәгән миллионнарча крестьяннар җирле булды. Үзеннән-үзе аңлашыла, авыл кешесе бу җиргә ябышып ятты, шуның белән көн күрергә ышанып, киләчәккә зур өметләр баглады. Әмма унбер елдан соң ук, әлбәттә, тагын да изгерәк максатларда, аерым хуҗалык-

ларның җирләрен берләштереп, колхозлашу хәрәкәте башланды. Җиргә тиенгән крестьян моны аңлап җитмәде, тарихи котылгысыз булган хакыйкатькә төшенү дә сәгате-минуты белән генә барып чыкмый икән. «Үземнеке — үз, киндер булса да бүз» дигән игенче «минеке»ннән «безнеке»нә күчүне сыкрау-сыктаулар, үпкә-үч, хәтта кан коюлар белән кичерде. Моның өстенә, колхозлашу барган елларда иң уңган, иң булган, игенчелек серләрен нечкәләп белгән урта хәлле крестьянның да бер өлешен кеше хезмәтен эксплуатацияләүче кулаклар җөмләсенә кертү фактлары булды, өлешчә гайрәт чигүгә китерде.

Аннары байтак төбәкләрдә һәм озак еллар буена хезмәткә түләү мәсьәләсе аяныч хәлдә кала бирде. Кешеләр тора-бара төп игътибарны үзенең каралты яны биләмәсенә һәм абзарындагы мал-туарына, кош-кортына юнәлтергә мәҗбүр хәлдә калды. Җае килгәндә, шәһәргә китү ягын каерды сала кешесе.

Менә хәзер, күп еллар үткәч, җиргә мәхәббәт, аңа береккәнлек тойгысын ияту, тергезү, көчәйтү һәм яшь буында да тәрбияләү өчен биниһая зур эш башкару зарур. Бу исә бөтен җәмгыятебездәге эйдәүче көчләр тырышлыгы белән генә гамәлгә ашырыла ала. Соңгы елларда үзен тулысынча аклаган коллектив подряды, звено подряды һәм гаилә подряды дигән факторлар шушы юлда зур роль уйнарга тиешләр. Гаилә подряды аеруча нәтиҗәле... Әмма, Рәүф Әһлиуллин фикеренчә, эшче көчләр санаулы булган урыннарда үтә кулай булган бу подрядның да, авылда эшче көчләр тулысынча җиткән очракта, мәгълүм кытыршылыкларга китерүе мөмкин. Димәк, тәңкәнең икенче ягын да хәтердән чыгармаска кирәк. Авылда төпләнеп яшим дип торган һәр сау-сәламәт кешене эш белән тәэмин итү мәсьәләсен күз уңында тоту кирәк...

Сүз инеше үз уңаена агып бара торгач, мин Рәүф Абдулловичтан конкрет бүгенге эштә нинди мәсьәләләр баш калкытуын сораштым.

— Тулаем алганда, комбинатта һәм аның филиалларында эш әйбәт кенә бара,— диде ул.— Коллектив эшчән. Аңлы хезмәт дисциплинасы — төп фактор.

Хәл итәсе мәсьәләләрме? Бар алар, бик бар. Һәрбер товарлыклы сөтчелек фермасына, һич тә булмаса, һәр колхозга, сөт үлчәгечләр кирәк. Хәзергә ул бер-ике колхозда гына җиһазландырылган.

Утка салганы — сөт суыткычларының җитмәве. Әле егермегә якын фермада ул юк. Җитештерелгән барлык сөтне суытып кабул итеп булмый дигән сүз. Бу хәл дәүләткә дә, колхозларга да зыян сала. Суытылмаган сөт, ачылыгы арту аркасында, түбән сорт белән кабул ителә.

Сөтне машинага төяү мәсьәләсе дә четерекле. Ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен 86 насос кирәк, районда исә аларның саны утызга да тулмый.

Инде барыннан да кыены — юллар. Аһ, ул юллар! «Чулпан», «Коминтерн», «Марс» колхозы фермаларына үтү — сират күперен кичү белән бер.

Сөйләшә торгач, көзге кичнең район үзәге өстенә күгелҗем-кара бөркәнчек япканын абайламый да калганбыз. Рәүф Абдуллович кул сәгатенә күз төшергән иде, һай-һулап куйды.

— Тугызынчы киткән бит! Әйдә, кузгалдык! Безгә кайтабыз, чәй янында гәпләшербез,— диде. Аннары, кул хәрәкәте белән һаваны ялгандай, кырт кисеп әйтте.— Бүгенгә эш турында сөйләшмибез!

Комбинат ишегалдындагы машинага игътибар иттем:

— Бу монда куна мы?— дидем.

— Каравылчы килә монда. Килгәндер, карап, тикшереп, барлап йөри булыр.— Директор шулай диде.— Бездә машиналарны файдалану коэффициенты шактый югары. Әмма моңа техниканы тәмам сафтан чыкканчы йөрү бәрабәренә ирешелә. Аннан соң автомашинаны теләсә кайда төзәтәсе була, чөнки сөт промышленносте системасында ремонт базасы юк. Комбинаттагы унбиш машинаны сафта тоту өчен, кемнәр алдында гына бүрек салырга туры килми?!.

Мин чак кына көлеп җибәрмәдем. Рәүф бит әле моннан бер минут элек кенә: «Эш турында сөйләшмибез!» — дигән иде. Булмаганны! Әһлиуллин булсын да эш турында сөйләшмәсен! Аның бөтен тормышы машиналар, ашлык, ит, сөт һәм юллар турында кайгыртудан, дәүләт планнарын уңышлы башкарып чыгу ысулларын эзләүдән гыйбарәт ич!

*Буа-Казан.*



**И. Курмашев,**

КПССның Алабуга шәһәр комитеты
беренче секретаре

# КАМА СУЫ БУЕНДА

Бүгенге көндә Алабуга Татарстанда һәм промышленносте, һәм авыл хуҗалыгының алга киткән районнарның берсеннән санала. Чамалап карау өчен бер генә сан китереп китим: без ел саен 120 миллион сумлык байлык җитештерәбез.

Районның горурланырлык яклары аның борынгысына ук барып тоташа. Шулай да, хәзерге яңалыкларга кадәр безнең хакта аз беләләр иде. Моннан берничә ел элек районда илкүләм әһәмияткә ия булган Кама трактор заводы салына башлады. Безнең яклар турында үзәк газеталар, «Огонек», «Смена», «Вокруг света» журналлары язып чыкты. Төзелешнең канәгатьләнерлек темп ала алмый азаплануы исә үзәк телевидениене дә хафага салды.

Мәкалә авторларының беренче чиратта безнең якның тарихына, табигатенә мөрәҗәгать итүе һич тә очраклы хәл түгел. Алабуга тарихы искиткеч сәхифәләргә бай. Шәһәргә якын гына җирдә Ананьино каберлеге саклана. Бу борынгы истәлек тарих фәнендә «Ананьино культурасы»на нигез булып тора.

Пароходлар тукталышында, биек тау башында «Шайтан каласы» дигән манара бар. Ул — болгар чорына караган кадерле истәлекләрнең берсе. Теле булса, манара безгә үзе күргән бик күптәнге хәлләр турында бәйнә-бәйнә сөйләр иде. Бу тарихи манара Болгар бабаларыбызның ничек көн итүен дә, монгол басып алучыларының бу җиргә нинди афәтләр китергәнен дә, 1552 елгы вакыйгалардан соң бу якларныңниләр кичерүен дә — барын да күреп торган бит. Иван Грозный гаскәрләре Казан ханлыгын алганнан соң Кама буе урманнарына да руслар килеп чыга. Алар Тойма елгасына якын гына Трехсвятское авылын салалар. Алабуга шәһәре шул авыл нигезендә барлыкка килә.

Себергә сәфәр чыккан Ермак гаскәрләре дә Алабуга аша үтеп китә. Емельян Пугачевның Казанга ашыгучы гаскәрләре дә Алабугада тукталыш ясыйлар. Безнең шәһәрдә Себер сөргененнән кайтып баручы А. Н. Радищев та була. Фельдмаршал М. И. Кутузовның ординарецы Надежда Дурова исә Алабугада шактый озак яши. Ул елларда безнең шәһәргә А. С. Пушкиннан хатлар килеп тора. Мәшһүр шагыйрь Бородино сугышы каһарманы Надежда Андреевнаның әдәби язмаларына сокlануын белдерә. Шәһәребезнең хәзерге Мәскәү урамында Надежда Дурова яшәгән йорт сакланып калган. Без анда Дурованың музеен оештырырга ниятләп торабыз. 1941 елда Жданов урамындагы 20 нче йортта исә күренекле шагыйрә Марина Цветаева яшәгән. Аның кабере — безнең зиратта.

Ишеткәнегез бардыр: безнең районны «Шишкин яклары» дип тә йөртәләр. Бөек рәссам И. И. Шишкин бездә туган, балалык елларын һәм үсмер чагын монда уздырган. Зур рәссам булып танылгач та ул туган җиренә еш кайткан һәм бу якның хозурлыгын мәңгеләштерерлек әсәрләр иҗат итеп калдырган. «Арыш», «Нарат урманы», «Кызыл кыя» кебек рәсемнәргә карап кем генә сокланмаган?! И. И. Шишкин яшәгән йортта без мемориаль музей ясадык. Аңарга ел саен илле меңнән артык тамашачы килә.

Безнең яклар тарихында язучылар Салтыков-Щедрин, Короленко, Пришвин, галимнәр Менделеев һәм Бехтерев, маршаллар Говоров һәм Чуйков турында якты истәлекләр бар. 1919 елда Алабугага Н. К. Крупская килә. Ул чыгыш ясаган бинага мемориаль такта кадакланган.

Гомумән, безнең кешеләр шәһәр тарихына бәйле һәр истәлекне кадерләп саклау ягында. 1811 нче елны салынган Спас чиркәвен яңадан төзәтә башладык. Анда орган

куеп, борынгы бинаны заманча җиһазландырылган концерт залына әйләндерергә уйлыйбыз.

Бөек Октябрь революциясе Алабуганың элекке тормышын тамырдан үзгәртә. Моңа кадәр шәһәрдә сәүдәгәрләр, поплар һәм жандармнар гына рәхәт күргән. Халык исә иртәдән кичкә кадәр алар өчен тир түккән. 9 чиркәү, бер мәчет һәм монастырь шәһәрдә дин әһелләренең күпләп туплануына сәбәп булган. Өяздәге чиркәүләрнең саны кырыкка якынлашкан.

Алабугада, өяз шәһәрләре арасында беренче буларак, 1917 елның 16 ноябрендә үк Совет власте урнаштырыла. Яңа тормышның җиңүе өчен кискен көрәш башлана. Без бу юлда әйдәп йөрүче большевиклар С. Н. Гассар, Я. С. Тугаров, М. Х. Исхаков, А. Н. Чувыгиналар истәлеге алдында баш иябез. Аларның данлы исемнәре шәһәребез урамнарына бирелде. Гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган каһарманнарга багышлап һәйкәл салдык.

Алабуганың совет власте елларындагы тарихы Татарстан тарихы белән уртак. Бүгенге тормышка аяк басканчы район республикабыз кичергән барлык көрәшләрне үтә: гражданнар сугышы, бөлгенлеккә төшкән хуҗалыкларны аякка бастыру, кулакларга каршы көрәш, ачлык, тиф, ваба авыруларыннан арыну... Болар район халкыннан зур тырышлык, түземлек сорый. Шәһәрнең үзендә исә промышленностьны кичекмәстән аякка бастырырга кирәк була. Шул ук вакытта культура үсешенә, халык мәгарифен юлга салуга да зур игътибар бирелә.

Җиң сызганып иҗади эшкә тотынган халыкның киләчәккә булган якты хыяллары фашистлар Германиясенең ил өстенә көтелмәгән ябырылуы аркасында тормышка аша алмый кала. Районның унөч мең кешесе фронтка китә. Фронтовикларыбызның ун меңләбе, сугышта күрсәткән каһарманлыклары өчен, илебезнең орден һәм медальләренә лаек була. Бу тиңдәшсез фидакарьлекне олылап куелган Дан обелискы каршында көн-төн мәңгелек ут ялкыны җилпенә. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә багышлап салынган һәйкәл янына иң кыю ун ир-егетебезнең барельефын ясатып куйдык. Алабугадан киткән бу ун егет сугышта Советлар Союзы Герое исеме алды. Шунда ук Дан орденының өчесенә дә лаек булган Р. Х. Гайнуллинның да барельефы беркетелде.

Сугыш чорында районның промышленность предприятиеләре дә, колхозлары да фронт таләпләренә җайлашып эшли башлыйлар. Механика заводы гранаталар ясый. Тегүчеләребез фронтка сырган чалбарлар, җылы курткалар озатып тора. Сугышчыларны азык-төлек белән тәэмин итү өчен әзерләнгән икмәккә Татарстанда беренче булып салынган консерв заводы продукциясе дә кушыла. Алабуга һәм районның кайбер авыллары Мәскәү, Ленинград якларыннан эвакуацияләнгән күп санлы кешеләрне үзенә сыендыра.

Бөек Җиңү район халкын яңа иҗади эшкә дәртләндерә. Шәһәр һәм авыллар сугыш китергән күңелсезлекләрдән мөмкин кадәр тизрәк арынырга тырышалар. 1955 елда, Кама буенда бай нефть ятмалары ачылгач, районның промышленносте аеруча алга китә. Беренче нефтьчеләр үзләрен ерактагы утрауда калгандай хис итәләр иде. Нефть чыга, әмма аны кирәкле якка озатыр чара юк. Җәен ярый әле — Кама буйлап баржалар йөри ала. Кышын исә монда бары тик чана юлы гына иде. Тора-бара элемтәләр җайга салынды. Нефть үткәргеч төзелде. Аэродром үзгәртеп корылды. Түбән Кама ГЭСының буасы исә безне «зур дөнья» белән аеруча ышанычлы иттереп тоташтырды. Казанга кадәр автомобиль юлы салынды, тимер юл да булдырылды.

Кыскасы, нефть районыбызның йөзен балкытып җибәрде. Квартиралар газ белән тәэмин итепде, юлларыбызга асфальт түшәлде. Нефть промышленносте район биргә торган байлыкның, акчага күчереп исәпләгәндә, яртысын алып тора. «Прикамнефть» идарәсе эшчәннәре илгә йөз миллион тоннадан артык сыек ягулык бирделәр инде.

Алабугада тарихы 1772 елга ук тоташкан арматура заводы эшли. Аңа Тула ягыннан килгән Красильников дигән сәүдәгәр нигез салган. Ул кеше Саралы авылы янында бакыр рудасы чыгаруны башлап җибәрә. Утыз-кырык эшчесе булган завод исә шул бакырдан чиркәү чаңнары коя. 1890 елны заводны Алабугага күчерәләр һәм чуен кою заводына кушалар. Совет власте елларында, беренче бишьеллыклар чорында завод чын-чынлап зур эшләр майтара башлый. 1968 елда заводны үзгәртеп кору чарасына керешкән идек. Хәзер аны тынырлык та түгел. Аның продукциясе СЭВ илләренә дә, кайбер капиталистик илләргә дә җибәрелә. Безнең арматурчылар, беренчеләрдән булып, дәүләт кабул итүе шартларында эшли башладылар.

Фидакарь коллективларның һәрберсе турында тәфсилләп сөйләргә тотынсак, бик күп вакыт кирәк булыр. Аларның һәммәсе кызыклы тарихка, матур үрнәкләргә, горурланырлык күркәм гадәтләргә ия. Уку-өйрәтү предприятиесе, киҗе-мамык берләшмәсе, ит консервлау һәм сөт комбинаты, тегү фабрикасы, исерткечсез эчемлекләр заводы — барысы да намуслы хезмәт белән рухланып эшли.

Районның 18 колхоз-совхозы карамагына сиксән тугыз мең гектар чамасы җир тапшырылган. Терлек-туарлар саны да меңнәр белән исәпләнә: мөгезле эре терлекләр — егер-

ме биш мең чамасы, дуңгызлар — унбер меңнән артык, сарык — унөч мең ярым.

Хуҗалыкларның материаль-техник базасы ел саен ныгый бара. Машиналар белән тәэмин итүгә, авылларны төзекләндерүгә акча тоту артканнан-арта. Шул ук вакытта колхоз-совхозларның дәүләткә сата торган азык-төлек күләме дә сизелерлек күбәйде, хәзер без аны ел саен утыз миллион сумлык озатабыз. Узган ел аеруча уңышлы булды. Октябрьнең 70 еллык юбилеена без авыл хуҗалыгы буенча бишьеллыкта билгеләнгән ике еллык планнарыбызны тулысынча үтәдек. Терлекчеләребез һәр сыердан елына өчәр мең литр сөт савып алуга ирештеләр.

Авылларыбыз карап торышка да төзекләнә, матурая бара. Колхозчылар өчен уңайлы йортлар салына. Аларга көнкүреш хезмәте күрсәтү ягыннан да алга китеш бар. Яңа мәктәпләр, балалар бакчасы, больницалар, клублар арта.

Мәгълүм булганча, безнең як кешеләре элек-электән укырга маһир. Утызынчы елларда Алабугага «уку комбинаты» — дигән яңа атама да өстәлгән. Шәһәрдә педагогия институты, СССР эчке эшләр министрлыгының милиция мәктәбе, медицина һәм республика культура-агарту училищелары эшли. Педагогия институтының егерме кафедрасында өч йөзләп укытучы алты меңгә якын студентка югары белем бирә. Институт илгә ун меңнән артык педагог әзерләп чыгарды.

Район кешеләренә белемнәрен күтәрергә дә, культуралы ял итәргә дә барлык мөмкинлекләр тудырылган. Кырыкláп клубыбыз, утызга якын китапханәбез бар.

Трактор заводы да салынса, шәһәр кешеләренең тормыш-көнкүреше тагын да матураер дип уйлыйбыз. Чөнки зур завод үз эшчеләренең тормыш шартларын яхшыртуны һәм буш вакытын тагын да мәгънәлерәк итүне үз өстенә алачак. Хәзер салынып ята торган 10 нчы һәм 11 нче микрорайоннарга карасаң, шәһәр өченче кат яңара дип әйтәсе килә. Яңа корылышларыбызга Мәскәү, Казан һәм Алабуганың үз белгечләре зур әһәмият бирәләр. Аларның яңа төзелешне шәһәрнең тарихи казанышларын истә тотып алып барырга омтылулары һәркемне шатландыра. Төзелештәге яңалыклар борынгы шәһәрне заманчалаштыруда матур бер адым булачак. Алабуга бернечә мәртәбә зураячак, яшәрәчәк. Бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек иттереп салынган архитектура ансамбльләре, иркен парклар, тын бакчалар — барысы да шәһәр һәм районыбыз кешеләренең тормышын тагын да күркәмрәк итәчәк.

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

Әхмәт Рәшитов

# ШИГЫРЬ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬ

## Урап кайтыйк әле үткәннәрдән...

Белла Әхмәдуллинаның «Аргументы и факты» газетасына (30 сан, 1987 ел) биргән бер интервьюсы һич кенә дә хәтердән чыкмый — ул мине ачы һәм ачык хакыйкате белән сискәнергә мәҗбүр иткән иде. Атаклы шагыйрә, үзенең әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәте хакында сөйләп, тәнкыйтьчеләр Маяковскийны башта үтерделәр, аннан пьедесталга күтәрделәр, дигән фикер әйтә. Шуны укыдым да уйлана калдым, бөтен әдәбият тарихын күз алдыннан кичергәндәй булдым. Бу сүзләр дөреслектән ерак йөрмиләр икән ләбаса! Хәтта без тәнкыйть эталоны дип йөрткән В. Г. Белинский да, А. С. Пушкин өстендә кара болытлар куерган иң авыр вакытта аның таланты саега башлау турында сүз куертып, бөек шагыйрьнең йөрәгенә яра салудан тартынмаган. Соңрак чорда С. Есенин, А. Ахматова, Б. Пастернак, А. Твардовский кебек шагыйрьләрнең фаҗигале язмышларында да иң шәфкатьсез хөкем карарын чыгаручылар тәнкыйтьчеләр булды.

Вульгар социологлар шәхес культы елларында күпме талантларның бугазыннан бумадылар да, нинди генә фаҗигаләргә сәбәпче булмадылар?! И бичара шигърият, сабый күңелле, саф, бәллүр күк чәлпәрәмә килергә торган үтә нәзберек шигърият! Нинди генә явыз ниятле һәм кыйбласы югалган кешеләр ул чорда сине пычрак итекләре белән кереп таптамады?! Син һаман нәрсәгәдер ышанып яшәдең. Син әле һаман борынгының бөек утописты Томаззо Кампанелланың «Киләчәктә дөнья белән шагыйрьләр идарә итәр» дигән беркатлы сүзләренә алданып яшисең!

Шагыйрьләргә яшәү бервакытта да җиңел түгел. Шөкер, шигъриятькә үтә утилитар күзлектән генә карау, һәртөрле «изм» ярлыклары тагу заманнары үтеп бара бугай. Соңгы елларда илдә барган бөек үзгәрешләр үткәнне генә түгел, бүгенгене дә яңача бәяләргә, һәммә нәрсәгә башкачарак хөкем чыгарырга чакыра. Ләкин ни хикмәттер, тәнкыйтьчеләребезнең бер өлеше бу күчеш, сыйфат үзгәреше чорында тотрыклы тигезлек саклап кала алмадылар — инерция буенча икенче чиккә ташланып, һәр әдәби күренешкә фәкать эстетларча бәя бирә башладылар. Бу, үз чиратында, кайбер шагыйрьләр иҗатын гомумән инкарь итүгә, әдәбиятта бертөслелекне алга сөрүгә, мирасыбызга битараф карауга китерде. «Утызынчы, кырыгынчы, илленче еллар поэзиясендәге торгынлык» дигән стереотип фикер бер тәнкыйть мәкаләсеннән икенчесенә күчеп йөри. Әлеге еллардагы мәгълүм шигъри казанышларга күз йому ничек мөмкин икән ул?! М. Җәлилнең «Хат ташучы»сы һәм «Моабит дәфтәрләре», Ә. Фәйзинең «Флейталар»ы, Ф. Кәримнең сугыш чоры поэмалары, С. Батталның «Олы юл буйлап» шигъри повесте, М. Садриның «Бәхет турында җыр» поэмасы, С. Хәким, Ә. Ерикәй, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов, З. Мансур һәм башкаларның җыр һәм шигырьләре бүген дә безнең рухи арсеналда түгелмени?!

Татар шигърияте, нинди генә киртәләргә юлыкса да, сәламәт көчләргә кытлык кичермәде — Тукайлар, Җәлилләр эстафетасын дәвам итүчеләр табыла торды. Ш. Маннур, С. Хәким, С. Баттал кебек шагыйрьләрнең ул чор иҗатына игътибар итегез — анда җәмгыятьтәге негатив күренешләргә каршы юнәлтелгән, якты идеал-

лар өчен көрәшне бөтен драматизмы белән ачып салган әллә никадәр ихлас шигырьләр табарсыз. Шушы илленче еллар уртасында шигърияткә Р. Гәрәй һәм И. Юзеев кебек яшь көчләр килеп кушылды. Фронт хакыйкатен шигъри иманына ялгый алган Х. Камаловның тавышы яңгырады. Озакка сузылган газаплы эзләнүләрдән соң, ниһаять, Г. Афзал да үз сукмагын тапты. Шигърияткә бәрәңге буразнасыннан атлаган Ш. Галиев өчен тавыш сынау чоры башланды. Әле ул вакыт аларның берсе дә лауреатлык дәгъва итми, фәкать өмет кенә уята иде. Еллар үтте, табышлар да, югалтулар да байтак булды. Вакыт галиҗәнап ул чор тәнкыйтьчеләренең күрәзәчелегенә байтак төзәтмәләр кертте.

Бунтарьлык, бәхәс, җәмгыятьтәге торгынлыкка карата көрәш тойгысы белән күтәрелеп килгән яңа бер буын мең төрле «ярамый!»ларга таянган тәнкыйтьнең бердәм һөҗүменә юлыкты. Ул шагыйрьләрдән авыз-борыннарын канатып Роберт Әхмәтҗанов, М. Шабаев, Ә. Баяновлар гына исән калды. Ә. Рәшитов, Р. Хисмәтуллин кебекләре, йөрәк яраларын бәйли-бәйли артта калдылар, гомум сафка соңрак килеп бастылар. Ә күпме талантлар бөтенләйгә шигырьдән читләште.

Тәнкыйть Фәйзуллиннар буыны шагыйрьләрен, юк, һич юк, кул чабып каршыламады. Ләкин бу гайрәтле егетләр, әлгәрләреннән үзгә буларак, кыю һәм бердәм, нәрсә әйтергә теләгәннәрен, нәрсәгә омтылганнарын, максатка ничек ирешергә мөмкин икәнлекләрен беләләр иде. Шуның өстәвенә алар байрак итеп күтәргән хакыйкатьне якларлык, яңача, заманча уйлый белгән тәнкыйтьчеләр дә әдәбият мәйданында кылыч уйнаталар иде инде.

Партиянең XX съезды карарлары иҗат офыкларын киңәйтеп җибәргән, әдәбиятта һәм сәнгатьтә саф җилләр исә башлаган бу чорда Н. Юзиев, Р. Мостафин, И. Ахунҗанов, Т. Галиуллин һәм башкалар тәнкыйтьче буларак формалаштылар. Алар шигъриятнең үсеш тенденцияләрен, шигырьнең асылын әлгәрләреннән ачыграк, төгәлрәк билгели алдылар. Алар әлгәрләреннән киңрәк карашлы иделәр. Бу чорда шигырь һәм тәнкыйть кулга кул тотынып үсте. Әлеге буын тәнкыйтьчеләр теге яки бу шагыйрьгә ашыгып бәя бирүдән, гомерлек ярлык ябыштырудан бигрәк, аларның ни әйтергә теләгәннәрен аңларга һәм шуны үз укучыларына аңлатырга тырыштылар. 60 нче елларның шигъри ренессансы чын мәгънәсендә әдәбият игътибарын җәлеп итәрлек күренеш иде.

Яшь поэзия хәтта С. Хәким һәм Н. Арслан кебек өлкән шагыйрьләр иҗатына да уңай йогынты ясый алды, бүтән жанрларда эшләүчеләрне дә күтәрелеп карарга мәҗбүр итте. Тора-бара бу көчле төркемгә Зөлфәт һәм М. Әгъләмов кебек гаять үзенчәлекле авазлар килеп кушылды. Шигърият күгендә берсеннән-берсе яктырак йолдызлар яна, ә тәнкыйтьчеләр исә уздырыша-уздырыша алар язганны шәрехли башладылар. Ләкин шигъри шартлаулар чорыннан соң поэзиянең агышы тынычланасы һәм салмакланасы, билгеле бер эзгә төшәсе көн кебек ачык иде. Кайсыдыр бер мизгелдә тәнкыйтьчеләр, миңа калса, әнә шул мөһим факторны, ниндидер нюансларны исәпкә алып бетермәделәр, үсеш диалектикасын аңлап җиткермәделәр шикелле. Төрле тәнкыйтьчеләрнең төрле мәкаләләрендә иерархия баскычын хәтерләткән монолит исемлекләр барлыкка килде. Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан... Болары — аксакалларыбыз иде. Икенче исемлеккә Ш. Галиев, И. Юзеев, Г. Афзал, Р. Гәрәй кертелде. Шигърияткә шаулап-гөрләп бер вакытта килеп кергән яшьләрдән дә нәкъ чеховтагыча ранглар табеле төзелде — Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Г. Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Мингалим, Р. Харис... Хәтта ике кешелек исемлектә дә субординация саклауны кирәк таптылар — башта Зөлфәт, ә аннан соң гына — М. Әгъләмов. Бу исемлекләр ясалма булса да, теге яки бу шагыйрьнең күпмедер вакыт аралыгында шигърияткә керткән шәхси өлешен исәпкә алмаса да, егерме елга якын бер мәкаләдән икенчесенә күчеп йөрде. Кызык хәл: язучылар съездындагы һәм әдәби ел йомгакларына багышланган докладларда сүз Туфаныбыздан башланып, рәттән саный-саный М. Әгъләмовка кадәр килеп җитә иде. Бу чорда заманга, кешеләргә иң кирәкле һәм иң үтемле сүзне кайсы буын вәкиле әйткән, укучылар кайсы шагыйрьне күбрәк укыйлар?— бу кадәресенә игътибар ителми иде. Исемлекләр китап һәм журнал битләрендә яши бирде, ә тормыш үзенекен итте: ул шагыйрьләрнең кайберләрен бөтенсоюз һәм хәтта дөнья аренасына чыгарды, икенчеләрен хәтта әлеге исемлекләргә кермәгән башка шагыйрьләр белән алыштырды.

Күрәсең, Р. Мостафин тәкъдим иткән «шигъри дулкыннар» теориясе дә шигъри чынбарлыктагы хәлне чагылдырмый, фәкать тәнкыйть игътибарыннан читтә калган башка талантларга беркадәр өлеш чыгарырга гына тырыша иде.

Җитмешенче еллар ахырында тәнкыйтьчеләр отрядына бүгенге шигъри казанышларга битараф булмаган Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Р. Кукушкин, С. Маннапов, Ф. Зөлкарнәев кебек яшьләр килеп кушылды. Дөрес, алар яңа талантлар ачмадылар, алтмышынчы еллардагы кебек шау-шуларга юлыкмадылар, ә тыныч кына өлкән иптәшләренең эстафетасын дәвам иттеләр. Яхшысы да, яманы да алар арсеналына

күчте. Җитмешенче, сиксәненче еллардагы җәмгыятебездәге торгынлык чоры шигырь тәнкыйтендә абайлана башлаган негатив күренешләрне тирәнәйтте генә. Төче мактаулар, дан өләшүләр гадәти хәлгә әверелде. Азмы-күпме дәрәҗәле урын биләгән һәр шагыйрь, классик ук булмаса да, атаклы һәм күренекле дип игълан ителде. Ул елларда орденнарны да, мактаулы исемнәрне дә кызганмадылар. Шушы обстановкада тәнкыйтьчеләребез эстетик ориентирны да югалта башладылар. Кайбер шагыйрьләрнең һәр язганына «даһи» мөһере сугылып барылды. С. Хәким, Ш. Галиев, И. Юзеев кебек һичшиксез зур талантка ия шагыйрьләр гомумән тәнкыйтьтән өстен шәхесләргә әверелде. Шул ук вакытта бик күп шагыйрьләрнең иҗаты игътибардан читтә калдырылды яки алар адресына дорфа, тупас, дәлилсез бәяләр әйтелде.

Шуңа күрә КПСС Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть турындагы мәгълүм карары шигърияттәге сәламәт көчләр тарафыннан канәгатьләнү хисе белән каршыланды. Ләкин аны тормышка ашыру өчен әле күп эшләр башкарасы бар иде. Күнегелгән штамплардан, стереотип бәяләрдән баш тарту бу үзгәреш заманында да җиңел түгел шул.

## Ә шулай да... нәрсә соң ул шигырь?..

Бүгенге татар шигъриятенең тамырлары тирәндә, ябалдашлары күк. Ул меңнәрчә еллык тормыш тәҗрибәсен дә, ничәмә-ничә идеологияләр йогынтысын да, кешелек тарихында һәркайсы билгеле бер эз калдырган халыкларның культура мирасын да үзенә сеңдергән. Анда Шәрык белән Гареп очрашкан, фаҗига белән тантана кушылган, салкын акыл белән кайнар йөрәк уртак тел тапкан.

Ә шулай да... нәрсә соң ул шигырь?

«Шигырь — кеше җанының теле»,— ди Н. Юзиев һәм шагыйрьне хикмәт иясе, тылсымлы сүз остасы дип атый. (Н. Юзиев. «Шигырь гармониясе», 3 бит).

«Шигърият — кеше күңеленең иң иркен, иң ирекле, иң кешелекле һәм иң матур яшәеше ул...» Бусы — тәнкыйтьче М. Вәлиев фикере. «Күңелнең көткәне» дигән мәкаләләр җыентыгында моңа тагын: «Чын шигърият, чын сәнгать — ул үзәккә үтәрдәй моң икән! Бүтән берни дә түгел, әсәрдә бөек, олы, тирән бер моң яшәве кирәк икән!!» дип өсти. Сүз дә юк, матур әйтелгән. Шапырынкы, чәчәкле-чуклы, үтә абстракт булса да, хаклык та юк түгел сыман.

Алайса фәнгә сүз биреп карыйк соң! «Зур Совет Энциклопедиясе»нең 24 томында менә нәрсә язылган: «Стих (от греч.— ряд, строка) — художественная речь, фонически расчлененная на относительно короткие отрезки (каждый из них так же наз. С.), к-рые воспринимаются как сопоставимые и соизмеримые. Членение на стихи обычно отмечается графическим оформлением текста (печатание отд. строчками) и часто сопровождается рифмой и др. фоническими признаками. Средством подчеркнуть сопоставимость и соизмеримость стихов является метр — чередование внутри стихи сильных и слабых мест: но он может и отсутствовать (в чисто тонич., свободным стихе и пр.)».

Бу билгеләмә исә шигырьнең күбрәк техник ягына, шигырь архитектурасына игътибар итә, аның эмоциональлек, экспрессия кебек сыйфатларын бөтенләй телгә алмый. Әмма без бу билгеләмә белән дә санашмый булдыра алмыйбыз — чөнки ул шигъриятнең теоретик асылын нигездә төгәл чагылдыра.

Шигырьнең вазифалары күп булган кебек, жанрлары-исемнәре дә бик күп төрле. Гимн, ода, җыр, кантата, оратория, поэма, эпос, дастан, баллада, мәсәл, декламация, эпиграмма, сонет, касыйдә, газәл, бәет, танка, эпитафия... Кыскасы, тормышның һәр очрагы өчен шигырь арсеналында кирәкле сүз бар. Кызганычка каршы, тәнкыйтьчеләребез бу ачык хакыйкатьне еш кына онытып җибәрәләр, үзләренең күзәтүләрендә, тикшерүләрендә, рецензияләрендә ниндидер үзенчәлеге анык булмаган абстракт «шигырь» дигән төшенчә белән эш итәләр. Халбуки, бездә аерым жанрларда аеруча уңышка ирешкән шагыйрьләр бар. Ләкин Ә. Исхак мәсәлләре, М. Хөсәен сонетлары, М. Әгъләмов балладалары, К. Мостафин эпиграммалары турында авыз тутырып кайсы тәнкыйтьче саллы сүз әйтте соң?!

Равил Фәйзуллинның «Арсланнар көтү булып йөрми» дигән шаян сүзе искә төшә. Теге яки бу шагыйрьнең иҗатын тикшергәндә, безнең хөрмәтле тәнкыйтьчеләребез нәкъ менә аларның әдәби портретын билгеләрдәй үзенчәлеген онытып җибәрәләр, аларга көтүдәге арыслан итеп карыйлар. Ә андый үзенчәлекләр тел-сурәтләү чараларының бай арсеналыннан ничек һәм ни күләмдә файдалануга килеп бәйләнә, теге яки бу шагыйрьнең поэтикасына барып ялгана.

«Поэтика» сүзе безнең тәнкыйтьчеләребез хезмәтләрендә гомумән сирәк кунак. Кызганычка каршы, хәтта безнең бөек Тукаебызның поэтикасы да тиешенчә эшләнмә-

гән әле. Югыйсә үрнәк алырдай, өлге булырдай тикшеренүләр дә юк түгел. Борынгы төрки әдәбият белгече И. В. Стеблева тугандаш халыкларның уртак хәзинәсе саналган руник язма истәлекләргә — Күлтәгин һәм Тоньюкук язмаларына, Мәхмүт әл-Кашгариның «Диване лөгатет-төрк»ендәге шигъри текстларга сюжет-композиция җәһәтеннән булсын, аваз-ритмика җәһәтеннән булсын шактый җентекле анализ ясаган иде. Үзебезнең хәятта бу темага Х. Госман, Н. Юзиев, Х. Курбатов, Ф. Сафиуллина һәм башкаларның җитди хезмәтләре билгеле. Әмма җанлы әдәби процессны бүген актив эшләүче шагыйрьләрнең иҗатын тикшергәндә, безнең тәнкыйтьчеләребез әдәбият белемендә кабул ителгән универсаль критерийларны бөтенләй санга сукмыйлар, яңа билгеләмәләр, яңа терминнар уйлап чыгарып, шулар тирәсендә сүз куерталар. Ә баксаң, сурәтләү чаралары арсеналы бетмәс-төкәнмәс икән ләбаса! Берәүләр авазлар яңгырашын, йөгерек ритмиканы кулай күрә, икенчеләр эчке рифмаларны уйната, өченчеләр фикерен тирән ассоциацияләр аша әйтеп бирә, дүртенчеләр чагыштыруларны катлы-катлы итеп төрә, бишенчеләренең шигъри бизәкләре, гадилеге, халык җырларындагыча табигыйлеге белән отышлы була. Ләкин теге яки бу шигырьдән өзек умырып алып (әйтерсең, тәнкыйтьчеләр шигырьнең бер бөтен организм икәнен аңламыйлар!), аның астына «әлеге юллардагы ватанпәрвәрлек пафосы да шагыйрьнең бөтен иҗатына хас күренеш» (Р. Мөхәммәдиев «Әгәр без янмасак», 10 бит) яки «Менә бу юлларны укып чыкканнан соң, китапны беренче мәртәбә кулга алган укучыны күз алдына китерик. Ул аннан нинди яңа хис, яңа фикер, яңа кичереш алды? Юк бит!» (М. Вәлиевның «Казан утлары» журналында 8 сан 1987 ел — басылган мәкаләсеннән, 167 бит) кебек дәлилсез раслаулар, риторик эндәшләр генә әсәргә чын бәя була алмый шул. Шигырьне тәнкыйтьләүче кеше жанрның бөтен нечкәлекләрен тоеп конкрет әсәрне поэтика критерийлары белән үлчәп хөкем чыгарырга тиеш. «Ошый-ошамый» үлчәүләре хөкем өчен аргумент була алмый. Әйтик, В. Хлебников, Б. Пастернак кебек шагыйрьләр иҗаты хакында бүгенгәчә бәхәсләшәләр, әмма аларның шагыйрьлекләрен беркем дә инкарь итә алмый.

Шигърият хакында язучы тәнкыйтьчеләр бездә ул кадәр күп түгел. Бу мөһим эшне нигездә шагыйрьләр үзләре башкаралар. Озак еллар буе әдәби процесска Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан кебек өлкәннәребез юнәлеш биреп килде. Хәзер исә көндәлек матбугатта шагыйрьләр иҗаты турындагы фикерләр белән Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Ә. Баянов, З. Мансуров, Р. Миңнуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Гәрәй, Ә. Габиди мәкаләләре аша танышабыз. Шунысы гыйбрәтле, бу мәкаләләр, дәлилле, нечкә сиземләү, төгәл күзәтү белән бергә, шагыйрьләргә карата хөрмәт саклап, хәерхаһлык рухында язылганнар. Шуңа күрә алардагы ачы тәнкыйтьне дә шифалы дару итеп йотасың, киңәш-теләкләрне барыбер мыегыңа урап барасың.

## Бүгенге шигырь... ул чыннан да начармы?

Соңгы елларда шигырьгә игътибар кимү, шигырь китапларының тиражлары азаю турында бик еш яза башладылар. Тәнкыйтьче Р. Мостафинның Татарстан китап нәшрияты баш редакторы В. Нуруллин белән әңгәмәсе дә нигездә шушы мәсьәләгә багышланган. Нәширләр борчыла, тәнкыйтьчеләр чаң суга, тик нишләптер шагыйрьләр генә тыныч... Бәлки шагыйрьләр мәсьәләгә философлар биеклегеннән карый торганнардыр, кем белә?!

Шулай шаян сүз белән генә котылып булса, ни әйтер идең дә бит. Ләкин проблема тирән, сәбәпләре буталчык һәм катлаулы. Дөресен генә әйткәндә, аны тикшергәндә, үзебезнең татар мохиты белән генә чикләнмичә, еракларак китеп барырга кирәк.

Игътибар итегез әле: бөтен дөнья күләмендә нindидер бер сәер процесс бара. Сәнгатьнең кабул ителгән, инде канунлашкан критерийларын, бөек шәхесләрнең авторитетлы бәяләрен санга сукмыйча, халыкның мәгълүм өлеше Бетховеннарны, Шопеннарны, Дебюссиларны түгел, без үзәкләр өзелеп тыңлаган халык моңнарын түгел, нindидер рок һәм «хеви металл» корольләрен күтәрә, һәртөрле модернистик конструкцияләрне, маймыл пычраткан киндерләрне Ренессансның бөек рәссамнары ясаган шедеврлардан артыграк күрә. Абстракция, мәгънәсезлек, хаос гармонияне, камиллекне аренадан куып төшерергә тырыша. Егерменче гасыр, тарихка байтак кына рухи хәзинә васыять итсә дә, ул нигездә металл заманы, фәнни-техник революция заманы булып кала. Бу чор кешенең рухыннан, хисеннән бигрәк, аның прагматик акылына мөрәҗәгать итте. Сәнгать әсәрләренең тематикасы да якындагы һәм ерактагы реаль бурычлар белән билгеләнде. Кайбер язучылар, композиторлар, рәссамнар, кино, театр, концерт оешмалары эшлекләре үз иҗатларын тоташ үзгәреп торган политик коньюнктура белән бәйләделәр. Кулны күкрәккә куеп әйткән чакта, безнең

гасыр әдәбияты һәм сәнгате Эйнштейн, Циолковский, Попов кебек галимнәр дәрәҗәсенә торырдай шәхесләр бирмәде. Карашлар романнарга һәм шигъри юлларга түгел, информация белән болай да шыплап тутырылган башны ял иттерердәй, уйламыйча да аңлашыла торган массовый культура атрибутларына текәлде, кеше экран һәм магнитофон колына әверелде, рухи кыйммәтләрне матди байлыкларга алыштырды.

Бәс, шулай булгач, матур әдәбиятка игътибар киму, шигырь китапларының тиражы азая бару тенденциясе бик табигый күренеш. Һиндстанда булуым вакытында мин бу хакта һинд язучыларыннан да сорашкан идем. Шигырь китапларының тиражы мең данәдән артмый, диделәр. Франциядә ул шулай ук 600-700 тирәсе генә. Мондый мәгълүматларны көндәлек матбугаттан әледән-әле укый торабыз.

Укучыны шигырьдән читләштергән сәбәпләрнең берсе — андый китапларның полиграфик яктан шапшак эшләнүе, макулатурага гына яраклы түбән сортлы кәгазьдә басылып чыгуы. Әгәр шигырьләр яхшы кәгазьгә һәркайсы аерым-аерым иркен итеп урнаштырылса, зәвык белән ясалган миниатюралар һәм гравюралар белән бизәлсә, тышлыгы ук күңелне тартып торса, мәсьәлә бүгенгечә кискен төс алмас иде.

Моның белән мин безнең шигърияттә барысы да ал да гөл дигән фикер үткәрергә җыенмыйм. Проблемалар байтак, эчне пошырган нәрсәләр адым саен, телне тотлыктырып, кулны бәйләп торган факторлар бар. Әмма бүгенге татар поэзиясе тулаем алганда абруйлы, бөтен союз һәм дөнья аренасына чыгардай дәрәҗәдә. Балтик буе республикалары, Татарстан, Башкортстан, Дагстан шагыйрьләре турында күренекле тәнкыйтьчеләрнең гомуми фикере һәрвакыт уңай булды һәм хәзер дә шулай булып кала. Ә нишләп соң алайса безнең шигърият казанышлары турында чаң сукмыйбыз, үтә тыйнак булып, як-яктан ишетелгән мактауларга авыз бөреп кенә елмаябыз? Сорауны шагыйрьләргә түгел, тәнкыйтьчеләргә адресларга кирәктер. Ачыктан-ачык сөйләшү заманы — әйдә, тел яшереп маташмыйк, фактларга мөрәҗәгать итик. Хәсән Туфанның бөек шагыйрь булуына беркем дә шикләнми торгандыр. Ләкин аны, дөнья күләмендә димим, илебез күләмендә тиешле дәрәҗәдә beләләрме соң? Бу бөек иҗатны еракка кем ишеттерергә тиеш? Тәнкыйтьчеләр. «Литературная газета», «Литературная Россия», «Литературное обозрение», «Литературная учеба», «Вопросы литературы» һәм башка бик күп басмаларда нишләп татар тәнкыйтьчеләренең тавышы ишетелми соң?!

Безнең Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим кебек шагыйрьләребез Советлар Союзының иң абруйлы журналларында һәм нәшриятларында гына түгел, чит илләрдә дә актив басылалар. Ә тәнкыйтьчеләр күрмиләр, югары трибуналарга чыгып тавышларын ишеттермиләр. Шагыйрьләребез иҗаты күләгәдә калырлык түгел югыйсә. Тәнкыйть даирәсенең тарлыгы, мөһим мәсьәләләрне икенчел, өченчел дәрәҗәдәгеләрдән аера алмау, жанр интересларыннан өстен булмау «әдәбият хөкемдарларын»тар кирталәргә кертеп бикли.

Бүген актив иҗат итүче урта буын шагыйрьләребез рус Н. Костров, белорус Рыгор
Бородулин, грузин Хута Берулава, украин Павло Мовчан, үзбәк Абдулла Арипов,
литвалы Ю. Марцинкявичюс, казах Олжас Сөләйманов кебек киң танылган шагыйрь-
ләр белән чагыштырып карагыз. Хәлебез йөз кызартырлык булмас. Соңгы егерме-
утыз ел эчендә туган һәм вакыт сынавын узган зур күләмле әсәрләрне генә санап
үтик — беркемне дә рәнҗетмәс өчен авторларын алфавит тәртибендә тезик: Ә. Бая-
нов — «Сез аңларсыз мине», Ә. Давыдов — «Йокысыз төннән соң», Зөлфәт — «Ти-
мерче турында баллада», «Йөрәкләрдә — үлмәс дастан», З. Мансуров — «Кылдан
нечкә, кылычтан үткен», Р. Мингалим — «Иртәгә», «Ике авыл арасы», Г. Рәхим —
«Каһәрләнгән мәхәббәт», Ә. Рәшитов — «Минем шәҗәрәм», «Иптәш коммунист»,
Р. Фәйзуллин — «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн», «Сәйдәш», Р. Харис — «Мулла-
нур», «Рәссам», «Ант суы», С. Хәким — «Васыятьләр», «Кырыгынчы бүлмә», М. Ша-
баев — «Җирән Конрад», И. Юзеев — «Язылмаган поэма», «Мәхәббәт китабы»,
М. Әгъләмов — «Онытма, Европа», «Тукайдан хатлар», Роберт Әхмәтҗанов — Таш
еллады», «Фидаи», Рәшит Әхмәтҗанов — «Биш таш» һ. б. һ. б. Болары әле истә кал-
ганнары, телгә кергәннәре. Шигырь һәм җыр жанрында теләсә кемгә бил биргесез
Н. Арслан, Г. Афзал, Ш. Галиев, Р. Гатауллин, Ә. Исхак, Р. Зәйдуллин, Р. Миңнуллин,
Г. Моратов, Ф. Сафин, К. Сибгатуллин кебек талантларны да санасак, картина тагын
да тулырак булыр.

Вакытында кадерен белмәдек — ни аяныч! Саҗидә апабыз Сөләйманова исеме
Ю. Друнина, Зөлфия, Р. Ахматова, Т. Җумакулова исемнәре белән рәттән аталырга
тиеш иде бит! Инде исәннәрен рәнҗетмик — К. Булатова, Ф. Гыйззәтуллина, Н. Из-
майлова, Г. Зәйнашева, Л. Шакирҗанова, Э. Шәрифуллина кебек кызларыбыз ир-
егетләр белән ярыша-ярыша шигъри мәйдан тота.

Шигъри сарайларны уптым илаһи җимерү һәм шуның өстендә тәнкыйть париен

биетү авыр эш түгел, ә менә булганның кадерен белеп, талантларның чәчәк атуы өчен шифалы яңгырлар сибәләү, ялгыш иҗади адымнардан саклау, һәр шигъри җан өчен борчылып тору шактый читен. Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, тәнкыйтьчеләр ахырын-азагын уйламыйча шигырь атлы, бәллүр кебек ватылырга торган үтә нәзберек организм янәшәсендә алай таяк болгамасыннар иде. Чүлмәкче нәрсә эшләмәс! «Казан утлары» журналының 8 нче санында (1987 ел) басылган «Шигъри бушлык» дигән мәкаләне күздә тотып әйтүем.

Инде кат-кат икърар иткәнемчә, бүгенге татар шигърияте хаталардан хали түгел, юк, һич түгел. Профессиональ осталык тел-теш тидермәслек булса да (иншаллаһ, язарга өйрәндек!), тема ярлылыгы, тарихи һәм географик тарлык, иҗади куркаклык, ай-һай, үзен сиздерә әле. Татар тәнкыйтенең еллар буе читтән генә бармак янап торуы, һәр иҗатчы йөрәгенә кереп оялаганы «бусы ярый — бусы ярамый» дип мөһер сугып утырган рухи цензор кайчагында әйтергә теләгәнеңне дә әйттерми шул!

Нишләп бездә Е. Евтушенконың «Мама и нейтронная бомба», «Фуку!» поэмалары кебек, А. Вознесенский, Р. Рождественский шигырьләре кебек кыю әсәрләр юк, дип шауларга яратабыз, дөнья киңлекләренә чыга алмыйбыз, дип зарланабыз. Ә нишләп иҗат ителгәнен «курорт шигыре», «турист шигыре» дип игълан итеп, шагыйрьләрне белгән нәрсәләр турында гына язарга өндәп, Арча һәм Минзәлә кысаларына куып кертергә тырышабыз. Без ниндидер шигъри провинциализм шартларында яшәдек. Татар халкы югыйсә гомер-гомергә илгизәр, гомер-гомергә интернациональ рухлы халык: ул, руслар белән бергә Парижга бәреп кереп, «Рус-француз бәете»н язган, әллә кайда, җир читенә барып, «Порт-Артур»ны җырлап йөргән, аның моңына «Шамшәриф», «Ашхабад», «Уфа», «Чиләбе», тагын әллә нинди ерактагы географик атамалар кушылган. Шагыйрьләребез хәзер ерак сәфәрләргә дә чыгалар һәм, табигый, чит мәмләкәтләрдән әйбәт-әйбәт шигырьләр дә алып кайта башладылар. Көтик әле, матур нәтиҗәләре булмый калмас.

Шигырь гамьнән башлана, дөньяны үзгәртергә, төзәтергә теләүдән, борчылу-уйланулардан, күңел газапларыннан башлана. Шигырь язу — үзе үк газап, йөрәкләрне җәрәхәтли торган, гадәти яшәешеңнән әллә нинди утларга алып ташлаучы авыру халәт. Бәлки кайчагында күкрәктә кайнаган хисләрне тулысынча кәгазь битенә төшереп бетеп тә булмыйдыр, осталык, талант җитенкерәмидер. Анысы икенче мәсьәлә. Шигырь язу — үзе үк батырлык. Аңарда да йөрәк бер генә, аңа да гомер бер генә бирелгән. Шуңа күрә, һәр шагыйрь алдында башлар иярлек.

Без катлаулы, каршылыклы заманда яшибез. Җир йөзендә бүген ни генә юк. Ерак планеталарга юл алган космик кораблар һәм кешеләр матдәнең иң вак кисәкчекләрен синхрофазотрон мичләрендә яндырып тапкан бихисап куәт-энергия. Ген инженериясе һәм уйлаучы машиналар. Бу акыллылыктан акылдан язарга мөмкин. Шул ук вакытта ачка тилмерүче сабыйлар һәм дөнья буйлап СПИД хәшәрәтен таратып йөрүче фахишәләр, күзләре тонган, миләре түнгән наркоманнар, кансызлык, ерткычлык, туган иленнән мәхрүм ителгән халыклар, баш өстендә Домокл кылычы булып асылынып торган бөтендөнья сугышы куркынычы, батырлык, кыюлык, ихласлылык янәшәсендә ялган, хыянәт, вак җанлылык... Менә шундый заманда шагыйрь булып кара да, көн саен туып торган меңләгән сорауларга җавап табып кара! Күңелне төшенкелек упкынына ташлаучы күренешләргә адым саен юлыгып тор да, кешеләрне я яшәү мәгънәсен татырга чакырып кара, матур киләчәк белән кызыктырып кара. Рияланырга кирәкми, шагыйрьләргә яшәү җиңел түгел. Алар, күктән сөрелгән пәйгамбәрләр кебек, кешеләр бәхете өчен яшәеш сахраларында хакыйкать эзләп йөриләр.

# ШИГЫРЬ БЕЛӘН УЙНАМЫЙК

Нәрсә соң ул — чын шигърият? Бу сорауга беркайчан да төгәл җавап табылмас, һәм табылмасын да иде. Шигърият ул гүзәл, серле хатын-кыз шикелле — серенә төшенүгә, кызыгы бетәчәк. Ләкин, мәңгелек сер, аңлата алмаслык могҗиза булса да, аны танырга һәм аның белән тәэсирләшләшырга мөмкин...

Бер уйласаң, бөтен тормышны шигырь көче белән камилләштерү өчен чиксез мөмкинлекләр бар шагыйрьләр кулында. Бар алар, бар мәңгелек остазлар булырлык шәхесләр. Кешене, табигатьне, вакыт-ара төшенчәләрен, искитәрлек итеп, берничәшәр юллык шигъри табышлар белән бәйли белгән Р. Тагор. Мәхәббәт һәм гаделлек җырчысы Р. Бернс. Моңсу да, гамьсез дә Г. Хәйям. «Шүрәле» кебек шигъри симфонияләр яза белгән Тукай. «Мокамай», «Мәхәббәт тәүбәсе» кебек драматик соналалар калдырган Такташ. Башын чапкан балтадан чәчрәгән кан тамчылары кебек тетрәтерлек җырлар калдырган Җәлил...

Инде бүгенге көнгә килик. Монда хәлләр башкачарак.

Мәсәлән, Әмир Мәхмүдовның 1987 елда дөнья күргән «Мәңгелек моң» җыентыгында төрле шәхесләргә багышланган шигырьләр арасында «Биш Казан комиссары турында баллада»га кергән монологлар бер-берсеннән әллә ни аерылып тормыйлар. Мөһим тарихи темага хәзерлексез, саксыз, илһамсыз кагылып, гомумән, кемгәдер (бигрәк тә танылган шәхесләргә) багышлап шигырь язганда, иҗатчы үз өстенә икеләтә зур җаваплылык ала. Җиңелчә генә аккан әңгәмәдә кемнедер сүз уңаеннан гына искә алган, матур, ләкин буш һәм илһамсыз сүзләр тезмәсе безнең шигъриятә адым саен очрый.

Менә Нур Әхмәдиевнең быелтыр чыккан «Ак бишегем» җыентыгындагы «Нарком Цурюпа» дип исемләнгән шигырен алыйк. Бүгенге көндәге кайбер тискәре күренешләр белән чагыштырганда күңелләрне сызлатырлык, тетрәтерлек поэмалар язарлык исем ул Цурюпа... Ә шигырьдә ничегрәк ачылган соң бу тема?

*Революция,*
*Революция!*
*Бу сүзгә күпме*
*Мәгънә сыя.*

Әлеге юллардан ук күренеп тора — могҗиза, тетрәнү булмаячак. Сизенүебез безне алдамый:

*Нарком да кеше —*
*Килә яшисе.*
*Нарком да кеше —*
*Килә ашыйсы!*

Шигырь шушы югарылыкта бара һәм менә кульминация, югары драматизм:

*Саклап калырбыз*
*Башкала халкын...*
*Башы әйләнеп*
*Егыла нарком...*

Мәктәп укучылары осталыгы дәрәҗәсендә язылган бу тезмә катлаулы, кырыс чор һәм фидакарь шәхесләр турында нинди тәэсир калдырырга тиеш? Алга таба, җир язмышы турындагы фәлсәфи уйлануларга корылган озын шигырендә дә автор, юл йөргәндә безнең «шәһит булган батырларның йөрәгенә», «... чибәрләренең күзләренә» баса-баса үтүебезне искәртә. Ярый, «безнең өчен гомерләрен биргән батырлар алдында һәр адымыбыз өчен җаваплы» дигән фикер әйтелергә тиеш булса, бу юлларны аңларга булыр иде әле. Ләкин әлеге юлларны турыдан-туры, ничек язылган шулай аңларга кирәк булып чыга, чөнки:

*Корбаннарның саны*
*Чыпчыктан да күп ләбаса.*

Йомшак кына итеп әйткәндә, сәер фикерләү. Әйе, шигърият белән уйнап алырга яратабыз без!

Рөстәм Мингалим — катлаулы һәм күпмедер дәрәҗәдә «элитар» шагыйрь. Ва-

кыты белән балкып та ала торган һәм тәнкыйтьчеләрнең, укучыларның зуррак игътибарына лаек шагыйрь. Менә аның яңа китабыннан («Шигырьләр һәм поэмалар», 1987 ел) «Коегыздан су алдык» шигыре. Гади генә бер күренеш — су алганнан соң хатын-кызның коены каплавын күреп, сиздерми генә, безнең игътибарыбызга көчләп такмыйча гына, шагыйрь шушы гади күренештән глобаль гомумиләштерүгә күчә:

*Коелар өстен япсак,*
*елгалар өсте ачык.*
*... Диңгезләр өсте ачык.*
*океаннар өсте ачык.*

Кечкенә генә шигырьгә экология дә, халыкара хәл дә сыйган. Китапта уйландырырлык мондый табышлар аз түгел. Ләкин, дөресен әйткәндә, мондый рәвеш, беренче карашка, игътибарны җәлеп итми. Ә икенче тапкыр борылып караучылар бик аздыр. Без, кайвакыт шигырьләрне «акыл белән» язсә «хис белән» язылган, дип бәялибез. Һәм гадәти булмаган әйберләрне аңларга, кабул итәргә ашкынып тормыйбыз. Р. Мингалим, минемчә, күбрәк яшертен аң (подсознание) белән сюрреалистик шигырьләр яза. Кайвакыт ул максатына ирешә, ә кайвакыт, сәнгатьтә күнегелгән аңлашу принципларыннан артык ерак китә.

*Яңа чишмә килеп сезне таш дип белсә,*
*еламаган Ил икәнне Кояш таныр.*

Мондый ребусларның киң катлам укучыларга тәэсирен күз алдына китерү кыен. Берничә тапкыр укып чыккач, шигырьнең ниндидер серенә дә төшенәсең кебек. Тик бу инде ачышка әйләнми, таныш күренешләрне артык кыландырып сөйләүгә генә кайтып кала, дүртпочмаклы көпчәк кебек, тигез урында сикертә. Юк, мондый эзләнүләргә һич тә каршы килергә ярамый, юкса сәнгать үсеше туктап калачак. Әмма, мондый эзләнүләр белән иҗат итү тәнкыйтьтән азат булу дигән сүз түгел. Шулай ук бүгенге көндә барыбызга да диярлек хас булган күпсүзлелек тә Р. Мингалим иҗатын көпшәкләндерә.

Кызганыч, әдәби тәнкыйтебез җитди анализ ясап, шигъри бушлык күренешен вакытында аңлатып бирә алмады. Мондый игътибарсызлыкның шигърияткә зыяны зур. Эш яклаучылар белән гаепләүчеләр бәхәсенә генә әйләнеп калмаска тиеш.

Бер карасаң, шигырьне «чишендерү» бәлки кирәкмидер дә. Теләсә нинди матур йортны сүтсәң, ташлар, кирпечләр генә кала бит. Ләкин бу чагыштыру чын шигырьләр өчен генә урынлы. Аларны сүтеп карауның хаҗәте юк, алар болай да «әйбәт эшлиләр». Ә начар, төссез шигырьләрнең эчендә ни җитмәгәнлеген тикшереп карау гөнаһ булмас. Тик үпкәләшүләрсез, укучылар белән киңәшеп, актив сөйләшү, бәхәс кирәк.

**Рәниф ШӘРИПОВ.**

# ТӘКЪДИМНӘРЕМ БАР...

Журналның быелгы беренче санында Рафаэль Мостафин белән Вакыйф Нуруллинның «Заман һәм шигырь» дигән баш астында чыккан әңгәмәсен укыгач та хат язып салырга булдым.

Р. Мостафин Татарстан китап нәшриятының баш редакторы В. Нуруллинга бик принципиаль сораулар куя. Сорауларның берсенә җавап буларак әйтелгән «өстән шалтырату» мәсьәләсе... Нәшрият аларны сылтау итеп алмасын, бастыру эшенә, барыбер, нәшрият җаваплы булып кала бит!

Шундый сорау туа: әсәр «өстән шалтыраткан» өчен басылганди, ә ул «өстән шалтыратучы» әдәбиятны ни дәрәҗәдә белә? Мин бер тәкъдим кертергә батырчылык итәм: редакция әнә шул «өстән шалтыратучылар»дан рецензия таләп итүне законга кертеп куйсын. Ул чакта ачыктан-ачык була.

Икенче тәкъдим: китапның тиражын билгеләүче махсус комиссия төзелсен иде. Ул комиссия эченә сәүдәгәрләр түгел, күренекле әдәбият белгечләре, фидакарь тәнкыйтьчеләр керсен. Бу комиссия киң җәмәгатьчелеккә (матбугат аша) отчет белән чыга торган булсын: «без фәлән тираж дип билгеләгән китап фәләнчә сатылып бетте» дип. Ә сәүдә хезмәткәрләре тираж билгеләү белән түгел, ә үз эшләре белән шөгыльләнеп, аларга ярдәм итеп торсыннар.

Китап кибетләрендә филологик белеме булган кешеләр эшләми, алар кайсы китапның күпме сатыласын алдан белә алмый. Әнә шул тираж дөрес билгеләнмәгән аркасында бит инде... Мансур Вәлиевнең прозасын ни Казан, ни Чаллы китап кибетләреннән таба алмадым. Үзебезнең Альберт Сафинның «Күз карашы»н кешедән алып торып кына уку бәхетенә ирештем. Роберт Миңнуллинның балалар өчен шигырьләрен табар хәл юк. М. Мәһдиев, М. Юныс, Ә. Еникиләр чыгуга таралып та бетә. Ә китапларның кайсыларыдыр сатылмый ята, имеш.

Тираж билгеләү эшен әдәбият-сәнгатьне әйбәт белгән һәм җаваплы караган кешеләр башкарса, китап белән спекуляция дә булмас, дәүләткә дә кереме күп булыр иде. Әнә, бер Америка язучысы безнең илдә сорау күп булган китапларның «уртакул»лар белән бер үк тиражда басылганын ишеткәч: «Нәрсә, сездә акча басарга кәгазь юкмыни?!» — дип гаҗәпләнгән, ди.

Өченче тәкъдим: Язучылар оешмасы, нәшрият һәм культура министрлыгы китап сәүдәсе хезмәткәрләре белән тыгыз бәйләнештә торсын иде. Сәүдә начальникларының китап сату буенча отчетларын тыңлауны алар үз планнарына кертеп куйсыннар иде. Нихәтле җитешсезлек бит шул китап сәүдәсендә!.. Шушындый укымышлы заманда, укымышлы илдә!.. Вак-төякләрдән әйтик, бәләкәй авыл кибетләрендә китап сату эше оештырылмаган урыннар күп. Сәүдә җитәкчеләренең гаять дәрәҗәдә ваемсызлыгы бу.

Аннары: китап кибетләре алдагы елларга планга кергән матур әдәбият исемлеге белән тәэмин ителгәнме? Шул планнарны яктырткан брошюралар җитәрлек дәрәҗәдә кайтмаган икән, мәсьәләне ничек хәл итәргә? Алар вак-төяк авыл кибетләренә кәтле таратылса, бу эшне нәшрият үз өстенә ахыргача алса ничек булыр?


Әлегә болай эшләнми. Шулай була торып, тиражны сәүдә хезмәткәрләре билгели икән — бу инде ... җавапсызлыкның теге ягына чыгып киткән хәл.

Нәшриятның тематик планнары килеп җиткән сәүдә оешмалары да агитация белән шөгыльләнеп мәшәкатьләнми бит әле. Минем үзебезнең Чаллыдагы «Глобус» кибетенә кереп, шундый планнарны еларга җитешер дәрәҗәдә сорап торганым бар... Кабат-кабат сорап, әрсезләнә торгач кына алып карый алдым шуларның кайберләрен.

Кыскасы, «Казан утлары» журналында күтәрелгән мәсьәлә бик җитди. Һәм идеологик яктан, һәм материаль, һәм әхлакый-әдәп ягыннан. Әдәбият һәм нәшрият эшен үзгәртеп коруга йөз тоткан әңгәмә-бәхәс бик күптән хәл ителергә тиешле бу эшләрне тизрәк тормышка ашырырга булышса иде, дигән теләкләрдә калам.

**Равия АБДУЛЛИНА,**
Алабуга педагогия институты

## Уфада культурабыз истәлекләре



**«Хәсәния» мәдрәсәсе урнашкан бина**

*А. Тимергалина рәсеме.*

# «ХӘСӘНИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

1903 елның көзендә, кадимчеләр һәрбер яңалыкка, хосусән, заман рухындагы, азмы-күпме үзгәрешләр кертелгән мәктәпләргә аяк терәп каршы торган вакытта, Уфаның хәзерге Нуриман һәм Лесопильная урамнары чатында, татар җәмәгатьчелегеннән җыелган акчага салынган ике катлы бинада, Мөхәммәтсабир хәлфә Хәсәнов тарафыннан, шәһәрдә мөселманнар өчен икенче уку йорты — «Хәсәния» мәдрәсәсе ачыла. Беренчесе — 1887 елда Хәйрулла Госманов нигезләгән «Госмания».

Мөхәммәтсабир әл-Хәсәни 1865 елда Самара губернасы Богырыслан өязе авылларының берсендә ярлы крестьян Мөхәммәтҗан гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне туган якларында ала, соңыннан Троицкига килеп, «Мәдрәсәи Рәсүлия»дә (1884 елда ачылган) Хәлил хәлфә Зәйнидә укый, шунда ук берничә ел мөгаллимлек кыла.

Ул гарәпчә, төрекчә яхшы белгән. Шәкерт вакытыннан ук казах арасында зур абруй казанган. Дәүләкән мәктәпләренең берсендә рус теленнән имтихан тотканлыгы, белем даирәсенең киңлегендә укытучыларның исе киткәнлеге мәгълүм. Дөнья әдәбияты һәм Европа педагогикасы нигезләре белән җитди кызыксынган.

Бөек Октябрь социалистик революциясе көннәрендә М. Хәсәнов большевикларга теләктәшлек күрсәткән. Күренекле татар язучысы, галиме Р. Фәхретдинев 1924 елның 13 апрелендә якын дусты, каләмдәше, «Идел» газетасының нашире һәм баш мөхәррире Г. Гомәровка язган хатында: «Уфада Сабир әл-Хәсәни, берәр ай кадәр вакыт авырып йөреп, дөньядан күчте вә 29 шәгъбан... дәфен ителде... Бер биргән кызыннан башкалары яшьләр вә уку берлә мәшгульләр иде. Дөньясы да бик иркен түгел иде...» — ди.

М. Хәсәнов, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң, үз мәдрәсәсендә укыту оештыру тәртибе ягыннан берникадәр үзгәрешләр керткән: иҗекләп уку методы аваз ысулы белән алмаштырыла, уку башы һәм азагы билгеләнә, дәресләп укыту, дәресләр арасында тәнәфес ясау, укуны тәмамлагач имтиханнар үткәрү гамәлгә ашырыла. Мәдрәсәнең аскы катында ике сыйныфтан торган 4 еллык башлангыч мәктәп урнашкан. Өске катта — өч сыйныфлы, 3 еллык урта мәктәп, шунда ук шәкертләр торагы һәм Сабир хәлфә үзе сабак биргән «дәресханә» бүлмәсе. 1905-1907 еллар революциясе вакытында «Хәсәния» мәдрәсәсе халык тарафыннан киң танылабашлый. Белем бирү күләме буенча да «Хәсәния»дә берникадәр үзгәрешләр ясала: схоластика бераз йомшартыла, татар теле укытыла, дөньяви фәннәр (хисап, география, тарих, анатомия һ. б.) өйрәнелә башлый.

Мәдрәсә халыктан алынган керемнәр исәбенә яши (химая итүчеләре Фазлулла һәм Әхиярулла сәүдәгәрләр), чөнки патша хөкүмәте татар мәдрәсәсенә бер генә тиен белән дә ярдәм итми.

Столыпин реакциясе елларында күп кенә мәктәпләр һәм мәдрәсәләр эше өстеннән яшерен күзәтүләр оештырыла, укытучыларны мәдрәсә бинасыннан чыгармыйча, тентүләр үткәрелә. Тентү нәтиҗәсендә бик күп хатлар, китаплар һәм дәреслекләр җыеп алынып, мәдрәсәләр ябыла, яңа ысул белән укытучыларны җәберләү-рәнҗетүләр башлана. Милли мәктәп-мәдрәсәләрне чикләү, кысулар чорында да «Хәсәния» мөгаллимнәре туган телне, дингә бәйләнеше булмаган бүтән фәннәр укытуны дәвам иттерәләр.

«Хәсәния»не тәмамлап, халкыбызның мәдәнияте һәм мәгарифе тарихында сизелерлек хезмәт күрсәткән шәхесләр арасында Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәкый ага Исәнбәт, «Хәсәния»дән соң «Галия» мәдрәсәсендә һәм Казан дәүләт университетында тәрбияләнеп, Уфа югары уку йортларында эшләгән өлкән педагог-галим Мәгъдән ага Мәһәдиев (аңа хәзер 93 яшь), мәктәп укытучылары, совет, партия эшлеклеләре бар.

«Хәсәния» мәдрәсәсе 1920 елның маенда Мөхәммәтсабир Хәсәнов һәм башка мөгаллимнәр тарафыннан Уфа шәһәр халык мәгарифе бүлеге карамагына тапшырыла. Монда берничә ел татар башлангыч мәктәбе эшли. Ул 1923 елда ябылып, бинасында татар китапханәсе оештырыла. Хәзер биредә шәһәрнең Ленин районындагы 5 китапханәсе урнашкан. Димәк, халыкка мәгърифәт бирү традицияләре дәвам итә.

*Р. Үтәбаев тексты.*

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әхмәт Сәхапов

# ТЕРЕ ХӘТЕР

„Я безнең әсир төшкән офицерны азат итәсең, я без синең әтиеңне кылыч белән тураклыйбыз...»

Шамил Рәкыйповның «Ак канатлы хатирәләр» исемле әдәби-документаль романында кызыл полкның яшь командиры Василий Гордовка дошман әнә шундый әчтәлекле ультиматум җибәрә. Акгвардиячеләрнең таләбен кызыл командир кискен рәвештә кире кага. Үз әтисенең гомере бәрабәренә булса да, Василий Гордов ак армиянең күренекле офицерын азат итми. Бу эпизодның күңелгә тәэсир көче, романның беренче китабында китерелгән гаять бай фактик материалга караганда да зуррак. Чөнки, Ш. Рәкыйпов үз героен һәм ул яшәгән чорның психологиясен ачу чарасын эзләгәндә, сәнгать дөреслегенә таянган. Әсәрдә без Гражданнар сугышы тарихына багышланган махсус әдәбият һәм фәнни-тикшеренүләр аша укучыга инде мәгълүм булган, яки язучының үз эзләнүләре нәтиҗәсе буларак табылган яңа фактлар белән очрашкач, ул кадәр зур тойгы кичермибез. Бары сәнгать дөреслегенең фактик дөреслектән, тормыш дөреслегеннән тагын бер тапкыр зуррак, олырак булуына гына ышана барабыз.

Матур әдәбиятның әдәби-документаль жанры әле тулысынча өйрәнелмәгән өлкә. Аның жанр табигате дә, үзенчәлеге дә, формалары да бигүк ачыкланып бетмәгән. Синтетик жанрда иҗат итү Ш. Рәкыйповка да җиңел түгел, билгеле. Хәтта фактик материал рөхсәт иткән дәрәҗәдәге иҗади уйланма да кайбер югалтулардан коткарып бетерә алмый. Иҗаттагы ике мөстәкыйль алымның берсе яки икенчесе өстенлеккә дәгъвалаган чакларда, бу хәлнең табигый нәтиҗәсе буларак, әсәрнең композицион төзелеше һәм формасы да әлеге йогынтыны үзендә сизә башлый. Әдәби-документаль романның беренче китабында мондый өстенлек фактик төгәллеккә бирелгән. Шул ук вакытта, романның күп геройлы булуы, язучыга аларны югары камиллеккә җиткереп сурәтләргә дә комачаулый төсле. Нәтиҗәдә, йөз чалымнарын һәм индивидуаль сыйфатларын югалткан кайбер төссез образлар туа... Ләкин тәҗрибәле язучы буларак, Ш. Рәкыйпов синтетик жанр кысаларының йөгерек фантазиягә тышау салуын сизми калмаган. Бу «чикләү» Василий Гордовның рухи дөньясын тасвирлаганда күренә, күңел хәрәкәтенең юнәлешен күзәткәндә сизелә. Тик күңелдә «бу геройлар язучы алдан сызып куйган схема буенча яшәмиләрме соң» дигән борчулы уй туарга өлгерми, язучы Гордовны әнә шулай авыр сынау мизгеленә куя. В. Гордов бу сынауны уңышлы уза. Үзен чын революция солдаты, партиягә ихлас бирелгән кеше итеп таныта, шуны сугыш кырында батырлык күрсәтеп тә дәлилли.

Әлеге романында гына түгел, гомумән, элегрәк иҗат иткән башка әсәрләрендә дә автор геройлары кылган гамәлнең төсен билгеләү өчен менә шундый «лакмус кәгазьләрен» әдәби чара буларак уңышлы файдалана белә. Барлык әсәрләрендә дә диярлек, аның геройлары яшәү белән үлем мәсьәләсе хәл ителгән мизгелдә сыналалар. Бу сынауның нигезендә яшәешнең шушы ике чиге арасында барган мәңгелек көрәш-тартыш ята. Геройларның әхлак көче шушы арада тирбәлә. Кайсы өстен чыгар? Хәлиткеч минутта нинди юл сайланыр?

Ш. Рәкыйпов авыр ситуациядә калып, яшәү белән үлемнең берсен сайларга тиеш булган кешенең эчке дөньясына үтәргә омтылыш ясаганда, әнә шундый мөһим әхлакый-социаль проблемага юлыга.

Ш. Рәкыйпов геройлары хәл кылырга тиеш булган бу четерекле мәсьәлә бүгенге көн өчен дә әһәмиятле. Сугыш михнәт-газаплары белән кино-әдәбият аша гына таныш булган укучыны күп нәрсәгә өйрәтә аның әсәрләре. Әйтик, халкыбызның күмәк батырлыгы һәм рухи ныклыгы сыналган Чернобыль трагедиясе генә дә җөйләнә башлаган

күңел ярабызны нык авырттырып алды. Ә шуңа охшаш экстремаль ситуацияләр даими туып торган сугыш кырында исә ул көчлерәк сизелә. Ике чикнең берсен сайлау еш кына кешенең асылын ачып сала.

Сугышның һәр кеше бәгыренә тирән үтеп кергән, бернинди бизмән белән дә үлчәп булмаган әрнү-авырту тойгысын һәм аның вәхши йөзен Ш. Рәкыйпов «Ак канатлы хатирәләр» романының икенче китабында ачарга омтыла. Гражданнар сугышында актив катнашканнан соң югары хәрби белем алган һәм зур бәрелешләргә командалык иткән Василий Гордовның гыйбрәтле язмышын үзәккә алып, автор киң фронт панорамасын, ерым алганда, икенче бөтендөнья сугышының борылыш этабы булган Сталинград бәрелешен тасвирларга ниятли. Яу кырында гаскәрләр белән уңышлы командалык итүе һәм шәхси батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган генерал-полковник чинындагы югары дәрәҗәле бу хәрби офицер якташыбызның (ул Минзәлә районында туган) сугышчан юлы махсус хәрби әдәбиятта да яктыртылган. Әмма Ш. Рәкыйпов мемуар һәм хәрби әдәбият аша укучыга инде мәгълүм булган бай фактик материалны икенче китапка «дыңгычлап» тутырырга уйламый. Ул хәрби таланты ил азатлыгы өчен көрәш чорында ачылган крестьян улының күңел дөньясына юл эзли.

Бөек Җиңүнең очраклы бер күренеш түгеллеген идеалыбыз куәтенә, иманыбыз ныклыгына бәйләп аңлата, сәламәт идеологиябездән көч алган зарурият икәнлеген геройлар язмышы аша дәлилли.

Игътибар итик: «Чәчәкләр сөйли белә» һәм «Кайдан син, Жан?» повестьлары дөнья күргәч Барый Шәвәлиев белән Иван Кабушкинның батырлыгы алдында кем генә таң калмады икән? Алар гүзәл Ватаныбыз өчен гомерләрен кызганмыйча, күңелләребезне кузгаттылар, язмышны җиңә алуның матур үрнәген бирделәр.

«Чәчәкләр сөйли белә» повестеның язылу тарихы кызыклы. Фашистик Германияне тар-мар итүнең егерме еллыгы алдыннан СССР Кораллы Көчләренең Үзәк музеен карап йөргәндә Шамил Рәкыйпов көтмәгәндә тәмам саргаеп беткән бер листовкага юлыга. Анда кече сержант Барый Шәвәлиевның рядовой Александр Матросов каһарманлыгын кабатлавы хакында язылган була. Ул батыр якташы белән кызыксынып китә һәм аның турында материал туплый башлый. Архив документлары, истәлекләргә таянып, шушы повестен иҗат итә.

Повесть эчке монолог рәвешендә үзенчәлекле алым белән язылган. Барый Шәвәлиевның балачагы, ул туып-үскән авыл, аның табигате ифрат җылы тасвирланган. Язучы Барый үскән тирәлекне сурәтләүгә дә зур игътибар бирә. Аның характеры формалаша бару, кыйбласы ачыклану процессы да күренә. Тыйнак халкыбызның күркәм гадәтләре, матур йоласы, бай мәдәнияте нигезендә тәрбияләнгән Барыйның рухи җитлегү чоры сугыш вакытына туры килә. Өлкәннәрдән алга узып йөрмәгән, үзенә талапчан бу сабыр егетне командиры Ильченко башкаларга үрнәк итеп куя, аны сугышчан тәртипнең өлгесе дип саный. Хәлиткеч минутта да югалып калмый Барый. Һөҗүм итүче гаскәрләр өстенә үлем уты яудырган фашист пулеметын күкрәге белән каплап, полкташларына сугышчан бурычны үтәргә булыша. Әлбәттә, тормышны өзелеп сөйгән Барый Шәвәлиев күңелендә дә Ватан алдындагы изге бурыч белән яшисе килү теләге аз тартышмагандыр. Кеше, нинди генә ситуациядә калса да, иң элек аны үз ихтыярына буйсындырырга омтылган табигый инстинкт — үз-үзен саклау хисе белән бәрелешергә мәҗбүр. Барый Шәвәлиев кебек намуслы, үзәкләре нык кешеләр бу сынауда ялгышмыйлар. Легендар партизан разведчигы Иван Кабушкин кебек («Кайдан син, Жан?») гестапо тырнагында да кешелек сыйфатларын югалтмыйлар.

Ш. Рәкыйпов Барый Шәвәлиев белән Иван Кабушкинның үлем белән күзгә-күз очрашкандагы халәтен, эчке кичерешләрен тасвирлауга зур әһәмият бирә. Бары шул мәлдә генә аларның яшәү белән үлем арасында тирбәлгән рухи халәтен аңларга мөмкин. Батырлыкның күзне камаштыргыч тышкы бизәкләрен тасвирлау белән мавыкмыйча, геройларның ныклыгын чик ситуациядә күзәтү Ш. Рәкыйповка каһарманлыкның тирәндә яткан рухи нигезенә күз салырга һәм шул рәвешчә, фашизмны җиңүнең иҗтимагый-тарихи һәм социаль-әхлакый тамырларын ачарга мөмкинлек бирә. Бу принципның язучы иҗатында ни дәрәҗәдә чагылуын алда күреп узган идек инде. Автор үзәк образларны гына түгел, эпизод геройларын иҗат иткәндә дә шул алымга таяна.

Мәсәлән, «Кайдан син, Жан?» повестенда эпизод герое рәвешендә генә чагылып киткән майор Кадерматов образын гына искә төшерик. Героик асылы балакай гына бер эпизодта кинәт ачылып киткән бу образның тәрбияви көче зур.

...Гестапо җәзалавына түзә алмаган бераү майор Кадерматов отряды хәрәкәт иткән урынны күрсәтә. Фашистлар шундагы авыл халкын майданга җыялар да, партизаннарга ультиматум куялар: әгәр билгеле бер вакытка кадәр коралсызланмасалар, картлар һәм бала-чагалар атып үтереләчәк. Шулай итеп, алар сак астына алынган авыл халкы алдында патриотларның абруен төшерергә ниятлиләр. Янәсе, сез аларга булышасыз, а үзегез авыр хәлдә калгач, партизаннар сезнең язмышка төкереп тә бирмиләр. Бу

«политик акция» барып чыккан тәкъдирдә, фашистлар халыкны партизаннарга каршы кую өчен үтемле «пропаганда коралы» алачаклар. Һәм моны партизаннар хәрәкәтен көчсезләндерү өчен дә кулланулары бик ихтимал.

Майор Кадерматов фашистлар акциясенең төбендә зур мәкер-провокация ятуына тиз төшенә. Ул җәзачылар уйларына да китерә алмаганны эшли — үз ирке белән дошман кулына бирелә.

«Ул чыкты, эре-эре атлап, өй ышыгыннан чыкты. Бүреген салды һәм парад кабул иткәндәгечә көчле, көр тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Тимәгез гаепсез халыкка, мин — Кудров!

Унбишләп солдат башын горур тотып, тиз басып килгән майорга ташланды... Аның кулларын артка каерып бәйләделәр һәм чанага өстерәделәр».

Әнә шулай, гомерен корбан итеп булса да, ул йөзләрчә кешене үлемнән йола, партизаннарның халык алдында йөз аклыгын һәм абруен саклап кала. Сугыш чорының кырыс кагыйдәләре күзлегеннән чыгып караганда, батыр командирның бу гамәле акланмаса да, тәпкәрәк төшеп фикер йөрткәндә, аның зуррак, олырак батырлык — коралдашларын гына түгел, илбасарларны да шаккатырган рухи батырлык күрсәтүен аңларбыз.

Кешелек тарихы гасырлар буе туплап килгән рухи кыйммәтләрне һәм югары әхлак белән тыгыз үрелгән асылны саклап калу өчен Барый Шәвәлиев, Иван Кабушкин, майор Кадерматов кебек, күрәләтә үлемгә барган каһарманнар кылган гамәлнең кешелекле асылын сәнгатьчә яктыртуда илебез әдәбияты шиксез уңышларга ирешә. Ә бит корал көче ярдәмендә кылынган каһарманлык табигый дип саналганда, кеше күңелендә ясалган батырлыкны төрлечә кабул итүчеләр дә юк түгел. Хәтта партизан Вафин да командиры майор Кадерматов адымын аклап бетерми кебек. Ә Василь Быковның «Круглянск күпере» повестенда Бритвин дигән партизан исә, коралдашы Маслаковның үзен яшереп яткырган кешеләрне коткару өчен дошман кулына үз ихтыяры белән бирелгән яралы комбриг хакындагы хикәясен тыңлагач, ачы ирония белән «шәфкатьле комбриг» дип куя. Шул рәвешчә, сугышның икенче, тагын да куркынычрак йөзе — адәм балаларының тәнен юк итү белән генә канәгатьләнмичә, җаннарын да үтерергә омтылган имәнеч асылы ачыла башлый. Сугыш фронт сызыгы аша гына түгел, бәлки кеше күңелен дә икегә ярып үтә.

Шулай итеп, адәм балаларының җанында урнашкан «стратегик биеклекләрне», «тактик плацдармнар»ны яулап алу өчен дә кискен һөҗүм операцияләре бара.

Бөек Ватан сугышында капма-каршы позициядә торган ике көчле системаның матди куәте белән хәрби техникасы гына бәрелешмәде, бәлки идеологияләренең көче дә гамәлдә сыналды. Ә бит фашист идеологлары «балчык аякларга ябышкан башак иле» дип мәсхәрәләгән Ватаныбызда шәхси хуҗалыкларны күмәкләштерүдән риза булмаган крестьяннар восстаниесе кабынып, йөздән артык милләт һәм халык яшәгән илдә төрле диндәге кешеләр арасында үзара канлы суеш башланып, Сталинның шәхес культыннан хәлсезләнгән дәүләтебез эчтән таркалып, җимерелеп төшәр дип ышанганнар, шуңа өметләнгәннәр иде.

Фашизмның кан белән сугарылган идеологиясен кире кагып, уртак Ватан бәйсезлеген яклап кулларына корал алган төрле милләт вәкилләренең какшамас дуслыгы язучының «Таңнар һаман матурмы?» повестенда ачылды. Ул татар егете Гыйльфан Батыршин белән украин улы Иван Чернопятко образлары аша бер түбә астында яшәүче халыкларның рухи бердәмлеген, бу дуслыкка көч өстәп торган идеалыбызның гуманлы асылын сурәтләде. Әсәр безгә каһарманлыкның табигый нигезен аңларга ярдәм итә.

Интернациональ дуслыкның янә бер сокландыргыч үрнәге язучының «Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» дигән ике китаплы әсәрендә дә сурәтләнә. Составы белән хатын-кызлардан гына торган Кызыл Байрак орденлы төнге бомбардировщиклар полкы очучылары хакында әдәби-документаль әсәр язу Шамил Рәкыйповка җиңел булмагандыр, билгеле. Аңа авиация полкының шанлы юлын дөрес яктырту белән бергә, хатын-кызларның сугыш шартларындагы рухи халәтен төгәл күрсәтү бурычын да хәл итәргә туры килгән. Кыю һөҗүмнәре белән дошманга һәм аның сугыш техникасына сизелерлек зыян китергәне өчен гитлерчылар «төнге убырлар» дип атаган хатын-кыз очучыларның күңел дөньясына үтеп керергә омтылганда, автор кайбер югалтулар кичерсә дә, аларның экстремаль ситуациядәге халәтен тасвирлаганда шиксез уңышка ирешкән. Дилогиянең үзәгендә халкыбызның батыр кызлары Мәгубә Сыртланова белән Ольга Санфирова образлары торса да, язучының игътибары аларның төрле милләттән булган көрәштәшләрен дә читтә калдырмый. Рус, украин, татар, белорус, казах, удмурт һәм башка милләт кызларының бердәм гаиләдәй дус яшәүләрен һәм көрәшүләрен ача. Кызлар кырыс сугыш шартларында да нәфис сыйфатларын, нечкә тойгыларын югалтмаска тырышалар. Баш очларында үлем фәрештәсе уйнап торганда да киләчәкнең матур хыяллары белән җылынып яшиләр.

Кешелеккә дошман булган фашизмның вәхшилеген ачу һәм аның ялчыларын гаепләү пафосы язучының «Батырлар үлмиләр», «Геройлар эзеннән», «Мәңге сакларга», «Аяз күктә карлыгачлар» исемле җыентыкларында да үстерелә төште. Әлеге китапларга тупланган очеркларда язучы ил азатлыгын яклап көрәш кырында башын салган батырлар хакында яза, халкыбызның күмәк батырлыгын яктыртырга омтыла, каһарманлыкның асылын совет солдаты күңеленнән эзләвен дәвам итә, Бөек Җиңүнең тарихи әһәмиятен яшь буынга аңлатырга тырыша. Бу очракларда ассоциатив образлар һәм катлаулы әдәби-психологик детальләр сизелми, алар җиңел һәм мавыгып укыла. Бу әсәрләр, авыр сугыш чынбарлыгын романтик буяулар белән җиңелчә бизәп эшләнгән гади беллетристика түгелме соң дигән фикер дә уята. Шуңа нигез дә бар төсле: кайбер очракларда, геройның батырлык күрсәтүе шундый җиңел, әкияттәгечә гади сурәтләнә ки, хәтта аның олы каһарманлык эшләвенә күңел дә ышанмый башлый. Бары очерк ахырында китерелгән бүләкләү турындагы рәсми кәгазьләр ярдәмендә генә геройның шундый кыю гамәленә дәлилләр табасың. Икенче төрле очеркларда үлем белән күзгә-күз калган солдатның күңел дөньясын сугыш ыгы-зыгылары, пуляләр сызгыруы, снарядлар ярылуы, бомбалар шартлавы күмеп китә. Андый чакларда ирексездән Илья Эренбург, Константин Симонов, Габдрахман Әпсәләмовларның сугыш чоры очеркларындагы психологик тирәнлекне, масштаблылыкны, реалистик романтизмны сагына башлыйсың. Әдәби иҗатта очрый торган кайбер кимчелекләргә нигезләнеп, кемдер Шамил Рәкыйповның шундый рухта язылган очеркларын чирәм җирне сука белән ертып барганда сузылып калган тигезсез буразналарга тиңләгән иде. Әмма, хикмәт бит чирәм җирне эшкәртүдә генә дә түгел әле! Бөек Ватан сугышы тарихында әле шактый булган «ак таплар»ны бетерү кебек савaплы эшкә курыкмыйча тотынуда, «батырлыкның документаль елъязмасын» язуга алынуда. Әлбәттә, Шамил Рәкыйпов үз әсәрләрендә Алесь Адамович кебек әдипләр иҗатында чагылганча глобаль масштабтагы проблемаларны күтәрми, тыйнаграк максатларга омтыла. Аларны чишү юлларын эзләгәндә дә очерк жанрының традицион алымнарыннан ерак китми. Шуңа күрәдер инде, ул очеркларда еш кына тормыш дөреслеге нәфасәт дөреслеген кысып чыгара һәм сугыштагы кеше кылган гамәлгә юнәлеш бирүче, аны хәрәкәтләндерүче көч герой күңелендә түгел, бәлки тирәлеккә бәйле дигән уйга җирлек тә бирә. Ләкин, язучының «Аяз күктә карлыгачлар» дигән очерклар һәм әдәби-документаль хикәяләр тупланмасы белән танышып чыккач, анда батырлык темасының башка җыентыкларга караганда уңышлырак яктыртылуын күрербез. Очеркларда күтәрелгән кайбер проблемаларның бүгенге көн өчен дә актуальлеген сизәрбез. Мәсәлән, «Комбат истәлеге» исемле очеркта сөекле командиры Федор Баталовның якты истәлеген тузан кундырмыйча саклаучы Максимычның яраткан комбаты хакындагы матур хатирәсе лирик чигенешләр, автор авазлары белән өзелгәләп ала. Бу — әсәрнең кимчелекле ягы түгел. Бәлки композицион төзелешнең язучы үзе тапкан үзенчәлекле бер формасы. Автор лирик чигенешләр ясап, җан сызлатып торган мәсьәләне — билгесез солдат каберләрен карау мәсьәләсен дә калку итеп куя. Әрнеп сыкранган, күңел коррозиясеннән качарга өндәгән язучы-гражданин авазы безне дә дулкынландыра, уйландыра.

Иҗтимагый тормышыбызда сиземләнә башлаган әлеге күренешнең хәтәр ягы шунда: кайбер яшьләр героик үткәнебезне оныта, үзләренең битараф гамәлләре белән ямьле тормышыбызның олы бәясен төшерә. Дуамал һәм чибәр Роза кебек җилбәзәкләрне кылган эшләре хакында җитди уйланырга мәҗбүр иткән Файзулла ага белән илебез куәтенә хилафлык китермәсен өчен Максимыч сыман тырышучы тынгысыз кешеләр белән танышабыз. Хезмәтләре өчен Ватаннан бурыч түләтергә омтылган Дагъва Вәлиев кебек бәндәләрнең дә гыйбрәтле язмышы безне рухи сукырлык турында кисәтә. «Сөенчегә — алтын сәгать!» дигән бер эзләнүнең тарихы әнә шундый мөһим әхлак мәсьәләләрен күтәрүе белән дә әһәмиятле. Эзләнүнең нигезендә Дагъва Вәлиев атлы бер ветеранның язмышы ята. Сугышның бөтен дәһшатен солдат башы белән татый ул. Яралана, әсир төшә, лагерьдан кача, яңадан кулына корал алып сафка баса. Сугыштан исән әйләнеп кайта, таза хуҗалык корып җибәрә. Барысы да җитә, тик бер үпкәсе генә бар: аның хезмәтен һәм батырлыгын илебез тиешенчә бәяләмәгән икән.

«Иярләгән атлар» драматик повесте да актуаль проблемалар күтәрүе белән заман таләбенә күпмедер дәрәҗәдә җавап бирә диярга мөмкин. Драматик киеренкелеккә ирешеп, кайбер гомумиләштерүләргә омтылган, форма үзгәлеге һәм фикере агынлы исәп тоткан, кайбер гомумиләштерүләргә омтылган, форма үзгәлеге һәм фикере агышына карап нан чыгып караганда да әсәр синтетик жанрның мөмкинлекләре файдасына сөйли. Драматик повесть, сугышның ачы сабаклары белән исәпләшмичә, аны яңадан дөрләтергә маташучыларның бүгенге көндә дә булуын искәртеп чаң суга. Кызганычка каршы, дөнья әле дә тыныч түгел. Җир шарының төрле почмакларында һаман сугыш авазлары ишетелгәләп куя, янәү тавышлары яңгырый. Бүгенге көндә, җир һәм кешелек язмышы өстендә атом коралыдай зур афәт эленеп торган бер заманда, тынычлыкны саклау һәм ныгыту эше һәркемнең изге бурычына әйләнде.

Хәрби темага, бигрәк тә Ватанны яклау темасына язылган әсәрләр кешелекнең тере хәтере сыман, булып узган зур афәтнең аяныч нәтиҗәләре хакында адәм балаларының исләренә гел төшереп торалар, илләр һәм халыклар арасындагы дуслыкны ныгытырга өндиләр.

Менә шундый игелекле миссияне үтәүгә сизелерлек өлеш керткән Шамил Рәкыйпов әсәрләре илебездә яшәүче кайбер халыклар теленә тәрҗемә ителде. Танылган тәрҗемәчеләр ярдәмендә аның иҗаты белән Бөтенсоюз укучысы да таныша алды. Әсәрләре кибет киштәләрендә озак ятмаган бу язучының иҗатына карап тигез түгел. Бераүләр аны сәләтле язучы дип саныйлар, шундый авыр эшкә алынырга теләсә кемнең хәленнән килми дип исәплиләр. Икенчеләре исә, иҗади уңышка ирешү серен Ш. Рәкыйповның тырышлыгына һәм тапкырлыгына бәйләп аңлаталар. Әмма аның иҗаты хакында фикер йөртүчеләр язучының күңелләрне тетрәтерлек язмышлы кешеләр хакында тәэсирле итеп, башкаларны да тирән дулкынландырырлык итеп язу мөмкинлеге барлыгын һич инкарь итмиләр.

РСФСР Язучылар союзы каршында эшләгән хәрби-патриотик әдәбият буенча Советның 1983 елның маенда узган җыелышында Шамил Рәкыйпов иҗаты тикшерелә. Әйтергә кирәк, бу утырышта катнашкан Юрий Лукин, Иван Черных, Анатолий Кожевников, Федор Кравченко, Флүн Мусин һәм башка әдипләр, әдәбият белгечләре язучының иҗатына төпле анализ ясаганнар, кимчелекләрен ачканнар, уңышларын да күрсәткәннәр. «Шамил Рәкыйповның бу зур хезмәте,— ди йомгаклау чыгышында философия фәннәре докторы Юрий Лукин,— авторның шәхси үзенчәлеге нәтиҗәсе генә түгел. Бу яктан мин Шамил Рәкыйповны иҗат принципларының һәм максатларының берлеге нигезендә, үзебезнең Сергей Смирновка тиңләр идем. Батырлар хәтерен мәңгеләштерү өчен алып барган эзләнүләре, шул өлкәдәге күпкырлы хезмәтләре, актив эшчәнлеге хуплауга гына түгел, бәлки ихтирам белән хөрмәт хисләренә дә лаек».

Игелекле, авыр һәм катлаулы бурычын әнә шундый фидакарьлек һәм сокландыргыч сабырлык белән үтәп, Шамил Рәкыйпов Ватан азатлыгы өчен һәлак булганнарның якты истәлеген яңа әсәрләрендә терелтүен дәвам иттерә. Меңнәрчә язмышларга ачыклык кертә, билгесез югалганнарны ил, халык алдында билгеле итә. Шуңа күрә дә язучы: «Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк. Тереләрнең җаны тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында. Ир-егетләр турында. Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы — изге»,— дип укучының хәтеренә төшерә.

# ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫН ЯКТЫРТУЧЫ ХЕЗМӘТ

**Акбиев С. Х. Связь времен и дружбы литератур. Махачкала, Дагестанское книжное издательство, 1985.**

Туганда́ш халыклар белән әдәби-культура бәйләнешләрен яктырту өлкәсендә галимнәребезнең фидакарь эш башкарулары һәркемгә билгеле. Үзәк һәм Татарстан матбугатында төрле милләт галимнәренең үзбәк, каракалпак, әзербайҗан, казах, комык, кыргыз, удмурт, мари һ. б. халыклар әдәбиятлары белән татар әдәбияты арасындагы иҗади бәйләнешләрне тасвирлаучы бик күп хезмәтләр басылып чыкты.

Комык галиме, филология фәннәре кандидаты Солтанморат Акбиев берничә дистә еллар буена Дагстан халыклары әдәбиятының татар әдәбияты белән иҗади бәйләнешен тикшерүдә игътибарга лаеклы эш башкара. Аның соңгы елларда гына да шушы мәсьәләгә багышланган күләмле мәкаләләре Татарстан матбугатында басылып чыккан иде. Ниһаять, Дагстан китап нәшриятында С. Акбиевның «Вакытлар бәйләнеше һәм әдәбиятлар дуслыгы» дигән дагстан — татар әдәби бәйләнешләренең кайбер мәсьәләләрен яктыртуга багышланган китабы рус телендә дөнья күрде.

Фактик материалларга шактый бай тугыз мәкаләне берләштергән бу хезмәтнең беренче бүлегендә дагстанлыларның һәм Идел буе татарларының культура-әдәби бәйләнешләренең үсү юллары конкрет мисаллар ярдәмендә яктыртыла. Бу бүлектә дагстан һәм татар халыкларының ерак гасырлардан үзара дуслык бәйләнешендә яшәүләре турында кызыклы мәгълүматлар бирелә. Күп кенә күренекле дагстан галимнәре Казанда белем алганнар, фән эшлеклеләре булып формалашканнар. Мәсәлән, Мирза-Али Казем-бек утыз елга якын Казанда яшәгән, гади лектордан Казан университеты профессоры булу дәрәҗәсенә кадәр үскән. Күренекле татар галиме, мәгърифәтчесе Ш. Мәрҗани дагстанлы Абдуллатип Гаджи Аварскийның галим булып формалашуына булышлык иткән. Үз нәүбәтендә татар халкының күп кенә күренекле фикер ияләре һәм шагыйрьләре Дагстан авылларында яшәгәннәр һәм иҗат иткәннәр. Мәсәлән, билгеле татар укымышлысы «Тәварихе Болгария» дигән җыентыкның авторы Таҗетдин Ялчыгол XVIII гасырның икенче яртысында Аксай дигән борынгы дагстан авылында яшәгән. XIX йөз ахырында — XX гасыр башларында Казанда Дагстан халыкларыннан комыклар һәм аварлар өчен дистәгә якын матур әдәбият әсәрләре, уку кулланмалары, фольклор җыентыклары басыла. Шул ук вакытта Дагстанда җирле авторлар белән бергә татар каләм осталарыннан З. Бигиев, Г. Камал, Ф. Бурнашларның аерым әсәрләре дөнья күрә.

Татар-комык һәм татар-нугай фольклор һәм әдәби бәйләнешләрен яктыртуга багышланган бүлекләр бай фактик материалларга нигезләнеп язылулары белән җәлеп итәләр.

С. Акбиев комык, нугай һәм татар халыклары авыз иҗатының төрле жанр әсәрләренә чагыштырма анализ ясау юлы белән төрки телдә сөйләшүче халыкларның фольклор әсәрләре гомуми генетик нигезгә корылган булуын раслый, татар фольклорында комык һәм нугай халыклары әкиятләренә тематик һәм сәнгать чаралары ягыннан охшаш әкиятләр күплеген күрсәтә. Автор бу халыклар фольклор әсәрләрендәге сюжет сызыкларының туры килүен генә түгел, ә бәлки аларда бер типтагы характерлар, тел элементлары чагылуын, һәр халыкның үзенә генә хас булган милли үзенчәлекләр тасвирлануын да ачыклый.

С. Акбиев халык авыз иҗатының башка жанрларында да (мәкальләрдә, табышмакларда һ. б.) күп уртаклыклар булуын билгеләп үтә, әдәбият, тел, фольклор буенча күптөрле гомумтөрки ядкарьләрне тудыруда бу халыклар керткән уртак өлешне күрсәтә. Г. Тукай һәм М. Курманалиев иҗаты мисалында поэтик уртаклыкның дәвам итүен раслый.

Автор хаклы: безнең халыкларның культура бәйләнеше мәгърифәтчелек хәрәкәте таралган чорда аеруча киң үсеш ала. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкилләре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов һәм К. Насыйрилар үз заманындагы Көнчыгыш һәм Европа илләренең фән һәм культура өлкәсендә ирешкән уңышларына таянып, халыкны аң-белемле итү өчен кулларыннан килгәннең барын да эшләгәннәр, тугандаш халыкларга ярдәм кулы сузганнар. Татар мәгърифәтчеләренең иҗади эшчәнлеге Урта Азия һәм Кавказ халыкларының мәдәни үсешенә дә уңай йогынты ясый.

Хезмәттә Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр Дагстан халыклары өчен матур әдәбият, уку кулланмалары бастырып чыгаруда Казан керткән өлеш шактый киң яктыртыла. Дагстан язучыларының беренче китаплары татар типографияләрендә яки татар халкының алдынгы иҗат интеллигенциясе вәкилләре ярдәмендә дөнья күрә. Мәсәлән, Дагстан шагыйремәгърифәтчесе М. Э. Османовның «Ногайские и кумыкские тексты» (1883), «Наставление» (1899) дигән китаплары Казанда басыла. Аварлар өчен «Первоначальный учебник русского языка для авар» (1898), «Учебный учебник для авар» (1898) кебек кулланмалар, нугайларның фольклор әсәрләре җыентыгы Казанда дөнья күрә. Дагстанда китап басу эше юлга салынгач, З. Бигиевның «Гүзәл кыз Хәдичә» (1912), Г. Камалның «Уйнаш» (1921), Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә» әсәрләре комык һ. б. халыклар телләрендә басылып чыга.

Көнчыгышны өйрәнүче XIX гасыр галимнәре арасында Мирза-Али Казем-бек исеме билгеле урынны алып тора. Ул тарих, филология фәннәре өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен Россия империясенең һәм Көнчыгыш Европа илләренең иң югары дәрәҗәле исемнәренә, хөкүмәт бүләкләренә лаек була. «Казем-бек Казанда» дигән бүлектә автор 40 ел гомерен Көнчыгышны өйрәнүгә багышлаган күренекле галимнең фәнни-педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеген яктырта. Фәнни әдәбиятны, бай архив материалларын җентекләп өйрәнү нигезендә язылган бу бүлек шул елларда Көнчыгышны өйрәнүгә зур өлеш керткән Казан университетының ролен шактый киң һәм тулы итеп күрсәтү ягыннан да зур әһәмияткә ия.

«Каюм Насыйров һәм Әбүсуфьян Акаев» дигән бүлектә татар һәм комык халыкларын агартуга гомерләрен багышлаган мәгърифәтче әдипләрнең фәнни эшчәнлегенә, алар арасындагы бәйләнешләргә тирән анализ ясала. Автор конкрет мисаллар нигезендә Ә. Акаевның бөек татар галиме К. Насыйрига якын булуын, аннан күп нәрсәгә өйрәнүен ачыклый. Китапта К. Насыйриның эстетик карашлары комык әдәбиятының күренекле вәкилләре Д. Шихалиев, М. Османов, М. Казанбиев, Т. Бейбулатов, Батырморзаевларга да уңай йогынты ясавы ассызыклап әйтелә.

Озак еллар Казанда яшәгән, иҗат иткән, Кәримовлар типографиясендә эшләгән комык әдибе Нухай Батырморзаев һәм татар мәгърифәтче язучылары (М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдинев, З. Һади һ. б.) арасындагы иҗади уртаклыкны тасвирлаучы бүлек тә фактик материалларга нигезләнгән булуы, анализ җентеклелеге белән аерылып тора.

Бөек татар шагыйре Г. Тукайның тугандаш төрки халыклар әдәбияты үсешендә роле гаять зур. С. Акбиев китабының бер бүлеген тәшкил иткән «Габдулла Тукай һәм комык әдәбияты» дигән мәкаләдә комык әдәбияты үсешенә Г. Тукай ясаган уңай йогынты Н. Батырморзаев, Ә. Акаев, З. Батырморзаев, А. Салаватов, А. Аджиев кебек әдипләр иҗатын яктырту мисалында күрсәтелә.

Күренекле комык революционеры, мәгърифәтче һәм нашир Сәид Габиев белән татар халкының ялкынлы улы, ленинчы-большевик Мулланур Вахитов озак еллар буена үзара якын бәйләнештә булганнар, халык арасында зур иҗтимагый эш, революцион пропаганда алып барганнар. Хезмәттә бу эчкерсез хезмәттәшлек, дуслык сәхифәләре дә чагылыш тапкан.

Тугандаш комык халкы галиме С. Акбиев тарафыннан әдәбиятлар, халыклар дуслыгын ныгытуга өлеш кертүче мондый фәнни хезмәтнең дөнья күрүе куанычлы күренеш. Әлбәттә, бу хезмәт аерым җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Мәсәлән, татар сүзләрен, китап, газета-журнал, татар язучылары исемнәрен язганда шактый гына төгәлсезлекләр җибәрелүе күзгә ташлана. С. Акбиевның «Муса Җәлил Дагстанда» дигән мәкаләсе Татарстан матбугатында 1978 елда басылып чыккан иде. Ни сәбәптәндер әлеге мәкалә китапка кертелми калган.

Дагстан-татар халыклары әдәбиятын өйрәнүне дәвам иттереп С. Акбиев тугандаш халыкларның төрле өлкәдә дуслык бәйләнешләрен үстерүгә, ныгытуга билгеле өлеш кертә.

**Фәнис ИСЛАМОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты

# МОҢ ЕЛГАСЫ

**Н. Акмалов. Учак. Шигырьләр һәм поэма. Татарстан китап нәшрияты, 1986.**

Шигъриятнең күп гасырлар буе сыналып килгән кануны бар: шагыйрь хис һәм фикер гармониясенә никадәр ирешә алса, аның иҗаты шулкадәр камилрәк була. Таш күтәрәлырдай куәтле фикер дә, кеше күңеленең иң изге, иң саф хисләре белән өретелеп үткәндә генә үз җегәрлеген ала, үтемле була.

Яшь шагыйрь Нияз Акмаловның беренче шигырь җыентыгын укыганда бу хакыйкатькә тагын бер кат инанасың. Биредә моң яши, вакыты белән күңелләрне җилкендерерлек, вакыты белән күзләрдән яшь сыгып чыгарырлык моң... Әмма төшенкелек сөременә тәрелгән моң түгел бу. Ул күп мәртәбәләр янып-туңып сыналган моң...

*Аңла, кайчак алтын тавы түгел,*
*Бер җылы моң кирәк кешегә.*

*(«Халәт»)*

Нияз Акмалов шигърияте сиксәненче еллар татар поэзиясендә вакыйга итеп каралырга хаклы шигърият. Һәм менә ни өчен. Анда инде менә ничә еллар буе көтелгән, кайбер яшь шагыйрьләр иҗатында күренеп тә калган, әмма һаман аякка баса алмаган халыкчан лирик аһәң бар. Беренче карашка лирик геройның үз күңел кичерешләрен, алай гына да түгел, үз күңел тарихын гына тәшкил иткән хис-тойгылар өермәсе торабара зур мәгънәви җегәрлек ала һәм бөтен бер гаилә, авыл, төбәк, һәм ниһаять, ил, халык язмышы, халык тарихы, халык моңы булып әверелә. Шул рәвешле, шагыйрьнең таркау булып тоелган (әмма бик тә аңлаешлы!) уй-хисләре сил ташкыны булып кузгалалар да, вакытның салкын гранит кыяларын аударып, ватып, хәтер тирәнлекләрен ачып ташлыйлар...

*Сил кузгалса, калка*
*калыкмаска,*
*Кагылмаска дигән урыннар.*
яки
*Сил кузгала йөрәк телгәләнсә,*
*Кузгала сил — җанга моң тулса...*

*(«Сил ташы»)*

Сиксәненче елларда беренче җыентыкларын чыгарып өлгергән шагыйрьләр иҗатында, талантлы очкыннар чәчрәтеп калу белән бергә, ниндидер эчке бер кискенлек, күңелне, җанны киереп ачып бетермичә, хисләрне учка җыеп калдыру гадәте күренгәләде.

Бу нәрсәдән килә соң? Иң беренче чиратта, фикер җегәрлеген, фикер төзлеген үзмаксатка әвереллдерүдән, фикри логиканы ничек тә сакларга тырышудан... Схематизм, ясалмалылык белән янәшә торучы мондый шигърият талантлы каләм астында фикернең кискенлеге, көтелмәгән ассоциацияләр бәйләме аша матур гына үрнәкләрен дә бирә аладыр. Алар укучы тарафыннан кабул да ителәдер. Әмма мондый фикер поэзиясе, укучыны үзенең интеллектуаль кысасына йолып ала да, аны шул салкын канлылыкта, фикер төзлеге тәгълиматында тәрбияли башлый. Ә моңы, шигъриятнең илаһи моңы, соңгы чиктә, көе, музыкальлеге кая?..

Икенчедән әдәбиятка килеп кергән кайбер яшь шагыйрьләр, гражданлык рухындагы поэзия тудырабыз дип, лозунг-поэзиягә, риторик шигъриятка йөз тоттылар, плакат алымнарын үзләштерә башладылар.

Нияз Акмалов шигъриятендә мин салмак сызылып ятучы моңны тойдым. Моңны да, халыкчанлыкны да бер асыл сыйфат туганлаштыра икән. Ул — эчкерсезлек. Ягъни күңелебездә ярсып туган уй-хисләр, мең газап, мең шатлык кичереп, моң булып өлгерәләр. Ул уй-хисләр чын, ихлас икән инде — алар бөтен бер илнеке, бөтен бер халыкныкы булырга да хаклы!

Елгадагы берничә катлы агым кебек, тарих та берничә катлы булып ага. Нияз шушы агымнарның иң тирәненә үтеп керә. Ул агым, беренче карашка тыныч, әмма чынында исә үтә дә ярсу Сарман елгасы кебек, ике як яры арасында бәргәләнепбәргәләнеп ага, ташый-ташый ага... Тагын да эчтәрәк, тирәндәрәк яшәгән агымнар елганы шулай ярсулы, давыллы итә икән («Кайтып була, үткәннәргә кайтып була...»). Шагыйрь фикеренчә, яшәеш, халыкның җанлы тарихы язгы күкрәү булып («Җыр елгасы»), көзге көндәге изге бер халәт булып («Халәт»), җылы учак булып («Учак»), шифалы тамчы булып («Тамчы»), яшь малайның зур мәхәббәте булып («Нәҗибә апа»), әнисенең яраткан төсе — ал төс булып («Хәтерлим күлмәк алганың») һаман кабатлана, сөенеп яисә борчылып, газапланып кабатлана.

Нияз Акмалов шигырьләрендә тарих бар, мәхәббәт бар, гражданлык мотивлары бар. Ул хәтта бер үк вакытта романтик та, реалист та. Ул ярата да, нәфрәтләнә дә, ул мәгърур эндәшә дә һәм бер үк вакытта үксеп елый да... Нияз үз шигъри фикерен махсус настроениегә, махсус фикерләү тибына гына яраклаштырып бирми. Ул моңлана, хисләнә, чын табигатендәгечә яшәп, янып яза...

Халык җырларында ничек — һәр җыр-

ны халык үзенең билгеле бер күңел халәтенә яраклаштырып сайлаган, җырлаган. Үз кайгысын, үз борчуын якисә үз шатлыгын кушып, өстәп җырлаган. Нияз шигърияте белән дә нәкъ шулай: ул да, халык җырлары кебек, укучыны иң элек үз язмышы хакында уйланырга мәҗбүр итә. Бу аның шигъриятенең халыкчанлыгы, гражданлык көче турында сөйләүче иң зур дәлил түгелмени?

Нияз Акмалов — баштанаяк моң шагыйре, дидек. Ә хис, моң күңел ярларына тулышып килгәндә, шагыйрьнең иң кадерле фикерләре, уйлары да түгелеп, чайпалып куюы бар. Нияз шигырьләрендә ничек? Ургылып килгән хисләр ташкынында аның әйтергә теләгән фикере күмелеп калмыймы? Юк икән. Шагыйрьнең уйлары төзек, нык, аңлаешлы. Аның шигыре аңлаешлы, күңелгә бата!

Шигъриятнең салкын акыл белән генә ирешеп булмый торган середер инде бу, күрәсең. Төелеп-ургылып торган хисләр, як-якка чәчелеп, җәелеп китмичә, ниндидер сихри көч белән, күзгә күренми торган ярлар белән тәртипкә салыналар... Күрәсең, шигырьне укып чыгу белән, аның кулын кулга, аягын аякка аерып карап булса — ул чын шигырь була да алмыйдыр.

Н. Акмалов иҗатындагы моң ярларын озак эзләдем. Кабат укыдым, тагын укыдым, кычкырып та, эчемнән генә, көйләп тә...

*Агардымы дөнья,*
*каралдымы —*
*Уйнап алды җанда минем яшен.*
*Тамчы тамды,*
*җил сызгырып куйды*
*Һәм сиздереп куйды:*
*мин яшим...*

Игътибар итегез: шушы беренче строфадан соң автор, үз сүзен җөпләгәндәй, яшен вакытында җил, гарасат уйнаганда гына була торган, бераз шомлырак бушанганлык, таркаулык белән бар хисен, моң агышын бушатып җибәрә. Гүя тау куенынннан бәреп чыккан чишмә аска агып төшеп китә һәм үзәнлекнең (күңелнең) барлык уйсулыкларына да кереп тула башлый. Төсләр фәлсәфәсен кеше тормышы, кеше язмышы белән бәйли-бәйли, шагыйрь шулай үзенең уй йомгагын сүтә... һәм менә — бу таркау ташкын бөтенләй чәчелеп китте инде дигәндә, шагыйрь бер сулыш белән үз тойгыларын, уйларын җыеп ала һәм аларны беренче халәтләренә кайтара:

*Агарырмы дөнья,*
*каралырмы?*
*Юа алырмы дөнья күз яшен?*
*Тамчы тамсын,*
*җил сызгырып куйсын*
*Һәм сиздереп куйсын:*
*мин яшим...*

Әсәрне тагын бер тапкыр укып карагыз: соңгы строфа беренче строфаны тулысынча кабатламый икән бит («...һәм сиздереп куйды: мин яшим» — «...Һәм сиздереп куйсын: мин яшим»). Шул рәвешле, беренче очракта тыныч кына тасвир ителгән тормыш картинасы соңгы вариантта, ныклы ышаныч, өмет, инану белән өртелеп, хыял чынлыгы булып кабул ителә.

Инде килеп «Халәт» шигырендәге беренче һәм соңгы строфаларны чагыштырып карагыз:

*Уйна миңа, уйна шушы көйне,*
*Елатырлык итеп, өздереп,*
*Җан түрендә йөргән ап-ак сагыш*
*Куйсын, әйдә,*
*үзен сиздереп...*

Һәм:

*Килә тавыш...*
*Шул чагында сагыш*
*Куя үзен, куя сиздереп.*
*Уйна миңа, уйна татар көен*
*Елатырлык итеп өздереп...*

Шушы ике яр арасында нәрсә бар, дисезме? Катлау-катлау хис, бу хис дулкыны кайтавазлар булып безнең күңелләрдә чыңлап тора.

Шагыйрьнең барлык әсәрләре дә диярлек күпнокталарга бетә. Бу — пунктуация кагыйдәләре белән шаярумы, ниндидер башка төрле һәвәслекме? Һич юк. Шагыйрь әйтмешли, әлеге «җыр, моң елгасы»ның очсыз-кырыйсыз һәм тирән булуын белдерү өчен кирәк алар. Шул ук «Тамчы тама», «Төне буе йокламаган чаклар», «Туган тел» шигырьләрен тагын да дәвам итеп була дигән сүз бу. Шагыйрь күңелендә туган уй-хис йомгагына укучы үз моңын да кушып җибәрә алсын өчен кирәк ул.

Шагыйрь үз күңелендә оешкан шигъри калыпларга ябышып ятмый. Ул каләмен төрлечә сынап карый. Үзе тапкан кадерле моң елгасын югалтмыйча, аны һич болгатмыйча сыный. «Ташны тишеп чыккан гөл» — шундый үзенчәлекле әсәрләрдән. Автор монда фикер үсешен билгеләүче ике сыйфатны янәшә куя да, моң тамчысын иң ахырдан гына сыгып чыгара...

*Яшәү — иң олы омтылыш.*
*Максатка барып чыккан —*
*Куралар да сокланалар —*
*Ташны да бәреп чыккан!*
*Бәреп чыккан,*
*бәреп чыккан...*
*Ләкин бит гарип чыккан!*
*Таш җәймәгез*
*гөлләргә...*

Шагыйрь бу моңны махсус өзеп калдыра. Ул укучы күңеленә куначак, ничә кеше бар, шулкадәр төскә кереп, шулкадәр көй чыгарып бик озак яңгырап торачак әле: таш җәймәгез гөлләргә...

Шул уңайдан Ниязга бер шелтә дә белдерәсе килә. Ул кайбер шигырьләрен моңы китермәс борын тәкъдим итә. Мәсәлән, «Хатын-кыз» әсәрендәге моң елгасының ике яры бер-берсенә шулкадәр якын торалар, хисләр ярлы, уйлар сай, ә соңгы фикер бөтенләй дә «көпшәк», ясалма булып калган.

«Март башы» белән «Никтер уйлар көйләнә...» шигырьләре дә фикер ярдәмендә бөтен әсәр булып берләшергә, оешырга тиешләр иде. Икесе дә матур өзекләр, әмма алар кадерсез булып чәчелеп яталар...

«Рәхмәт яугыры яңгырга!..», «Көзге коеш» әсәрләре дә Ниязның бөтен, үзенчәлекле моң елгасыннан чәчрәп калган тамчылар гына.

Н. Акмаловның поэмасы — «Сарман жыры» үзенең исеме белән дә, формасы белән дә шартлы әсәр. Чыннан да, шагыйрьнең җыентыгына тупланган барлык әсәрләрне дә диярлек шул исемдәге бер лирик поэма-китап итеп оештырырга булыр иде. Сарман буйларында сызылып аткан ал таң, елга ярын җылытып янучы учак, лирик геройның беренче мәхәббәтен алып калган Нәҗибә апасы, шул елгада коенып үскән Нәсим энекәше... Шул рәвешле, автор үзе моны телиме-теләмиме, елга образы аның баштагы шигырьләр тукымасына да килеп кергән. («Сил ташы», «Җыр елгасы» һ. б.).

Поэмадагы Җыр образы белән дә укучы җыентыкның беренче битләрендә үк очраша («Сизгер булсаң», «Туган тел», «Җыр елгасы», «Кар ява бөтерелеп» һ. б.). Ә менә «Төне буе йокламаган чаклар» шигыре бөтенләй дә «Сарман җыры» поэмасының ялгыш төшеп калган бүлеген хәтерләтә.

Әмма бу — һич кимчелек түгел. Киресенчә, бу — китапның уңай ягы. Автор, гүя башта моңлы шигъриятенең матур чаткыларын сибеп ала да, үз шигъриятенең бөтен булган төсен бер Салават күперенә берләштереп, ягъни мең төрле уй-хисен бер ноктага җыеп, бер тойгы, бер җыр итеп бирә.

Поэманың төзелешенә килгәндә, ул да Ниязның шигъри әсәрләренә хас композицион принципка корылган. Әсәр башындагы фикер, яңарып, баеп, көчәеп, аның ахырында кабатлана, ягъни поэманың да калкыбрак торган ике яры бар.

Бирге як (башлам):
*Ә без башлыйк*
*Һәм җырлардан башлыйк,*
*Җанга якын шушы җырлардан.*
*Халык белән бергә*
*чордан-чорга*
*Уза алган һәрбер җырга дан!*
Аргы як (ахыры):
*Язмышларда җырым*
*Киләчәккә*
*Яулык болгый зәңгәр таулардан.*
*Чордан-чорга*
*Халык белән бергә*
*Уза алган һәрбер җырга дан!..*

Лирик геройның уй-хисләр дулкыны, аргы якка барып җиткәнче, күп силләр уза, күп давыллар кичерә, чәчрәп күккә чөелә, елга төбенә төшеп кайный... Әмма аларның хәрәкәте тәртипсез дә түгел. Текстта һаман-һаман очрап торучы таныш юлларга (утраучыкларга) игътибар итегез... (...Һәрбер җырга дан!..). Менә шулар лирик геройның ярсу хисләренә таралып китәргә ирек бирми торалар.

Поэманың һәр бүлегендә «Сарман» җырының мөлаем образы үзәккә куелган, ул җыр, тарих шавына кушылып, тарихның һәр яңа баскычында үзенчә чагылып, үз гомерен яши...

*Халык һәм җыр...*
*Җирдә бер үк гомер,*
*Аерылмас тән һәм җан кебек.*
*Җыры барда — халык мәңгелек тә,*
*Халкы барда — «Сарман» мәңгелек!*

Шагыйрь иҗатының төп иҗат кредосы менә шушы юлларда. Моңнан, җырдан, туган телдән халык язмышын аерып карап булмый. Тән һәм җан берлегенә ия булган бу ике тамыр — җирдәге яшәешнең иң мөһим кан тамырлары кебек... Н. Акмалов китабы буенча ага торган төп лейтмотив шул.

Шагыйрьнең бу фәлсәфәсен сизкәнеп тыңлыйсың. Бу кан тамырларының зәгыйфьләнмәве, өзгәләнмәве өчен без нәрсә эшлибез соң? — дип уйланып тыңлыйсың.

Нияз Акмалов шигъриятенең көче әнә шунда.

**Галимҗан ГЫЙЛМАНОВ.**

# УКЫТУЧЫ, МАТБУГАТ ЭШЧЕСЕ, ЯЗУЧЫ

## ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гасырыбыз башында халкыбызның рухи яңарыш хәрәкәтенә килеп кушылган, берничә тармакта алтмыш ел буе бирелеп хезмәт иткән, халык мәгарифе, матбугат һәм әдәбиятыбыз тарихында үзенчәлекле эз калдырган Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири дә бар. Аның тормыш һәм иҗат юлы көтелмәгән күчешләре, кызыклы борылышлары, төрле өлкәдәге җитди казанышлары белән бүген дә игътибарны тарта.

З. Бәшири эшчәнлегенең кайсы гына тармагына күз салсаң да, үз халкын чын мәгънәсендә аң-белемле, ирекле, мәдәниятле итәргә янып-көеп йөргән, бу юлда күп кыенлыклар кичергән, әмма сайлаган юлыннан чигенмәгән мәгърифәтчене, кайнар йөрәкле көрәшчене күрәсең. Бер карыйсың, ул туган ягындагы Акъегет, Чүти авылларында балалар укыта, икенче карыйсың, Пенза, Тамбов губерналарының Яңа Аллагол, Вәрәки һәм Күршә авылы шәкертләренә сабак бирә, ул да түгел, Казахстанның Капал, Үзбәкстанның Ташкент шәһәрләре яшьләрен татар, үзбәк, уйгыр теле һәм әдәбияты белән таныштыра. Егерме яшендә ул Оренбург шәһәрендә «Чүкеч» журналы секретаре, революция дәверендә Алма-Атада татар журналы «Садат» һәм уйгыр газеталары әдәби хезмәткәре, егерменче елларда Ташкентта үзбәк вакытлы матбугатын, утызынчы елларда Донбасста татар шахтерлары газетасы «Пролетар»ны чыгаруда катнашучы. Әдәбият мәйданында ул башлыча шагыйрь буларак танылa, әмма каләменнән хикәя, очерк, мәкаләләр дә мул коела. «Чуваш әдәбияты», «Үзбәк әдәбияты», «Уйгыр әдәбияты» китаплары татар укучыларын кардәш халыклар рухи байлыгы белән таныштыруга хезмәт итә. «Шаян Фәһим», «Ефәк корты» хикәяләре, күп кенә шигырьләре балаларга җан азыгы булса, «Чуваш кызы Әнисә», «Каракош явы» повестьлары өлкән буын укучылар мәхәббәтен дә казана. Аның «Замандашларым белән очрашулар» дигән истәлекләр китабы исә культурабыз тарихын җанландырып сурәтләгән кыйммәтле чыганак.

Зариф Бәшири Казан губернасының (Татарстанның Апас районы) Чүти авылында 1888 елның 5 маенда туа. Башлангыч белемне әтисеннән алганнан соң, Буа шәһәре (1898-1902), Акъегет авылы (1902-1906), Казан каласының «Мөхәммәдия» (1907-1908) мәдрәсәләрендә укый. «Яшә, хөррият» («Казан мөхбире» газетасы, 1906) исемле беренче шигырен бастырганнан соң, аның әсәрләре татар вакытлы матбугатында еш-еш күренә, аерым китапларга тупланып та нәшер ителә башлый. Ул әсәрләрдә шагыйрь укучыларын мәгърифәткә өнди, тормышта очрый торган тискәре якларны камчылый, гади кешеләрнең бәхетсез язмышын сурәтли, табигать күренешләре, мәхәббәт хисләрен тасвирлый.

З. Бәшири иҗатында халыклар дуслыгын гәүдәләндерү дә күркәм урын тота. Аның «Чуваш кызы Әнисә» (1910) повестен укучылар аеруча яратып каршылый. Яхшы күңелле, шаян табигатьле, хезмәт сөючән Әнисәнең иске тормыш шартларында сулган мәхәббәтен әдип искиткеч тәэсирле һәм ышандыручан итеп чагылдыра. Яшьлек шигърияте, хисләр пакьлеген, табигать матурлыгын җылы, ихлас сурәтләгән бу әсәр әле дә яратып укыла.

Зариф Бәшири Октябрь революциясеннән соң да иҗат дәртен суытмый, «Памир — җирнең кадагы», «Завод кызына», «Юксылга» кебек шигырьләрендә яңа тормышны җырлый. Хикәяләрендә һәм повестьларында хезмәт ияләренең кискен көрәшләр аркылы шатлыклы казанышларга ирешүен күрсәтә. Байтак әсәрләрен, шул исәптән, басылмый калган «Тау култыкларында» романын да ул Урта Азия, Казахстанда яшәүче кардәш милләтләр хәятын сурәтләүгә багышлый, аларның Татарстан һәм татар халкы белән дуслыгын яктырта.

Зариф Бәширинең барлыгы кырык тугыз китабы дөнья күрә. Аның байтак әсәрләре вакытлы матбугатта, шул исәптән, казах, үзбәк, уйгыр, башкорт телләрендә дә басылган килеш чәчелеп ята, кульъязмаларның шактый өлеше исә Казанда, СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге институты архивында саклана. Соңгы китабы моннан егерме ел элек чыгуын истә тотсак, язучының тулырак басмасын татар укучыларының яңа буынына тәкъдим итәргә вакыт җитте. Аның иң яхшы әсәрләре моңа, әлбәттә, лаек.

Зариф Бәшири, соңгы гомерен Уфада яшәсә дә, Казан белән бәйләнешләрен даими сакларга тырышты. Ул 1962 елның 21 октябрендә вафат булды.

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

# КИЧӘ ГЕНӘ ӘЛЕ ФЕВРАЛЬ ИДЕ...

ХАТИП ГОСМАНГА 80 ЯШЬ



Хатип Госманның эш бүлмәсе китап белән тулган. Уң стенаны да, сулын да китап каплаган. Китап урындыкларга да, өстәлләргә дә чәчелгән. Бүлмә хуҗасы гадәтенчә көннәр буе урыныннан кузгалмыйча эшли. Мин кереп эшеннән бүлдерәм. Хатип абый үзенең яңа табышлары белән рәхәтләнеп уртаклаша. Төрки шигыренә багышланган хезмәтенең өченче китабы әле язылып бетмәгән. Шул эше турында ул кулларын болгый-болгый дәртләнеп сөйли. Күренеп тора: хәтта һәр табышы, табышның уңышлы дәлиле, кыска итеп әйтелгән гомумиләштерүе турында сөйләве дә чиксез шатландыра аны.

Сиксән яшь... Гомер үзенекен иткән. Көч башка, хәл башка... Ә менә дәрт шул ук. Үземчә юбилей көне якынлашуына ишарәләгән булам. Хатип абый гомумән юбилей тантаналарына каршы кеше. Аңлашыла, үткән еллар турында сөйләү авыр аңа. Дәһшәтле утызынчы еллар аны күп мәртәбәләр изеп, таптап ташлый. Тормышка аяк басыйм дигәндә генә юлын кисә. Ләкин ул елларның да якты хатирәләре бар. Аңа ярдәм кулы сузучылар табыла. Бу куллар аны аякка бастыралар, хакыйкатька ышанычын югалта башлаган йөрәккә ышаныч бирәләр, көч өстиләр.

Ул үткән тормыш юлының биографик белешмәләргә кермәгән өлеше күп. Болары хатирә. Тормышның драмасы, көрәш өлеше.

Хатип абыйның әтисе Госман бабай үз авылында бер мәл мәзин булып торган. Хатип абый әтисенең төсен-битен, йөрешен, бүген күргәндәй хәтерли. Госман бабай озын буйлы, киң җилкәле, таза беләкле көрәшче булган. Үз авылында гына түгел, күрше авылларда да батыр калган. Батырның тимер беләкләре эштә дә сынатмаганнар. Ул гомере буена иген иккән. Бер аты белән үзе дә ат кебек эшләгән. Ук кешелек гаилэсен туйдырган. Кышларын тегү машиналары, сепараторлар, ургыч машиналары төзәтеп көн күргән. Аты белән башкаларга ялланып та эшләгән: бүрәнә, таш, салам ташыган.

Көчле кеше киң күңелле була. Госман бабай йортыннан да кеше өзелми. Юлаучы руслар, марилар, татарлар авыл читендәге ялгыз йортка җыелалар. Хуҗаның күрше авыл руслары белән дуслыгы аеруча нык була. Ул үзе русча яхшы яза, сөйли. Улларын да шул авылга рус мәктәбенә бирә. Русча дөрес сөйләшсеннәр өчен өйләрендә алар белән русча сөйләшеп йөри. Менә шундый мәзин. Гражданнар сугышы елларында шул ук бер аты белән ул кызылларга корал ташый, аннан соң аны гомумән тәэминат бүлегенә алалар һәм азык ташучы итеп билгелиләр. Шул атын җитәкләп Госман бабай колхозга да керә. Гомере буена шунда эшли.

Көчле кешенең дуслары күп булган кебек, дошманы да бетеп тормый. Еллар үткән саен, аңа үзе онытып бетергән мәзинлеген исенә төшерә торалар. Башта бер улын алып китәләр, аннан соң икенчесен... Күп еллардан соң алар акланачаклар. Ләкин берсе генә кире әйләнеп кайтачак. Улы Хатипны утыртмыйлар. Ләкин аның хәсрәте башкалардан ким булмый.

Хатип абый рус мәктәбендә укыганда иң көчле математик һәм рәсем ясаучы булып таныла. Укытучылар аңа рабфакка керергә тәкъдим итәләр. Рабфакта да беренче елны ук үзен иң өлгер укучы итеп таныта. Тик тырыш егет кемгәдер ошамый. «Ул мулла улы» дип язып бирәләр. Хатип абыйны ярты сәгать эчендә Казан рабфагыннан куалар, шул ук ярты сәгать эчендә комсомолдан чыгаралар. Ул әтисе янына кайтып асбест карьерында эшли. Шул елларны ук газета-журналларда шигырьләрен бастыра башлый. Ләкин уку өметен өзми. Казанга килеп газета редакциясенә техник секретарь эшенә урнаша.

Әмма шул ук газетага аның турында мәкалә язалар һәм, әлбәттә, кулак, мулла улы дип гаеплиләр. Редактор үзенең тырыш секретарен шул ук көнне эштән чыгара. Дөрес, беркадәр вакыттан соң, Хатип абый үзенең гаепсезлеген раслаучы дәлилләр китерә һәм шул ук газетада әлеге хәбәрне кире кагу бастыртканчы көрәшә.

Аннан соң Хатип абый Мәскәүгә барып чыга һәм хәтмәгәндә Шамил Усманов белән очраша. Шамил Усманов ач егетне ашата, акчалата ярдәм итә, хәтта эшкә дә

урнаштыра. Әмма Казан педагогия институтына имтихан биргәч, Хатип абый тагын килеп абына: кабул итү комиссиясе председателе аңа бер кәгазь күрсәтә һәм «безнең кеше түгел, чыгышың башка, кабул итә алмыйбыз», ди. Егет Свердловскидагы рабфакка барып керә. Хат бу ерак шәһәргә дә барып җитә...

Игелекле кулын сузып аңа Муса Җәлил дә ярдәм итә. Чираттагы куылудан соң Хатип абый язган хатка ул шунда ук җавап бирә һәм МТС политбүлегенә урнашырга ярдәм итә. Тик политбүлекләр тиздән бетерелә. Ә педагогия институтына барыбер кереп беренче курсны «бик яхшы» билгесенә генә тәмамлагач, Хатип абый кабат әтисе янына кайтып егылырга мәҗбүр була. Монда ул балалар укыта һәм үзлегеннән институт имтиханнарына әзерләнә. Ниһаять, аны, белеменә карап, бишенче курска алалар. Институтны Хатип абый кызыл диплом белән тәмамлый.

Абыйлары еракта булып, әти-әнисе үлеп киткәч, ятим гаилә Хатип абый кулына кала. Ул беркадәр вакыт Алабугада эшли, анда да игелекле кешеләр ярдәмгә килә. Соңрак танылган профессор Линцер белән Муса Җәлил аны педагогия институтына чит ил әдәбияты укыту өчен чакырталар.

Хатип абый Бөек Ватан сугышында баштан алып 1946 елга кадәр була. Ул Төньяккөнчыгыш фронтында сугыша, лейтенант булып Польшаны азат итүдә катнаша, Украина фронтында газета чыгарыша.

Ә бераздан аны «За Родину» фронт газетасының яңа ачылган татар редакциясенә редактор итеп җибәрәләр. Ярдәмгә Шәрәф Мөдәррис килгәнче, Хатип абый бер елга якын үзе редактор да, җаваплы секретарь да, хәрби хәбәрче дә булып газетаны ялгызы чыгарып килә. Сугыш елларында ул күп санлы очерклар, шигырьләр, повестьлар язып бастыра.

Гвардия капитаны Хатип Госманов үзенең институтына фәкать 1946 елда гына кайта һәм шунда ук фәнни эшкә чума. Күп тә үтми кандидатлык диссертациясе яклый. Казан дәүләт университетының тел һәм әдәбият кафедрасына мөдир булып күчкәч, докторлык диссертациясен дә яклый.

Фәнни эшен ул Һади Такташ иҗатын тикшерүдән башлый. Такташ — татар поэзиясенә моңа кадәр күренмәгән яңа сыйфат алып килгән шагыйрь. Галимне ул бәлки шул ягы белән кызыксындыргандыр, бәлки сирәк очрый торган көчле шәхес булганы өчен үзенә тарткандыр? Ә бәлки аның өчен генә түгелдер...

Һ. Такташ хисләрен таслап биргән галим Хатип абый булды. Галимнең фәнни эшендә шагыйрьнең кичерешләре мөстәкыйль яшиләр. Ә менә бер өзеккә Хатип абый аеруча игътибар итә: «Кичә генә әле февраль иде...» Февраль — шигырьдә салкын буранлы, җанны өшетерлек кышкы бер ай. Ләкин шул ук вакытта ул февраль да түгел. Ул үткән көн, кичәге көн, бүгенге тормыштагы салкын мохит. Чөнки март аеның нечкә билле җиле инде сузылып ятып җиргә кар ашый. Кышкы салкын кар белән көрәшкә чыккан нечкә билле җил образына Хатип абый сокланып туя алмый.

Аннан соң Хатип абый татар совет поэзиясенең башлангыч һәм формалашу чорына багышланган зур хезмәтен яза. Тарих, социология, философия, әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, психология... нинди фәннәр ачкычы белән генә ачмый ул бу дәвердәге шигъ-рият үсешенең серләрен. Фәнни хезмәт җыйнаклана, бербөтен күренешкә әйләнә, матурая. Фикер тирәнлеге — һәрвакыт матурлык ул.

Аннан соң сәнгать тарихының тагын да ераграк еллары — борынгы гасырлар. Бу еллардагы төрки кулъязмаларына хәзер нибары 3—4 галимнең генә «теше үтә». Хатип абый төрки шигыренең яңа гына оеша башлаган чорыннан алып бүгенге халәтенә кадәр тикшереп чыга. Төрки шигыре дә, шуннан үсеп чыккан татар шигыре дә үз законнары белән үсәләр дип исбат итә. Гаҗәп, ә бит шушы көнгә кадәр безнең галимнәребез бик җитди итеп, безнең үз шигыребез юк иде, без фәкать гарәп гарузы ярдәмендә генә кеше булдык дип исбат итәләр. Хатип абый бу тәгълиматны үзенә генә хас дәлилләр белән юкка чыгара. Гарузның да, бармакның да борынгы халык иҗаты әсәрләрендә үк яшәвен күрсәтә.

Хатип абыйның нияте — бу зур хезмәтен татар поэзиясенең бүгенге көненә кадәр китереп җиткерү. Ә хәзер ул XIX гасырга килеп җиткән.

Мин Хатип абыйның эш бүлмәсеннән чыгып киттем. Ул кәгазьләре өстенә иелеп калды. Эшли... Көч тә элеккечә түгел, әлбәттә, хәл дә. Ләкин күпме ихтыяр көче саклан-ган бу гаҗәп кешедә, күпме мәхәббәт саклаган... Әдәбиятка, фәнгә, кешеләргә... Ә шундый кеше, бик тели икән, теләгенә ирешмәсмени?! Хатип абый үз эшен ахырына җиткерергә бик тели. Зур эшен, фундаменталь эшен. Ышаныч белдерик, уңыш телик үзенә.

**Альберт ЯХИН.**

## Нури Арсланов

# ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛГАНДА

Сибгат Хәкимне мин аңа хас булган бик күп сыйфатлары белән күз алдыма китерергә тырышам. Менә ул: сабыр-салмак холыклы, тыйнак, уйчан, акыллы, кешеләр белән мөгамәләдә гади, бер вакытта да тавышын күтәреп сөйләшмәс шагыйрь тере килеш каршымда басып тора.

Сибгатне мин күптәннән беләм. Әле Бөек Ватан сугышына кадәр үк шагыйрь Галимҗан Мөхәмматшин, карикатурачы Зәбих Шәйхуллин, язучы Ибраһим Салаховлар белән бергәләп җыелышып әңгәмә коруларда минем дә булгалаганым бар. Мондый чакларда мәҗлеснең тамадасы Галимҗан Мөхәмматшин булып, кичәгә рух биреп утыра торган иде. Без шаркылдап көлешкәндә, Сибгат Хәкимнең бер кырыйда, тыныч кына елмаеп, үзенчә бер тыйнаклык белән утыруын әле дә хәтерлим.

Аннан шактый еллар узды. Мин фин сугышына да барып, әйләнеп кайттым. Сугыштан соң да редакцияләрдә рәссам булып эшләгәнгә, ә Сибгат инде танылган шагыйрь буларак нәшриятка һәм язучылар союзына йөргәнгә күрә, без матбугат йортында еш кына очраша идек. Аның өстенә, тагын әдәби кичәләрдә күрешә идек. Аннан Бөек Ватан сугышы да башланып китте. Без сугышта Сибгат белән бер үк юнәлештә булганбыз икән. Ниһаять, сугышлардан да исән кайттык.

Сугыш елларында, яраланып госпитальдә ятканда, мин ике поэма яздым. Шуннан Язучылар союзына да алдылар. Сибгат сугыштан кайтып кулына каләм алу белән, безнең арада иҗади дуслык яңача көчәеп башланып китте. Ул минем әсәрләремә рецензияләр, китапларыма кереш сүзләр язды, юбилейларымда докладлар белән чыгышлар ясады. Мин аларны, әле күптән түгел генә, яңадан карап, барлап чыктым. Аларда шагыйрь Сибгат Хәкимнең шигырьләремә югары бәя бирүе, дусларча иҗади хәерхаһлыгы күренеп тора.

Шулай ук ул миңа үз әсәрләрен дә, тәрҗемәгә булсын, яки рецензиягә булсын, бик ышанып тапшыра иде. Әсәрләренә русча юлга-юл тәрҗемәләрне дә күп эшләдем. Рус шагыйрьләре тарафыннан эшләнгән әдәби тәрҗемәләренә русча рецензияләр яздым. Гомумән, без яшьрәк чакта үзара бигрәк тә якын мөгамәләдә булдык. Һәр язган яңа әсәребезне бер-беребезгә укып, фикер алышулар сирәк булмады. Сибгат Хәким мондый чакларда үз әсәре турында әйтелгән фикергә зур игътибар бирә, тирән уйчанлык һәм сабырлык белән тыңлый иде.

Хәтеремдә, бервакыт Сибгат, «Фазыл чишмәсе» җырын язып йөргән чагында, кинәт миннән сорап куйды:

— Арслан, (ул миңа гомер буена исемем белән түгел, фамилиям белән эндәште), ялкын түгеләме?

Болай ярдәмче сүзләрдән башка бик үк ачылып җитмәгән бу әйтелеш турында мин уйлана калдым. Ул шунда:

— Суларым түгел, ялкыным түгелде йөрәгемнән, дип әйтеп буламы диюем,— дип кабатлады.

— О, бу инде бөтенләй башка әйбер! Монда йөрәктән ялкын түгелү сурәте бик көчле әйтелә. Әнә бит халык җырында да:

> *... Керфегеннән гөлләр тама,—*
> *Күрсәң йөрәгең яна,*

— диелгән.
Керфектән гөл таму да, бер карасаң, сәер күренеш. Ләкин ул кызның сылулыгын тасвирлап бирү өчен, «Күрсәң йөрәгең яна» дигән өстәмә сүзләр ярдәмендә, җырга гаять кирәкле сурәт булып кушылган. «Фазыл чишмәсе» җырындагы сурәтне халык җырыннан алынган мисал белән «дәлилләп» бирүем ошады булса кирәк. Сибгат Хәким бик канәгать булып елмайды.

Менә бу мисал, кечкенә бер деталь булуга карамастан, сәнгать чараларын куллану бабыннан шигърият турында фикер алышуның мөһим зур бер күренеше. Шундый детальләрне еш куллана алсак безнең шигъриятебез, һичшиксез, нур өстенә нур булып балкый алыр иде.

«Казан утлары» журналында шигърият бүлеге мөдире булып сигез ел эшләдем. Сибгат Хәким журнал редколлегиясе әгъзасы булганга күрә, күп кенә авторларның әсәрләрен бергәләп карап чыгарга туры килә иде. Бигрәк тә минем фикерләрем белән килешмәгән авторларның кулъязмаларын, миннән соң, Сибгат тикшерә иде. Гаҗәп, ни гомерләр бергә эшләп тә, безнең арада фикер каршылыклары булмады диярлек. Язмаларны китерә, плюс, минус билгеләре белән алдыма куя да:

— Фикерләрең белән килешәм, эшләрлеге барларын эшләсен,— ди иде. Әгәр дә мин берәр сәбәп белән эш урынында булмасам, ул үзенең гадәти эре хәрефләр белән язылган «хөсне хат»ын, кәгазьнең бер почмагыннан икенчесенә диагональ булып төшкән юллар белән сызгалап калдырадыр иде. Миндә ул кадерле язмаларның кайберләре әле дә саклана.

Шигъри әсәрләр караганда фикер берлеге турында тагын бер вакыйганы әйтеп үтүне кирәк саныйм. Бусы «Казан утлары»нда эшләгәнгә кадәр үк булган хәл.

Ул замандагы урта буын шагыйрьләрдән берсе (озын гомерле булсын — ул әле дә исән) миңа шигырьләрен китерде. Мин ул чагында «Социалистик Татарстан» газетасында рәссам булып эшли идем һәм, әлбәттә, инде шагыйрь дип үк тә беркадәр танылган идем. Шулай булмаса, әлеге шагыйрь шигырьләрен күтәреп миңа килмәгән дә булыр иде бит.

Шигырьләрен укыдым. Әйбәт кенә фикерләре һәм әйтер мәгънәсе булса да, әйтеп җиткермәгән икән әле дигән нәтиҗәгә килдем. Шагыйрь күңелсез генә торды, кәгазьләрен җыеп алды, папкасына салды да, чөйдә эленеп торган минем мутон бүрегемә карап:

— Сезнең бүрекләрегез дә бер төсле шул,— диде.

Мин гаҗәпләнеп:

— Кемнең ул сезнең? — дип сорадым.

— Сибгат белән икегезнең,— диде теге.

Юк, ул ачуланмады, чөнки кětмәгәндә аерым-аерым ике кешенең фикере, алдан сөйләшкәндәй, уртак булып чыгуы аны ышандырды, әлбәттә. Соңыннан бу хәлне мин Сибгатка сөйләп көлдердем һәм аның бүрегеннән күземне алмадым: чыннан да безнең бүрекләр нәкъ бер төсле булган икән шул.

Укучылар мине гафу итсен, мин тормышта булган сәеррәк хәлләргә күбрәк игътибар бирүчән кеше инде. Монда да Сибгат Хәким кебек олы шагыйрь турында язганда биегрәк трибунадан торып, олырак фикер йөртү кирәк иде диючеләр булмый калмас. Ләкин кешенең олылыгы аның кечелегендә бит. Кече күңелле олы шагыйрь Сибгат Хәким белән мин әле дә, исән дустым белән сөйләшкәндәгедәй, тәкәллефсез сөйләшәм.

Хәер, ни әйтсәң дә, ничек итеп әйтсәң дә, шагыйрь Сибгат Хәкимнең арабыздан китүе татар әдәбияты өчен гаять зур югалту! Шигъриятебезнең тигез сафларында Сибгат Хәким урыны буш. Ул бушлыкны күп елларга кадәр тоячакбыз... Ул безнең Туфаннарыбыз белән берлектә милли шигъриятебезне, озак еллар буена, җилкәсендә күтәреп килде. Татар халык шагыйре Сибгат Хәкимнең иҗаты совет әдәбиятының алтын фондында кыйммәтле мирас булып сакланачак.

Сибгат турында әле язылачак, сөйләнәчәк сүзләр күп, алары — киләчәктә...




# КАШАН ШӘҺӘРЕ

Атаклы болгар шәһәрләре арасында гөрләп үсеп, шаулап чәчәк атып утырганнарының берсе Кашан каласы булган. Болгар дәүләте тормыш-көнкүрешендә гаять әһәмиятле вазифа үтәгән Кашан шәһәре көньяктан килүче кәрван юлы белән су юлы кисешкән җирдә — Чулман (Кама) суының уңъяк ярында, Татарстанның хәзерге Лаеш районы, Шуран авылының көнчыгышында урнашкан булган. Бу беренче Кашан. Икенчесе шулай ук Каманың уңъяк ярында, хәзерге Балык Бистәсе районының Сорочьи Горы авылыннан бераз көнбатыштарак урнашкан булган. Кашан шәһәренең тарихта яшәү чоры X—XIV йөз ахырлары дип исәпләнелә.

Үз заманында шәһре Кашанның даны еракларга таралган. Анда сәүдә үскән. Элекке шәһәр урынында сугыш кораллары, йорт-көнкүреш кирәк-яраклары, алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләре, гер һәм акчалар, тимер йозаклар һәм башка әйберләр табылу — бу урында зур сәүдә үзәге булу турында сөйли. Кашан базарларында күп илләрнең сәүдәгәрләре төрле-төрле товарлар белән сату иткәннәр. Ул экономика һәм культура үзәге булган. Анда һөнәрчелек чәчәк аткан. Һөнәрчеләр керамик чүлмәкләр, төрле кораллар, алтын-көмеш әйберләре, тормыш-көнкүреш өчен кирәкле җиһазлар ясаганнар. Чистай районында табылган борынгы хәзинә әйберләре арасында «Шәһре Кашан» дип язылган алтын беләзек тә бар.

Кашан каласы турында С. М. Шпилевский туплаган мәгълүматлар әһәмияткә ия. Ул Кашанның рус елъязмаларында Казан формасында кулланылуын да искәртеп үтә, ә үзе бу шәһәр исемен Кошан рәвешле яза. Кашанны үзе барып өйрәнгән XIX йөз археологы П. А. Пономарев аның турында махсус хезмәт яза. Шунысы зур игътибарга лаек, галим, табылган һәм җыйналган әйберләрнең характерына һәм күплегенә карагандa, Кашан данлыклы Болгар иленең күп җирләргә билгеле булган, шөһрәт казанган Болгар һәм Биләр шәһәрләреннән генә бераз калыша торган зур кала булган дигән нәтиҗәгә килә. Һичшиксез, су юлы өстенә урнашкан Кашан күп дәүләтләргә билгеле булган. Төрле товарлар төягән сәүдә кораблары, аның аша үтеп, күп җирләрдә сату-алу мөмкинлеге алганнар. Кашан исеме Рус дәүләте законнары җыелмасында да искә алына. Мондый әһәмиятле чыганакта телгә алынуы аның Болгар дәүләте сәүдәсендә, культура, иҗтимагый тормышында лаеклы урын тотканлыгы турында сөйли.

Шәһәрнең тирә-юне үтеп чыгарга кыен булган тирән чокырлар һәм ясалма ныгытмаларның бөтен бер системасы белән чолганып алынган. Кашан ныгытмаларының төзелеш формалары башка болгар шәһәрләренекеннән аерылып тормый.

Болгар, Биләр, Суар һәм башка болгар шәһәрләрендәге кебек үк, Кашан каласы һәм аның тирә-юнендәге болгар авылларында да мәктәп-мәдрәсәләр эшләп килгән. Монда да укымышлы һәм алдынгы фикерле кешеләр, тормышны чын күңелләреннән сөя торган, хәләл хезмәт белән көн итүче фидакарь халык яшәгән.

Кашан шәһәре халкыбызның хәтер түрендә. Аның матурлыгы, һөнәрчелек һәм сәүдәнең гөрләп үсүе һ. б. үзенчәлекле яклары халык авыз иҗатында мәңгегә ныгып калган. Болгар иленең башка якты йолдызлары арасында сүнмәс маяк булып балкыган Кашанга халык ихтирамы зур булган. Аның исеме җырларда, дастан-риваятьләрендә кабатланыла. Кашанга атап чыгарылган тарихи җырда мондый юллар бар:

*Шәһре Кашан — җиһан гөшә.*
*Олуг, кечег һөнәр пишә,*
*Аның бу мәдхе сез гүшә. ,*
*Биңзәер нурлугъ көнәшә.*

*Әһле Кашан — җиһан гөшә,*
*Халайыкы һөнәр пишә,*
*Кеми сәввагъ, кеми зәргәр —*
*Бу сүзә кыйлмагъ әндишә*[1].

---

[1] Хәзерге телгә тәрҗемәсе:
Шәһре Кашан — җиһанның бер (гүзәл) почмагы. Олысы, кечесе һөнәр алдынгысы. Аның мактаулы сыйфатламасын (айтик) сезнең колакка: охшар ул нурлы кояшка.
Кашан кешеләре — җиһанның бер (гүзәл) кисәге. Халкы һөнәр алдынгысы: берсе — корыччы, берсе — алтын-көмешче, бу сүзгә шикләнмә, гаҗәпләнмә.

Халык авыз иҗатында Болгар, Кашан һәм Казан калаларын үзара тыгыз бәйләнештә карау юкка гына түгел. Кайбер риваятьләрдә шәһре Болгарны Аксак Тимер пыран-заран китергән вакытта болгар патшасының исән калган балалары, берникадәр гомер авышканнан соң, Кашанга һәм Казанга килеп нигез табулары турында сөйләнә. Имештер, Габдулла хан хатыны һәм балалары белән хөкем сарае — Кара палатага кереп бикләнә. Аксак Тимер сарайны төрле яклап бүрәнә белән күмәргә һәм ут төртергә боера. Гүзәлләрнең гүзәле хан кызы гына янмый кала. Кызның чибәрлегенә, зирәклегенә таң калган Тимер аңа яшәү бүләк итә, очраклы рәвештә генә исән калган Шәүнә-бәк исемле ир туганы белән бергә аны Сәмәркандка алып китә. Ханның тагын Алтын-бәк һәм Галим-бәк исемле ике малае могҗиза белән генә исән-имин калганнар һәм Казан суы ярына килеп, Казан шәһәрен нигезләгәннәр. Тимер үлгәннән соң, ниндидер сихри көч белән әсирлектән котылган болгар патшасы кызы һәм аның туганы газиз болгар җирләренә, туган туфракка кире әйләнеп кайталар. Башта алар шушы Кашан шәһәрендә яшиләр. Патша малае, үзенең чын исемен яшереп, укытучылык белән шөгыльләнә. Ахырдан туганнарының Казан шәһәрен салуларын һәм шунда яшәп ятуларын ишетеп, анда күчеп китәләр.

П. А. Пономарев, элеккеге Кашан шәһәре янындагы авылларда яши торган татарлар белән шәһәрлек урынында казу эшләре алып барганда, алар авызыннан еш кына Кашан каласы дип кабатлана торган озын җыр да ишетә. Ләкин ул аны язып ала алмый. Татарлар җыр сүзләрен аңа әйтүдән баш тарталар.

Кашан шәһәре тирә-юнендә яшәгән халык телендә «Кашан каласы — кызлар бәласе» — дигән тәгъбир таралган булган. Бу борынгы, тарихи һәм хикмәтле тәгъбирне татар халкында сакланып калган, әтисенә каршы баш күтәргән Шәһребану исемле патша кызы турындагы риваятьләр белән аңлатырга мөмкин. Ул кыз шактый урыннарга шәһәрләр һәм ныгытмалар төзеткән. Кызның әтисенә каршы чыгуы халыкка ошамый, аның мондый кыланышын халык гаепли, закон бозу дип кабул итә. Республикабызның байтак җирләрендә очрый торган «Кызлар каласы» дип аталган урыннар, бәлки, шушы тарихи риваятькә мөнәсәбәтледер.

Кашан исеме географик атамалар арасында да сакланып калган. Лаеш районында хәзерге көнгә кадәр «Кашан юлы», «Кашан чокыры» дигән топонимнар халык телендә кулланылалар. Моннан тыш тагын Кашан тавы, аның янында Шураннан Мурзихага чыгу өчен Кашан кичүе, шунда ук элекке вакытларда, ягъни 1703 елларда, Семиозерка монастыре (хәзерге Биектау районындагы Семиозерка авылы) өчен балык тота торган урын — Кашан култыгы, Кашан кыры, Чулман яры кырыендагы биек текә тау, ягъни Кашан түмгәге, Алексеевск районында Мурзихадан көньяк-көнбатышка таба ун чакрымнар чамасы ераклыкта Кошан исемендә рус авылы бар. Бу авыл янында галимнәр гомумболгар чорына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре һәм башка археологик истәлекләр таптылар, аның исеме Казан ханлыгы чорында да искә алына.

Профессор М. З. Зәкиев Кама ярындагы Кашан (Кошан) шәһәре кушан (кошан) төркиләре тарафыннан салынган булырга мөмкин, дигән карашта тора. Бу фараз игътибарга лаек, чөнки халык исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар бер Кашан (Кошан) гына түгел, саный китсәң, берничә дистә. Шушы җәһәттән А. Г. Яхин һәм М. Х. Бакировлар да бу борынгы болгар каласының исеме Кушан булган дигән карашта торалар һәм шуны дәлилли торган тарихи фактларны бик урынлы файдаланалар. 1179—1229 елларда яшәгән гарәп галиме Якут әл-Руминың география буенча төзелгән энциклопедик сүзлегендә: «Кушан — иң ерак төрки мәмләкәте чигендә урнашкан шәһәр. Аның хөкемдары бик көчле халык булган тугызгузлар (угыз кабиләләре — Ф. Г.) йорт-иле белән дә идарә итә һәм иң бөек төрки патшаларның берсе булып санала»,— дип язылган. Бу юлларны Якут әл-Руми чыгышы белән Кашаннан булган Мөхәммәт әл-Кушани дигән кеше мәгълүматларына таянып яза.

Кашан каласы өстеннән фаҗигале вакыйгалар: талау-бөлүләр, искәрмәстән килеп һөҗүм итүләр, халкын әсирлеккә алып китүләр күп узган. 1391 елда Кашанны Новгород һәм Устюг ушкуйниклары талаган, 1396 елда Мәскәү кнәзьлеге гаскәрләре яу килеп бөлдергән. Кашанның җимерелүе халык күңеленә төзәлмәс яра салган. Татар халык фольклорында аның Аксак Тимер тарафыннан туздырылуы әйтелә. Кашан каласы да, кызганычка каршы, җир белән тигезләнә. Кама елгасының уңъяк ярында шәһәрнең урыны, ә халык хәтерендә мәңге җуелмаслык булып исеме калган.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Вакыйф Нуруллинның «Җавап бир, кеше» («Казан утлары» № 6, 1987 ел) повесте бик гыйбрәтле әсәр. Бу фикеремә башкалар да кушылды. Адәм баласының башыннан ниләр генә узмый диештек. Һәм уртак фикер, уртак нәтиҗә шул булды — боларның һәммәсенә дә кеше үзе гаепле. Тормышта кеше, кем булса да, әхлак кагыйдәләренә буйсынып, барысы да кеше өчен дип яши, эшли икән, бернинди авырлыклар, күңелсезлекләр аны куркытмаячак. Ә менә «Җавап бир, кеше» повестендагы Хәнәфи, үзе гомере буе җитәкче постларда эшләсә дә, кеше өчен яши белми. Ул бик үҗәт кеше, эгоист, комсыз, үчлекле, азгын кеше була. Каян җыеп бетергән үзенә тискәре сыйфатларны, кайда һәм кемнән туган, кем тәрбияләгән аны шундый итеп? Әлбәттә, дуслары, ришвәтчеләр, хәсрәт җитәкчеләр шулай узындыралар аны. Аның бозыклыкларына җәза бирәсе урында яклап калалар, бер эштән икенчесенә күчерәләр. Әйтерсең лә, Хәнәфидән башка бер эш тә бармый, аңардан башка җитәкче таба алмыйлар кебек. Нәтиҗәдә, оештыру сәләте булган кеше бозыла, хәтта саулыгын югалта, кеше күзенә карап торырга кала. Әмма авылдашлары, дуслары, сөяркәләре аны күрергә дә теләмиләр. Кайчандыр аның өчен җанын фида кылырга торган сөяркәсе Хөсниҗамал да: «— Безнең сөйләшәсе сүзләр сөйләнеп беткән инде синең белән»,— дип кенә кырт кисә.

Улы Хәсән белән хатыны Хәлимә дә Хәнәфинең азгынлыкларыннан хурланып, күптәннән Казанга киткәннәр. Хәнәфи ялгызы гына капка төбендә утыра. Әбиләр чуагының соңгы көннәре. Хәнәфи кояшның соңгы шәфкатьле, рәхимле җылысыннан һәм кешеләрдән ярдәм көтеп утыра, ә үзенең эче тулы миһербансызлык. «Мондый иканегезне, болай буласыгызны белгән булсам, мин сезне изеп, сытып бетергән булыр идем, аз булган әле»,— дип үкенеп утыра ул.

Әмма аның явызлыкларын беркем дә онытырлык хәлдә түгел. Хәтта, инде акыллы, белемле, алтын куллы егет булып өлгергән Исмәгыйль дә аннан чиркана, күңеле белән хәтта аны кызганса да. Чөнки ул Исмәгыйльнең җиденче класста укыганда, җәй буе зелпе тамыры, юкә бөресе, имән чикләвеге җыеп тапшырган өчен бирелгән җирдән җыеп алган печәнен ут төртеп, арбасы-ние белән яндырды бит.

Кыскасы, повесть бик гыйбрәтле, тәрбияви тәэсире зур. Бик урынлы һәм бик кирәкле проблемалар күтәрә язучы.

Вакыйф Нуруллин әсәрләрен тормышчан, гыйбрәтле, матур тел белән, халыкчан һәм ышандырырлык итеп язылганнары өчен без һәрвакыт бик яратып укыйбыз, көтеп алабыз.

Сүземне кыскартып шуны әйтәсе килә: Хәнәфи тупас, шәфкатьсез, бозык кеше буларак үзенең җәзасын алды — табигать аны тиешенчә каһәрләде. Ә аның яклаучылары, шешә дуслары, ришвәтчеләр, сөяркәләре белән нәрсә булды соң? Нинди җәза алдылар, әллә һаман да кәеф-сафа корып яталармы? Болары ачыкланып бетмәде. Шуның өчен без Вакыйф иптәш Нуруллиннан бу повестьны дәвам итүен сорыйбыз.

**З. ГОМӘРОВА,**
Чаллы шәһәре.

Мәдинә Маликованың «Басып сайрар талы бар» романын укып чыктым. Роман кызыклы итеп, укучыны ышандырырлык итеп язылган. Иң мөһиме, анда сафлык, тугрылык турында язылган. Яши торгач, без бу төшенчәләрнең мәгънәсен онытып барабыз шикелле. Күпме гаиләләр җимерелә, күпме күз яше түгелә. Мәхәббәткә күбрәк Эльвира кебек карашта торабыз. Романда пьесадан өзекләр бирелә. Ул романның рухын ачып җибәрә. Кадимбикәнең иренә тугрылыгы — ул илгә тугры булуның нигезе. Ул иренең сызлануларын гына түгел, иленең сызлануларын да әллә кайн сизеп тора.

**Г. ГАДЕЛШИНА,**
Казан шәһәре.

М. Маликованың «Басып сайрар талы бар» әсәрен журналның яңа саннарыннан көтеп алып укыдык. Безгә бик үк таныш булмаган театр тормышын сурәтләгән әсәрне әле беренче тапкыр укуыбыз. Сәхнә кешесенең хезмәте, гаилә тормышы, иҗат омтылышлары, уй-хисләре дә хәзер безгә кадәри хәл таныш инде. Мәдинә ханымга иҗатында яңа уңышлар телибез.

**Ә. АЙТУГАНОВА,**
Әгерҗе районы, Нарат авылы.

«Казан утлары»ның 5 санында Марсель Зариповның «Сигез сыер асраганчы...» дигән язмасын укып чыккач, мин сезгә үземнең фикерләремне әйтергә булдым. Үзебезне туйдыра торган сыер турында без бик аз беләбез икән бит. Мин үзем әлеге очеркны укыгач, бик зур мәгълүмат алдым. Аны русча да, татарча да китап итеп бастырып чыгарырга кирәк. Һәр фермада, һәр савымчы кулында булырга тиешледер бу китап.

**Х. САДЫЙКОВ,**
БАССР, Туймазы шәһәре.

Әхәт Гаффарның «Яшиселәр алда иде әле» повестен дулкынлану белән укыдым, язучыбыз өчен сөендем. Әсәр эчке кичерешләргә бик бай. Анда чын хезмәт тәме һәм шуның аркылы гына чын хөрмәтле кеше булып китү, яшәү мәгънәсен тирәннән тою, халкыбызның иң асыл традицияләрен яңарту, буыннар алышынудагы каршылыклар сурәтләнә. Иң мөһиме — эчкечелеккә каршы, сугышка каршы көчле нәфрәт кузгата бу әсәр, көрәшкә чакыра.

Әйтергә теләгәнем шул: без башка милләт язучыларын гына түгел, үзебезнең язучыларны да күрә һәм күрсәтә белергә тиешбез.

**Ф. ХӘЙРУЛЛИН,**
Чаллы шәһәре.

Журналның 10 санында Зәки Зәйнуллинның «Үрләр аша» повестен бастырып бик яхшы эшләгәнсез. Башта үзем укыдым, аннан гаиләм белән бергәләп. Ничә мәртәбә күңелем тулып, туктап тордым. Укып бетергәч, җанга уелып калган сугыш елларын, айларын, көннәрен бөртекләп хәтердән үткәрдем. Рәхмәт, Зәки туган. Шушы повестьны гына язып, башка бер әсәр язмасаң да, Зәки Зәйнуллин дигән язучы исеме күңелләрдә сакланыр дип уйлыйм.

**Әмир ЯППАРОВ,**
Куйбышев шәһәре.

«Казан утлары» журналында 1987 елда дөнья күргән бер хикәя һәм бер повесть хакында кайбер фикерләремне бәян итәсем килде. Моңа ни-нәрсә сәбәп булгандыр, анык кына тәгаенләп әйтүе кыен. Бәлки, язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең бу өлкәдә берәкәтле эш алып барырга мөмкинлекләре булып та, сүлпән-салмак кыймылдауларыдыр?

Иң элек Рашат Низамиевның 8 санда басылган «Беренче мунча» дип исемләнгән хикәясенә тукталам. Хикәядә яшьләр авылга кунакка кайта. Авыл чынбарлыгы үзенең һавасы, кешеләре, инде дә килеп мунчасы белән шәһәр кешесенең эчке дөньясын пыран-заран китереп атарга сәләтле микәнни соң? Шулай булган тәкъдирдә искиткеч булыр иде ул. Күңелендә икеләнү, уңайсызлык сизгән һәр кешене авылга кайтарып, «эзгә» кертер идек диюем.

«Шәһәрне макта, авылда тор», дигәннәр элгәре. «Авылны макта, шәһәрдә тор», дип яраклаштырган очрак та чынбарлыкка якынрак килү булмас иде микән. Һәркемгә үзенеке. Ә менә авылны идеаллаштыру чынбарлыкка туры килеп бетми бит.

Дөрес, табигате элеккечә үк гүзәл булмаса да, начарлардан түгел. Ә кешеләре инде бөтенләй башка. Соңгы елларда җәмгыятебездә күзәтелгән күп кенә кимчелекләрдән берсе — табыш артыннан куу, җиһаз колы булу. Кызганычка каршы, авыл кешесе дә бу ямьсез күренештән өстен булып кала алмады.

Р. Низамиев хикәясендәге Сабира апалар авылда хәзер сирәк, үтә сирәк очрыйлар. Бәхеткә каршы, заманалар уңай тарафка таба үзгәрә башлады шикелле. Авыл кешесенең күңеле дә азлап-азлап, утырган юшкыннан арчыла башлар дип ышанасы килә. Белмәссең, күпләрнең шәһәргә тартылу «шаукымы» да басылыр иде. Һәм, «шәһәрне макта, авылда тор», дигән мәкаль үз көчендә калыр.

Янә дә килеп журналның 7 санында басылып чыккан Рафаил Төхфәтуллинның «Чатта тукталу» повестена карата берничә сүз. Әсәр заман рухына ияреп, көн кадагы таләп иткән темага язылган. Аның атамасы күпне вәгъдә итә.

Чатта тукталу. Әсәрнең ике баш герое Салих белән Зиннурның чатка кадәр юлсукмаклары, характерлары төрле булуга карамастан, бергә бара. Килә бер көн, инде Салих идарә башлыгы Зиннурның икейөзлелеге белән риза булып кала алмый.

Аларның юллары чатта кисешә. Чатта Салих бәхетсезлеккә очрый: машина астына керә. Тик инде фараз кылырга урын бар, ул савыккач, һичшиксез, башлаган эшен ахырынача җиткерү өчен көрәшер.

Әмма повестьның кайбер яклары бәхәскә этәрә. Әлеге дә баягы Салих — утларсулар кичкән егет, шактый гына тормыш мәктәбе үткән. Армия хезмәтеннән соң төньяк котыпка китеп эшләгән, аннары университет тәмамлаган. Нык характерлы максатка омтылучан егет промыселга геолог булып килә. Хуп, бусы белән килешәбез. Тик менә көчле ихтыярлы ирнең классташ иптәше Зиннур йогынтысына бирелүе, күп очракта дөрес түгеллеген белсә дә, аның сүзеннән чыкмавы... ябышып җитми кебек. Һәрхәлдә, Салих ише шәхескә. Миңа калса, алар арасындагы конфликтны баштан ук тирәнәйтергә кирәк шикелле.

**Фирдәвес ХУҖИН,**
Алабуга районы, Илмәт авылы.

## Хәниф Хөснуллин

### Кәгазь җыю кооперативы

Кооператив ачтык әле,
Кәгазь чүбе җыябыз.
Без барлыгы өчәү генә —
Тар бүлмәгә сыябыз.
Чыгып киттек өч тарафка,
Вак-төяк кәгазь эзләп.
Чыгып йөрмәс идек тә бит —
Шундый ул яңа хезмәт.
Берчак Ханнан кайтып төште —
Кибән чаклы кәгазе.
Анда җитмеш начальникның
Мең дә җитмеш вәгазе.
— Зур бурыч,— ди бер башлыгы,—
Шулдыр минем уемча:
Иптәшләр! Без алда барыйк
Алда бару буенча.
Ә бер җирдә бәйләмнәргә
Гел рапортлар җыелган.
Матур шома кәгазьләргә
«Җиңдек!» сүзе сыенган.
— Фәлән, фәлән, фәлән, фәлән
Бәйрәмнәр хөрмәтенә
Безнең коллектив,— ди берәү,—
Хезмәттә үргә менә...
Өйрәндек алда барырга
Хезмәттә һәм парадта.
Арттагылар безне күрмәс
Бинокльдән карап та...
Рапорт алу, рапорт бирү —
Рәсми мактану бит ул,
Мең начардан бер яхшыны
Табып шатлану бит ул.

Гарифҗан да бик күп җыйган,
Төп-төгәл өч машина.
Жалу-шикаять кәгазе
Төягәннәр барсына.
Минем жалу язганым юк,
И, күп язалар икән.
Кайберләре яза-яза
Тәмам азалар икән...
Бер кеше үз коймасына
Бер кадак артык каккан.
Күршесе аннан шикләнә:
— Эзләгез. Каян тапкан?..
Тоз чәйнәгән кебек итте,
Йөзен чытты Гарифҗан.
Аны бик нык хурлап язган
Ниндидер бер гарип җан:
— Экономика — заводның
Акчалы йөрәге ул.
Экономист шул йөрәкнең
Кирәкле тәрәге ул.
Ә Гарифҗан Сайкин үзен
Шул йөрәктән аера,
Барлык исәп-хисаплавы
Үз ягына каера...
Тик Гарифҗан көлә башлый,
Үзеннән көлә микән?
Әллә кешедән көләрлек
Бер сәбәп белә микән?
— Изге дип йөри торгандыр
Сәлим һәм Ханнан үзен.
Аларга да юллаганнар
Монда чеметү сүзен:
«...Лозунглар яза Ханнан,
Унны буйый көненә.
Тик нигәдер йөрәкләрдә
Урын булмый сүзенә.
«Ак яка» булып йөргәнче,
Ул эш эшләсен,— дигән,
Безнең ашка көя булып
Бүтән төшмәсен,— дигән.
Берсе әйткән: «Папка тоткан
Укытучы Сәлим дә.
Аның укытам дигәне
Гел укытмау хәлендә»...
Бер көлабез өчәүләшеп,
Ярсыйбыз язучыга.
Дөреслек бар дип карыйсың,—
Жалудан агу чыга.
Үзебезнең кем буluны
Белер идек кайда без?
Кооператив ачып, таптык
Үзебезгә файда без.
Кемнәр ярамас эш кылган,
Кемнәр нәрсә сөйләгән...
Шундый серләр белән безне
Кооператив төйнәгән.
Эшләребез гөрләп бара,
Котелми бәла-каза.
Кәгаземе?
Анысы — диңгез,
Бөтен ил кәгазь яза.

*Китаплар дөньясында*

# Хөрмәтле укучыларыбыз!

Татарстан китап нәшрияты 1987 елда түбәндәге китапларны басып чыгарды:

**Нури Арсланов.** Сөмбелләрем. Шигырьләр, балладалар, поэмалар. 152 бит. Бәясе 80 тиен.

**Мирсәй Әмир.** Әсәрләр. II том. Саф күңел. I китап. Роман. Пьесалар. 544 бит. Бәясе 2 сум 20 тиен.

**Әмирхан Еники.** Соңгы китап. Истәлекләр. 504 бит. Бәясе 1 сум 90 тиен.

**Риза Ишморат.** Гомерем сукмаклары. Истәлекләр. 408 бит. Бәясе 1 сум 60 тиен.

**Шәүкәт Галиев.** Сайланма әсәрләр. Балалар өчен. 423 бит. Бәясе 1 сум 50 тиен.

**Акъегет.** Ак болыт шәүләсе. Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 25 тиен.

**Фирдәвес Бәширова.** Сезнең өчен тибә йөрәгем. Шигырьләр. 48 бит, портрет белән. Бәясе 10 тиен.

**Марат Әмирханов.** Таш һәйкәл. Повесть. 132 бит. Бәясе 20 тиен.

**Гөлчәчәк Әдһәмова.** Үкенечкә калмасын. Повесть. 80 бит. Бәясе 25 тиен.

**Илдус Гайфуллин.** Хәтәр сукмаклар. Хикәяләр. 63 бит. Бәясе 15 тиен.

**Госман Гомәров.** Уйна гармуныңны. Повесть. 96 бит. Бәясе 20 тиен.

**Нәбирә Гыйматдинова.** Чәрелдек. Балалар өчен хикәяләр. 64 бит. Бәясе 15 тиен.

**Аяз Гыйләҗев, Алексей Литвин.** Алтынчы августка кадәр. Роман. 350 бит. Бәясе 1 сум 40 тиен.

**Әсрар Галиев.** Асыл кошым минем. Повесть. 128 бит. Бәясе 20 тиен.

**Рафис Гыйззәтуллин.** Урман юлы. Хикәяләр. 94 бит. Бәясе 15 тиен.

Дуслык аланы. Хикәяләр. 392 бит. Бәясе 2 сум.

**Җәүдәт Дәрзаманов.** Җир авазы. Повесть. 192 бит. Бәясе 55 тиен.

**Ямаш Игәнәй.** Игелекле тобәк. Шигырьләр. 110 бит, рәсем белән. Бәясе 65 тиен.

Идел. 1987. Яшьләрнең әдәби альманахы. Повесть, хикәяләр, шигырьләр. 80 бит. Бәясе 20 тиен. Альманахның 1981—1986 елларда чыккан саннары да сатуда бар.

Иркен минем туган илем. 1-3 класслар өчен өстәмә әдәбият. 272 бит. Бәясе 60 тиен.

**Барлас Камалов.** Мирхәйдәр Фәйзи турында повесть. 160 бит. Бәясе 25 тиен.

**Рафис Корбанов.** Буран кайда йоклый. Балалар өчен шигырьләр. 32 бит, рәсемнәр белән. Бәясе 10 тиен.

**Рәфкать Кәрами.** Йөрәгемне ут алган. Повестьлар һәм хикәяләр. 272 бит. Бәясе 1 сум 10 тиен.

**Мәдинә Маликова.** Басып сайрар талы бар. Роман. 320 бит. Бәясе 1 сум 30 тиен.

**Кәрим Тинчурин.** Әсәрләр. III том. Проза, әдәбият-сәнгать турында мәкаләләр. 512 бит. Бәясе 2 сум 60 тиен.

**Гөлсем Мөхәммәдова.** Эзләнүләр. Галимҗан Ибраһимов турында документаль повесть. 376 бит. Бәясе 1 сум 50 тиен.

**Атилла Расих.** Әсәрләр. 1 том. Ялгыз авазлар. Роман. Повестьлар, хикәяләр. 488 бит. Бәясе 1 сум 90 тиен. II том. Ике буйдак. Роман. Повестьлар, хикәяләр. 552 бит. Бәясе 2 сум 10 тиен.

**Энҗе Мөэминова.** Күңел түрендә. Шигырьләр һәм поэмалар. 32 бит. Бәясе 10 тиен.

**Раушания Низамова.** Мин авылда укыйм. Балалар өчен хикәяләр. 56 бит. Бәясе 10 тиен.

**Вакыйф Нуруллин.** Җавап бир, кеше. Повестьлар. 288 бит. Бәясе 1 сум 20 тиен.

Пионер сәхнәсе. Сигезенче китап. 144 бит. Бәясе 35 тиен.

**Госман Садә.** Җиләкле тәрәзәләр. Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 30 тиен.

Туган як кичләре. Ноталары белән басылган татар җырлары. 40 бит. Бәясе 60 тиен.

**Зәкия Туфайлова.** Без — Ленин оныклары. Балалар өчен шигырьләр. 64 бит, рәсемнәр белән. Бәясе 30 тиен.

**Зөфәр Фәтхетдинов.** Кем кемне. Повестьлар. 192 бит. Бәясе 50 тиен.

**Мәгафүр Ханнанов.** Төнге кунаклар. Юрист язмалары. 112 бит. Бәясе 20 тиен.

**Хәким Хәйруллин.** Ургыл. Роман. 304 бит. Бәясе 1 сум 20 тиен.

**Мөсәгыйт Хәбибуллин.** Чоңгыллар. Роман. 528 бит. Бәясе 2 сум 10 тиен.

**Альберт Хәсәнов.** Шулай бер мәлне. Повесть, хикәяләр, очерклар, истәлекләр, әдәби портретлар. 240 бит. Бәясе 1 сум.

**Ризван Хәмид.** Каен җиле. Пьесалар. 160 бит. Бәясе 45 тиен.

**Мәгъсүм Хуҗин.** Бәхет җире. Хикәяләр. 126 бит. Бәясе 45 тиен.

**Роза Хафизова.** Сак-сок тавышы. Хикәяләр һәм әкиятләр. 136 бит. Бәясе 40 тиен.

Шатлыклы кайгы. Юмористик һәм сатирик хикәяләр. 160 бит. Бәясе 55 тиен.

**Сәет Шәкүров.** Пьесалар. 248 бит. Бәясе 1 сум.

**Шәмсия Җиһангирова.** Яшел гармун. Повесть. 102 бит. Бәясе 30 тиен.

Яшьлек җырлый. Хәзерге татар эстрада җырлары ноталары белән. 96 бит. Бәясе 65 тиен.

*Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша соратып алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга-почтой»; 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга-почтой».*

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ БЕЛӘН ОЧРАШУ

25 февральдә Казанда, КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында, партия өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов республикабызның иҗат интеллигенциясе белән очрашты. Очрашуда иҗат союзлары җитәкчеләре, язучылар, композиторлар, кино, театр, нәшрият хезмәткәрләре, журналистлар катнашты. Иптәш Н. Х. Кадерматов үзгәртеп кору, яңарыш чорында әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, идеология өлкәсендә эшләүчеләр алдында торган бурычлар турында сөйләде, республикабызның социаль һәм экономик үсеше белән таныштырды, күптөрле сорауларга җавап бирде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

16 мартта Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы булып узды.

«Республика газеталарында язучы публицистикасы» дигән бу сөйләшүдә «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» һәм «Вечерняя Казань» газеталары хезмәткәрләре дә катнашты. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, әдипләр С. Баттал, Б. Гыйззәт, Л. Ихсанова, Г. Рәхим, М. Зарипов, К. Тимбикова, М. Насыйбуллин, М. Вәлиев һ. б. бүгенге публицистикабызның торышы турында сөйләделәр, бу жанрны тагын да үткенрәк итү хакында фикерләрен әйттеләр.

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ

17—21 мартта Татарстан композиторларының VI съезды булып узды. Әлеге форумда катнашу өчен Мәскәүдән, Әзербайҗан ССР, Казахстан ССР һәм Чувашия, Мари, Башкортстан, Мордва автономияле республикаларыннан кунаклар килде.

Съезд көннәрендә симфоник концерт, камера әсәрләре, фольклор коллективлары концертлары булды.

Съездның пленар утырышында республика Композиторлар союзы идарәсе председателе М. Яруллинның һәм ревизия комиссиясе председателе Ш. Шәрифуллинның отчет докладлары тыңланды, алар буенча фикер алышу булды. Аннары Композиторлар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составлары сайланды.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов чыгыш ясады.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, РСФСР Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары К. Е. Волков катнаштылар.

## БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

14 мартта Казанның Актерлар йортында «Ил тарихын сәхнәви гәүдәләндерү һәм милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасы» дигән темага Бөтенроссия фәнни-иҗат конференциясе булды. РСФСР һәм Татарстан театр эшлеклеләре союзлары оештырган бу конференциядә РСФСР Театр эшлеклеләре союзы идарәсе секретаре В. Г. Урин, «Театральная жизнь» журналының баш редакторы О. И. Пивоваров, Мәскәүдән, Казахстаннан, Башкортстан, Бурятия, Коми, Чувашия, Удмуртия, Төньяк Осетия автономияле республикаларыннан килгән галимнәр, театр эшлеклеләре, республикабызның культура һәм театр эшлеклеләре, республикабызның культура һәм театр җәмәгатьчелеге вәкилләре катнаштылар. Аларны ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов тәбрикләде һәм республикабызның социаль-экономик һәм культура тормышы белән таныштырды.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## БАЛАЛАР ФОНДЫ ОЕШТЫ

27 февраль көнне Казан шәһәренең Киров исемендәге культура сараенда В. И. Ленин исемендәге Совет балалар фондының Татарстан бүлеген оештыру конференциясе булды.

Конференциядә сүз, нигездә, балалар тәрбиясе, гаилә, мәктәп һәм хезмәт коллективларының үзара бәйләнешләре, балалар йортларының бүгенге хәле турында барды.

Оештыру конференциясендә Совет балалар фондының Татарстан бүлеге председателе итеп «Яшь ленинчы» газетасы редакторы, шагыйрь Роберт Миңнуллин сайланды.

Конференция эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## «НОВЫЙ МИР» ЖУРНАЛЫ КамАЗДА

КамАЗ эшчеләре белән «Новый мир» журналы редакциясе арасындагы күпьеллык иҗади дуслык, хезмәттәшлек дәвам итә.

Март аенда шәһәргә танылган рус әдипләре В. Орлов, М. Соболь, В. Сикорский,

Г. Резниченко, В. Селюнин, С. Гандлевский, Т. Карапетян, Л. Галимова килделәр.

Мәскәү кунаклары культура йортларында, китапханаләрдә, мәктәпләрдә, КамАЗ заводларында, «Камгэсэнергострой» һәм «Татэлектромаш» берләшмәләренең төзелеш мәйданнарында чыгыш ясадылар. «КамАЗ» культура сараенда узган йомгаклау кичәсендә «Новый мир» журналы хезмәткәрләре эшчеләргә ике яна китап — КамАЗ һәм Түбән Кама территориаль-промышленность комплексы турында журналда басылган очерклар тупланган бертомлык һәм «Чаллы өстендә аккошлар» исемле җыентыкның (икенче чыгарылыш) сигнал экземплярларын бүләк иттеләр, сорауларга җаваплар бирделәр.

## УФАДА — ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КЛУБЫ

Уфа Резина-техник әйберләр заводының культура сарае каршында татар мәдәнияте сөючеләренең Галимҗан Ибраһимов исемендәге клубы ачылды. Оештыру җыелышында клуб идарәсе сайланды. Аның составында әдәбият-сәнгать һәм фән эшлеклеләре — шагыйрь Айдар Хәлим, әдәбиятчы галим Риф Мөхәммәтҗанов, Башкортстанның атказанган рәссамы Гыйниадулла Хәйретдинов һәм башкалар бар.

Клуб күренекле татар язучыларының, сәнгать эшлеклеләренең, галимнәренең иҗат кичәләрен оештыруны, концерт һәм спектакльләр күрсәтүне, халыклар дуслыгын ныгытуга багышланган тагын бик күп культура чаралары уздыруны күздә тота.

## МИРАС КОМИССИЯСЕНДӘ

Тарихыбызны дөреслектән читләшмичә, яңача бәяләү юнәлешендә ил күләмендә җитди адымнар ясала. Шул процессның бер чагылышы буларак, татар халкының моңа кадәр игътибардан читтәрәк калып килгән күп гасырлык рухи мирасын җыю, өйрәнү, саклау һәм пропагандалау максатыннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында республика мирас комиссиясе төзелде. Аның составына язучылар, әдәбият һәм сәнгать белгечләре, тарихчылар кертелде.

22 январьда комиссиянең чираттагы утырышында вәисевчеләр хәрәкәте турындагы мәсьәлә каралды. Тарихчы С. Алишев әлегә кадәр бу мәсьәләнең берьяклы гына өйрәнелүен күрсәтеп үтте, хәрәкәтнең үз чоры өчен прогрессив булуын аңлатты. Фикер алышулардан соң, вәисевчеләр хәрәкәте турында Татарстан китап нәшриятына брошюра әзерләп тапшырырга дигән нәтиҗә чыгарылды.

Мирас комиссиясенең 24 февральдә узган утырышында «Үзгәртеп кору һәм егерменче йөз башы татар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләләре» дигән тема үзәккә куелды.

## ТАТАР ПЬЕСАСЫ — КАЗАХ СӘХНӘСЕНДӘ

Драматург Туфан Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» музыкаль комедиясе белән Алма-Ата шәһәрендә яшәүчеләр дә таныштылар. Әлеге әсәр буенча эшләнгән спектакльне Казах дәүләт балалар һәм яшүсмерләр театры күрсәтте. Комедияне казахчага Зөлкарнәй Сакиев тәрҗемә иткән. Режиссеры — Нурканат Жакипбаев.

## ТУГАНДАШ ӘДӘБИЯТЛАР БӘЙРӘМЕ

25 февральдә Чаллының «Төзүче» культура сараенда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Р. Фәйзуллин һәм Чувашия Язучылар союзы идарәсе председателе П. Афанасьев, Чувашия комсомолының М. Сеспель исемендәге премиясе лауреаты, «Ялав» журналының баш редакторы Ю. Семендер катнашында әдәби-музыкаль бәйрәм — «Дуслык кичәсе» булып узды.

Кичәдә совет милли культуралары, аларның үзара бәйләнеше, үзгәртеп коруда язучының урыны һәм социаль активлыгы турында сөйләшү булды.

Әдәби-музыкаль бәйрәмдә Чувашиянең атказанган артисты Николай Виноградов, композитор Юрий Ильгуш (Кудаков), Татарстан сәнгать осталарыннан яшь җырчы Г. Ибушев, Н. Бәдретдинов, «Сердәш» һәм «Чулпан» вокаль ансамбльләре, шулай ук шәһәрнең үзешчән артистлары катнашты.

Шундый ук әдәби-музыкаль бәйрәм Түбән Кама шәһәрендә дә узды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПОСТЫНДА

«Казан утлары» журналы һәм Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр коллективлары арасында иҗади хезмәттәшлек нидер бишенче ел дәвам итә. Шул чорда әлеге зур төзелеш турында журнал битләрендә бик күп санда очерк, мәкаләләр һәм бер роман басылып чыкты.

25 февральдә Кама Аланы клубында шушы хезмәттәшлеккә багышланган кичә булып узды. Аны атом электр станциясенең партия оешмасы секретаре Р. К. Кәтиев ачты. «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис иҗади хезмәттәшлек турындагы килешүнең үтәлеше турында сөйләде, редакциянең иҗат планнары белән таныштырды. Бер төркем төзүчеләргә редакциянең Мактау грамоталары тапшырылды, алар шулай ук «Казан утлары»на еллык подписка белән бүләкләнделәр. Алар — буяучылар бригадиры Т. Казаргилдинова, ташчылар бригадиры Ф. Корбангалиев, эшче С. Галимов, сылаучылар бригадиры С. Гыйнвранова, АЭС директоры урынбасары Ф. Фәйрушин.

Килешү шартларында каралганча, «Казан утлары» журналында басылган иң яхшы публицистик язма өчен прозаик М. Хәсәнов, шагыйрә Э. Шәрифуллина һәм журналист Х. Бәдретдинова АЭС төзүчеләренең премияләре тапшырылды.

Кичәдә шулай ук Татарстан һәм Чувашия әдәбият-сәнгать эшлеклеләре катнашты.

# КҮКРӘКЧӘ

Татар халкының борынгы сәнгать җәүһәрләреннән берсе булган күкрәкчәләр көндәлек тормышта шактый киң кулланылган. Аларны кайбер төбәкләрдә изү япмасы дип тә йөртәләр.

Бизәккә һәм төсләр балкышына үтә дә бай бу зиннәтләрнең гаҗәеп үрнәкләрен илебезнең төрле музейларында күрергә мөмкин. Аларны бик күпләр, истәлек-ядкарь итеп, әле бүген дә сандык төпләрендә кадерләп саклый.

Гамәли сәнгатьнең аерым бер төре буларак, күкрәкчәләргә дә үзенчәлекле сыйфатлар хас. Алар — төрле тукымаларның үзара ярашуында; һәр бизәкнең, һәр аерым өлгенең үз төсмере, үз сурәте булуда да, көндәлек тормышта файдалану үзенчәлегендә дә ачык чагыла.

Халык иҗаты кануннарын, татар сәнгатенең тотрыклы аһәңнәрен тирән сеңдергән бу җәүһәрләрдә төсләр муллыгы, матурлыкны сизгер тоя белү, үйтеләкләр һәм хис-тойгыларны төс-бизәкләр аша әйтеп бирергә омтылу күзгә ташлана.

Күкрәкчәнең гомуми өлгесе бераз сузынкы ярымтүгәрәккә охшаш. Аның төп композициясе үзара чиратлашып барган, укалы тасма яки башка бер бизәк белән каймаланган, буй-буй сузылып төшкән тукымалар рәтеннән тора. Үзәктән як-якка таба ялтыравыклы, укалы тасмалар сузыла һәм алар бәрхет, ефәк кебек йомшак һәм затлы тукымалар өстенә ята. Төрле төстәге яфракчыклар белән уратылган нәфис чәчәк бизәкләре әнә шулай туа. Төп өлгене әле тагын тегеп-чигеп урнаштырылган асылташлар бизи. Әлеге кыйммәтле, затлы ташларның нурланып җемелдәве тукымалардагы һәм каймалардагы төсләргә кушыла, күз явын алырдай балкыш тудырып, ай-кояш нурларын хәтерләтә. Борынгы чорларда, мәсәлән, кешеләр үзләренең изге утка, айга-кояшка табынуларын әнә шундый бизәкләр аша белдергәннәр, аларны тылсым көченә ия талисман итеп йөрткәннәр. Мондый талисман хатын-кызларны, аналарны төрле бәла-казалардан, авырулардан, яман көчләрдән һәм күз тиюише нәрсәләрдән сакларга тиеш булган.

Болардан тыш, халыкта әле әчке күкрәкчәләр дә булган. Алары исә, бизәкләр муллыгына омтылудан бигрәк, хатын-кызның интим кичерешләрен, аның хис-тойгыларын, сафлык, тугрылык сыйфатларын чагылдыруга йөз тоткан. Күлмәк әченнән генә киелсә дә, әчке күкрәкчә дә үзенчәлекле, аерым формага ия: андагы бизәкләр табигатьнең яңару символын, гомер агачының ныклы сулышын тасвирлый. Әчке күкрәкчәләрдәге бизәкләр үзгәрешкә чагыштырмача әкренрәк бирелгән, һәм, шуңа күрә, аларда халык көнкүрешендәге борынгырак күренешләр, борынгырак аһәңнәр сакланган.

Тагын шуны да әйтү кирәк: төрки халыкларында һәм фин-угыр халыкларында күкрәкчәләрнең төрле вариантлары бар. Һәм, әлбәттә, аларны һәр халык бер үк максатларда кулланган. Аерма — бары тик аларның форма үзенчәлегендә һәм нинди материаллар кулланып эшләнүендә.

Татар күкрәкчәләре форма ягыннан да, аларны файдалану ягыннан да (кыйммәтле ташлар тагып йөрү) бик үзенчәлекле. Һәм бу хәл әлеге җәүһәрләрнең мөстәкыйльлеген дәлилли, кайбер галимнәрнең аларга фин-угыр сәнгате төсмерләре тагуын кире кага.

Борын-борынгыдан ук үз төсен, үз йөзен җуймый килгән бу җәүһәрләр халык иҗатының, халык сәнгатенең тирән тамырлары турында сөйли.

Людмила **КОРОБЦОВА**,
Татарстан сынлы сәнгать музееның
фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда газета һәм журналлар нәшрияты.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

*Хөрмәтле укучыларыбыз!*

Журналның киләсе саннарында да сезне әдипләребезнең яңа әсәрләре белән күңелле очрашулар көтә. Аларның кайберләре белән таныштырабыз:

Хисам Камалов. **«Үлгәннән соң яздым»**. Роман.

Җәмит Рәхимов. **«Кыядагы чәчәкләр»**. Роман.

Рафаэль Мостафин. **«Кабан күленең серләре»**. Документаль повесть.

М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, М. Галиев. **«Илгә — игелек»**. Документаль повесть.

Рашат Низамиев. **«Фәрит Яруллин»**. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән.

Вахит Имамов. **«Күке»**. Повесть.

Шамил Шәйдуллин. **«Шөпшә оясында»**. Детектив әсәр.

Нәбирә Гыйматдинова. **«Ханым-солтаным»**. Повесть.

К. Булатованың әдәбиятыбыз аксакалы Хәсән Туфан турында истәлекләре.

**«Мәҗмугы-л-хикәят»**. Урта гасыр татар прозасы үрнәкләре.

*Борынгы әдәбият һәм тарихи истәлекләрне өйрәнергә теләүче күпсанлы укучыларыбызның теләген искә алып, журналның быелгы тугызынчы саныннан гарәп графикасы нигезендә уку һәм язу күнекмәләре бирелә башлый. Бер ел дәвамында сез татар имласына яраклаштырылган гарәп хәрефләре, аларның язылыш һәм укылыш үрнәкләре белән танышырсыз. Мөстәкыйль уку өчен текстлар да тәкъдим ителәчәк.*

**Исегезгә төшерәбез: журналны агымдагы елның теләсә кайсы аеннан башлап алдырырга мөмкин.**

**Киләсе ел өчен язылу, гадәттәгечә, 1 августтан башланачак.**

**Бер елга язылу бәясе 10 сум 80 тиен; ярты елга — 5 сум 40 тиен.**

**Индексы — 73210.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)